

# КАЗАН УТЛАРЫ

12
ДЕКАБРЬ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**12**

ДЕКАБРЬ

1981


## *Бу санда*


С. ХӘКИМ. Яңа шигырьләр . . . . . 3
В. НУРУЛЛИН. Һәлакәт. Повесть . . . . . 10
С. ГӘРӘЕВА. Урал дәфтәреннән. Шигырьләр . . 89
Л. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Якты күләгәләр. Шигырьләр 92

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Т. ӘЙДИ. Аталар һәм уллар . . . . . 94
М. РАФИКОВ. Язмышлар . . . . . 102

КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Яңа тормыш, яңа әдәбият хакына . . . . . 111

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Г. МӨХӘММӘДОВА. Фидакарьлек . . . . . 119

СИБГАТ ХӘКИМГӘ 70 ЯШЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Башка берни дә кирәкми . 127
С. ПОВАРИСОВ. Зөбәрҗәт, алтыннарың!.. . . 134

ЗӘКИ НУРИГА 60 ЯШЬ

Г. АХУНОВ. Көрәштә чыныккан поэзия . . . 138
П. МИНЧЕНКО, И. ЖАРКЕВИЧ. Оршадан хат . . 144
Г. РАМАЗАНОВ. Урманчы. Шигырь . . . . . 145
С. ДАНИЛОВ. Шагыйрь дуска. Шигырь . . . . 146
Котлау сүзе . . . . . 147
З. НУРИ. СССР Язучыларының V съездына әзерләнгән чыгыш . . . . . 148
Эш белән, ялкынлы сүз белән . . . . . 151
Һаман эзләп иң матур, иң яңаны . . . . . 156

ЮНЫС ӘМИНЕВКА 60 ЯШЬ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Кешелекле иҗат . . . . . 159



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**С. МАННАПОВ. Балачакка ешрак кайтыгыз** . . 163

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ш. ГАЛИЕВ. Аю качкан цирктан.** Шигырьләр . 166

ТӨРЛЕСЕННӘН

**М. АБДУЛЛИН. Халыкка каршы** . . . . . . . 169

УКУЧЫ СҮЗЕ

**Х. ЗӘБИРОВ. «Тукай» — шагыйрьнең фамилиясеме, псевдонимымы!** . . . . . . 176

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ. Чәнечкеләр, кечкенә мәсәләләр, нәни шаярулар** . . . . . . . . . . . . . 178

**1981 елда журналда басылган әсәрләр** . . 182
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . 189

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ (*баш редактор урынбасары*), РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА (*җаваплы секретарь*), СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 4/IX-1981 ел. Басарга кул куелды 25/IX-1981 ел. ПФ 09060. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,2). Тираж 102.944 экз. Заказ Д-303. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

Сибгат Хәким

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## 5924

Ульянов килеп җитте, дип,
Шушы төштә сөргенгә,
Ул аяк басты, дип, шунда,
Шунда — ерак Себердә,
Багана тора кыр-үрдә,
Баганада цифрлар:
Биш мең тугыз йөз егерме
Дүрт чакрым юл... киң кырлар...
Петербургтан — Себергә.
Баганада шул ара.
Моңа күп еллар узса да
Күңел һаман шомлана.
Яланда, үрдә багана,
Киң Себер тайгасыннан,
Иң ныгын эзләп арадан,
Иң ныгын сайлап шуннан,
Заман үз үренә каккан.
Каршылап зур чорны ул,
Эңгергә кереп баручы
Нindидер юлчыны ул,
Бер мосафирны уйлата.
Ай яктысы Себердә,
Йөрдем багана тирәли
Кичке сөер эңгердә.
Бу иге-чиге юк Себер,
Серле Җир синең өчен,
Йолдызлар яралган монда
Фәкать шул Себер өчен.
Әйләнде багана һәм үр,
Әйләнде бөтен галәм,
Юлыма китә алмыйча
Әйләндем мин дә һаман.
Тойдым аягым астында
Вак ташлар кыштырдавын,
Шушында җирнең ноктасы,
Мәңгелек шушында ул.

Тойдым бу мәңгелек җирне
Бер үзем калгач бары,
Эзләдем җирне берьюлы
Иңләгән карашларны.
Билгесез миңа бу Себер,
Миңа, җырчы-шагыйрьгә,
Мин киттем кереп, ияреп
Шул бөек мосафирга.

*1980*

## Кокушкинодагы фонарьлар

Кокушкино белән Шушенский...
Аралары ерак, кар баскан...
Сөйләшәләр төнге сәгатьләрдә,
Язмышлары белән кардәшләр.
Кокушкино гел борчылып яши
Саяннарда күрсә үрдән ут,
Сорый кебек: ничек барып җитте?
Хәле ничек? Ничек Ульянов?
Сөйләшәләр төнге сәгатьләрдә,
Серле итеп, утлар ымлаша...
Шушенскийдагы тәрәзәдә
Яшел лампа уты булмаса,
Кокушкино кинәт уйга кала,
Җилләр сөйли төрле хәбәрләр...
Хафалана, шомланалар төсле
Уйга талган төнге фонарьлар.
Себер, тайга, Саяннарны үтеп,
Исә җилләр гел Шушь буеннан:
Ике ара — ун ел... эшли көн-төн,
Шушенскийда эш муеннан...
Яшь Ульянов юлда, тагын юлда...
Кагылып узгангамы заманнар,
Ап-ак карга саргылт бер төс сирпи
Кокушкинодагы фонарьлар.

*1981*

●

Урамдамы, метродамы шунда,
Үз каршыма килгән төркемнән
Ватан сугышы кешеләрен эзлим,
Үз җаена берсе теркелдәр,
Бераз гына ул сөрлегеп атлар,
Уйларында атлар, онытылыр.
Бер як иңен я пулемет баскан,
Я миномет, яки ПТР[1].
Чыраенда землянкалар төсе,
Өсте-башы — барысы корымлы;
Яткан тигез фронт сабырлыгы,
Авыр еллар басынкылыгы.

---

[1] ПТР — противотанковое ружье.

Ял итәргә теләп, килер атлап,
Ничек атласа да җир өчен
Барыбер түгелмени? Үз заманы
Билгеләгән хәтта йөрешен.
Чыраенда алгы сызык төсе,
Бүген аңа, беләм, ял шушы;
ПТРын куеп ул хәл җыяр
Җиңеләйсә иле язмышы.

*20 февраль, 1981*

## Фронтовиклар фронтовикны күмдек

Җирләделәр туган абыемны,
Утырдылар җиргә чүгәләп.
Халыкта бит гайбәт китә, диләр,
Китми, диләр, бары бер гадәт.
Берәү туа җиргә, күзен ача,
Берәү аяк суза, күз йома.
Сәдака ул йолаларның берсе,
Борынгыдан калган бер йола.
Кесәдәге безнең тиеннәрне
Һәр көн саен еллар саната.
Ышанудан түгел, гадәт саклап,
Әдәп саклап бирдем сәдака.
Көрәкләре алда, кешеләр тын,
Язгы зират та тын, вакыт тын.
Утырдылар рәттән, утырган күк
Кырыена тезелеп окопның.
Сәдакага бирәр әйбер алыр
Абыемның алар төсе итеп...
Фронтовиклар фронтовикны күмдек,
Кешеләрчә күмдек, кеше итеп.
Утырдылар тезелеп бар гәүдәнең
Авырлыгын салып кыргычка.
Фронтта да шулар белән идем,
Шулар белән тыныч тормышта.

*1981*

## Ленинград, сугыш, блокада

Ленинград, сугыш, блокада...
Илдән илгә куды әсирлек...
Кайтты, истә әйткән сүзләре:
Ышанмагач, нигә яшим дип,
Медаль генә үзе югыйсә,
Кояшыдай яна өйләнең.
Бүтәннәрдә күреп уфтанды
Ватан сугышының медален.
Ышанучы кеше син генә,
Коткарсаң син коткараласың...—

Елый иде бәйрәм көннәрдә
Кочып үзенең ул карт анасын.
Елый иде тотып йөрәген,
Бар икән дип нинди яралар?
Тик анасы салыр шикелле
Йомшак кулы белән ямаулар.
Кеше бер чак дулый-дулый да,
Укыгачтын аңа җеназа,
Кинәт тынып, көтеп ята күк
Үзенә һаман хөкем, бер җәза.
Ята кеше көтеп җиренең
Гаделлекне яклап раславын.
Килде медаль, кабре өстенә
Койды усак соңлап яфрагын.

*1981*

## Елама, Әминә...

Тырыш ил, югыйсә, туфрагы
Фәннәрне, гөлләрне үстерә.
Ник карап елыйсың, Әминә,
Көнбатыш Германия өстенә.
Розалар шул Плетцензееда...
Февральнең ахыры, кар яуган.
Узганны каргама, Әминә,
Розалар шиңә күк каргаудан.
Розалар шул Плетцензееда
Керделәр кинәт кан төсенә.
Гөнаһлы булырмын кебек мин
Бассам да җирнең кай төшенә.
Елама, Әминә, елама,
Ник әле боегып баш идең,
Ишетәмсең, яңгырый тавышлар:
Юк, кире кайталмас фашизм.
Сабыр ит, батыр бул, Әминә,
Батырдан йөз үлем чигенә.
Сабыр ит, туйганчы еларсың
Җиткәчтен үз илең чигенә.
Еларсың туйганчы бер үксеп,
Юк, әйтмә: мине, дип, кем аңлар?
Синең үз илеңдә җир йомшак,
Су йомшак, йомшак таш диварлар.
Без инде яшь түгел, бергәләп
Яңадан килүләр икеле.
Ашкындык бу ерак сәфәргә
Алдан ук сизенгән шикелле.
Елама, Әминә, саубуллаш,
Соңгы кат Мусаның кулын кыс.
Мусаның гомере күк, мин беләм,
Синең дә гомереӊ үлемсез.

*1981*

## Берлин, Муса...

Берлин. Муса. Туган көне. Бәйрәм.
Рәсеменә аның мин карап,
Сүз сөйләүдән кинәт туктап калдым,
Мактадылар, ә ул битараф.
Сугыш алдындагы минем туйда
Муса, Кутуй, Хәсән Туфаннар
Экспромт сөйләп котырдылар
Котырганда тышта бураннар.
Нинди ул шат, нинди көләч иде!..
Суыныр икән кеше суынса.
Шул Мусамы? Ник елмаймый бер дә,
Ник дәшми ул миңа — шул булса?
Ул оныткан күптән шатлыкларын
Төш шикелле сабый дөньяның;
Барын күргән, юатудан узган
Бәйрәмнәре фани дөньяның.
Берлин. Муса. Туган көне. Бәйрәм.
Ул битараф, йөздә сарылык.
Күз кабагы искә төшереп тора:
Әллә кайда бар күк сабыйлык.
Ул битараф, салкын. Сагыш баскан
Шешенкерәк шул күз кабагы
Хәтерләтте читтә елап арган,
Үксеп торган ятим баланы.
Артта иксез-чиксез авырлыклар.
Бу җир йөзе — тоташ фронтлар.
Тормыштагы очрашулар алар
Бер минутлык экспромтлар.

*1981*

## Берлин. Төн. Берлин тын...

Шомлы соң Берлинның төннәре.
Ак карда Мусаның шәүләсе.
Я Алиш... Уйланып барганда
Чыгалар каршыма шаулашып.
Берлин. Төн. Берлин тын... Бусы кем?
Чыгалар шәүләләр чатлардан.
Кушыла төркемгә Курмашлар,
Кушыла Симайлар, Саттарлар.
Нәкъ Блоктагыча, миннән тыш
Барысы төп-төгәл унике.
Кычкырам белмәгән шикелле,
Егетләр, сез кайсы илнеке?
Башында яшь Муса... Унике...
Ниндидер охшашлык, кырыс кыш.
Юк, түгел нәкъ Блоктагыча;
Башында бармый бит Христос.
Урам тын. Урамнар кешесез.
Урамнар тагын да шомлырак.
Атлыйлар... Башында яшь Муса,
Туган ил, син ерак, син ерак.

*1981*

## Иске портфель

Җәлеп итмәк булып мин үземә
Генрих Гейне, Гете, Шиллерны,
Шул романтик бөек шагыйрьләргә
Сөйләп йөргән чакта шигыремне,
Муса үзе килеп чыкты чаттан...
Яз сизелә, исә март җиле.
Бер кулында портфель: Мәскәү — Казан
Арасында тузган портфеле.
Шагыйрь данын уртаклашкан портфель,
Вагоннарда аунап кыршылган.
Театр һәм концертларда булган
Иске портфель, көзге кыр сыман.
Таныш аңа «Алтынчәч»ләр даны,
Ишекләрен ачкан сарайлар...
Иске портфель игеннәрен җыйган
Көзге ялан кебек саргайган.
Ул ашыкты төнге сменага,
Берлиндагы «Тормызчылар»[1]га
Демократик яңа Германиянең
Киләчәген мактап җырларга.
Аерылыштык чатта... нигә әле
Кирәк булды сиңа портфеле?
Мин Мусаның үзе белән бергә
Шул портфелен сагынам, карт тиле.

*1981*

●

Плетцензее. Кешелекнең анда
Кулы белән салган тасмалар.
Тасмаларда: татар шагыйренә,
Коммунистка дигән язмалар.
Полиция килә салмак атлап,
Тасманың ул сыпырып ак карын,
Карый озак, гаҗәпләнү катыш:
Муса Җәлил, шагыйрь, тартарен[2]...
Тасмага ул үгез кебек карый,
Сөзим дигән төсле кай төшен.
«Коммунист»ка күзе төшә аның.
Планшеттан ала кайчысын.
Ул шул сүзне кисә шытырдатып,
Шул өлешен кисә тасманың,
Әйтерсең лә Совет шагыйренең
Икенче кат агыза яшь канын.
Бу баштарак шулай булган, диләр,
Полиция миһербанлыга
Әйләнгәнме, үзгәргәнме дөнья,
Бүтән, башка нидер бар монда,

---

[1] Тормызчылар — Муса Җәлил исемендәге бригада.
[2] Тартарен — татар.

Хәзер, имеш, тими башлаганнар...
Шагыйрь исеме анда ташта бар.
Коммунистик рухын саклап калган
Җәлил җаны кебек тасмалар
Ята карда... Килә полиция,
Чыгарырга кыймый кайчысын:
Коммунизм, татар, Совет, Җәлил...
Бу сүзләрнең кисим кайсысын?

*19 февраль, 1981*

## Туфан

*Каплан-кырда сөякләр ята...*
Хәсән Туфан

Ярты гасыр аша тавышын ишетәм,
Ярты гасыр аша кул сузам.
Каракалпакстан, чүлләреңдә
Очрар төсле иде яшь Туфан.
Утызынчы еллар башында ук
Килеп сиңа ерак Казаннан,
Ул сәяхәт кылган... Хәзер сагына...
Мамык кебек чәче агарган.
Киләчәктә дөге, мамык үсәр,
Бакча үсәр «Каплан-кыр»ларга
Тарихыңнан карап, яргаланып,
Комнан, тоздан каткан кырларга
Көрәк тотып ул каналлар ерган,
Чүлләреңнең гизгән һәр ягын...
Хәзер сагына... ята иркен сулап,
Үзе кебек Аму-дарьяның.
Сугарган да миллион күңелләрне,
Иксез-чиксез сахра-чүлләрне,
Ул ял итә Аму-дарья кебек,
Шул көннәрне сагына йөрәге.
Каракалпакстан, чүлләреңнән
Аерып булмаган күк сусауны,
Халыкларның олы язмышыннан
Аерып алып булмый Туфанны.

*1980*

## Вакыйф Нуруллин

# ҺӘЛАКӘТ

ПОВЕСТЬ

**Автордан**

*Кайбер укучылар, гадәттә, үзләре яратып укыган әсәрләрдә сурәтләнгән персонажларның тормыштагы прототипларын эзли башлыйлар. Әгәр әсәр беренче заттан, ягъни автор исеменнән язылган булса, анда сурәтләнгән хәлләрне автор үзе кичергән, ягъни үз тормышын язган, дип уйлыйлар. Мәсәлән, аның «Шинельсез солдатлар» повестен автобиографик әсәр дип кабул итеп, Равилне әле һаман да авторның үзенә тиңләп йөрүчеләр бар. «Аккан су юлын табар» исемле повесть чыккач, әсәрнең төп геройларыннан берсе булган «Булат Вәлиев сез үзегез булырга тиеш, сез колхоз председателе булып та эшләгәнсез...», дип язылган хатлар да аңа байтак килде. Хәтта гражданнар сугышы чорындагы, автор туганчы егерме еллар элек булып үткән вакыйгалар турындагы тарихи-документаль «Яшьнәп үткән яшьлек» исемле повесте дөньяга чыккач та «...мин дә ул елларда нәкъ шул вакыйгалар булган җирләрдә Совет властен саклап калу өчен көрәшеп йөрдем, сез бәлки мине хәтерли дә торгансыздыр әле, минем исемем фәлән» дип язылган хатлар да булгалады.*

*Язучы өчен бу, бер яктан, әлбәттә, куанычлы хәл. Әсәрен укучылар шулай якын итеп, чын итеп кабул иткән, димәк, ул аларның күңел ачкычын дөрес тапкан дигән сүз.*

*Ләкин әсәрдә сурәтләнгән хәлләрнең барысын да чын итеп, тормышта нәкъ шулай булган дип кабул итүнең кайчакта автор өчен уңайсыз яклары була һәм бу әсәр белән дә шундый нәрсә килеп чыгу ихтималы бар. Мәсьәлә шунда, биредә сурәтләнгән персонажларның берсе — артистка. Ә артистлар һәм артисткалар хакында сүз барганда укучыларның беркайчан да битараф булмавы барыбызга да билгеле. Шуңа күрә алдан ук искәртеп кую кирәк: башка әсәрләре кебек үк, бу повесть таниндидер конкрет шәхесләрне күздә тотып язылмаган. Биредәге барлык персонажлар да автор хыялы белән (әлбәттә, аның тормыштагы күзәтүләреннән чыгып) тудырылган әдәби образлар. Әсәрдә артистка образы яши икән, ул монда кайсыдыр бер аерым артистканы күздә тотып, аны фаш итү нияте белән түгел, бәлки авторга әсәрен язганда куйган максатына ирешү өчен шулай кулайрак булганга гына кертелгән. Бу очракта авторны Гасимәнең профессиональ яктан артистлыгы түгел, ә тормыштагы «артистлыгы» кызыксындырды һәм ул укучылар аны нәкъ әнә шулай кабул итәрләр дип ышана.*

## I

Фәләх килеп җиткәндә ул инде урамга чыккан һәм үзе фатирга кергән йорт каршындагы агач бакча буенда нервланып арлы-бирле йөренеп тора иде. Фәләхне күреп алу белән йөзе кинәт балкып китте һәм ул, очып кына дип әйтерлек килеп, әле машинасын сүндерергә дә өлгермәгән Фәләх янына кереп утырды да, ирен очы белән генә аны үбеп алды.

— Молодец! — диде ул, ниндидер сер әйткәндәй ярым пышылдап.— Молодец, ялгызың гына килгәнсең! Мин хәзер, әйберләремне генә алам да — киттек. Һәм бүген көн тулысынча безнеке!

Шулай диде дә, фатирга кереп, минут эчендә чемоданын алып чыкты.

— Кай якка барабыз? — диде Фәләх инде тәмам утырышкач. Гасимә авылдан дүрт-биш кенә чакрымдагы каракучкыл-күгелҗем урманны күрсәтте:

— Әнә шул тарафка!

— Карале, бала, мин бөтенләй әзерлексез килдем бит бу юлы. Бәлки, кибеткә кереп азык-төлек мәсьәләсен рәтләргәдер, ә?

— Ә мин синең шулай киләсеңне белеп тордым! — диде Гасимә, карусыз гына төрттереп.— Аптырама, ни кирәген үзем алдым. Әйдә, беркая тукталмыйча, туп-туры урманга!

— Ну зирәк тә инде үзең! Ир-ат акыллары бар синдә, ялгыш кына кыз булып тугансың ахрысы.

— Булыр-булмас ир-атлар белән эш иткәч, ни кыласың? Мәҗбүри рәвештә акыллы булырга туры килә.— диде Гасимә. Машина тәрәзәсен башта төшергән иде, юлда тузан кերә башлагач, яңадан күтәреп куйды.— Кстати, синең урында бүтән берәр джентельмен булса, иң элек гафу үтенер иде!

— Ни өчен? — диде Фәләх.— Хатыным, баламны калдырып янына килгән өченме?

— Юк! Кичтән килмичә, мине төн буе борчылып, көтеп торырга мәҗбүр иткәнең өчен. Менә килер, менә килер дип, керфек тә какмадым бит!

— Минем борчылу белән чагыштырганда синеке гел пүчтәк кенә икән алайса. Кичтән түгел, иртән дә мең бәла белән генә ычкындым әле Роза апаең яныннан. Без бит бүген аның белән туйга барырга тиеш идек!

Әлбәттә, берниндн туй да юк, моны ул Гасимә алдында үз дәрәҗәсен күтәрү өчен генә уйлап чыгарган иде. Ләкин Гасимә аңа гына эреп төшмәде:

— Ә син барыбер, күңел өчен генә булса да, гафу үтенергә тиеш идең! — дип Фәләхтән гафу үтендермичә туктамады. Тик шуннан соң гына: «Баштук шулай итәләр аны. Без хатын-кызларга күп кирәкмени— бер җылы сүз дә җитә!» — дип күзгә күренеп ачылып китте. Аннары кинәт кенә:

— Фәләх, Роза белән сез туйлап өйләнештегезме? — дип сорады.

Кая анда туй! Фәләх ничек итеп өйләнгәнен сөйләп күрсәтсә, чәчләре үрә торыр иде Гасимәнең. Ләкин бу Фәләх файдасына булмас: тапкан икәнсең кызыгыр кеше, шулайлар итеп йөрмәсәң, кыз бетәр иде мени сиңа шул Розадан башка, дип Гасимә аннан көләр генә шикелле тоелды. Шуңа ул:

— Һәй, ничек кенә туйладык әле! Башкаларныкы кебек ике көнгә генә түгел, атна буена сузылды безнең туй! — дип җавап бирде.

— Алайса син бәхетле кеше икән! — диде Гасимә һәм тирән итеп көрсенеп куйды: — Ә менә миңа ул бәхет тәтемәде. Кечкенә чактан ук туйда килен булып утырырга хыялланып йөргән идем. Бергә җыйналган туган-тумачалар, дус-ишләр арасында, табын түрендә ап-ак күлмәк киеп, ап-ак фата бөркәнеп, йөзек кашы шикелле балкып үз туеңда утырудан да зур бәхет юктыр шикелле иде миңа. Ләкин андый бәхет эләкмәде шул. Чөнки минем кияүгә чыгу кешеләрчә булмады. Хәер, сөйләгән идем бит инде Май бәйрәме көнне үзегездә кунакта утырганда.

— Ярар, бала, аптырама! Туйда мыни хикмәт. Әнә, икешәр-өчәр меңгә төшереп туй ясап өйләнешкән кешеләрнең, ике-өч ай да бергә яшәп алмыйча, аерылышканнары азмыни? Ә сез менә туйлап өйләнешмәсәгез дә инде алтынчы елыгызны әйбәт кенә яшәп ятасыз!

— Фи, шуны да яшәүгә санасаң...

— Ә тагын ни кирәк? Синең Гыйльфаның белән бик рәхәтләнеп яшәргә була, минемчә. Аның урынында бүтән берәү булса, бар, йөреп кара идең менә шушылай синең шикелле иркенләп!

— Син каян беләсең, бәлки миңа нәкъ менә нык куллы, йодрыгын-

да кысып тота торган, ләкин чын күңелennән ярата белгән, минем өчен барын да эшләргә әзер, тырыш, булдыклы һәм машиналы ир кирәктер!

— Ә Гыйльфаның кемнән ким синең? Аннан да әйбәтрәкне кайдан таба аласың?

— Слушай, Фәләх, житте сиңа! — диде Гасимә чын-чынлап үпкәли башлап.— Берни дә аңламаган булып ниемә кыланып киләсең, ә? Аның нинди ир икәнен теге көнне шашлык кыздырырга баргач үзең күреп кайттың бит инде! Я, әйт әле, син үз хатыныңны бөтенләй белмәгән-күрмәгән кеше янында калдырып, бүтән хатын-кыз белән шулай гөмбә җыярга урманга кереп китеп, сәгатьләр буе югалып йөрер идеңме? Әнә шулай, аның шикелле, аңыңны җуйганчы эчеп, үлемәле йоклап ятар идеңме?

— Ләкин бит син моңа үзең гаепле! Чамадан чыга торган андый гадәтен белгәч, юл куймаска, катырак торырга кирәк бит!

— Һәй, җаным, ир-атны хатын тотып торырга калгач — булмый инде ул! Бер генә түгел, йөз әйтеп караган инде аңа — яхшылык белән дә, усалланып та. Ә аңа, руслар әйтмешли, как с гуся вода... Баяныннан һәм аракыдан башка берни кирәк түгел аңа бу дөньяда.

Алар инде урман буена килеп җиткәннәр иде. Фәләх машинаның тизлеген кимәтә төшеп, эчкәре керергә уңайлырак җирне карап бара иде. Шуны сизеп, Гасимә аңа:

— Юк әле, юк, бу тирәдән булмый, әнә теге баштан урап керәсе,— диде.

— Әллә инде берәрсе белән бу урманда да булып кайттыңмы? — диде Фәләх, уенын-чынын бергә кушып. Нигәдер бүген теленә гел төрткеле сүзләр генә килеп тора, нигәдер Гасимәне ачуландырасы килә иде аның.

Ә Гасимә, киресенчә, шат, Фәләх ни әйтсә дә гел уенга гына алып бара иде. Хәтта аның әлеге ачыктан-ачык төрттереп куюыннан соң да кабынып китмәде:

— Булуын, әйе, булып кайттым,— диде ул иплән кенә.— Ләкин син уйлаганча, «берәрсе» белән түгел, ә бөтен бригадабыз белән. Кичә бу авылга килгәндә шул урман аша үткән идек. Барып җиткәч күрерсең әле, искиткеч матур бер алан бар бирeдә. Кичә безне китерә килүче шоферга, биш кенә минутка туктатып тор әле машинаңны шушы аланда, дип ялынсак та — тыңламады. Биш минут түгел, биш секунд та торалмыйм, уттай эш өсте икәнен беләсез, дип выжылдап кына узып китте. Ә минем шул аланда буласым килгән иде. Шуңа күрә кичә сиңа шалтыраттым да инде...

Гасимәнең ул аланы урман авызыннан ерак та түгел, юл буендагы бер иңкү урында икән. Чыннан да матур иде ул алан. Печәнен инде байтактан чабып алганнар булса кирәк, куе булып курпы үсеп чыккан, шунлыктан ул яшел хәтфә келәмгә охшап тора. Һәм аңа ятып, бала чактагы шикелле, туйганчы бер тәгәрисе-уйныйсы килә иде. Август ахыры булуга карамастан, көне дә гаҗәеп җылы һәм кояшлы. Алан буендагы каен, юкә, өрәңге, карама һәм усаклар, төрле-төрле төстәге күлмәк киеп, кичке уенга җыйналган авыл кызлары сыман күренәләр иде.

Шул хозурлыкка күңеле нечкәреп китеп, сабый чактагыча, майка белән трусиктан гына калып, бер җилкенеп алырга дип Фәләх чишенә башлаган иде, Гасимә аны артыннан килеп кочып алды да:

— Ашыкма, егетем, чишенергә. Әйдә, башта аланны бер урап килик әле! — дип кулыннан тотып үзе белән ияртеп китте.

Көн эссе булса да, һавасы саф, сулышка иркен, рәхәт. Дөнья мәшәкатьләрен онытып, чыннан да, менә шушылай, шундый иркенлек һәм сафлыкта бераз буласы килә иде...

— Күрдеңме инде? Аңладыңмы сине ни өчен Казаннан ук чакырып китергәнемне? — диде Гасимә, аланның аргы башына барып чыккач.

— Рәхмәт сиңа, бала! Мең рәхмәт, башыңа андый фикер килгәне өчен! — диде Фәләх һәм, хисләнеп китеп, үбеп тә алмакчы иде, ләкин Гасимә бармагын ирен турына куеп:

— Тссс, ярамый, иптәш Мөхәммәтов, әнә безне күреп торалар анда! — дип читкә тайпылды.

Чыннан да, чикләвектән кайтып килүче ике карчык алан аша юлга чыгып баралар иде.

— Син шушында торып тор, мин хәзер машинаны алып киләм дә әнә теге чикләвек куагы буенча палатка корып куябыз,— дип Фәләх үзенең «Жигули»ына таба бара башлаган иде, юк, монда тукталмыйбыз, моннан тынычрак, шәбрәк урын да булырга тиеш әле бу урманда, дип Гасимә дә иярде. Аңа каршы килеп булмый, аның тапкырлыгына бары тик сокланырга гына мөмкин иде.

Алар заманында атлылар йөргән, ләкин хәзер үлән басып бетергән ташландык тар гына юлдан урман эченә кереп киттеләр. Ике-өч чакырымнар баргач, тагын да зуррак һәм матуррак аланга килеп чыктылар һәм, икесе дә берьюлы аһ итеп, туктап калдылар: аланның теге як читендә, дөньяларын онытып, ике пошн үгезе сөзешеп тора, ә бер ана поши,' аларга гел дә игътибар итмичә, алан буендагы яшь усак яфракларын ашый иде. Сөзешүче пошиларның берсе инде карт иде булса кирәк: гәүдәгә зур, мөгезләре юан, әллә ничә тармаклы. Сакалы да озын һәм чалара башлаган. Ә икенчесе әле яшь күренә: мөгезе дә тегенекенә караганда шактый нечкә һәм кыска, гәүдәгә дә кайтышрак. Ләкин аның бер өстенлеге бар: ул җитезрәк, гайрәтлерәк һәм, карт поши никадәр генә көчле булса да, ул аңа бирешми, егетләрчә каршы тора иде. Ләкин мондый сөзешләрне инде күп күргән, тәҗрибәле карт поши белән тартышу аңа коточкыч авыр һәм тагын берничә минут шушылай дәвам итә калса, аның җиңеләчәге күренеп тора иде. «Ярар, юкка ватылып азапланма. Карт пошига юл куй да киләсе елга күбрәк көч җыйна. Һәм быел җиңелгәнеңә үкенмә. Карт пошиның, ихтимал, быел соңгы тапкыр җиңүедер. Ә синең әле — барысы да алда, киләчәктә», дип уйлады Фәләх тегеләрне карап торган арада һәм яшь көрәшчене ана поши алдында җиңелеп хур булудан коткару өчен, ачы итеп сызгырып җибәрде.

Күрәсең, үзе дә инде көрәшмәскә тели, тик ничек итеп туктарга икәнен генә белми, ә качып китәргә хурлана иде бугай, Фәләхнең сызгыруы булды — яшь поши шундук сөзешүдән туктап, артына да борылып карамыйча, урман эченә кереп китте...

Ләкин Фәләхнең бу эше Гасимәгә ошамады:

— Нишләдең син, юләр! — диде ул, чын-чынлап ачуланып. — Ник куркыттың инде шуларны? Кайсы җиңгәнен карап тору нинди кызык иде бит!

— Әнә теге карты, аланда калганы җиңә башлаган иде бит!

— Һе, башлаган иде, имеш. Һәр башлаган эш тә беткән эш дигән сүз түгел әле ул. Бәлки яшьрәге болай гына, көчен саклар өчен генә бирешә башлаган булгандыр? И-их, әйтер идем инде үзеңне дә. Гомергә бер очрый торган шундый кызыкны харап иттең бит...

Ул арада җиңүче булып калган карт поши гайрәтләнеп ана поши янына барып басkан, ә тегесе, ашавыннан туктап аңа сыенган да, батырның муеныи, колак артларын иплән кенә ялый иде. Күрәсең, ул аны: «Бик арыдыңмы, акыллым? Бик кыен булмадымы? Ну, егет тә инде үзең, тәки җиңеп чыктың бит шул яшь хәрәсәнне!» — дип мактый иде бугай.

— Әллә хайваннар да үзләренчә сөйләшә алалар микән? — диде Фәләх бу хәлгә исе китеп.

— Сөйләшә алалардырмы-юктырмы, анысын белмим. Ә минә сөешә алуларына тамчы да шигем юк: әнә ничек итеп сөеп тора бит ана пошн ата пошины. Син дә минем пошыем бит, әйеме?

Ул йомылып кына Фәләхнең иңенә сарылды да, кайнар куллары белән кочып алып, суырып үбәргә тотынды...

Аннары, нәрсәдер исенә төшеп, кинәт кенә читкә тайпылды да:

— Ой, онытып торам икән бит. Мин хәзер сиңа бер сюрприз эшлим. Ләкин, мин «булды» дип әйтмичә, бу якка карамый тор, ямә! — дип, чемоданын алып, машинадан чыгып китте.

— Ярый. Ә мин палатка корам,— дип Фәләх машина багажнигын ачты. Тегесе карамый тор дисә дә, Фәләх күз кырыен гына төшереп Гасимәнең табын әзерләп йөрүен чамалады. Туктале, ул әзерләп бетергәнче мин палатканы корып куйыйм, дип ашыкты, ләкин өлгерә алмады: ул әле палатканың казыкларын да беркетеп бетермәгән иде, Гасимә, аның каршына килде дә, яшь принцесса шикелле бик җиңел һәм итагатьле реверанс ясап:

— Хөрмәтле галиҗанәб Фәләх хәзрәтләре, рәхим итегез, табын әзер! — диде.

Гасимә менә дигән табын әзерләгән: алан буендагы ышык урында, агачы инде күптән киселгән юан төп өстенә бәләкәй ашъяулык җәеп, аңа биш йолдызлы коньяк, бер банка кара уылдык, бер өем туралган ит һәм бер кап «Татарстан» конфеты куйган. Туралган икмәге белән икс рюмкасы да шунда.

— Мин синең уңган хатын икәнеңне беләм, ләкин болай ук хәстәрле була алырсың дип һич тә көтмәгән идем! — диде Фәләх, чын-чынлап гаҗәпкә калып.— Син бит Казанның азык-төлек базасында эшләмисең, каян юнәттең бу деликатесларны авыл җирендә?! Хәзер бит мондыйны шәһәрдә табу да алай бик җиңел түгел!

— Һи, җаным, син дөнья хәлләрен бөтенләй белмисең, бөтен юньле әйбер шәһәрдә генә була дип уйлыйсыңмыни. Заманнар үзгәрде бит хәзер: шәһәрдә булмаганны нәкъ авылда табарга була да инде. Сөйләшә белергә кирәк җаен белеп, елмаебрак сөйләшсәң, хәзерге председательләр моның ише гадәти әйберләрне генә түгел, күгәрчен сөте дә табып бирә. Кичәге концерттан соң берсе безнең бригадада менә дигән итеп банкет оештырды. Шунда бераз кызып алгач: «Минем машина монда, капка төбендә генә, сеңелем. Әйдә, кырларны, су буйларын әйләнеп, саф һава сулап кайтыйкмы әллә?!» дип әгъвәләп азапланды.

— Ә син ни дидең соң?

— Нәрсә дисең инде бабай кешегә? Ахмак син, дип турыдан-туры әйтеп булмый бит. Бик рәхәтләнеп әйләнеп кайтыр идек, фәлән-фәләнеч, ләкин мин иптәшләремнән аерылып йөри алмыйм шул: ирем бик көнче, дип ялганлап котылдым.

— Каян килгән сиңа шул кадәр акыл? Гениально килеп чыккан бит бу! — диде Фәләх.— Кил әле, шуның өчен бер пәп итим үзеңне! — дип үбәргә тотынды.

Ә теге пошилар һаман китмәгән, ни кылана икән бу адәм балалары дигән сыман, аптырап, колакларын торгызып, аларга карап торалар иде. Ләкин карт пошига уңайсыз булып китте булса кирәк: ул, ризасызлык белдереп, башын чайкап куйды да, күкрәге белән этәрә-этәрә, ана пошины урман эченә алып кереп китте.

Нарат төбенә әзерләнеп куелган коньяк бик хәтәр ымсындырып торса да, руль тотып Казанга кайтасы булганга, Фәләхкә бүген тамчы да кабарга ярамый иде.

— Бер рюмка тотканнан гына берни дә булмас. Син бит аңа гына бирешә торган егет түгел. Син бит баһадир! — дип Гасимә кыстап караса да, Фәләх якын да килмәде:

— Эчмәгән нәрсә түгел, ярамагач ярамый инде! Телисең икән, үзең азрак эч булмаса. Ә мин бик һәйбәтләп уылдык ашыйм әле! — диде ул ике сөйләшеп торырга урын калдырмаслык итеп.

Шуннан соң Гасимә дә артык ирексезләмәде:

— Булды, акыллым, ышандырдың. Әйе, эчүнең беркемне дә яхшылыкка алып барганы юк әле. Ә шулай да, бу хозурлыкта утырганда мин азрак кабам әле. Син ачуланма инде, бу дөньяда тик бер генә яшибез бит. Менә шушы бүгенге көнне елап үлсәң дә кире кайтарып булмаячак! Сагынып сөйләргә генә калачак ул! — диде дә, озын нәфис бармаклары белән рюмканың билепнән чеметеп кенә тотып, озаклап, сөзеп-сөзеп кенә эчеп куйды.

Фәләх аңа конфет алып каптырды. Инде сәгать унбер тулып килә, ә аларның әле ашаганы юк иде: бер тын бик әйбәтләп ашап алдылар. Аннары Гасимә:

— Булгач — пар булсын инде. Монысын синең исәнлеккә! — дип тагын бер рюмка эчте. Һәм, күп тә үтмәде, күңеле нечкәреп, хисләнеп Фәләхнең күзләренә текәлеп карап торды да:

— Арсланым минем! Нинди чибәр син! Һәм нинди көчле! — дип күкрәгенә сарылды.

...Алар палаткадан чыкканда көн инде кичке якка авышкан иде. Бик хәтәр җилли башлаган һәм кояш баешы ягыннан ярты күкне иңләп каракучкыл-аксыл болытлар күтәрелеп килә. Яңгыр ява башлаганчы чыгып калырга кирәк, югыйсә урманда батып ятуың да бар дип, Фәләх палатканы җыярга тотынса да, Гасимәнең ашыгыр исәбе юк иде.

— Аптырама юкка. Ул болыт килеп җиткәнче асфальтка биш тапкыр чыгып өлгәшәбез әле! Уф, үләм, тамагым кипте, аннары ашыйсы да бик килә. Әйдә бераз утырып алыйк әле! — дип ул Фәләхне тагын табынга чакырды. Андый чакта карышып тору килешмни бит инде, тыңларга мәҗбүр булды Фәләх. Аннары аның үзенең дә бик нык тамагы кипкән, ә Гасимә, уңган хатын, бер генә стакан сыешлы нәни термос белән чәй дә алып килгән булган икән.

— Сиңа барыбер ярамый, мә, син чәй эч, ә миңа монысы да ярап торыр,— дип термосны Фәләхкә бирде, үзенә коньяк салды һәм эчеп тә җибәрде.

Фәләх конфет каптырмакчы булган иде, Гасимә:

— Торып тор әле, чатнауны басмады бу,— дип тагын бер рюмка эчте. Бу юлы хәмер үзенекен итте: аның моңарчы нурланып торган чиста зәңгәр күзләре тоныкланды, хәрәкәтләре салмакланды, хәтта теле дә көрмәлә башлады.

— Карале, йомшый башладың түгелме соң син, бала? — диде Фәләх хафага төшеп һәм: — Яңгырга хәтле кузгалыйк! — дип, табынны җыя башлады.

Ләкин Гасимә, баласына куркыныч янаган ана арслан житезлеге белән сикереп кубып, аның кулыннан тотты:

— Юк, егетем, ашыкма әле алай! Розочкаң янына кайтырга өлгерерсең. Минем янда онытканда бер генә буласың. Әйдә, утырыйк әле бер рәхәтләнеп!

— Җитеп тормас микән инде, акыллым! Болай да башыңа киткән ич синең. Кичен концертта да җырлыйсың бар бит!

Гасимә Фәләхкә төбәлеп, әмма аны күрмичә, берәр минут чамасы нидер уйланып торды. Аннары егылып китмәс өчен Фәләхкә тотынды да:

— Беррен-че-дән, бүген бернинди концертка да бармыйм! — диде.— Икке-нчедән, мин грам да исерек түгел. Башыңа киткән, имеш! Юк әле, егетем, аның белән генә башка китми әле Гасимә апаңның! Кая, бир әле монда шешәне, карап тор әле...

Исерек хатын-кыздан да яман җан иясе бар микән җир йөзендә? Калган коньякны шешәсе ние белән төп башына бәреп ватасы да Гасимәнең үзен бөгәрләп машинага салып кайтып кына китәсе иде Фәләхкә. Бер үпкәләр иде дә Гасимәсе, шуның белән бетәр иде. Ә аның шуңа тәвәккәллеге җитмәде. Һәм ул Гасимәгә үз кулы белән тагын бер рюмка салып бирде. Инде тәмам әлсерәр дә йоклап китәр дип өметләнгән булды. «Хәзер палатканы алып җәям дә, бераз ятып торырсың», — дип тә әйтеп караган иде. Ләкин тегеңә акыллы сүзне тыңлау кая ул?

— Син мине ккем дип беләсең, көппә-көндез йоклап ятарга? Юуук, мин тамчы да исерек түгел! Телисеңме, хәзер әнә шул калганын эч-чеп беттерәм и чуртым да булмаячак! Телиссеңме? — дип чат ябышты.

Хәзер инде аннан болай гына котылып булмый, калганын даулап, барыбер Фәләхнең җанына тиячәк, чөнки ул үзен-үзе белештерми башлаган, ә эчерсәң кирегә генә китәчәк иде. Ә ничек итеп булса да җайларга, бүтән эчмәскә ризалаштырырга да кирәк: теге кара болытлар якын ук килеп җитеп, чатырдатып яшен дә яшьнәп җибәрде.

Менә шунда каушау-каударлану аркасында Фәләх бик зур ялгышлык җибәрде: ни эшләвен үзе дә белештермичә, тотты да калган коньякны шешәсеннән генә эчеп куйды. Үзе шунда, эгоист дип, ник миңа калдырмадың дип, Гасимә тавыш куптармаса ярый ла дип шикләнеп тә алган иде. Ләкин, ни хикмәттер, бу юлы нәкъ киресенчә булды: Гасимә аның эчкәненә мәгънәсез шаккатып карап торды да, кинәт бик нык сөенеп, тагын кочагын җәеп Фәләхкә сарылды һәм:

— Ну, вот! Монысы егетләрчә булды ичмаса! Ато, как баба, кыстатып торган идең. Вот молодец! ыммм! ыммм! — дип үбәргә итенә башлады.

Ләкин Фәләхтә аның кайгысы түгел, ялт-йолт яшен яшьни, дөньяны дер селкетеп күк күкри, ургылып килгән кара болытның беренче эре тамчылары чыжылдап коела ук башлады инде. Ул Гасимәне ачу белән читкә какты да тиз генә палатканы сүтеп багажникка тыкты:

— Әйдә, утыр тизрәк, югыйсә калдырам да кайтып китәм! — дип, табынны җыеп та тормыйча, машинасын кабызды.

Ул арада тагын чалтыратып яшен яшьнәде дә орып яңгыр яварга тотынды. Шулай итеп, Гасимә дә, сәрхүш булса да, тетрәнеп куркып китте һәм:

— Кайтам, акыллым, кайтам! — дип Фәләх янына алгы урынга кереп утырды.

Исерек кешене беркайчан да шофер белән рәттән утыртырга ярамаганын бик яхшы белә иде Фәләх. Гасимәне дә артка утыртмакчы булган иде. Ләкин, я тагын истерика күтәрер, дигән фикер күңеленә килде дә, ул хакта сүз кузгатып тормады. Тулы итеп газ биреп, урыннан ук выжлатып кузгалып китте.

Һәм бик вакытлы кузгалган булып чыкты: ишелеп ява башлаган яңгыр җирне ныклап чылатып өлгергәнче олы юлга исән-имин аяк бастылар. Инде ашыкмаска да була: тәүлек буе яуса да куркыныч түгел иде.

Машина берәр җирдә утырып калмагае дип куркып, рульгә чиләшеп ябышып, чамадан тыш киеренке хәлдә килү үзенекен иткән — Фәләхнең хәтта чәч төпләренә хәтле тирләп чыккан иде. Асфальт юлдан бераз баргач, машинасын туктатып, азрак тын алырга булды ул. Юлда килгәндә генә сизелмәгән икән, коньяк инде чымырдап аның бөтен тәненә таралган, күз алларын да әлҗе-мөлҗе китерә башлаган иде. Ә туктап берничә минут торгач аңа шул тикле рәхәт булып, күңеле киңәеп, дөньялар матураеп китте ки, хәтта җырлап та җибәрәсе килә башлады. Җырлый башласам Гасимә дә кушылып китәр дә туктатып булмас дип шикләнеп һәм алда әле озын юл кайтасы барын исенә алып кына тые-

лып калды. Шул хәлендә руль тотып йөз чакрымнан артык җир кайтасы, ГАИ постларын үтәсе бар иде бит әле. Дөрес, менә шушылай, машинада утырган килеш кенә, берәр сәгать йоклап алганда зыян итмәс иде дә, ләкин вакытында өйдә булырга кирәк. Башта Ленин районына машинасын илтеп, аннары трамвай белән Горкига кайтып җиткәнче күпме вакыт үтәчәк. Ә шуңарчы Гасимәне концертлары буласы авылга илтеп куясы бар иде әле.

Ә Гасимә үзе, дөнья хәлләреннән бихәбәр булып, башын күкрәгенә салган да матур гына йоклап киткән иде. Аның йоклавы бик әйбәт, ләкин Фәләхнең көтеп торыр вакыты юк шул.

— Әй, бала, бер генә минутка тор әле, зинһар? — диде Фәләх. Иплəп кенә иңенә кулын куеп, селкетә башлады: уяу йокылы икән — шундук сискәнеп уянды.

— Ник туктадык? Әллә машина ватылдымы?

Әллә биш-ун минут йоклап алуның файдасы тигән, әллә ишеп явып торган яңгырның шифасы идеме, Гасимә хәйран гына айнып киткән кебек иде.

— Бүген концертыгыз буласы авылны беләсеңме, бала? Кая илтим хәзер сине?

— Ничек кая? — диде Гасимә. Көн әллә ни салкынаймаган булса да, нигәдер туңып-калтыранып куйды.— Казанга кайтабыз, әлбәттә!

— Бригадагызны ташлапмы?

— Әйттем ич сиңа, биш кенә концерт бирдек дип. Безнекеләр күптән Казандадыр инде. Сәгать унбердә кузгалабыз дип калганнар иде. Әй, шофер, әйдә Казанга, атыңны ку, на-на-на! Ә мин, Фәләх галиҗанәпләре, сезнең рөхсәт белән эвен базарына бара торам, ярыймы?

— Ярый гына түгел, кирәк тә ул, бала. Ирең янына кайтканда аек булырга тиеш син!

— Курыкма, хәзер дә исерек түгел мин. Һәрхәлдә, ул миннән аеграк булыр дип уйламыйм!

— Алайса кузгалдык!

— Әйдә! Күпме тизрәк кайтсаң — шул хәтле яхшырак булачак!

— Ләкин бер шарт белән: юлда мине сөйләштермисең, кыбырсынып, миңа комачауламыйсың. Булдымы?

— Бик хаҗәтең бар иде. Менә, карап тор: читкә үк борылып утырам да, Казанга кайтып җиткәнче сүз әйтү түгел, күтәрелеп тә карамыйм син гөрбиянга!

Һәм ул, чыннан да, Фәләхкә бүтән сүз катмады. Уяулы-йокылы хәлдә үзе өчен генә нидер сөйләнеп һәм үз алдына гына җырлаштыргалап бара башлады. Асфальтта урман юлындагы шикелле сикертми-селкетми, машина бер көйгә йомшак кына тирбәлеп, әйбәт кенә җилдерә иде. Яңгыр инде узган. Ләкин шул хәтле күп яуган, юлның иңкү урыннарында һәм як-якларында күлләвекләр җыелып тора. Дөнья сафланып, чистарынып калган. Яңгыр хәтта инде батып бара торган кояшны да юып киткәндер шикелле: аның нурлары хәзер аеруча чиста, үткен, күзне гадәттәгегә караганда да ныграк чагылдыра иде. Ләкин юл иркен, каршы килүче машиналар сирәк-мирәк кенә очраштыргалый, шуңа күрә һич хәвефләнмичә сиксән-туксан километр тизлек белән бара Фәләх. Алар инде Дербышкага якынлашып киләләр, күп куйганда да тагын утыз-кырык минуттан Казанда булачаклар иде. Ә аннары ул Гасимәне компрессорныйда трамвай тукталышында төшереп калдырачак та (шәһәр буйлап барганда танышлары күреп калуы бар), машинасын тиз генә гаражга илтеп, хатыны белән сөекле кызы янына кайтачак. Балык булмады инде булуын. Ләкин гомер эчендә бер балыксыз кайту гына әллә ни зур гөнаһ саналмас. Әнә, бүтән хатыннарның ~~ирләре~~ биш баруның

дуртесендә буш кул белән кайталар бит әле. Шулай булгач... Аннары, балыксыз кайтуның сәбәбен Розаның үзенә аударып калдырырга да була. Син кичтән җибәрмәдең, ә иртән турсаеп калдың. Төш җиткәндә чыгып китеп балык тотып була мыни, дип үзен гаепли башласаң, бер дә алай әллә кая сикерә алмас... Юк, ничек кенә булмасын, әйбәт үтте бүген аның көне. Практикасы әллә ни булмаса да, машинаны да бер дә кешедән ким йөртми икән әле.

Кыскасы, Фәләх үзенең бүгенге сәяхәтеннән канәгать, ә күңеле тулы шундый хозурлык, шундый рәхәтлек — аның каядыр еракларда буласы, күкләргә ашасы һәм туйганчы бер дөнья гизеп йөрисе килә иде.

Ләкин бу мөмкин түгел, ә ташыган хисләрне ничек тә бушатырга кирәк иде. Һәм ул чара табылды: Фәләх, үзе дә сизмәстән, ишетелер-ишетелмәс кенә мыгырданып җырлап бара башлады:

Бакчага ямь кирә,
Хуш ислэр бөркелә,
Сиреньнәр чәчәккә бөреләнсә.
Син сөйгән сиреньнәр,
Син күргән сиреньнәр —
Күңелгә иң якын бер нәрсә.
Җырларың тыңласам,
Син барны уйласам...

Әнә шулай онытылып, искиткеч ләззәт кичереп җырлап барган чакта тизлеген киметә төшкән иде булса кирәк, ул аны-моны абайлаганчы, үкереп, бөтен җирне дер селкетеп аны бетон плитәләр төягән «КамАЗ» машинасы узып китте. «КамАЗ» тавышына Гасимә дә кинәт күзләрен ачты һәм, эшнең нәрсәдә икәнен абайлап алгач:

— Син нәрсә, егет? Җиңел машиналарны гына түгел, унбиш тонна төягән йөк машиналарын да уздыра башладыңмыни? Болай булса, тиздән безне җәяүлеләр узып китә башлаячак! — диде.

Дөресен генә әйткәндә, Фәләх үзе дә шулайрак уйлап, гарьләнеп бара иде, инде Гасимә дә төрттереп куйгач, тәмам ачуы чыкты: ул, газны ахырына кадәр басып, инде шактый ераклашырга өлгергән «КамАЗ»ны куа башлады. «КамАЗ» шоферы да, Фәләх шикелле, мин-минлекне ярата иде булса кирәк, ул да бар көченә куа башлады. Бу хәл Фәләхнең көнчелеген тагын да арттырып җибәрде. Ут өстенә ялкын өстәп дигәндәй, җитмәсә Гасимә дә, үзе чыгып чабарга җитешеп:

— Ну, ну! Я инде, я! И була, була хәзер! — дип кодрәт биргән була.

Шулай бер-ике чакрым баргач, Фәләх үзенекен итте — тәки куып узды «КамАЗ»ны. Ә Гасимә узу куанычыннан ни эшләгәнен үзе дә белмичәдер инде, кинәт Фәләхне үбәргә сузылды һәм шул чакта гәүдәсе белән алны каплады. Ә алда аларга каршы мотоцикл килә иде. Шуның белән бәрелешмәгәек дип коты алынып, Фәләх Гасимәне иң башы белән селтәп җибәреп тормозга басты һәм машинасын уңга борды. Ләкин соң иде инде: мотоциклчы аның машинасының арткы канатына бәрелеп юлның бер ягына очып китте, Фәләх машинасы юлның икенче ягындагы телефон баганасына барып бәрелде...

## 2

Аңына килеп, күзләрен ачып җибәргәндә, ул ялгызы гына зур бүлмәдә ята иде. «Бу нинди бүлмә икән, ник түшәмнәре шундый биек, нигә тып-тын, ник беркем дә юк монда, әллә соң өнем түгел, төшемме бу?..» дип ул беркавым аптырап торды. Аннары торып утырмакчы булган иде, сул аягы шундый нык чатнап авыртып куйды, ул хәтта чыдый алмыйча кычкырып җибәрде. Нишләде икән соң бу аяк дип яхшылабрак

караган иде, һушсыз кала язды: аның аягын әллә нинди тимерләр белән кыршаулап, әллә нинди баулар белән бәйләп, ул бауларга гер сыман зур-зур тимерләр асып, тарттырып караватка бәйләп куйганнар иде...

Тик шуннан соң гына ул чын-чынлап өненә килде һәм юлда һәлакәткә очрауларын, аннары үзләрен больницага китергәннәрен хәтерләде. Үзен операциягә әзерли башлауларын, врачка аякны кисә күрмәгез инде, диюен, хәтта врачның «наркоз бирегез» дигәнен, «бер... ике...» дип саный башлаганын да азрак хәтерли иде ул. Ләкин шуннан соң ни булганын да, үзе ни эшләвен дә — берни дә хәтерләми иде. «Димәк, аякны калдырганнар!» — дип сөенеп куйды. Аннары Гасимәне исенә төшерде: «Больницага китергәндә: «Уф, үләм, башым! Алла, кулым!»— дип бик каты сыкрап-сыкрап килгән иде, аның хәле ничек икән? Берәр җире гарипләнеп калмаса гына ярый инде. Аңа бит сәхнәгә халык алдына чыгарга кирәк»... Аннары үзен орышырга тотынды: «Миннән дә ахмак кеше бармы икән бу дөньяда? Ни шайтаныма шул Гасимә артыннан әллә кайларга бардым? Күрмәгән нәрсәм иде мени?..»

Аягы авырткангa кычкырып җибәргәнне ишетеп булса кирәк, тавышсыз-тынсыз гына атлап, палатага өлкән яшьтәге сестра килеп керде.

— Уяндыңмы, энем? — диде ул сабыр гына сөенеп. Фәләхнең кулын алып, пульсын санап карады. Аналарча йомшак итеп, маңгаеннан сыйпады да:

— Хәлең ничек, наным? — диде.

— Тик кенә ятканда зыянлы түгел, апа, кузгала башлагач аяк бик каты авырта. Аннары баш бик шаулый.

— Алары гына булыр инде, энем. Ансына түзәрсең.

— Түзәм, апа, түзәм. Бу кайсы больница соң?

— Уникенче.

— Миңа операция ясаганда сез бар идегезме, апа?

— Әйе, дежур идем.

— Минем аяк адәм рәтле була алырмы икән, апа?

— Борчылма, энем, төзәлер. Бәхетең бар икән, сиңа операцияне Марсил Хатипович үзе ясады. Атаклы травмотолог ул Казанда.

— Минем белән тагын бер хатынны да китергәннәр иде. Белмисезме, аның хәле ничек икән, апа?

— Теге артискане әйтәсеңме?

— Әйе.

— Аныкы зыянлы түгелие. Машина тәрәзәсенең ватыклары тиеп, ике җирдән баш тиресе суелган да кул башы таеп чыкканые. Шуны урынына утырттылар һәм башын бәйләделәр дә кайтарып җибәрделәр үзен. Җиңел яралыларны салып тормыйлар монда. Авырларга да урын җиткереп булмый.

— Миңа биредә озак ятарга туры килер микән, апа?

— Бер дә әйтә алмыйм шул, наным. Төрле кешенең ярасы төрлечәрәк төзәлә. Бар, ярасы зур булып та, тиз терелеп чыгып китүчеләр. Бар, карап торырга әллә ни ярасы булмаса да, яртышар җыл ятканнары... Бер дә курыкма, наным, терел генә, аякка бассаң бер көн дә тотмаслар. Исән калганыңа шөкер итеп, тыныч кына ят. Аяк кына ничава, төзәлер. Рабучи кеше түгел икәнсең, күтәреп йөреп эшлисе түгел. Синеңише начальник кешене санаторга да, башкасына да җибәрерләр. Бездә хәлләре синекеннән яманраклар да күп, наным. Әнә сезнең машинага бәрелгән җегетнең язмышы кыл өстендә генә...

Фәләх йөрәгә жу итеп, күз аллары караңгыланып китте: «Я, рабби! Ул да һәлакәткә эләкте бит безнең белән! Аның өчен дә мине гаепләмәсәләр икән, ходаем!»

— Шулай ук бик каты яраланганмыни, апа?
— Каты, наным, бик каты: карарга да куркыныч хәтта.
— Операция ясадылармы әле аңа?
— Ясавын ясадылар да бит, каны бик күп аккан. Аннары, башы бик эштән чыккан. Һаман аңына килә алганы юк әле.

«Беттем бит мин, болай булгач! — дигән уй телеп үтте Фәләх миен.— Үлә калса — төрмә бит миңа!...»

Аның башы бик хәтәр әйләнә башлады һәм ул гаҗизләнеп күзен йомды.

Сестра моны Фәләх арыганнан шулай итте дип уйлады булса кирәк:
— Ярар, энем, тыныч кына йокла, ял ит! — дип тагын бер тапкыр Фәләхнең башыннан сыйпап, кергәндәге шикелле үк йомшак кына басып чыгып китте.

Ләкин Фәләхтә йокы кайгысы түгел иде хәзер: сестра палатада вакытта сорарга исенә дә килмәгән иде, ул чыгып китү белән үлеп су эчәсе килә башлады. Ул хатыны Розаны күз алдына китерде.

Әйе, Розасы берни дә белми иде бит әле бу хәлләр турында. Ике көн дүрт итеп, ул инде кичәдән бирле көтеп тора торгандыр. Аннан да бигрәк кызы Розалия тыңгысызланадыр. Фәләх чыгып киткәндә, озак торма, әтием, яме, дип калган иде бит сабый. Фәләх үзе дә, кичкә кайтам, дип китте. Шимбә көн иртән чыгып киткән иде ул. Ә хәзер инде якшәмбенең төш вакыты якынлашып килә. Сестрагамы, врачкамы телефон номерын әйтеп, шалтыраттырып куйсаң булыр иде булуын да, ләкин... шушы гарип хәлдә күренүеңнән күренми торуың хәерлерәк түгелме икән.

Күрәсең операция вакытында биргән наркозның тәэсире чыгып бетмәгән, шуның өстенә тагын авыруы да үзенекен итте булса кирәк, шулай уйланып ята торгач Фәләх йоклап китте.

## 3

Төшендә ул кызы Розалияне күрде. Ә үзе төрмәдә утыра, имеш. Зур җинаятьче буларак, аны аерым камерада тоталар икән, имеш. Ә Розалия аның хәлен белергә килгән. Ул инде зур, энисе хәтле булган. Нигәдер, Фәләх янына килми, ишек төбендә генә басып тора. Ике күзе дә мөлдерәмә яшь. Их, эти-эти, менә син кая килеп эләккәнсең икән бит. Нигә шулай башсызланып, әллә кайларга барып йөрдең? Ник эчтең соң син ул көнне? Эчмәсәң, һәлакәткә эләкмәс идең. Төрмәгә дә утыртмаслар иде, ди... Монда бер үзең генә ятулары бик куркынычтыр, әйдә, өйгә кайтыйк, эти, ди. Өйгә кайтсаң, мин сиңа җырлап та күрсәтермен, балалар бакчасында безгә яңа җыр өйрәттеләр, ди. Әни дә бик сагына, бик көтә, ди. Син кайтсаң, мин манный боткасын да күбрәк ашармын, сөтне дә күбрәк эчәрмен, элекке шикелле киреләнеп тормам, хәзер мин зур, акыллы инде, ди. Син кайтсаң, үзеңә генә күңелсез булмасын өчен, мин бакчага бармам, өйдә синең янында гына уйнармын. Телевизорны син ята торган бүлмәгә куярбыз да бергәләп мультфильмнар карарбыз. Син миңа экиятләр сөйләрсең, китаплар укырсың, ди. Син бар чакта әни миңа экиятләр сөйли, китаплар укый торган иде. Хәзер сөйләми, әллә нигә гел ачулы йөри, китаплар да укымый башлады, ди. Син кайтсаң, ул да шатланыр, мине элеккечә ярата башлар иде, ди. Венераның да, Асиянең дә, бүтән балаларның да этиләре көн дә өйләренә кайта, ә син инде кайчаннан бирле юк та юк. Кайтсаң, зоопаркка барып, узган елгы шикелле, филләрне, арсланнарны, маймылларны карап йөрер идек. Анда бер кечкенә маймыл баласы бар иде, шуны күрәсем килә: энкәсе хәтле булды микән әле? Маймыллар кешеләргә караганда

тизрәк үсә, дип үзең әйткән идең бит, ди... Үзе шул арада, менә тыңлап тор әле дип, Фәләх моңарчы бер дә ишеткәне булмаган бик моңлы яңа көйгә җырлап та ала. Әнидән оттым. Әнием үзе уйлап чыгарды аны, шуңа күрә бездән башка беркем дә белми әле, ди. Әни белән икегез миңа иптәшкә бер кечкенә малай алып кайтырга вәгъдә иткән идегез, син булмагач әни аны да алмый. Үземә генә бирмиләр, ди. Ә этиең, белмим, кайда йөри торгандыр, ди. Күрсәң әйт үзенә, бәлки ул анда миннән куркып, мин ачуланыр дип кайтмыйдыр, курыкмасын, мин аңа бер сүз дә әйтмәм, тик кайтсын гына, ди... Әйт әле, эткәем, кайтам, диген! Я инде, әйт...

Фәләхкә коточкыч кыен. Ул кызы Розалиягә ни җавап бирергә дә белми. Нилектән менә шулай килеп чыкканын ничек итеп аңлатмак кирәк ул сабыйга. Алты яшьлек бала аңларлык күренеп торган сәбәбе дә юк бит әле аның... Бала түгел, Фәләх үзе аңлый алмый әле нигә болай булганын. Ә сабый җавап сорый! Фәләхнең күзләренә текәлгән дә инәлеп-инәлеп җавап көтә... И-и-иххх, дөнья!..

4

Анын бу йокылы-уяулы һәм бик газаплы төше әле тагын дәвам итәр иде, ләкин кемдер иңеннән нык кына селкетеп уятты. Прокуратура тикшерүчесе микән әллә дип, коты алынып күзләрен ачып җибәрсә, караваты янында базык кына гәүдәле, түгәрәк кызгылт йөзле, кырык бишләр тирәсендәге ак халатлы ир кеше басып тора иде. Фәләх шундук танып алды: узган төн аңа операция ясаган врач иде ул.

— Нәрсә, энекәш, саташып алдыкмы әллә? — диде ул ягымлы елмаеп.

— Булды шул бераз. Кычкырып үк төшләнә идеммени?

— Һәрхәлдә, коридордан үтеп барышлый, мин сезнең тавышны ишетеп кердем. Я, үзебезне ничек хис итәбез? Аяк бик борчымыймы?

— Тик кенә ятканда түзәрлек. Бер килеш сулкылдап кына тора. Ләкин чак кына кымшанып куйсаң — һич чыдый торган түгел...

— Анысы гына булыр инде, энекәш. Сезнең хәлдә ул бик табигый. Ә баш ничек, әйләнмиме?

— Әйләнүен әйләнми, ләкин нидер тутырган шикелле булып, бераз шаулап тора.

— Алай гына булса — бик шәп. Ә менә әйләнсә — куркыныч булыр иде. Башыгыз да шактый каты бәрелгән булган сезнең. Миегез селкенмәде микән дип шикләнгән идем. Димәк, ул яктан барысы да тәртиптә. Ә шаулавы — наркоздан соң була торган гадәти нәрсә ул. Тагын берике сәгатьтән үтәчәк,— врач шулай сөйләнә-сөйләнә халат кесәсеннән фонендоскопын алды да Фәләхнең күкрәгенә куеп тыңлап-тыңлап карады. Аннары: — Ну, вот, барысы да әйбәт. Бөтенесе дә тәртиптә булачак. Сабыр гына, артык борсаланмыйча гына ятсагыз, ай ярым-ике айдан рәхәтләнеп йөри башлаячаксыз,— диде.

— Неужели шулай озак ятарга туры килер икән, доктор?

— Сезнең хәлдә шуннан да тизрәк терелү мөмкин түгел, энекәш. Да, теге артистка кемегез була ул?

Фәләх ни әйтергә белми аптырап калды:

— Үзе ничек диде соң?

— Ачык итеп әйтеп бирмәде шул. Башта туганнан туган абыем дигән иде. Ә менә сезгә операциядән соң, аңыгызга килгәнче яныгызда караштыргалап торуын үтенгәч исә, юк, ул минем туганым түгел, просто юл уңае килеп кенә машинасына утырган идем, биредә аны калдыра алмыйм, өемдә яшь балам бар, дип кайтып китте.

— «Ай-яй, каты күңелле икән! — дип уйлап алды Фәләх.— Яратам, дип йөргән булды тагын. Их-ма!» Ләкин врачка исә бер дә исе китмәгән булып җавап бирде:

— Әйе, доктор, дөрес әйткән: беркемем дә түгел ул минем. Кайтып китүе әйбәт булган.

— Анысы, ихтимал, шулайдыр. Ләкин сезнең хәлдәге кешеләр янында туган-тумачалары дежур торалар иде гадәттә. Мондый чакларда авыруларның җәмәгатьләре гадәттә я чираттагы ялларын алып, я үз хисапларына буш көннәр сорап, төннәрен больницага дежурга киләләр. Югыйсә бөтен травмотология бүлегенә бер генә дежур нянька бездә — кайсына гына житешсен. Сезнең ничегрәк соң ул яктан? Кемнәрегез бар?

— Хатын да алты яшьлек кызым.

— Да, әллә ни мактанырлык түгел икән. Кайберәүләрнең апа-абыйлары, пенсиядәге эти-әниләре була, чиратлап дежур торалар. Ә сезнең кыенрак шул. Кызыгыз янына төнгә берәр күрше карчыгы дәшеп торсагыз гына инде.

«Их, доктор, доктор, хикмәт анда мыни соң? Баланы аны авылга әби янына кайтарып куеп та булыр иде. Мондый очракта, каты күңелле булса да, үз әнием дә карый ала. Ләкин бит бу хәлләрдән соң Розаның миннән бөтенләй баш тартуы бар. Кыек юлда йөргәнемне сизенгән иде ләбаса ул? Шуның өстенә тагын кеше таптатканны да белсә...» Ләкин врачка бу уйларын әйтмәде Фәләх.

— Ничек тә берәр җаен табарга туры килер инде,— дип җавап бирде. Бик нык эчәсе килгәнлектән, тавышы пышылдап кына чыкты. Шуңа ул врач чыгып киткәнче су мәсьәләсен хәл итеп калырга ашыкты: — Миңа бер стакан гына булса да су эчәргә рөхсәт итсәгез иде, доктор?

— Хәзер, энекәш, эшлибез аны! — дип врач Фәләх караваты буендагы бәләкәй төймәгә баскан иде, минут та үтмәде, палатага баягы сестра ханым килеп керде:

— Нургаян апа, авыруга бер стакан су кертсәгезче? — диде врач. Аннары Фәләхкә мөрәҗәгать итте: — Хатыныгыз белмидер бит әле сезнең монда икәнне?

— Әйе, доктор, белми.

— Өегездә телефон юкмы?

— Телефонмы? — Ул арада Нургаян апа су алып кергән иде. — Хәзер, су гына эчим инде. Уфф, булды, җаннарым рәхәтләнеп китте. Рәхмәт сезгә, Нургаян апа. — Шуннан соң гына врачка җавап бирде. — Телефоны бар барын. Шалтыратсаң, хатын да хәзер килеп җитәчәк. Ләкин... ничек дип әйтергә инде сезгә... мин аның белән сөйләшергә әзер түгел шул әле.

Врач, гаҗәпсенеп, иңбашларын сикертеп куйды:

— Ничек инде әзер түгел? Нәрсәсенә әзерләнергә кирәк аның? Авариягә үзегез теләп яисә хатыныгыз аркасында эләкмәгәнсездер бит?

— Юк, әлбәттә. Анысы көтелмәгән, очраклы хәл. Ләкин алай берике сүз белән генә аңлатып биреп булмый торган четерекле яклары бар шул бу мәсьәләнең. Һәрхәлдә, хатын белән ничек һәм нәрсә сөйләшергә икәнен уйларга кирәк әле миңа, доктор. Ансыз булмый. Һич югы иртәнгә кадәр генә булса да уйларга кирәк. Сез анда Нургаян апагамы, ул кайтып китә торган булса, бүтән берәр дежур сестрагамы әйтеп куегыз инде, зинһар: санитарга гына ышанып тормасын, минем янга да кергәләп чыксын иде төнлә. Буш итмәм, соңыннан бәхилләтер идем. Ә хатынга бүген әйтмичә торыйк әле, яме.

— Анысыннан гына эш калмас. Бер төнгә ничек тә рәтләрбез. Ләкин иртәгә иртән, хатыныгыз эшкә киткәнче, шалтыратып әйтергә кирәк булыр. Ул бит сезне борчылып көтә торгандыр.

— Көтә, әлбәттә. Мин бит кичә үк кайтырга тиешле идем.

— Ярый, тыныч ятыгыз. Йоклап китәргә тырышыгыз. Йокы тизрәк сәламәтләнергә ярдәм итә ул,— дип врач чыгып китте.

Фәләх аннан теге мотоциклистның хәле турында сорарга теләсә дә, «аңына килә алмады, үлде» дигән җавап алудан куркып, дәшмәде. Чөнки болай әле ниндидер өмете бар, ә теге егет дөнья куйган булса, төрмәдән котылырга тырнак очы кадәр дә ышанычы калмаячак иде...

Врач йокларга кушып китсә дә, йокы кайгылары качкан иде Фәләхтән. «Каян башланды минем бу һәлакәтнең башы? Очраклы гына хәлме бу? Әллә инде азлап-мазлап күптән җыела килгән гөнаһларның бер нәтиҗәсеме? Бер миндә генәме моның сәбәбе»...

Аның күңелен әнә шул сораулар телә иде. Ә аларга азмы-күпме аныграк җавап табу өчен, хәзер бөтен үткән тормышын күзаллап, барлап чыгарга кирәк иде.

### 5

Фәләх семьяда бердәнбер бала иде. Әти-әнисе авыл җире өчен икесе дә шактый дәрәҗәле урыннарда эшлиләр: әнисе — кыз чагыннан бирле кибеттә сату итә, әтисе, Фәләх туган елдан алып, элемтә бүлеге начальнигы. Беркайчан да һәм бернәрсәгә дә кытлык кичергәннәре юк. Тормышлары мул. Кара-каршы итеп салынган гүрнәчә кебек ике өй. Зурысы — ун метрга ун метрлысы — дүрт бүлмәле. Бер залы гына да шәһәрнең ике бүлмәле фатиры хәтле — утыз ике квадрат метр. Икенчесе — әллә ни зур булмаса да, шыңгырдап торган сап-сары нарат бүрәнәләрдән салынган җәйге өй. Капка төпләрендә генә берәүнең өенә дә алыштыргысыз, кышын да җылытыла торган таш гараж. Алтмыш сигезенче елдан бирле машина тоталар. Башта «Москвич» алганнар иде. Биш ел йөргәч аны Кавказ ягыннан килгән шабашникларга үз бәясенә сатып, «Жигули» алдылар. Әнисе быел анысын да яңартырга, «Нива» алырга кирәк дип йөри иде, бәлки инде алганнардыр да... Әти-әниләре, этлемәчеле булып дигәндәй, үзара шактый еш ызгышсалар да, гомумән алганда алай начар тормыйлар. Яңадан яңаны гына киенәләр. Ә ашауэчүне инде әйткән дә юк. Хәзер сөт-май районда да, шәһәрдә дә сатыла. Һәрхәлдә, Фәләхнең әти-әнисе өчен зур проблема булмас иде. Ләкин әтиләре: «Мин хезмәтем буенча гына интеллигент, ә рухым, холкым белән крәстиян. Шулай булгач, авылда яшәп тә сыерсыз торуны мин аңламыйм һәм аңларга теләмим дә. Көн саен яңа сауган сөт эчеп, куе каймак ашап тормагач, дөньяда яшәүнең ни кызыгы бар да, ни хаҗәте кала?» — дип бура кадәр сыер тота. Теләсәләр, ит юнәтү дә әллә ни кыен булмас иде аларга. Ләкин әнисе: «Кеше суйган ит — итмени ул? Көн саен сбижиен ашап тормагач, яшим дип йөрмим дә мин аны!» — дип саный. Ел саен бер тана, җиде-сигез баш сарык суялар. Иллешәр баш чебеш алып үстерәләр. Кимендә ун-унбиш казлары, утызлап үрдәкләре була.

Ә узган ел Фәләхне зур гына автохуҗалыкның баш инженеры итеп күтәргәннән соң:

— Әйбәт кенә укып чыгып, яхшы гына урында эшли башласаң, машина алып бирермен дип адарынып куйган идек. Син беренче класста укый башлаганнан бирле шуңа дип акча җыя килдек. Маладис, улым, инде булды, кеше арасында йөзгә кызыллык китермәдең. Зур урынга да ирештең. Шәт моннан ары да шулай әйбәт кенә булырсың. Менә сиңа безнең икебездән бүләк! — дип әнисе белән әтисе аның үзенә дә өр-яңа «Жигули» бүләк иттеләр... Кичә авылга Фәләх нәкъ шул машина белән барды. Хәзер ул машина кайдадыр һәм ни хәлдәдер — шайтан

белгән. Хәер, исән-сау терелеп, төрмәгә эләгүдән котылып кала алса, маңгаена мылтык тәрәсәләр дә рульгә бүтән беркайчан да утырмас инде ул...

Әти-әниләре шундый хәлле, дәрәҗәле кешеләр булгач, әлбәттә инде, Фәләхне бала һәм үсмер чагында да, егет булып җиткәч тә авылда һичкем кыерсытмады. Дөрес, иптәш малайлары белән вак-төяк чәкәлешеп алулар булгалый иде булгалавын. Әмма телгә алып әйтерлек кимсеткәннәрен ул хәтерләми. Әтисе дә, әнисе дә: «акыллы бул, бала, кеше белән ирләшмә, сугышма, без икебез дә кеше күз алдында эшләүчеләр, безнең янга бөтен авыл халкы йөри, малаегыз алай икән, тегеләй икән дип әйтерлек булмасын»,— дип әледән-әле искәртеп торалар иде. Фәләх үзе дә акылсыз малай түгел: баш бәтәрлек итеп, теләсә кая чапмый, кирәкмәскә барып тыгылмый, иптәшләре белән чамасын белеп, алдын-артын карап кына уйный, кайбер коры куык-буш бугазлар шикелле, юкка-барга җикерenми, күбрәк бүтәннәр сөйләгәнне, бүтәннәр мактаганны тыңлап, шуннан үзенә гыйбрәт алып, нәтиҗә ясап тора иде. Шуңа аны малайлар үз компанияләренә бик теләп алалар... Хәер, бу уңайдан, үзе яхшы булган өчен аны шулай хөрмәт иткәннәр дип уйлау бик үк гадел булмас. Элек, Фәләх әле күп нәрсәне тиешенчә аңлап җиткерә алмаган бала чагында гына шулай тоелган ул. Ә менә хәзерге акылы белән уйлап карагач күренә: юк, почта начальнигы белән кибетче малае булганы өчен теләсә кайсы малай белән дус йөри алган икән ул. Бала чакта тәм-том әйберләргә, төрле уенчыкларга күңел бик кызучан була бит. Ә иң күп, иң әйбәт уенчыклар, иң тәмле конфет-прәннекләр Фәләхләрдә була һәм ул аларны нигәдер урамга алып чыгып ашарга ярата торган иде. Шуны күреп, иптәшләре кызыга. «Әз генә каптыр инде, малай?» дип аның тирәсендә песи урынына бөтереләләр. Фәләх алай саран малай түгел, булганын кызганмый, еш кына иптәшләре белән бүлешеп ашый иде. Шуңа күрә тегеләр аны беркайчан да диярлек кимсетмиләр, киресенчә, аңа ярарга, аны үпкәләтмәскә тырышалар иде...

Ә менә уку мәсьәләсенә килгәндә исә, чыннан да, һичнинди ташламасыз, бары тик үзенең тырышлыгы һәм булдыклыгы аркасында гына яхшы укыды ул. Аны укыткан укытучылар әле барысы да исән. Теләсә кайсыннан барып сора, берсе дә Фәләх үзенең хәләл көче белән укымады дип әйтмәс. Бу яктан аның әтисе мәсьәләне бик каты куйган: «Бүтән ялгышыңны кичерергә булыр, улым, әмма уку ягыннан йомшаклык күрсәтсәң, миннән рәхим-шәфкать көтмә! Укытучы бүген миннән сорамас әле дип, беркайчан да дәресеңне әзерләмичә барма! Чөнки син укытучы өчен укымыйсың, улым, белем үзеңә кирәк! — дип әледән-әле Фәләхнең исенә төшереп тора һәм, укытучылардан да: — Кибетче малае дип таләпне киметмәгез! Унны бетереп, югары уку йортына имтихан тапшырырга баргач, аннан әниең кем иде дип сорамаслар, белем таләп итәрләр! Зинһар дип әйтәм, дәресләрен ешрак, ныклабрак сорагыз!» — дип үтенә иде...

Фәләх моның шулай кирәген үзе дә белеп-сизеп тора һәм әтисенең ышанычын акларга тырыша. Тырыша дигәч тә, ай-һай, башкалардан артык тырышты микән ул? Юк шикелле. Ни өчен дигәндә, укуга Фәләхтән ныграк бирелгәннәр, көнен-төнен дәреслек өстендә утырган укучылар да бар иде алар классында. Бигрәк тә Роза атлы кыз, Фәләхтән калышмаска теләп, ничек кенә азапланмады... Ә Фәләх үзе бер дә алай интегеп утырмый, чөнки укуны ул җиңел үзләштерә, дәрескә дигәннәрне бер-ике кат укып чыгу белән хәтерендә калдыра, соңыннан шартлатып сөйләп бирә ала, өйгә бирелгән мәсьәләне бер утыруда чишә. Шуңа күрә аның кызыклы китаплар укырга да, урамда уйнарга да вакыты бик җитә торган иде.

Унынчыны ул көмеш медальгә тәмамлады. Һәм моңа авыл халкы да, укытучылар да, оһо, кибетче белән почта начальнигы үз малайлары Фәләхкә медаль алып биргәннәр, дип гаҗәп-хәйран калып тел шартлатмады. Бик табигый хәл дип кабул ителде бу. Чөнки Фәләхнең гел бишкә генә укуы барысына да мәгълүм, аның математикага аеруча сәләтен инде районда гына түгел, Казанда да беләләр: өч ел рәттән математика буенча республика олимпиадасында катнашып, өчесендә дә алгы урыннарга чыккан егет иде ул...

Ә менә Роза, күпме генә тырышса да, олимпиадаларда катнашып караса да, һәрвакыт беренче турдан да үтә алмыйча төшеп кала килде. Медаль ала алмады гына түгел, хәтта чыгарылыш имтиханнарында тарихтан дүртлене дә шул Фәләхнең тырышлыгы, аның ярдәме аркасында гына алды ул. Югыйсә, харап иде кызыкайның хәлләре: йөзеннән кан качкан, күзләре тонган иде бичараның. Аның «берни дә белмим» дигәнне аңлатып баш селкеп, ярдәм көтеп тилмереп утырулары бүген дә хәтерендә әле Фәләхнең. Әгәр шунда Фәләх аңа эләккән билетка җавап язып бирмәгән булса, беткән иде ул кызыкай...

Җае чыккан чакларда Фәләх аңа гел ярдәм итәргә тырыша иде. Ләкин тегесе нигәдер гел аннан читләшә, Фәләх ярдәменә бик сирәк таяна, һәр нәрсәне үз көче белән башкарып чыгарга тырыша һәм еш кына үз дигәненә ирешә дә иде. Бүтән кызлар, әгәр өйгә бирелгән эшне күчереп алырга рөхсәт итсәң, синең өчен утка керергә әзер. Тик күчерт кенә. Ә бу, киресенчә, ярдәмнән үзе баш тарта...

Шулай да нигәдер нәкъ менә шул Розага булышасы килә Фәләхнең, аның ярдәм сорап килүен тели иде. Ник шулай? Хикмәт нәрсәдә? Фәләх моның серенә башта үзе дә төшенә алмыйча йөргән иде. Соңыннан, сигезенче класста, ниһаять, аңлады: ярата икән бит ул әлеге Роза дигән кыз баланы. Карап торышка бер дә алай әллә нәрсәсе юк инде үзенең! Йомыры гына, җитез генә, беркайчан да үзенә игътибар юнәлтергә тырышып чәчрәп чыкмый, артыгын сөйләшми торган тыйнак кына, гап-гади бер кыз иде. Төс-бит тә алай чыкылдап торган чибәр түгел. Дөрес, ямьсез дип әйтеп булмый булуын. Коңгырт кара күзле, энҗе шикелле ап-ак, тип-тигез тешле, итләчрәк кенә алсу иренле, кыя кара кашлы, елмайган чагында нечектер эчтән балкып китә торган мөлаем йөзле ул кызны ничек итеп ямьсезләр чутына кертмәк кирәк? Әгәр инде буй-сынының зифалыгын һәм тал чыбыктай сыгылмалылыгын да искә алсаң, икеләнмичә, матур дияргә мөмкин. Фәләхләр мәктәбендә аңардан да сылурак, матурраклар бар иде барын, ләкин аның күңеле нигәдер гел әнә шул тыйнак һәм тырыш Розага тартылды, аны якын итте. Күпме тынгысыз көннәр, күпме йокысыз төннәр үткәрде Фәләх ул кызны үзенә карату өчен! Чын күңеленнән яратуын аңлатырга тырышып, сөйләшеп караган чаклары да күп булды, бик күп хатлар да язды. Бер-ике тапкыр аеруча илһамланып китеп, шигырь белән дә язып караган иде. Барыбер файдасы булмады: Роза Фәләхкә һаман битарафсалкын булып кала бирде. Бүтән берәрсе белән йөргәне дә сизелми иде үзенең. Аның кебекләрнең инде егетләр белән йөри башлаганнары байтак. Ә моңа — укудан башка берни кирәкми. Барса, атнага бер-ике тапкыр була торган киногә барып кайта да шуның белән — вәссәләм...

Шулай да бер тапкыр, Фәләх бик үтенгәч, киногә барып, аның белән рәттән утырды ул. Кинодан соң хәтта өйләренә кадәр озата кайтырга да рөхсәт итте. Фәләх шунда аңа:

— Ничек яратып йөргәнемне, синең өчен уларга да әзер торганымны беләсең бит инде, Роза. Әйт әле дөресен генә, ник читләшәсең син миннән? Шулай ук сөйкемсез булып күренәммени соң сиңа?! — диде. Мәсьәләне ачыклап, я тегеләй, я болай конкрет хәл итмәкче булган иде ул. Ләкин кая анда хәл итү!..

Дөрес, кыз аңа кистереп каршы килмәде.

— Нигә алай дисең, Фәләх? Мин сине класстагы бүтән малайларны якын иткән кебек үк ихтирам итәм, бит! — диде ул мәсьәләне чамадан тыш гадиләштереп. — «Сөйкемсез» диюең дә урынсыз. Синнән сөйкемле, синнән чибәррәк егет юк та әле безнең класста, бик беләсең килсә!

— Алай булгач тагын ни кирәк? Сиңа ошар өчен, әйт, нишлим мин, Роза?

Кыз уйланып калды. Ул нидер әйтергә теләи, әмма кыюлыгы җитми иде.

— Курыкма, Роза, күңелеңдәгеи туп-туры әйт. Ни дисәң дә үпкәләмәячәкмен. Чөнки минем өчен изге син, һәр сүзең кадерле!

— Беләсеңме, Фәләх... юк, берни дә эшләргә кирәкми сиңа... Мин сине... болай да яратам. Нәкъ менә шуңа күрә читләшәм дә инде.

Һәм ул сизелер-сизелмәс кенә, тавышсыз гына елап җибәрде. Монысы инде Фәләх өчен бөтенләй көтелмәгән нәрсә иде. Мондый чакта кызга ни әйтергә, аны ничек юатырга белмичә, ул югалып калды.

— Я инде, Роза, юләрләнмә болай! Нинди балавыз сыгу бу бер дә юктан. Кыен вакытта, билетка җавап бирә алмаганда еламаганны, хәзер, инде эш узгач, бернинди сәбәпсез елап торалар ди мени?

Бераздан Роза азрак тынычланып, күз яшьләрен сөртеп алды, маңгаена төшкән чәчләрен рәтләгәндәй итте дә:

— Имтихан нәрсә ул? Хәзер бирә алмаган булсам, көз бирер идем,— диде.

— Шулай булгач, нигә күз яше әрәм итеп торырга ди?

— Мин бит имтихан өчен түгел, Фәләх, сине якын иткәнгә елыйм мин!

— Нәрсә дигән сүз инде бу? «Үзем сөям, үзем качам, үзем белмим сәбәбен»,— булып чыгамыни?

— Юк, Фәләх, алай түгел шул. Киресенчә, сәбәбен бик әйбәт беләм мин аның!

Фәләх теләсә нәрсә ишетергә әзер, әмма кыздан мондый җавап көтмәгән иде.

— Кызык бу, зерә дә кызык! Ә миңа әйтергә ярыймы соң аны? Мөмкин булса, әйтче, зинһар, Роза?

Фәләх аны әллә нинди катлаулы фәлсәфәләргә кереп китәр дип көткән иде. Ә кыз бик гади генә итеп җавап бирде:

— Тиң түгел без, Фәләх. Хәзер генә шушылай өтәләнеп йөрисең син. Соңыннан санламаячаксың.

— Син нәрсә, кызый, тузга язмаган нәрсәләр уйлап чыгарасың? Минме? Мин синеме!.. Их, Роза! Роза! Бүтән беркем дә кирәк түгел миңа! Тик синең белән генә бәхетле булачакмын мин! Их, ничекләр генә итеп аңлатыйм икән күңелемдәге шул изге һәм кайнар хисләрне?! Ничекләр генә итеп?

Әнә шулай өзгәләнгән иде ул чакта Фәләх. Чын күңеленнән әйткән идеме икән ул боларны? Чыннан да шулай үлеп гашыйк идеме Розага? Гашыйгын гашыйк, әмма алай дөньясын онытырлык дәрәҗәдә үк түгел иде. Ә Розага чат ябышуының сәбәбе башка: кызның ярып әйткән әлеге сүзе мин-минлегенә тигән иде Фәләхнең. Тагын да ачыграк итеп әйтсәк, ул чакта Фәләх үзен көрәштә җиңелеп калган кеше сыман хис итте. Ә аның һич кенә дә җиңеләсе килми. Аның әле беркайчан да җиңелгәне юк, бары җинеп кенә килә: ул инде ике-өч кыз белән йөри башлап, барысын да үзе ташлаган иде. Ә монда менә шушы Роза дигән, коры горурлыгыннан башка бер дә алай шаккатмалы нәрсәсе булмаган бер кызый аның ихтыярына каршы килеп маташа! Юк, аңлашылмый иде бу Фәләхкә. Болай булырга тиеш түгел. Аныңча, Фәләх теләгәнчә, булырга тиеш иде!..

Шуңа күрә чат ябышты ул Розага.

— Роза-җаным, Роза-бәгырем! Син бит минем якты маягым. Өметем! Ышанычым! Яшәү чыганагым! Мин бары тик синең өчен яшим бу дөньяда. Мин сине гомерем буена сөячәкмен! Мин сиңа беркайчан да бер генә авыр сүз дә әйтмәм, тик минем белән йөрергә риза гына бул!

Әмма Роза шуннан ары да эреп китмәде:

— Ник бу кадәр төчеләнәсең, Фәләх? Нигә шул тикле гашыйк булган булып кыланасың? Күзләреңнән күреп торам, алдашасың бит, җаным! — диде ул, иплән кенә.— Без синең белән пар түгел икәнне үзең дә беләсең ич инде: син Нәгыймә белән Мөхәммәт малае, ә мин этисе кем икәнлеге дә билгеле булмаган бер ятимә.

Молодец булган бит ул кыз. Шул тикле дә реаль фикер йөртергә каян башына килде икән аның ул чакта? Аның шул сүзләрен ишеткәч, Фәләх үзе дә, ә бит чыннан да шулай, дип аптырап-югалып калган иде. Чөнки Розаның бөтен әйткән сүзе дөрес: әнисе аны кияүгә чыкмыйча гына тапкан, аннары да ир-атлар белән шактый чуалган. Аннары килеп, дөнья күтәргә дә алай бик үк атлыгып тора торган кеше түгел иде ул: иртәге өчен артык борчылмый, бүгенге белән генә яши. Шуңа күрә тормышлары да әллә ни түгел: сыерчык оясы хәтле генә өйләреннән, өч-дүрт баш сарыкларыннан һәм бер кәҗәләреннән гайре телгә алып сөйләрлек маллары юк иде аларның. Әмма шунысын әйтергә кирәк: Розаның әнисе һәрвакыт әйбәтне, яңадан яңаны киеп йөри, Розаны да ирле-атлы кешеләрнең кызларыннан болайрак киендерә һәм эшләп тапкан бөтен акчасын шул кием-салым алуга тотып бетереп бара да иде булса кирәк. Ә акчаны ул аз алмый, чөнки сыер савучы булып эшли һәм һәрвакыт алдынгылар рәтендә.

Ләкин бу фикерләр Фәләхнең башына секундның меңнән бере эчендә генә килеп китте. Аңа ул чакта мондый вак-төяк нәрсәләрнең әллә ни әһәмияте юк иде. Бары тик Розаны ничек тә кулдан ычкындырмаска, аның вәгъдәсен алырга кирәк.

— Ник юк нәрсәләр турында баш ватасың, кызый? Миңа әти-әниеңнең кем булуы түгел, син үзең кирәк. Мин бит үзеңне сөям! Рәйхана апаныкы гына түгел, шайтанның үз кызы булсаң да шушылай сөяр идем. Ә синең әниеңнең һич тә бүтәннәрдән ким җире юк. Бик беләсең килсә, аны мин ирле хатын-кызларның күбесенә алыштырмас идем әле.

Роза урынында бүтән кыз булса, бу сүзләргә баллавыз булып эрер иде. Ә ул мәсьәләне Фәләх гел көтмәгән якка борып, тагын да катлауландырыбрак җибәрде:

— Ярый, Фәләх,— диде ул беркайчан да булмаганча җитди-уйчан итеп.— Шулай да булсын ди. Бәлки син чыннан да шулай уйлыйсыңдыр. Ләкин бит әниең бар әле, егет! Минем белән дуслашуыңны белсә, икебезгә дә көн күрсәтәчәк түгел ул. Әле йөри башламаган көе дә миңа кан дошман итеп карый. Шушы араларда гына кибеткә конфет алырга кергән идем, үзе генә чагы туры килде дә өзеп әйтте: «Минем малайга күз атып йөрисең дилэр, кызый. Ишетсен колагың, азапланма юкка. Сиңа буласы егет түгел ул!» — диде.— Аның каршында ни гаебем бардыр — белмим. Алай дип кимсеткәнче, яңагыма чапса, ичмаса, җиңел булыр иде...

Роза шунда пышык-пышык елый башлаган иде дә Фәләх аны бик авырлык белән булса да туктатты. Әмма кызның фикерен үзгәртә алмады. «Бер-беребезне яраткач, әниең безгә ничек каравында ни эшебез бар? Ул безгә каршы ни кыла ала?» — дип тә карады ул аңа. Тик кызның бер дә алай исе китмәде.

— Булмастай белән хыялланып, башыңны ватма, Фәләх. Безгә ул турыда уйларга гомумән иртә бит. Әле укыйсыбыз, акыл утыртасыбыз бар. Ә аңарчы әллә кемнәргә гашыйк булып, әллә кемнәрне табарсың. Инде өч кыз белән йөреп карадың бит.

— Бәй, болай гына йөрдем лә мин алар белән!

— Инде минем белән дә «болай гына» йөреп карарга телисең, әйеме?

— Ай-яй, бу кадәр дә шикләнүчән җан булырсың икән! Үзең яратам, дисең, ә үзең минем белән дуслашудан читләшәсең?

— Дуслашудан ни мәгънә: барыбер ташлаячаксың...

— Син башта дуслашып карар идең. Шушы яшеңәчә беркем белән йөреп караганың юк... Гомер буена ялгыз яшәргә җыенмыйсыңдыр ич, кызый?

— Юк, мин обязательно кияүгә чыгам. Ләкин алай кызык өчен генә йөреп карарга җыенмыйм. Йөрсәм, тик берәү белән генә йөриячәкмен.

Фәләх аңа: «Син укырга кая керергә җыенасың? Әйдә бергә барыйк, кирәк чагында бер-беребезгә ярдәм итешербез», дип тә караган иде. Ләкин Роза: «Юк, Фәләх, миңа хәзер синең белән бергә укырга түгел, киресенчә, синнәнераграк булырга кирәк»,— дип риза булмады. Укырга кая керәсен дә әйтмәде хәтта.

Шуннан соң Фәләх, Казанда булсам, бер очрамаса бер очрап йөрәкне яндырыр, ичмаса күзем күрмәсен дип, укырга Мәскәү институтына барып керде. Аннары килеп, кайда укый дигәндә, Мәскәүдә укый дигән исеме дә бар иде бит әле. Авылдан китеп, Мәскәү югары уку йортларына укырга керү — уен эш түгел икәнен кем белми?

Ә Роза Казан финанс-экономика институтына кергән булып чыкты. Кышкы каникулга Фәләх: «Аны авылда күрермен дә тагын бер бик әйбәтләп сөйләшеп карармын, бәлки ул инде акыллылангандыр»,— дип кайтса да, өмете акланмады: Роза каникулга бөтенләй кайтмаган, курсташлары белән туристик походка китеп барган икән. Җәйге ял вакытында да күрә алмады ул аны: Роза студентлар отряды белән төзелешкә киткән иде.

Роза үзе юри шулай качып йөрдеме, очраклы рәвештә шулай килеп чыктымы — Фәләх аны тик өченче курсны тәмамлап кайткач кына очрата алды. Яшерен-батырыны түгел, узган эш, ул елларда Фәләх гел Роза дип, гел аның турында авыз суларын корытып кына утырмады, әлбәттә. Аны да яраткан кызлар булды, үзенең дә кайберләренә күңеле төшкәләде, дуслашып та йөрде. Ләкин, ничек кенә булмасын, берсе дә Фәләхнең Розаны ярату хисен кысрыклый алмады. Киресенчә, Фәләх аларның һәркайсын Роза белән чагыштырып карый, аңа тиңләргә, аңа охшатырга тырыша, әмма берсе дә Розага җитми: үлчәү тәлинкәсе гел Роза ягына баса һәм Фәләхнең күңеле алардан бик тиз суынып, битараф булып кала килде. Ә хатын-кыз халкы ир-атның битарафлыгын көне-сәгате белән сизенеп ала һәм аны һичкайчан кичерә алмый. Шулай итеп, Фәләх беркем белән дә алай дөньясын онытып гашыйк булып йөрмәде. Дөрес, бер иләсләнеп алды алуын. Ләкин анысы Фәләх үзе теләп, аның инициативасы белән эшләнгән эш булмады аның. Анысы гомумән башка статья... Я, хода! Әлеге алар күрешми торган өч ел эчендә Роза шундый нәфисләнеп, шундый тулып-өлгереп житкән иде ки, Фәләх башта хәтта аның йөзенә күтәрелеп карарга да кыймый торды. Билгеле, элек тә начар киенеп йөрмәде Роза. Ләкин ул чакта кигәннәре авылчарак, гадирәк була торган иде. Ә хәзер аның өстендә шундый затлы кремплин костюм, аякларында биек үкчәле (унике сантиметр!) итальян туфлие... һәм болар барысы да аңа шундый килешеп тора — әйтерсең, кыз Фәләхләр авылының сыер савучысы Рәйханә кызы түгел, әйтерсең, ул дөньяның атаклы кино йолдызы иде.

Институтта укыган елларда Роза тышкы яктан гына түгел, рухи һәм фикри яктан да бик нык үзгәреп кайткан икән. Шундый ягымлыланган, шундый тәмле теллегә, итагатьлегә әйләнгән — шаклар катырлык иде. Фәләх белән бернинди тайчынусыз, үз итеп, якын итеп, гомер буе бергә йөргән кешесе шикелле итеп сөйләште ул. Элеккечә пыр тузып кит-

мәсен дип, Фәләх аның кулын коты очып кына тоткан иде. Кыз тузынмады гына түгел, хәтта кулын тартып та алмады, берни булмагандай, тыныч кына атлый бирде. Аннары, Розалар өенә кайтып җитәрәк, Фәләх аны култыклап карарга булды. Монысына да кыз һичнинди каршылык күрсәтмәде. Киресенчә, Фәләхкә сыенарак та төште түгелме икән әле. Их, аның култыгының кайнарлыклары! И, Фәләх шул минутларда кичергән рәхәтлекләр!.. Җаен бер туры китереп, шул ук вакытта бик нык каушап, тез буыннары калтырап, Фәләх аны бер очтан үбеп тә карарга булды. Инде беренче генә үбүе түгел иде аның кызларны. Ләкин бүтәннәрен үбү бер нәрсә, ә менә моны, Розаны үбү — бу инде уен түгел, әискиткеч зур да һәм җаваплы эш тә, чөнки егет язмышының туксан проценты нәкъ менә шул минутта хәл ителергә тиеш иде. Дөрес, чынлап торып, онытылып ук үбешү булмады ул. Фәләх Розаның иреннәренә иреннәрен тидереп кенә алды ул чакта. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул барыбер үбешү һәм Фәләх өчен дөньяда иң изге, иң кадерле һәм иң татлы минут иде. Аннан ары инде күпме сулар акты. Әмма әнә шул беренче үбешү хисе Фәләх күңелендә һаман саклана әле, һәм, мөгаен, гомере буена онытылмас, кайнар бер хатирә булып сакланыр. Шулай булмаса, аны Гасимә күптән оныттырган булыр иде. Менә ичмаса ул үпсә үбә инде! Үлгән кешеңне терелтер, билләһи. Ул үпкәндә күккә-гарешләргә ашкандай була Фәләх. Рәхәтлектән башлары әйләнеп, күз аллары томаланып китә... Ләкин, ни хикмәттер, теге чакта Розаны үбү хисе барыбер онытылмый. Һаман янара гына бара.

Алар икенче көнне дә, өченче көнне дә очраштылар. Очрашкан саен бер-беренә тагын да кадерлерәк, якынрак була бардылар. Ә Розаның каникулы алданрак бетеп, Фәләх аны үзләренең машинасы белән Казанга илтә барганда менә мондый сөйләшү булды:

— Мин сине шул тикле яратам, Роза, мөмкин булса, бер генә минутка да аерылмас идем, сине гел янымда гына йөртер идем! Ә бит безгә тагын кимендә ярты ел күрешмичә торырга туры килә...

— Мин үзем дә гел синең белән бергә йөрер идем дә, бу очракта берни эшләп булмый шул, Фәләхҗан. Ләкин, икенче яктан караганда, моның шулай булуы начар да түгел. Аерылышулар кыен булмаса, кавышулар да шатлыксыз булыр иде. Көн саен күрешеп торсак, кем белә бәлки без үпкәләшеп-ачуланышып та бетәр идек инде. Ә болай икебез дә очрашу шатлыгын көтеп яшәрбез.

— Анысы, ихтимал, шулайдыр да. Ләкин нигәдер күңелем курка шул, акыллым: мин юкта берәрсе башыңны әйләндереп, үзенә каратып куймагае?!

— Алай ансат кына әйләнә торган баш булса, үткән өч елда күптән әйләндергән булырлар иде аны. Әйткән идем ич сиңа, мин Рәйханә кызы, миңа аеруча нык булырга кирәк, йөрсәм дә тик бер кеше белән генә йөриячәкмен, дип. Әллә шуны оныткан дип уйлыйсыңмы?

— Алай дип үк әйтмим әйтүен. Акылым белән мин сиңа тулысынча ышанам, Роза. Ә менә күңелне бер нишләтеп булмый, хәвефләнә. Антлар эчеп, вәгъдәләр бирешеп тә кавыша алмыйча калган кешеләр азмыни бу дөньяда?

— Алай булгач, Фәләх, минем хакта хәвефләнмичә генә уку өчен миннән нәрсә, нинди гарантия таләп итәлә? Һәм гомумән буламы соң андый гарантия?

— Барын бар инде ул. Тик син аңа риза булмассың шул.

— Әгәр хәлемнән килә икән, уйлап карармын.

— Чынлапмы?

— Чынлап!

— Уфффф! Әйтергә йөрәк җитми: ачуланырсың, яңагыма сугарсың шикелле.

— Сугарлык сүз әйтсәң, әлбәттә! Ләкин андый ахмаклыкка барырсың дип уйламыйм. Я?

— Роза...

— Әү, дим бит инде кайчаннан. Әү!!!

— Әйдә өйләнешәбез, Роза бәгырем.

— Һиии, шушы гына идеме бөтен әйтәсе сүзең?

— Ә бу минем өчен дөньяда иң-иң мөһим, иң зур сүз, Роза! Шуны сиңа әйтер өчен күпме көтеп-азапланып йөрдем!

— Их, юләрем-юләрем! Инде әллә кайчан искергән, әби-бабайлар заманындагы төшенчәләр белән яшисең икән бит! Бүгенге егетләр алай еллар буе әзерләнеп азапланамы соң шушы гап-гади сүзләрне әйтер өчен. «Синдә нәрсәдер бар, кызый, ошыйсың син миңа. Ихтимал, мин сиңа өйләнермен дә әле»,— дип сүзне нәкъ әнә шул өйләнүдән башлый алар. Ә, беләсеңме, нигә алай артык кыылануларының сәбәбен? ·

— Нигә?

— Чөнки сез, егетләр, без кызларга караганда сан ягыннан азрак — унга тугыз гына. Димәк, ничек кенә булсаң да, ун кызның берсенә барыбер егет җитми калачак. Димәк, алар дефицит. Ә дефицит әйбергә сорау һәрвакыт зур була. Менә шуннан инде мәсьәләнең күңелсез нәтиҗәсе килеп чыга: егетләр дефицит булгач, кызларга артык сайланып, талымлап торырга урын калмый: «Әллә чыгып калыйм микән алучысы барында!» — дип бер дә юктан гына җырланмый инде ул. Егетләр моны яхшы белә, шуңа борын чөеп йөргән булалар. Гәрчә шактый ук тыңкыш борынны да...

— Мине дә шулар рәтенә кертергә җыенмыйсыңдыр бит?

— Алай уйласам, шушыңарчы көтәр идемме? Бик беләсең килсә, мәктәптә укыганда да шул сине яратканга, синнән калышмаска, сиңа ошарга теләгәнгә отличник булырга тырыштым бит мин! Хәзер дә, гәрчә миннән еракта булсаң да, гел минем янда, минем һәр адымымны күреп-белеп торасың шикелле тоела.

— Карале, син аны... — диде Фәләх бу сүзләргә исе китеп.— Мин үзем дә нәкъ шулай бит, кызый! Һәр эшемне сиңа ошарлык булсын дип башкарам! Тик аны менә шушылай, синеңчә ачык итеп әйтеп бирә генә алмый идем...

— Димәк, икебез дә бер төрле уйлыйбыз икән! — диде Роза һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрде.— Шулай булгач, без бер-беребезгә беркайчан да алдаша алмыйбыз, чөнки бер-беребезнең нәрсә уйлаганын ерактан да белеп торабыз икән бит?!.

— Алай уенга кайтарып калдырма әле, Роза. Мин сиңа кешенең үз гомерендә бер генә әйтелергә тиешле бик җитди, бик җаваплы сүзне әйттем бит. Һәм аңа шундый ук җитди җавап көтәм.

— Нәрсә дим икән инде сиңа? Әгәр инде сүземә генә ышанмыйсың, гарантияләп куярга телисең икән, ну что ж, мин риза синең тәкъдименә!

Тигез асфальт юлдан Шаһгали авылы тирәсенә җитеп килә торган машина кинәт сызгырттырып тормоз салды да, юл читенә чыгып туктап калды.

— Розам! Розакаем! Нинди генә рәхмәтләр әйтим сиңа моның өчен! — дип Фәләх кызны кысып кочаклап алды һәм, куанычыннан ниэшләргә дә белмичә, беркавым исе китеп аның күзләренә карап торды. Аннары озаклап, бу юлы инде үзенеке итеп, иреннәреннән үпте дә:

— Вәгъдә — иман, Роза! — диде. — Хәзер Казанга барабыз да бүген үк загска гариза бирәбез, яме!

— Ләкин ике шарт белән. Ризамы шуңа?

— Биш куллап, Роза!

— Алайса тыңла: беренчесе — гариза бирәбез, язылышырбыз да.

Лэкин син укуыңны тәмамлап кайтканчы кыз белән егет булып яшибез. Икенче шартым шул: безнең язылышканны шуңарчы синең әти-әниләрең дә, минем әни дә белергә тиеш түгел!

— И аллам! Нәрсә була соң инде бу? Язылышкач, нигә аны кешедән яшереп йөрергә кирәк ди?

— Сәбәбе бик гади аның, Фәләх:. әгәр шулай эшләмәсәк, минем турыда әллә ниләр уйлап ятачаксың син үзеңнең Мәскәвеңдә.

— Дөньяда мондый хәлнең булганы бармы икән соң?

— Бәлки, юктыр да. Лэкин болай гына ышанмыйсың, гарантия сорыйсың ич. Аннары сине генә түгел, үз-үземне гарантияләп тору да булыр ул. Югыйсә мин дә җанлы кеше бит. Берәр тасма телле егет очрап, башымны әйләндереп куйса...

— Һыы, акыллы сөйлисең бугай син, кызый!.. Алайса — хәзер туп-туры загска!

— Минем шартларга риза булсаң — әйе.

— Егет сүзе — бер булыр, бәгърем!..



## 6

Лэкин Фәләх биргән вәгъдәсендә тормады.

Шул көнне загска гариза калдырып киткәннән соң бер ай үтүгә Мәскәүдән кайтып язылышкач, ул Розаны татар ашлары йортына ресторанга алып керде. Аларның өйләнешүен үзләреннән башка беркем дә белмәскә тиеш дип сөйләшкән булсалар да, серне ике арада гына калдырып булмады. Өйләнешүчеләр загста язылышканда аларны бәлә торган ике кеше шаһит булырга тиеш икән. Фәләхнең Казанда сер саклардай танышлары юк иде. Шуңа күрә, шаһит итеп, Роза үз группасыннан ике иптәш кызын алып килде. Ресторанга да бергә керделәр. Телләренә салынып, безгә комачаулап, мәҗлес ахрынача утырмаслар микән дип шикләнгән иде ул. Лэкин шаһит кызлар бик акыллы һәм сизгер булып чыкты: Роза белән Фәләхкә бәхет теләп, шампанскидан авыз иттеләр һәм азрак ашаштырдылар да, лекциягә барасыбыз бар, сез безгә карамагыз, бүген гомергә бер килә торган кадерле һәм бәхетле көнегез, рәхәтләнеп утырыгыз, дип чыгып киттеләр.

Ресторанда кеше күп түгел, рәхәтләнеп сөйләшеп утырып була иде. Икесенең дә ашыгасы җирләре юк. Аннары, октябрь ае гына булса да, урамда суык, янгырлап тора, ә ресторанда әйбәт, җылы иде. Шулай озаклап утыруының тагын бер сәбәбе бар: Фәләхкә Розаны ничек булса да көйләргә кирәк иде: чөнки ул шул көнне Розаны формаль яктан гына түгел, гомумән үзенеке итеп китәргә тели, Мәскәүдән үк шул максатны күздә тотып кайткан иде. Вокзалдан туп-туры «Волга» кунакханәсенә кереп, номер алып куйган һәм Розаны шунда алып кайтырга планлаштырган иде. Лэкин Роза анда болай гына бармаячак...

Һәм ул, өч-дүрт сәгать утырса утырды ресторанда, лэкин үз дигәненә иреште.

Роза башта, юк-юк, Фәләх, кирәкми, авызыма да алганым юк минем андый каты нәрсәне, дип, «Наполеон» коньягын — (Фәләх Мәскәүдән алып кайткан күчтәнәчне) якын да китермичә, миңа монысы да җитеп ашкан, дип аз-маз шампански гына капкалап утырса да, Фәләх бик кыстагач, «күчтәнәчне» дә бер рюмка авыз итте. Һәм... моңарчы тын гына, моңсурак кына булып, Фәләх сөйләгәнне тыңлап кына утырган Роза шактый үзгәрде: кыюланды, юк кына сүздән дә кызык табып, кычкырып көлә башлады. Матур гына булып, бит алмалары да кызарып китте...

Аннары алар гостиницага бергә кайттылар. Ә анда Фәләх иртән үк Мәскәүдән алып кайткан конфет-шоколадларны, бүтән затлы ризыкларны әзерләп куеп киткән иде. Кайтып кереп, өстәл өстенә капланган газетаны ачып җибәргәч, андагы лимон-мандариннарны, хөрмә-виноградларны, кавын һәм карбызны күреп, Розаның күзләре шар булды. Анда да алар байтак сыйландылар һәм... ул көнне гостиницада ничек кунып калганын Роза сизмәде дә, бичара...

— Их, Фәләх, Фәләх! Болай дип сөйләшкән идекмени без? Мин бит сиңа ышанган идем. Тормышыбызны шушылай итеп алдашудан башлап җибәрдекмени инде?.. Хәерле булып бетәр микән моның ахыры,— дип үкси-үкси елады иртән Роза. Аннары әйтте: — Менә нәрсә, егет, безнең арада берни дә булмаган дип исәплә, яме! Һәм безнең теге көнне Казанга килешли юлда сөйләшкән сүзебез тулысынча көчендә кала — син укуыңны бетереп кайтканчы, безнең өйләнешкәнне эти-әниләр белми һәм без синең белән егет белән кыз шикелле йөрибез!

Роза сүзендә торды: Фәләх институтын тәмамлап кайтканчы алар, чыннан да кыз белән егет шикелле генә йөрделәр.

Әнә шулай, әле чынлап торып яши башлаганчы ук, шундый зур уңайсызлык килеп чыккан иде алар арасында. Яхшылабрак уйлаганда, кичәге һәлакәтнең башы да Фәләхнең әнә шул чактагы вәгъдәсезлегеннән башланды түгел микән әле?..

## 7

Әллә Мәскәүдә укый башлаган елның беренче аенда, Фәләх үз группадашларын казылык белән шаккатырган кичәдән башланды микән?

Шуннанмы-юкмы, ләкин ул кичә Фәләх тормышында бик зур үзгәрешкә сәбәп булган иде. Бөтен хикмәт әлеге гап-гади казылыктан башланды.

Казылыкны кече-кечкенәдән яратты Фәләх. Башка яктан әллә ни мактарлыгы булмаса да, аш-су пешерү һәм бигрәк тә казылык кою мәсьәләсендә аның әнисе шикелле оста үз авылларында гына түгел, бөтен Татарстанда юктыр! Фәләхләр колхозы — начар хуҗалыклардан түгел. Игенчелек ягыннан булсын, терлекчелек өлкәсендә булсын, дәүләт заданиесен, алган йөкләмәсен ел саен арттырып үтәп килә. Унбиш урынлы кунак йортлары бар. (Урак өстендә һәм бәрәңге алган чакта шәһәрдән шефлар килгәч тә анда хәтта утызар карават куялар.) Шуның янында гына — менә дигән ашханәләре. Анда ике пешекче даими эшләп тора. Ләкин колхозга район һәм республика масштабындагы зуррак кунаклар килгәндә аларны кунакханәгә түгел, Фәләхләргә фатир төшерәләр. Чөнки авылда токмачны иң вак тураучы, тавыкны иң әйбәт итеп тутыра белүче кеше — Фәләхнең әнисе Нәгыймә. Ә казылык кою мәсьәләсендә әйтеп тә торасы юк инде! Бервакыт хәтта Мәскәүнең үзеннән килгән министрга хәтле Фәләх әнисе ат итеннән койган казылыкны шундый яраткан, шундый ошаткан, кайткач бүтән министрларга да ашатам әле мин моны дип, зур бер коем казылыкны алып та киткән иде. Ә бит ул министр дөньяның кайсы гына илендә булмаган да, нинди генә тәмле ризыклар ашап карамагандыр дисең! Шулай да Фәләхнең әнисе койган казылыкка һушы киткән әнә...

Фәләх институтта укый башлагач, группадашлары арасында аның дәрәҗәсе күтәрелеп китүгә дә әлеге шул казылык сәбәп булды. Югыйсә ул алай әллә ни кыю малай түгел. Әтисе шикеллерәк. Таныш булмаган кешеләр янында аеруча каушап-югалып кала: әйтер сүз, торыр җир таба алмый интегә: ничек итсә дә бүтәннәргә ошамас, ялгыш булыр да соңыннан үзеннән көлеп йөрерләр шикелле тоела. Коллективка бер

няләшеп киткәч, дөрес, кыюлана ул кыюлануын. Руслар әйтмешли, кампаниянең «жанына» әйләнә. Ләкин монысы аның соңыннан — кампаниядәге кешеләр Фәләхнең, Фәләх аларның кем икәнен белгәннән соң була...

Ә менә институтта укуының беренче көннәреннән үк, әлеге шул казылык аркасында группадашлары арасында бик тә тиз үз кеше, якын кеше булып китте Фәләх.

Башта ике ел армиядә хезмәт итеп, аннары өч ел рәттән сынау биреп карап та конкурстан үтә алмыйча йөргәннән соң, ниһаять, максатына ирешкән Мәскәү егете — группа старостасы тәкъдиме белән беренче уку көнен билгеләп үтәргә булганнар иде. Борын башыннан өчәр сум салып, шау-шусыз гына, алдан әзерләнеп тормыйча гына бер мәҗлес шикелле нәрсә оештырдылар. Үзе өчен артык мәшәкать булырын белеп торса да, группадашлары сездә җыйналыйк дигәч, каршы килергә арусынмады Фәләх. Аннары алар бүлмәсе коридорның аргы башында, тынычрак җирдә һәм башкаларныкыннан зуррак та иде. Закускага да коры-сары гына, эчемлеген дә сухули-мухули гына алып, җиңелчә генә утырышып алырга дип башласалар да, мәҗлес зурга китте. Бер башлагач «коры» шәраб белән генә калынмады. Группаларындагы украин егете, минем Киевтан ук алып килгән әйберем бар иде, дип шешәсенә кузаклы борыч салып ясалган горилка алып керде. Аның горилкасы, чыннан да «утлы» булып чыкты: студентларның болай да ташып торган хисләрен бик хәтәр кайнарлатып җибәрде. Җыр һәм бию-ләр китте. Аннары, мәҗлес тәмам кызып җиткәч, үзбәк егетенең дә туган көненә дип саклап торган бер «Үзбәкстан»ы өстәлгә килеп утырды. Ул нәрсә студентларның күңелен тагын да ныграк җилкендерә башлады. Ә өстәлдәге шешәләр бушап калып, инде таралышалар дип кенә торганда, ояла-ояла гына ишек шакып, кат-кат гафу үтенеп:

— Тыңлап яттым-яттым да сезне, һич тә түзәр чамам калмады: шундый матур итеп күңел ачасыз, дуслар! Рөхсәт итсәгез, ун гына минут яныгызда утырып чыгар идем? — дип, бер шешә коньяк тоткан кара мыеклы Кавказ егете килеп керде.

Болай да ташлары тәмам кызып, кем туры килсә шуның белән бии башлаган группа кызлары, теге чибәр егет килеп кергәч, башта һушлары китеп, телсез тордылар. Аннары «браво!», «браво!» дип кычкырышып, дәррәү кубып, Кара мыекны табынга кыстарга тотындылар. Алар өчен бу минутта группа егетләре бөтенләй юк, бу минутта алар тик Кара мыек белән генә мәшгуль, тик шул егет кенә алар өчен алла да, мулла да иде диярсең.

— Ничек бу кадәр вакытлы килеп кердегез сез!

— Безнең кавалерлар тәмам йоклый башлаганнар иде!

— Ни эчәргә әйберләре юк, ни танцыга чакырмыйлар! — диешеп тегенә куштанлана-куштанлана шешәсенең бөкесен ачтылар. Кайсының кулына нәрсә эләксә — шуңа коньяк салынды. Кара мыек белән чәкештереп, аның исәнлеге өчен тост күтәрделәр.

Фәләх шунда бер нәрсәгә игътибар итте: моңарчы кәнфитләнеп, рюмкаларына ирен очларын гына тидереп утырган кызлар да бу юлы берничди кыстатусыз эчеп бетереп куйдылар. Тик шуннан соң гына исләренә килеп, коньяк ачысын басар өчен берәр нәрсә капмакчы булып, өстәл янына бармакчылар иде, өстәл өсте шып-шыр икәнен күреп, аптырап калдылар. Аннары барысы да берьюлы диярлек кычкырып көлеп җибәрде. Бу көлүнең сәбәбен аңламыйча, миннән көләләр ахрысы дип шикләнеп, Кара мыек башта каушап калды. Ә эшнең асылын аңлап алгач исә, секунд эчендә яктырып китеп:

— Один минута! — диде дә ашыгып бүлмәдән чыгып китте.

Аның «один минута»сы унбишкә сузылды һәм ул, сөмсере бик коелып, буш кул белән әйләнеп керде.

— Хулиганнар! — диде ул кемнәрнедер ачуланып. — Тапканнар үен. Өйдән алып килгән киптергән сарык итем бар иде. Кичә үзем сыйлаганда ашамадылар. Ә бүген мин юкта бүлмәдәш малайлар бөтенесен ялмап бетергән!

Ә бит, дөресен генә әйткәндә, кызларның өмете зурдан иде ул егеткә. Тиктомалга шешәсе белән коньяк тотып кергән кешенең берәр төрле ару гына закускасы да бардыр әле дип өметләнгән иде алар. Кара мыек буш кул белән әйләнеп кергәч, кызларның кайсы, бөтенләй һушы киткән атлы булып, лып итеп урындыкка утырды, ә кайсылары:

— Неужели, закускага бер телем кара икмәк тә таба алмаслык ук дәрәҗәдә булдыксыз инде безнең егетләр!

— Тайга уртасында түгел бит без! Уңган егетләр анда да безнең ише кызларга берәр нәрсә табып бирерләр иде! — дип шаулаша башладылар.

Сәгать инде уникe тулып килә иде. Ә иртәгесен бәйрәм түгел, иртәнге тугызга лекциягә барасы иде. Фәләх шул турыда әйтеп тә карагаң иде үзләренә. Ләкин аның сүзен ишетергә дә теләмәделәр.

— Юк әле, юк! Нинди кайту әле ул!

— Без бит инде балалар түгел, самостоятельный шәхесләр!

— Давай, син, Фәләх, хуҗа кеше, җир астыннан булса да закускага берәр нәрсә тап та утырыйк әле бер рәхәтләнеп! — дип ду куптылар.

Менә шул чакта Фәләхнең әнисе биреп җибәргән теге ат казылыгы ярап куйды да инде!

Фәләхнең әтисе дә, әнисе дә алдан күреп эш итә торган бик тә хәстәрле кешеләр. Бигрәк тә әнисе шундый. Тормышта нинди генә көтелмәгән хәл килеп чыкмасын, беркайчан да югалып калмый, шундук берәр җаен табып ала. Чөнки ул бүгенге көн белән генә, бүгенгә булса — шул житкән дип кенә яшәми. Артсын, үрчесен дип, берне ике итәргә тырыша. Фәләхләрнең кара-каршы салынган ике өйләре бар икән — алар әниләренең тырышлыгы нәтиҗәсе. Әтисенең өченче группа Ватан сугышы инвалиды кенәгәсен тотып, башта райбашкармага, аннары кирпеч заводына, урманчылыкка йөреп, төзү материалларын ул юллап кайтартты. Тирә-як авыллардагы балта осталарын һәм ташчыларны чакыртып, өйләрне ул төзетте.

Фәләхнең укырга Мәскәүгә китүен дә ул хуплаган иде. Югыйсә әтисе Фәләхнең анда барып укырга керерenә бик үк ышанмады һәм гомумән аны алай еракка җибәрергә ниятләми иде. Затлы ризыкны уптым илаһи гына ашап бетермичә, саклап тотарга да әнисе өйрәтте аны. Фәләхнең Мәскәүдә яши башлаганына инде айдан артты. Аның урынында бүтән берәү булган булса, комсызланып, теге казылыкны инде күптән ашап бетергән булыр иде. Мәскәү дигәч тә, Мәскәүдә күгәрчен сөте дә табарга була дигәч тә, анда да бөтенесен әзерләп, сине көтеп кенә тормыйлар, абзыкаем! Кибетләрдә чират. Чөнки килеп-китеп йөрүчеләр күп. Һәм һәркайсына нидер кирәк. Бәлки аларның үз авылларындагы һәм шәһәрләрендәге кибетләрдә дә кирәкле әйберләр тулып ятадыр. Ләкин, юк, аларга нәкъ менә Мәскәү кибетеннән алып кайтырга булсын! Шуңа алар барысы да ашыга, абына-сөртенә бер кибеттән икенчесенә чаба. Менә шуннан — урам тулы халык. Мәскәүдә тагын бер нәрсәгә игътибар итте Фәләх: метрода китап укыйлар, троллейбуста укыйлар, ә менә кибетләрдә яртышар сәгать чират торучылар арасында китап укып торучылар бөтенләй диярлек күренми. Чөнки аларның берсе дә Мәскәүнекеләр түгел, Мәскәүгә я командировкага, я турист булып, яки туган-тумачаларына кунакка килгән, я узып барышлый туктаган кешеләр икән. Ә мәскәүлеләр үзләре, дәрәҗә төшереп, чират тормый. Аласы әйберләрен я иртән, килгән кешеләр әле кибетләргә чыгып өлгергәнче, я кичен, килгән кешеләр инде арып-талып кунакханәләренә, фатирларына кайтып киткәч алалар. Акыллыраклары

исә кибеткә чыгып та тормый, кирәк әйберләрен телефоннан заказ биреп, өйләренә генә китертәләр.

Башкалада инде айдан артык яшәп Фәләхкә дә азмы чабарга туры килде? Студент булганлыгы тәгаенләнгәч, яңа өс-баш алу артыннан байтак йөрде. Чөнки киеп килгән киемнәре аның авыл малае икәнен белдереп әллә кайдан кычкырып тора, ә Фәләхнең авыл мокыты булып күренәсе килми. Теләгән гамәлгә ашырырга мөмкинлеге дә бар: әнисе аңа, студин булсаң, теләгән киемнәреңне алырсың дип, мең тәңкә акча биреп җибәрде...

Кыскасы, кая монда нинди дер колбасаларга, сырларга чират торырга вакыт калсын ди? Әнә шундый чакларда Фәләхкә чемоданындагы казылык бик ярап куясы иде, әлбәттә. Ләкин ул әнисенең «ел тотсаң да бозыла торган әйбер түгел, улым, иң кирәкле кешеләрең килгән чакларда куярга саклап кына тот» дигән сүзләре исенә төшеп тыелып кала килде. Әнисенең сүзен тыңлап бик яхшы иткән ул! Чөнки менә хәзер, аның белән бергә биш ел укыйсы егерме дүрт группадашы алдында, шуның өстенә тегеләр бер кабым закускага тилмереп торганда, әлеге казылыкны чыгарсаң да була иде!

Шуңа күрә ул бик зур ачыш ясаган һәм шуны игълан итәргә җыенган бер тантаналы кыяфәт белән, әле һаман Кара мыек тирәсендә кайнашкан кызларны аралап урталарына килеп керде дә:

— Игътибар, иптәшләр! Бер генә минутка игътибар сорыйм? — диде.

Бик нык шаулашкан булсалар да, бүлмә хуҗасы сүз сорагач, тынып калдылар:

— Тыңлыйбыз сезне, галиҗанәп Фәләх!

— Мин сезне хәзер хәтта Парижның иң затлы рестораннарында да булмаган бер нәрсә белән сыйлаячакмын. Ләкин башта сез минем бер шартымны үтәргә тиешсез!

— Әйт кенә, безнең кадерле Фәләхебез, синең өчен без барсына да әзер! — дип чыркылдашты кызлар.

— Ике генә минутка бүлмәдән чыгып торуыгызны үтенәм! — диде ул һәм кайберләренең, бу безне алдап чыгарып җибәрергә җыенмый микән дип, шиккә калуын күреп: — Моны ни кадәр оешканрак төстә эшләсәгез, мин вәгъдәмне шул кадәр тизрәк үтәячәкмен! — дип өстәде.

Группадашлары өч кенә түгел, биш минут ук торып кергәндә ул инде, йон оекбашлар, бияләйләр һәм кием итек астына, чемодан төбенә үк салган казылыкны алып юка гына итеп турап та куйган иде. Иптәшләре аны сырып алып:

— Ну и Фалях!

— Ты, оказывается, большой жук: имея такую закуску до сих пор молчал!

— А что это такое? Импортная колбаса что-ли? — диешеп сырпаланыша башладылар. Ләкин берсе дә Фәләхтән рөхсәтсез казылыкка үрелмәде.

Ә Фәләх юри ашыкмады. Чөнки ул белә: берьюлы берничә кешенең бер кешегә менә шушылай сокланып һәм зур өмет белән каравы — көн дә була торган хәл түгел. Әнә шул чакта татыды ул материал өстенлекнең асылын. Аңа шул өстенлеген сизеп тору рәхәт иде. Бу рәхәтне мөмкин кадәр озаккарак сузасы килеп, ул казылыкның бары тик татарларга һәм башкортларга гына хас ризык икәнлеген, аның тарихын һәм кою ысулын да сөйләп бирмәкче иде. Ләкин группадашлары аны көтеп тормадылар, эш озаккарак китә башлагач, бердәм кыюланып, күңелне кытыклап, майлары тибеп торган казылыкка ябырылдылар. Күз ачып йомган арада тәлинкә бушап та калды.

Фәләх тантаналы речьләр тотмаса да, аның тарихын сөйләмәсә дә, ул көнне казылыкның дәрәҗәсе кимемәде генә түгел, киресенчә, артып төште. Рюмкаларына салынган ак аракыны (анысы да Фәләхнеке, ани-

сенең киңәшен тотып, запаска алып куйган әйберсе иде) «төчкертеп» куеп, аны казылык белән өстән бастырганнан соң, группадашларының кәефләре күзгә күренеп күтәрелеп китте дә алар үзләре үк:

— Каян алдың бу искиткеч шәп деликатесны?

— Нидән һәм ничек ясыйлар аны?

— Нәкъ асылташ шикелле үтәли күренмәле иде бит! — диешеп, берсен берсе бүлешә-бүлешә казылыкны мактарга, аның тарихы белән кызыксынырга тотындылар.

Фәләх аларга казылык хакында үзе белгәннәрен барысын да сөйләп бирде. Иптәшләре аһ итеп, «Ну, акыллы да булган сезнең бабаларыгыз! Ат итен үн ел тотсаң да бозылмый торган һәм шулай искиткеч тәмле итеп әзерли белергә кирәк бит!» — дип шаккатып тордылар...

Моңарчы группада берни белән дә аерылып тормаган, тик русчаны чамалырак белүе һәм авылчалыгы белән генә күзгә ташланган Фәләх әнә шул бер кичтә группаның йөзек кашына әйләнде дә куйды. Шул кичтән группа кызлары аны «Мухамметов»тан «Фаляхчик» иттеләр. Ә ул кызларның берсе, ап-ак йөзле, зәп-зәңгәр күзле, картлар әйтмешли, тал чыбыгыдай зифа буйлы Мәскәү кызы Наилә, Фәләхне шундый итеп бөтереп үз орбитасына алып кереп китте, Фәләх ни булганын үзе дә абайламыйча калды.

## 8

Наилә! Наилә! Кайларда һәм ниләр эшләп йөри икән хәзер ул? Күрәсе иде үзен бер генә тапкыр? Күпме йөрәк җылысын бирде бит ул Фәләхкә. Ә үзе бер нәрсә дә таләп итмәде, бернинди шарт та куймады. Күпме хис, күпме наз иде ул шайтаный җанда...

Фәләхнең аның белән танышлыгы да әлеге шул беренче уку көне уңае белән оештырылган кичтән башланды.

...Башкалар ул кичне салган берен диярлек эчеп бетерен барды. Тик Фәләх кенә җаваплы кеше — бүлмә хуҗасы буларак, һәм гомумән эчүгә шаккатмаганлыктан, беренче тосттан соң азрак шампански эчеп куйды да мәҗлес таралганчы тамчы да капмады. Ә кайбер егетләрнең кичә ахырына күзләре шактый калайланган иде. Ләкин бернинди тавыш-фәлән булмады. Мәскәүлеләрнең кайберләре, безгә метрога утырасы түгел дип, кайтып китте, кайберләре, без метросыз кайта алмыйбыз дип, тулай торакта яшәүчеләрнең бүлмәләрендә кунарга калды. Тик бер Наилә генә: «Миңа да кайтырга ерак. Ләкин мин куна алмыйм. Миңа обязательно кайтырга кирәк!» — дип мәсьәләне бик кискен итеп куйды.

Китсә китсен, берәү дә тотмый иде аны. Ләкин ул үзе генә китәргә теләмәде, озатып куюны үтенде. Ахыр чиктә, анысы да әллә ни зур проблема түгел: хатын-кызның шушы Наилә кебек сөлек шикеллесен озата барырга егетләрнең теләсә кайсы атлыгып тора иде. Ләкин Наилә аларны якын китермәде:

— Мине Фәләх һәм бары тик ул гына озата. Бүтән беркем белән дә китмим! — дип кырт кисте.

Озатып куймаслык түгел иде Наилә. Ап-ак чиста йөзле, нәфис озын муенлы, тар инбашлы, декольтесыннан ташып чыгарга торган мул һәм тыгыз күкрәкле, тарттырып буып куйгандай күренә торган нечкә билле, артык юан да, артык нечкә дә булмаган искиткеч матур аяклы һәм елмаймаганда да елмайган шикелле булып, күңелне үзенә җәлеп итеп торган гаҗәеп сөйкемле бер зат! Мәҗлес барышында Фәләх бик яхшы күреп торды: группа егетләренең берсе дә битараф түгел иде Наиләгә. Танцы вакытында барысы да аның белән биергә тырышты. Тик Наилә-

нең аларга әллә ни исе китмәде, чакыручыларның барысы белән дә түгел, үзе теләгәннәре белән генә, анда да артык онытылып китмичә, иренебрәк кенә биеде. Кыскасы, үз дәрәҗәсен үзе белә иде Наилә. Йөреш-торышы белән дә, киемнәренең затлылыгы белән дә бүтәннәр арасында әллә кайдан аерылып тора. Әгәр ул үзе теләсә, аны группа егетләре барысы да бергәләшеп озатып куярга да риза иделәр. Ләкин ул аларны түгел, Фәләх озатып куюны теләде.

Әлбәттә, Фәләх үзе дә ул хур кызын озатып куярга каршы түгел. Ләкин ул әле Мәскәүне юньләп белми, шуңа күрә кайтышлый адашып, әллә нинди көтелмәгән бәлаләргә юлыгудан шикләнә иде. Әмма куркуын Наиләгә сиздерәсе дә килми иде үзенең. Шулай да:

— Вакыт та соң инде, Наилә. Бик нык арылды да. Иртәгә иртүк лекциягә дә барасы бар. Бәлки үзең генә дә кайта алырсың, ә? — дип, аңлаган кешегә аңларлык итеп, әйтеп тә караган иде ул, урамга чыккач.

Ләкин Наилә аның ай-ваена бөтенләй игътибар итмичә:

— Неужели син шундый ялкау һәм куркак инде, Фәләхчик? Неужели аз гына да рыцарьлык хисе юк синдә?— дигәч, шуның өстенә тагын Фәләхкә ялварулы итеп карап та торгач, каршы килергә урын калмады...

Соңыннан аңлады Фәләх: Наилә аңа үзе генә кайтырга курыкканнан түгел, бәлки аны ошатканга, аның белән бергә буласы килгәнгә озаттырган икән.

Фәләх уйлаганга караганда күпкә акыллЫ булып чыкты ул кызый: урамга чыгу белән иң элек такси тотты. Һәм моны ул шундый тиз эшләде, Фәләх хәтта сизмичә дә калды. Алар машинага кереп утырып, кузгалып китеп баргач кына исенә килде ул. «Такси булгач мин барып йөрмим инде, үзең дә кайтып житәрсең»,— дип аны шунда озатып кына калырга башына килмәгәнгә бик нык үкенеп куйды. Ләкин хәзер берни дә эшләр хәл юк, машина туктатып вакдана башласа, Наиләнең, «акчасын кызганды инде бу хәчтерүш, шуңа төшеп калды» дип уйлавы мөмкин иде. Кыскасы, калган көтү — калган, эшләр болайга киткәч сер бирергә ярамый иде хәзер. Китсә — ун сум акчасы китәр. Аның каравы бүтән вакытта акыллырак булыр. Бер тапкыр алданудан гына дөнья харап булмас, шәт!..

Фәләх шуларны уйлап барганда:

— Менә, кайтып та життек! — диде Наилә. Шоферга түбәнге ике каты гранит плитәләр белән тышланган зур гына бер йортның ишек алдына керергә кушты. Фәләх аны-моны абайлап өлгергәнче таксистка биш сумлык акча да сузды. Таксист әле таксометрын сүндермәгән, анда нибары ике сум житмеш өч тиен генә күрсәтә иде. Шофер сдача бирергә җыена башлаган иде, Наилә аның иңбашына кулын куйды да:

— Кирәкми, рәхмәт! — диде.

«Күрәсең, минем кайтыр юл расхутын да үз өстенә алмакчы була бу кызый»,— дип уйлаган иде Фәләх. Ләкин ул көткәнчә булмады. Наилә машинадан чыкты да Фәләхкә гаҗәпләнеп карап:

— Ә син ни көтәсең, кавалер? Ник чыкмыйсың? — диде.

Фәләх аннан бу сүзне түгел, бәлки, ярар, Фәләхчик, сау булып тор, рәхмәт озатып куюың өчен, дип әйтер дип көткән иде. Ә Наилә әлеге «ник чыкмыйсың»ны шундый итеп әйтте ки, аңа каршы килү мөмкин түгел, хәтта ул турыда уйларга да ярамый иде.

Подъездга кереп, икенче каттагы дүртенче квартира ишеге төбенә килеп житкәч, Наилә иңенә элгән сумкасын идәнгә куйды. Фәләхне шундый иңле, шундый йомшак итеп кочып алды да, аяк очларына басып — ул Фәләхкә караганда тәбәнәгрәк иде — онытылып, озак итеп үбеп алды.

еп алды.

Наилә: «Ә хәзер керәбез һәм син бездә кунасың, ярыймы!» — дигәндә Фәләх өйгә керергә генә түгел, җәһәннәмнең аргы ягына барырга да әзер иде...

Шулай да тегеләрнең фатирына кергәч, аңына килеп:

— Юк, Наилә, мин кайтыйм әле. Малайлар да борчылып көтеп торыр. Әти-әниеңнән дә ару түгел,— дип караган иде каравын. Әммә Наилә ике сөйләшеп торырга урын калдырмады:

— Ташла әле шул үзеңнең авыл мокытлыгыңны! Мин күн дим икән, димәк, нишләгәнемне белеп әйтәм инде! — диде ул һәм Фәләхнең өстендәге пинжәген үзе салдырып, галстугын үзе чишә башлады. Тагын бер тапкыр: «Курыкма, пожалуйста, өйдә бер кем дә юк безнең. Һәм булмаячак та!» — дип искәртте.

Наиләнең сүзенә бик үк ышанып бетмичә, Фәләх аларның фатирын үзе тикшереп чыкты. Әйе, кызый хаклы: аларның һәркайсы болын хәтле дүрт бүлмәле фатирларында хәтта күзләрен-колакларын да йон баскан бияләй кадәр генә ак эттән башка җан иясе юк иде.

— Син кая алып кайттың мине, Наилә? — диде Фәләх фатирдагы җиһазларның һәм зиннәтле әйберләрнең күплегенә шаккатып. Андагы мебельне, әллә күпме хрустальны, алтынланган сервизларны, картиналарны күргәне генә түгел, ишеткәне дә юк иде аның.— Әллә берәр антиквар әйберләр музеена алып кердеңме син мине?

Фәләх шулай шаккатып торган арада Наилә, инде мәҗлестән кайткан киемнәрен салып, искиткеч бизәкләр төшерелгән һәм ялт-йолт итеп, күз яуларын алып торган атлас халат киеп, кухняда кайнашып йөри иде. Борынгы көмеш подноска уймак хәтле генә ике алтын рюмка, ике алтын чәй кашыгы, алтын йөгерткән ике кофе чынаягы, ярты шешә ниндидер чит ил коньягы, әле яңа гына ачылган бер банка кара уылдык, кәгазь калынлыгы гына итеп киселгән дүрт-биш телем икмәк һәм ак майга кадәр әзерләп куйган. Тик кофе кайнап чыкканны гына көтеп тора иде.

— Әйе, музейга алып кердем! — диде Наилә һәм рәхәтләнеп, кычкырып бер көлеп алды.— Ә үзем шушы музейның төнге каравылчысы булып эшлим.

Фәләх монысына да ышанырга әзер иде. Нигә, азмыни Мәскәүдә төрле тарихи шәхесләрнең музей-йортлары? Ләкин Наилә кинәт кенә житдиләнеп китте дә:

— Әй, юләрем минем, юләрем! Аптырама инде ул кадәр! Бернинди дә музей түгел, үзебезнең фатирыбыз! — диде.

— Әти-әниеңнәр кем соң синең, кызый?

Наилә үзе «син» дип сөйләшкәч, Фәләх инде «син»гә күчкән иде. Наилә үз әтисенең исемен әйтүгә исә Фәләхнең чәчләре үрә торды: бөтен илгә билгеле атаклы галим икән ләбаса аның әтисе!

Фәләх башта, әллә яхшы чакта чыгып кына китимме, юньлегә алып бармас шундый кешенең кызы белән бәйләнешеп йөрү, дип тә уйлаган иде. Ләкин, Наиләнең бигрәк куркак икән бу егет, бигрәк томана икән, дип уйлавыннан шикләнеп, калырга тәвәккәлләде.

— Алайса аңлашылды, Наилә,— диде ул, артык исе китмәгән булып.— Молодец икән атаң: эшли генә түгел, заманча итеп яши дә белә икән!

— Әти түгел, әни шулай йорт җанлы безнең,— диде Наилә.— Ә әти ул бөтен җаны-тәне белән үзенең фәненә чумган кеше. Тормыш кирәк-яраклары турында уйлап та карамавын әйткән дә юк инде, хәтта житәкләп алып килеп утыртмасаң, ашарга кирәклеген дә оныта ул.

Кофе кайнап чыгып плитәгә түгелә башлады да Наилә «ой» дип сискәнеп, кофейникны подноска алып куйды:

— Әйдә, ишекләрне ачып син алдан бар. Минем бүлмәгә керик, анда уютныйрак булыр,— дип үз бүлмәсенә алып керде.

Шәп иде аның бүлмәсе. Керүгә сул яктагы стенага күз явын алырлык матур чәчәкле келәм эленгән. Ул шундый зур, хәтта Наиләнең софасы аша төшеп, ярты идәнне диярлек каплап тора. Өч өлгеле зур тәрәзә буенда аяклары буынтыкландырып, ишекләре бизәкләп, өсте яшел бәрхет материя белән каплатылып эшләнгән борынгы язу өстәле. Аның өстендә әйбәт-әйбәт тышлы күп кенә китаплар ята. Уң як стена буенда рус һәм дөнья классикларының күп томлы китаплары белән шыплап тутырылган зур китап шкафы. Шкаф пыяласы белән китаплар арасындагы бушлыкка Наиләнең төрле елларда төшкән фоторәсемнәре куелган. Стенаның шкафтан калган өлешенә атаклы киноартистларның, язучыларның һәм җырчыларның журналлардан кисеп алынган рәсемнәре, төрле афишалар эленгән. Наиләнең софасы буенда гына — журнал өстәле. Анда япон магнитофоны һәм бик күп кассеталар ята иде.

Фәләх шуларга карап, адәм баласы мена нинди ожмахи шартларда да яши икән бит, дип хәйран булып торган арада Наилә, кулындагы подносны аңа тоттырып, тиз генә журнал өстәлен бушатты. Аннары подносны өстәлгә куйды да:

— Ник аптырап калдың, егетем? Бүлмәдәге тәртипсезлеккәме? — диде.

— Киресенчә, бүлмәнең гаҗәеп зур зәвык белән җиһазландырылган булуына исем китеп торам! — диде Фәләх.

Ләкин ул моны чын күңеленнән түгел, Наиләнең кәефен кырмас өчен генә әйтте. Чөнки Наиләнең хәтта урыны җыелмаган иде: алсу атлас җирлеккә ниндидер чәчәкле үсемлек рәсемнәре төшерелгән йомшак һәм җиңел юрган софаның бер читендә аунап ята, ә кардай ап-ак урын җәймәсе сыдырылып калган... Фәләх тиз арада: «Бигрәк тә ялкау икән бу кызый, ник шундый кешеләр бәхетле була икән?» дип күңеленнән Наиләне шелтәләп алырга һәм, «безнең авыл җирендә булса, өч көн дә яши алмас иде бу ялкаулыгы белән» дип нәтиҗә ясап куярга да өлгергән иде.

— Әйдә, алай мактаган булма, яме! Күзеңнән күреп торам бит, бигрәк җубалгы икән бу кызый, дип уйлаганыңны. Бүлмәдә тәртип юклыгын үзем дә беләм. Иртән озаграк йоклаган идем дә җыештырырга өлгермәдем. Кил, утыр. Азрак ашап алыйк. Мин бик ачыктым!

— Ә син, кызый, әти-әниеңнәр кайда икәнен әйтмәдең бит әле? — диде Фәләх, өстәл янына килеп утыргач. Тегеләрнең кайту-кайтмавын тәгаенлисе килде аның. Чөнки менә-менә кайтып керерләр дә үзен пыр туздырып куып чыгарырлар, аның аркасында Наиләгә дә эләгер дип курка иде.

— Котың чыкмасын инде, зинһар! — диде Наилә, Фәләхнең артык төпченүен ошатмыйча.— Шәһәрдә түгел алар. Дачада. Һәм бүген кайтмаячаклар. Төн уртасында түгел, көндезләрен дә сирәк кайта алар җәен. Әгәр инде ниндидер бер могҗиза булып, кайтып керсәләр дә берни булмаячак. Бездә алай бүлмәләргә кереп, кемгә кем килгәнен тикшереп йөрү гадәте юк!

Тик шуннан соң гына, ниһаять, эченә җан кереп, кофе чынаягына үрелде Фәләх.

Ул арада Наилә теге юка гына итеп киселгән икмәк телемнәренә башта май, аннары калын итеп уылдык ягып бутерброд ясаган иде. Уймак хәтле генә алтын рюмкаларга салынган коньякны эчеп куйгач, икесе дә берьюлы шуңа үрелделәр. Бер-беренә карашып, сүзсез генә, күз карашлары белән генә үзара сокланышып бераз утыргач, Наилә кинәт өстәлнең каршы ягыннан Фәләх янына күчеп утырды. Күзләрен майландырып, йомшак һәм кайнар куллары белән Фәләхнең иңенә сарылып, битләрен, колакларын үбәргә тотынды. Ә үзе сизелер-сизелмәс кенә, әмма бәгырьләрне айкый торган итеп, «Какой ты хороший!» дип пышылдый иде.

## 9

Менә хәзер, больница койкасында уйланып ятканда, Фәләх үзе өчен бер ачыш ясады: Гасимә белән шул Наилә арасында ниндидер бик нык охшашлык бар икән ләбаса! Дөрес, алай ачыктан-ачык күренеп тора торган охшашлык түгел ул. Аларның тормышларындагы аерма — җир белән күк арасы. Наилә — Мәскәү кызы, атаклы кеше баласы. Ә монысы — гап-гади бер авыл семьясында, гап-гади татар авылында туып үскән җиде баланың уртанчысы. Берсе ак ефәк биләүләргә генә биләп, әти-әниеннән тыш, махсус нянька да карап-саклап үстергән һәм семьяда бердәнбер бала булса, икенчесе һичнинди кадер-сансыз, ни житте шуны киеп, ни булса шуны ашап, тире-йон җыючы Шадра Шәрәф гаиләсендә кечкенәдән үк су ташып, идән юып, бәләкәй сеңелләрен карап һәм еш кына салып кайтып тавыш чыгара торган этисенең эре, типкесе астында үскән кеше.

Тышкы кыяфәтләрендә дә бернинди охшашлык юк Гасимә белән Наиләнең. Икесе дә чибәр чибәрлеккә. Әмма Наилә борынгыча, аристократларча ап-ак, көпшәк һәм ясалмарак чибәр. Ә Гасимә авылча, тыгыз, табигый чибәр. Бернинди кершән-иннек якмаса да, бит очлары һәм иреннәре алланып тора торган сәламәт чибәр...

Ә шулай да охшашлык бар алар арасында. Ир-атка гаҗәеп дәрәҗәдә ошый белү, аның башын әйләндерә алу осталыгы — менә шунда аларның үзара охшашлыгы... Әгәр теге көнне урманнан кайтып килгәндә Гасимәнең юхалануына бирешмичә, аны артка гына утыртып кайткан булса, менә хәзер гарип булып больницада ятасы кеше идеме Фәләх? Хурлыгына, фаш булуына да түзәр иде әле. Теге мотоциклчы егет тә исән калмаса, больницадан савыгып чыгу белән утыртачаклар бит Фәләхне! Андый гына аварияләр гел булып тора. Бәлки ул егет үзе гаепле булгандыр. Ләкин бөтен бәла шунда — Фәләх бераз салмыш иде... Аннары килеп, Роза...

Я, рабби, аны исенә алу белән йөрәкләре чәнчеп куйды Фәләхнең. Сизенүен ул сизенә иде соңгы вакытларда Фәләхнең кыек юлда йөргәнен. Ләкин Фәләх, нинди дә булса сәбәп табып, Роза алдында гел аклана килде. Ә хәзер, менә бу хәлләрдән соң, ничек итеп акланмак кирәк?.. Бик яхшы белә Розаның холкын: моннан соң бер көн дә тормаячак, аерылачак. Розалияне, әлбәттә, үз янында калдырып...

Андый чакта закон хатын-кызны яклый ул. Их, Фәләх, Фәләх!

Уйлый башласаң — акылдан язарлык, билләһи! Ни пычагыма кирәк булды аңа шулай башсызланып йөрү? Ул көнне авылга Гасимә янына бармый калса дөньяның чите кителгән булыр идеме? Аннары бит андый кыек юлда йөрүнең яхшылыкка алып бармаганын ул инде бик яхшы белә. Үз җилкәсендә татыды. Әлеге шул Наилә белән чуалып йөргәндә булган иде анысы.

## 10

Иркәләү белән генә Фәләхнең тартыну-оялуын җиңә алмаячагын аңлады булса кирәк, теге чакта Наилә аның тезләрендә утырган җиреннән кинәт кенә сикереп купты да ике хрусталь фужер алып килде. Икесенә дә тутырып диярлек коньяк салып:

— Менә, Фәләхчик, әгәр чын егет булсаң, шушыны бетереп эчеп куясың! Үзем бик яхшы күреп утырдым, син үзегездә кич буе бөтенләй дә эчмәдең. Һәм бик дөрес эшләдең. Бүтәннәр шикелле салган берен эчеп барсаң, син миңа ошамаган да булыр идең,— диде.

— Ә хәзер нигә кыстыйсың соң алай булгач?

— Ә хәзер — бөтенләй башка мәсьәлә. Хәзер мин синең нменно минә шушыны эчеп куюыңны телим!

Әнә шунда Фәләх әллә нишләде. Наиләгә рәхмәт әйтеп, бер-ике йотып кую белән чикләнәсе урында:

— Менә, күр алайса! — диде дә тамчысын да калдырмыйча эчеп җибәрде.

Ә Наилә, хәйләкәр җан, ирен очын гына тидереп, фужерын өстәлгә куйды да:

— Ой, молодец! Вот какой ты молодец, Фәләхчик! — дип мактый-мактый аңа закуска сузды. Кайнар куллары белән аның битләрен-чәчләрен сыйпарга тотынды. Март аендагы күк йөзе шикелле чиста зәңгәр һәм өмет тулы күзләре белән Фәләхнең күзләренә текәлде...

Шуннан соң нпләр булганын төштә күргән шикелле генә хәтерли Фәләх. Тик бер нәрсә генә исендә ачык булып калган: моңарчы аны беркем дә болай иркәләгәне юк иде әле. Күрәсең шуңадыр, Наиләнең сихри назы Фәләхне тәмам эретте, тормыш-дөнья мәшәкатьләрен оныттырды. Аның өчен ул чакта җир йөзендә тик бер Наилә генә бар, аннан гайре беркем дә, бернәрсә дә юк һәм кирәк тә түгел иде кебек. Хәттә аңа өйләнергә дә әзер иде Фәләх. Шул чакта аның үзенә әйтеп тә карады. Ләкин Наилә:

— Ой, какой ты наивный, Фәләхчик! — дип көлеп кенә җавап бирде.

— Ничек инде ул, наивный? — диде Фәләх аптырап калып. — Синеңчә, тик наивный кешеләр генә өйләнә мени?

— Мин аннан әйтмим лә. Мин бит инде кияүдә, законлы ирем бар!

Фәләх аркан авып китә язды. Ул Наиләне ир хатыны булыр дип күз алдына һич тә китерә алмый, чөнки әле бик яшь, үсмер кызлар шикелле генә күренә иде.

— Ни сөйлисең син, кызый? — диде Фәләх, корт чаккандай сикереп торып.

Бер сүз дә әйтмичә генә, Наилә бик шәп альбом алып килде дә Фәләхкә сузды:

— Мә, кара, ышанмасаң!

Альбомның беренче битендә Наиләнең никах күлмәге киеп кияве белән загста төшкән рәсеме урнаштырылган. Аннары аларның дусишләре, туган-тумачалары белән туйда төшкән рәсемнәре теркәлгән иде...

Наилә әйткәннәр дөрес булуына ышангач, Фәләхнең күңелендә иң элек аның иренә кызгану хисе туды. Рәсеменә караганда, акыллы гына, чибәр генә күренә ул. Һәрхәлдә, Фәләхтән бер дә кайтыш җире юк кебек. Тик яшькә генә олырак та — утыз биш-кырыклар чамасында булырдыр — башы яртылаш пеләш иде. Ул бичара мондагы хәлләрне башына да китермичә, ниндидер бик мөһим эш артыннан йөри торгандыр әле, дип уйлады Фәләх. Һәм үзен явыз бер угры хәлендә хис итте.

— Соң, ирең булгач, нигә шушылай кәмит ясап, җилбәзәкләнеп йөрисең син? — диде ул һәм чыгып китәргә дип киенә башлады.

— Сине яратканга! — диде Наилә бер дә алай исе китмичә. — Син миңа бер күрүдә үк ошадың һәм моның өчен тамчы да үкенмим!

— Алай булгач, әйдә, аерыл аннан да, чык миңа кияүгә?

— Ә менә анысы булмый, егетем! Минем әти-әниләр бар бит әле. Аларның репутациясе бар. Һәм алар минем иремнән аерылып йөрүемне гомергә кичермәячәкләр. Алай гына да түгел, инфаркт булачак аларга. Яратышкач, сиңа соң ничек яшәсәк тә ярамый мени?

— Юк, ярамый! Мин алай кеше хатыны белән йөри дә алмыйм, теләмим дә. Ә ирең кем соң синең? Кайда ул? Ә менә хәзер кайтып керсә, нишләмәкче буласың?

— Курыкма, пожалуйста. Кайта торган булса, сине өйгә чакырып идемме? Чит илдә командировкада ул, минем Яков Исакович. Кайтырына тагын айга якын вакыт бар әле.

Шуннан соң гына бераз эченә җан керде Фәләхнең. Югыйсә куркуыннан бөтенләй дерелди үк башлаган иде. Ләкин ул Наиләне барыбер гаепле саный иде:

— Ярый,— диде ул аңа, бу юлы инде кайнарланмыйча гына.— Кайтмасын да, берни сизмәсен дә ди ирең. Ә үзең соң? Намусың?

— Син боларны миңа ни өчен сөйлисең? — диде Наилә әле һаман софасында кырын яткан килеш.

— Мин боларны шуның өчен сөйлим: йөрмә болай яшерен, хыянәт итеп!

— Әгәр бик беләсең килсә, мин түгел, минем ирем хыянәтче! — диде Наилә.— Миңа кадәр инде Одессада өйләнгән һәм хатынын ташлап Мәскәүгә аспирантурага укырга кергән булган ул. Аның инде унбер яшьлек кызы бар. Ләкин миңа өйләнгәнче ул боларның берсен дә әйтмәде. Үзен өйләнмәгән егет дип йөрде... Так что минем бу бер хыянәтем аның йөз хыянәтенә нибары бер җавап кына ул!

— Тормышмы инде шушылай яшәү?

— Ә ни эшлисең?

— Ә минем белән булсаң, кешеләрчә яшәр идек!

— Син, Фәләх, әйбәт, акыллы егет. Ләкин без бергә яши алмаячакбыз. Чөнки икебез ике төрле тәрбия алган кешеләр, икебез — ике дөнья кешеләре без. Минем Яков Исакович — ул фәннәр кандидаты һәм үзенә шулай дип эндәшкәнне ярата — ул яктан идеальный кеше. Мин ни әйтсәм — шуны эшли, мин ни кушсам — шуны үти. Шәхес буларак формалашкан, җәмгыятьтә инде үз урынын тапкан кеше: институтта инглиз теле укыта. Минем ирекне кысмый, көнләшми. Шулай булгач миңа тагын ни кирәк?

— Бәхетле булу өчен болар гына җитми бит әле,— диде Фәләх, теге кызыйның чамадан тыш аек фикер йөртүенә шаккатып һәм ачуы чыгып.— Бәхетле булу өчен, барыннан да элек, мәхәббәт кирәк, бер-береңне ярату кирәк дип язалар бит китапларда. Бармы соң сезнең арада әнә шул мәхәббәт? Яратасыңмы син үзеңне бик тыңлаучы Яков Исаковичыңны?

— Әйбәт кеше ул. Мин аны хөрмәт итәм.

— Ярый, алай булгач, хуш, кызый! Мин киттем һәм без бүтән берберебезне белмибез, яме!..

Ләкин Фәләх ансат кына чыгып китә алмады: тегеләрнең ишекләре нindидер серле йозак белән бикле иде, ни тырышып та аның җаен таба алмады. Ә Наилә аңа ишек ачарга уйламый да иде. Хәйләкәр елмаеп, тик утыра бирде. Фәләх аның янына бик хәтәр җилләнеп килеп:

— Кыланма, кызый, ач ишекне! — дигәч тә бер дә исе китмәде.

— Миңа кызганыч түгел, ачуын ачармын,— диде ул.— Тик син сәгатеңә кара башта: төнге дүрттә кая бармакчы буласың? Бу вакытта гомуми торакка кем кертсен сине?

Наилә хаклы иде. Вахтер керткән тәкъдирдә дә төнлә иптәшләрне бимазалап йөрү булыр, аннары, дөресен генә әйткәндә, ялгызы гына кайтырга курка да иде ул. Шуңа күрә Наиләнең сүзен тыңларга мәҗбүр булды. Инде өстенә кигән пинжәген салып тормыйча гына, тирбәлчек канәфигә утырып, башын артка ташлады да күзен йомды.

Наиләнең моңа бер дә исе китмәде. «Фи!» дип үз алдына гына мыскыллы елмаеп куйды да стенага борылып ятты.

Йокысызлык үзенекен иткән: күзен йому белән йоклап киткән иде Фәләх. Иртән ул Наиләнең:

— Торыгыз, граф, сезне бөек эшләр көтә! — дигән ягымлы тавышына уянды.

Наилә инде юынган, киенгән һәм кофе кайнатырга да өлгергән иде. «Карале син аны: әзергә — хәзер булып, иркә үссә дә, үзенә кирәк булганда вакытында уяна да, эш тә эшли белә икән бит бу!» дип уйлап алды Фәләх. Аның әле йокысы туймаган, кофе эчәргә бер дә теләге юк иде. Ләкин Наилә:

— Бар, тиз генә юынып кил һәм кофе эчеп алабыз да — институтка! Лекциягә бармый калсак, безнең турыда әлләниләр уйлавы бар группадашларның! — дигәч, Фәләхнең йокысы шундук качты.

Наилә үзен һични булмагандай тыныч тота. Күңеле дә күтәренке. Фәләхне дә шул җайга салмакчы булган иде ул. Ләкин егеттә шаяру кайгысы түгел, аның бик нык эче поша, ул үзен коточкыч зур җинаять эшләгән дә хәзер шуның өчен эти-әнисе, группадашлары һәм гомумән бөтен кешелек дөньясы каршында җавап бирергә тиешле кеше кебек хис итә. Аның шул зур җинаятен бөтен кешеләр дә белә, тик, үзенә әйтмичә, эчләреннән генә көлеп торалардыр шикелле иде. Бигрәк тә яраткан кызы Роза алдында уңайсыз иде Фәләхкә. Роза аңа: «Их, син, хәчтерүш, яратам дип алдашып йөргән булдың тагын! Яраткан кеше шушылай хыянәт итә мени?» — дип чирканып карап торадыр кебек иде...

## 11

Ләкин юкка гына борчылган икән Фәләх. Группадашлары берни дә сизмәде. Аудиториягә бергә килеп керсәләр дә Наиләгә хәтта игътибар итүче булмады. Ә Фәләхкә: «Кайда кундың син, егет? Без инде, берәр хәл булды ахрысы моңа дип, куркыша да башлаган идек. Кунасы булгач, әйтеп китәләр аны, авыл мокыты!» — дип бәйләнә башлаганнар иде башлавын. Ләкин Фәләх бик тиз хәйләсен табып: «Мәскәүдә безнең туганнарыбыз бар, шуларга кереп кундым»,— дигәч авызлары томаланды.

Наилә дә сер тота белгән акыллы баш булып чыкты. Фәләх белән булган хәлләрне беркемгә дә сиздермәде. Башкалар белән нинди битараф һәм тыйнак мөнәсәбәттә булса, кеше алдында аның белән дә шулай булды. Шул ук вакытта үз орбитасыннан читкә дә җибәрмәде Фәләхне. Җаен туры китереп, бүтәннәргә сиздермичә генә киноларга да алып барды, кафе-рестораннарга да кергәләп тордылар. Болай йөрү Фәләхкә уңайсыз һәм оят иде. «Кызлар беткән мени миңа аннан башка. Ир хатыны бит ул. Бер сизенмәсә, бер сизенер иде. Ярамый болай, ташларга кирәк бу эшне!» — дип үзен әледән-әле табалап тора иде. Ләкин Наиләне күреп, аның тавышын ишетү белән бу аек акылы шундук томалана да ул тагын тегенең ихтыярына буйсына иде.

Тора-бара Фәләх Яков Исаковичны да ул кадәр кызганмый башлады. Я бер мәхлук җандыр ул, яки Наиләгә артык исе китми торгандыр, югыйсә хатынын болай ук иректә йөртмәс иде, дип уйлады. Һәм, дөресен генә әйткәндә, Наилә белән очрашулардан бөтенләй үк ваз кичмәде.

Көн артыннан көн үтә торды. Кышкы сессия дә килеп житте. Имтиханнар башлангач ташларга кирәк бу хәтәр уенны, яхшыга алып бармас дип йөрсә дә асылда Фәләхнең эшләр киресенчәгә әверелеп китте. Имтиханга бергәләп әзерләнү сылтавы белән, Яков Исакович Мәскәүдә булган чакларда да Наилә Фәләхне өйләренә алып кайта башлады. Фәләх килеп кергәндә кайчакларда Яков Исакович үзе дә өйдә туры килә һәм, кочак җәеп үк каршыламаса да, караңгы чырай күрсәтми иде. «Я бу адәм Наиләне бөтенләй яратмый, янсә, ратса да, күңләшү дигән нәрсәнең ни икәнен дә белми торгандыр», — дип уйлаган иде Фәләх, аның шул хәтле түзем булуына исе китеп.

Әмма ул ялгышкан булып чыкты. Көнләшә дә белә һәм боларның имтиханга гына әзерләнеп йөрмәүләрен дә бик яхшы сизенгән икән Яков Исакович. Тик, югары культуралы интеллигент буларак, түземлек күрсәткән, вакыты җитми торып, тавыш чыгарырга гына теләмәгән. Моментны җиткәч шундый итеп китереп каптырды ки, әгәр теләсә, Фәләхне институттан эһ тә итмичә кудырта ала иде...

Бүтән фәннәрдән ярыйсы гына укый торган Наилә, сопроматны һич кенә дә үзләштерә алмый азапланды. Шул предметны өчкә генә бирә алсам да, миннән дә бәхетлерәк кеше бу дөньяда булмас иде, дип бик куркып йөри иде. Ә менә Фәләх ярдәме белән шуны «удов»ка гына түгел, бәлки «хор»га тапшырып чыккач исә аның куанычына чик-чама булмады! Кәеф-сафа коруга болай да һәвәс «кызый» имтиханнан соң Фәләхне, ай-ваена һич тә карамыйча, ресторанга алып керде. Анда шактый утырып кәефләнгәч, әйдә, Фәләхчик милый, саф һава сулап бер рәхәтләнеп кайтыйк әле дип, такси яллап, дачаларына алып китте. Фәләх аңа, иреңнән, әти-әниеңнәрдән яхшы түгел, кирәкми, бармыйк, синең өчен борчылып торырлар дип, йомры тelләрен яссы итеп әйтеп караса да, тыңламады Наилә. Дачаларында телефон да бар иде. Бирәдән генә шалтыратып үзеңнең кайда икәнеңне әйт, дип тә караган иде Фәләх.

— Юк, кирәкми. Монда икәнне белсә, хәзер килеп җитәчәк Яков Исакович. Аның килүен теләмим! — дип анысын да эшләмәде.

...Аларны дачада төнге сәгать өч тулып килгәндә, дөньяларын онытып, изрәп йоклап ятканда уяттылар. Бик каты итеп ишек шакыганга башта Фәләх уянды. Уянды да беркавым үзенең кайда икәнен абайламыйча торды. Ә эшне чамалап алгач, тәннәре эсселе-суыклы булып китте. Тиз генә киенергә тотынды. Ә ишекне һаман дөбердәтәләр иде. «Нишләргә? Тәрәзәдән генә чыгып сызыр идең дә, хәзер аны ничек ачасың?» — дип уйлап алды ул. «Тор әле, тор!» дип Наиләне уятырга тотынды. Ә Наилә чайкап йоклый, әйтерсең, мәрткә киткән. Бик ныклап селкетә башлагач кына, ниһаять, җан керде.

— Ой, Фәләхчик, я так устала. Давай, поспим еще хотя бы часок! — диде дә, юрганын башыннан ук бөркәнеп ятты. Ә ишек инде һаман саен ныграк дөберди.

— Син нәрсә, юләрләндеңме әллә? — диде Фәләх ачыйгланып. Хуҗабикәнең өстеннән юрганын алып ташлады.— Ишектә кеше бар дим бит! Тор тизрәк!

Шуннан соң гына Наилә чынлап уянып, иләсләнеп торып утырды.

— Ә кем килгән? Ник ачмыйсың соң?

— Юк, мин ачмыйм, әйдә, мине берәр җиргә яшер дә үзең ачарсың.

— Их, син, трус!

Наилә өстенә халат кына элде дә, өялдына чыгып, кем бар анда дип сорап та тормыйча, ишекне ачты һәм... ире Яков Исакович белән әтисен иярткеп керде.

— Нишләп болай соңлап килергә булдыгыз? — диде аларга Наилә берни булмагандай тыныч кына итеп.— Әнигә бер-бер хәл булдымы әллә?

Бер мәлгә авыр тынлык урнашты. Наиләнең бүтән әйтер сүзе юк, ә тегеләр икесе дә нәфрәтләнүләреннән телсез калганнар иде. Сүзне Яков Исакович башлады.

— М... менә күр... дегезме инде, хәр... мәтле Хәбиб Хәкимович! — диде ул, ачудан һәм хурланудан тотлыга-тотлыга.— Күр...дегезме инде, кад... дерле кызыгыз...ның ниләр эш....ләп йөр...гәнен? Югыйсә һаман миңа ышан... мый ид... дегез!

— Дааа! — диде Хәбиб Хәкимович аптырашка калып. Өйдә бер дә алай эссе булмаса да, бөртек-бөртек тир бәреп чыккан маңгаен сөртеп алды. Аннары тагын бер тапкыр «дааа!» дип куйды да, алып кадәр дәү гәүдәсенә хас булмаган җитезлек белән Фәләх каршына килде. Кирәк кадәр кулы белән аның якасыннан эләктереп алды:

— А ну-ка, щенок, сыпырт моннан яхшы чакта! — дип тезе белән Фәләхнең арт санына тибеп чыгарып җибәрде. Артыннан: — Һәм үзеңне иртәгәдән институттан куылган дип сана! — дип кычкырып калды.



12

...Я, рабби! Ул төн исенә төшкән чакларда әле хәзер дә тәннәре чымырдап куя Фәләхнең: юньле кеше этен дә урамга чыгармаслык зәмһәрир суык январь төне иде. Күктәге йолдызларга хәтле салкыннан тоныкланып, кечерәеп калган һәм алар да дер калтырап тора кебек. Аяк астындагы кар, «ой-ой!» дигән шикелле итеп, атлаган саен шырыйлап кычкыра сыман. Ә юл буендагы каеннар һәм чыршылар, сулу алырга да курыккан кешеләрдәй, тып-тын калган. Тик вак чыршыларның хәле генә арурак: өсләренә ап-ак кар юрганы ябынганнар да, Фәләхләр ихатасында аякларын мамык арасына, башларын канат астына кыстырып яткан казлар шикелле, рәхәтләнеп йоклый бирәләр. Тик кайберләренең генә юрганы кыскарак булып, аяк очлары ачылып киткән һәм шуннан җылы бөркелеп чыгып торадыр шикелле тоела. Шуларның берәрсенең итәк астына сыенып, биш-ун минут кына булса да җылынып аласы килә... Ләкин Фәләх алай эшли алмый. Чөнки чыршылар янына кар ерып керергә кирәк, ә Фәләхнең аягында шәһәр көязләре киеп йөри торган көзге ялтыравык туфли: юлдан читкә атлау белән балтырына кар тулачак. Җитмәсә өстендә дә көзге пальто гына, чөнки Мәскәүдә көндез бер дә болай салкын түгел иде. Кем белә бит кинәт шушылай суытып җибәрәсен! Ә башында... Әле хәзер дә чирканып куйды Фәләх: башы бары тик шул пальтоның башлыгы белән генә капланган.

Барысы да шул хәерсез «кызый» аркасында: имтиханнан соң туләй торакка кайтып, юньләп киенеп чыгарга да ирек бирмәде. «Пүчтәк нәрсәләр белән маташып йөрмә. Такси белән барасы ич. Ә кайтканда поездга нибары ун-унбиш минутлык юл!» дип ашыктырды. Дөрес, дачалары станциягә ерак түгел, күп дигәндә километр ярымнар гына булыр. Кичтән Наилә белән үткәндә тоймый да калган иде Фәләх. Ә менә хәзер, төнге сәгать өчтә, җылы өйдән куылгач ай-һай суык иде аңа. Тышкы дөнья салкыны гына түгел, эчке рухы, җаны суынудан да өши иде Фәләх. Ул коточкыч зур һәм төпсез упкын читенә килеп баскан һәм түбәнгә мәтәлүдән котылу өчен берниндн чара күрү дә мөмкин булмаган кеше шикелле хис итә иде үзен. Наиләдән ишеткәне бар аның: Хәбиб Хәкимович Фәләхләр институтының ректоры белән таныш, заманында бергә укыган булганнар. Аннары аның авторитеты да хәдайга шөкер. Хәтта чит илләрдә дә беләләр аның хезмәтләрен. Рас ул Фәләхкә «институттан куылган сана» диде икән — эшләячәк инде ул моны. Яков Исакович алдында кызын ничектер аклап калырга тырышу йөзеннән генә булса да эшләячәк... Бигрәк тә ахмак кыланды шул Фәләх, ни пычагыма кирәк иде аңа монда ияреп килү? Хәбиб Хәкимовичның да әйтерең бармы? Рәтле кеше югалган кызын әзләргә киявен ияртеп чыгамы соң? Кызының нинди(рәк икәнен белмәсә дә азрак чамаларга тиеш иде бит инде! Әгәр дачага үзе генә килгән булса, Фәләхне дә, кызын да шунда бик ныклап бер орышыр иде дә — шуның белән беткән булыр иде. Әшне зурга җибәреп, Фәләхне инсти-

туттан ук кудырып, фаш итеп йөрмәс иде. Андый чакта кара тапның гаепләнүчегә генә түгел, гаепләүченең үзенә дә тиеп калуын Фәләхкә караганда яхшырак белә торгандыр. Юк, Яков Исаковичны алып килеп әйбәт итмәгән иде Хәбиб Хәкимович. Чөнки ул хәзер, Фәләхне сытып ташлау өчен, кулыннан килә торган явызлыкның барысын да эшләячәк. Һәм бу бер дә гаҗәп түгел. Аның урынында Фәләх үзе дә нәкъ шулай иткән булыр иде. Аннары бит Яков Исакович үзе дә ниндидер бер төшеп калган мәхлук түгел, утыз биш яшендә фән кандидаты булган. Хәзер ул кырык белән бара. Докторлык диссертациясен тәмамлап йөри. Һәрхәлдә, бер Фәләхне генә бөгәрлеге бар. Монысы — һичшиксез!.. Әлбәттә, бу очракта Наиләнең үзен ничек тотышы зур роль уйнаячак. Фәләхнең гаебе юк, барысына да мин үзем гаепле, аны үзем алып бардым дачага,— дип барысын да үз өстенә алуы кирәк. Хатынкыз буларак үзен акларга тырышмый калмас...

Фәләх станциягә килеп җиткәндә сәгать өч тулып дүртенчегә киткән иде. Ә суык бәгырьләргә төшеп һаман туңдыра. Станция беркемсез булмас, кассирга бер биш сум акча бирермен дә поезд килгәнче аның янында утырып торырмын дип өметләнде ул. Ләкин касса тәрәзәсе ябык, ишеге тыштан бикле иде. Ә расписаниегә карагач, Фәләх аһ итте: иң тиз килергә тиешлесе дә алтынчы яртыда гына булачак иде! «Катып үләм болай булса! — дигән уй котын алды аның.— Ике сәгать түгел, ун минут түзәргә дә чамам юк...» Аңа әле үз гомерендә мондыйны беркайчан да кичерергә туры килмәде, башка вакытларда ничек тә берәр җае табыла торган иде. Ә менә хәзер, хет шартла, берни дә эшләп булмый. Тик торырга да ярамый — шундук катып үләчәк. Аяклары өшеде ук бугай инде: бармаклары берни toймый, ул үзен көчләп, туктаусыз йөреп торырга мәҗбүр иде. Ә төн һаман салкынайта бара. Йөреп кенә үлемнән котылып булмаячагы көн кебек ачык. Станциядән ерак түгел ун-унбиш йортлы кечкенә генә авыл бар иде. Берәрсенә фатирга кереп тору уе белән ул шунда китте. Ләкин анда да юлы уңмады. Кырыйдан икенче йортның болдырына менеп, ишекләрен шакый башлаган иде, өйалларыннан коточкыч калын тавышлы эт өреп кугач, куркып, кире китеп барды: ул этнең тана хәтле булуына шик юк, ә андый эт асраган кешедән рәхим-шәфкать көтеп булмаслыгын Фәләх, яшь булса да, чамалый иде. Ишеген ачасы кеше бер шаку белән ача ул. Ә биредә хәтта ут та кабызмадылар... Тагын бер йортның ишеген шакып карамакчы иде, анысының эте шакый башлаганны да көтмәде: «Ыыыюк, ыыыюк!» дип алдан ук кисәтеп куйды. Фәләх әлеге шул бәләкәй авыл урамында катып үлгән булыр иде. Бәхетенә каршы, егеткә дачалар ягыннан якынаеп килүче машина уты күренде. Ул шундук юл уртасына чыгып кулын күтәрде. Такси шоферы, Фәләхнең хәлен чамалап алгач, машинасы инде тулы булуга карамастан (дүрт кеше утыра иде анда) — кысылыбрак утырудан берни дә булмас дип, алгы урындыктагы кешене артка, аның урынына Фәләхне утыртып алып китте. Ә Фәләхкә ботинкасын салып, аяк бармакларын кыймылдатып барырга кушты һәм шәһәргә җиткәч аны больницага ук илтеп куйды.

Больницада ятып, нәүбәттәге имтиханга әзерләнәсе өч көн вакыт әрәм киткәнгә бик үк үкенмәде Фәләх. Имтихан — философиядән иде. Ә Фәләх фәлсәфәне ярата: укытучы кушканнарны гына түгел, фәлсәфәгә кагылышлы өстәмә әдәбиятны да байтак укыган иде. Ул көннәрдә аның йөрәк маен тик бер генә нәрсә — институтта калу-калмау мәсьәләсе сыздырып торды. Хәтта гомуми торак комендантына да аны бөтенләй кертмәскә дип әйтеп куйганнардыр инде дип, курка-курка гына кайтты Фәләх больницадан. Ләкин аның Мәскәүдән китәргә нияте юк, ул хакта уйларга да ярамый, ничек итеп булса да, шунда ябышып калырга иде исәбе. Чөнки, әгәр эти-энисе аның бу хикмәтләрен белә

калса — эш харап! Бигрәк тә әнисе дөнья сасытачак иде... Аннары килеп, җир йөзендә Роза дигән кыз да бар иде бит әле. Дөрес, алар йөрешергә сүз куешкан кешеләр түгел. Хат та алышмыйлар. Ләкин Фәләх аны барыбер ярата, ничек тә бер аңлашырбыз әле дип өметләнеп йөри һәм үзенең киләчәген Розадан башка гомумән күз алдына китерә алмый иде. Өметләнергә бөтенләй үк нигезе дә юк түгел: үткән ел чыгарылыш кичәсеннән соң Фәләх озата кайтканда, Роза аңа үзе дә яратуын сиздергән иде ләбаса! Тик, әниеңнән куркам, дип кенә әйткән иде. Анысы гына булыр инде аның. Фәләх Мәскәүдә укуын дәвам итсә, ничек тә бер аңлашырлар иде әле. Ә инде институттан куылып авылларына кайтып китәргә туры килсә — бетте: Роза аңа мәңге тәтемәячәк! Шуңа күрә Фәләхкә Мәскәүдән китәргә һич ярамый иде. Инде бүтән җае юк икән, урам себерүче яки вокзалда носильщик булырга да ризаланып, Мәскәүдән китмәскә кирәген күңеленә беркетеп куйды ул. «Биш-алты айга ничек тә түзәрмен, ә аннары бүтән берәр институтка керермен»,— дип уйлады.

Әмма, бәхетенә каршы, тулай торакта да, имтиханга баргач та, Фәләхкә берни әйтүче булмады. Ул укуын дәвам итте.

Ләкин Фәләхне гаҗәпкә калдырганы бу түгел, аны хәйран иткәне шул ук Наилә иде. Фәләх инде «кызый» миңа якын да килмәс дип уйлаган иде. Ә ул Фәләх больницада чакта ук аларның гомуми торагына Фәләхне сорап дүрт мәртәбә килеп киткән. Телефон шалтыратып та бүлмәдәш малайларны аптыратып бетергән. Ә инде Фәләхне институтта очраткач исә, беркемнән дә тартынып тормыйча, дүрт-биш ел күрешмичә сагынып көткән иң якын кешесе белән күрешкәндәй, кочаклап алды:

— Ой, Фәләхчик, ой, милый! Где же ты так долго пропадал! — дип куанычыннан еларга җитешеп, сокланып торды.

Ә бит Фәләх, «кызыйны» да болай гына калдырмаганнардыр, аны ире я бик шаплап яргандыр яки бөтенләй аерылышканнардыр ук дип, хәвефләнеп йөргән иде. Ләкин Наиләдә бернинди үзгәреш сизелми, ул тагын да яктырыбрак, чибәрләнебрәк киткән кебек.

«Шул тамаша четерекле хәлдән ничек болай ансат кына котыла алды икән?» дип уйлаган иде Фәләх, аны Наилә кочып торган арада. Бу хакта Наиләнең үзеннән дә сорашмакчы иде дә, теге төндә менә шушы хатын аркасында чак кына катып үлми калуы исенә төшеп, ул уеннан кире кайтты. Аның яныннан тизрәк читкә китеп, группа малайлары кырына барып басты.

Шул ук көнне, җаен туры китереп, Наилә аны читкә дәшеп алды да:

— Ни булды сиңа, егетем? Нигә кәефең начар? Минем өчен борчыласың мәллә? Курыкма, барысы да тәртиптә! Бер ни дә үзгәрмәде. Һәм безнең мөнәсәбәтләр дә үзгәрешсез калырга тиеш! — диде.

— Ә син этиең миңа ни әйтеп калганын ишеттеңме соң?

— Ә-ә-ә, син әнә нәрсәдән куркасың икән! — диде Наилә кычкырып көлеп.— Оныт аның ул сүзен! Минем эти андый хөсетле кеше түгел ул. Кызган чакта гына шулай әйтеп ташлады ул аны. Мин аны иртәгәсен үк җайладым. Тыныч бул, яме!

— Ә ирең?

— Ул да юләр түгел бит. Нигә вакланып, үзен фаш итеп йөрсен ди? Әлбәттә, бик каты сөйләште. Ачуыннан ярылырга җитешкән иде прямо. Әле дә бөтенләй үк кайтып төшкәне юк. Ләкин, курыкма, ул да тавыш кузгатып йөрмәячәк.

Менә шуннан ары гына күңеленә азрак җылы керде Фәләхнең. Ләкин ул теге төнне үз-үзенә биргән сүзенә тугрылыклы булып калырга булды һәм Наилә элекке мөнәсәбәтләрне кайтарырга никадәр генә тырышып караса да, аның янына бүтән бармады. Бөтен көчен укуга

бирде һәм Роза белән очрашуны көтте. Гомумән андый җиңел холыклы хатын-кызлар белән бүтән беркайчан да бәйләнешмәскә, алар тирәсеннән ераграк йөрергә булган иде ул. Һәм, инде ничә ел, шул карарын бозганы юк иде. Ләкин менә быел, уйламаганда-көтмәгәндә, Гасимә белән чуалып китте бит, шайтан алгыры! Ай-һай, катлаулы булачак аның эшләре!..

## 13

Күрешеп сөйләшмәсәләр дә, өченче курстан соң өйләнешкәч, Роза белән көн саен диярлек хат язышып тордылар. Хатларын бик җылы, якын итеп яза иде Роза.

Ә Фәләх институтын тәмамлап Казанга кайтканда Роза аны вокзалга ук килеп каршылады. Бернинди тартынусыз, ике-өч атна гына аерылып торгандай, үз итеп күреште.

Аның да укуы инде тәмамланган, тик Фәләхне генә көтеп торган иде. Фәләх Казанга килеп төшкән көнне үк авылга кайтырга булдылар.

— Хәзер инде серне ачарга вакыт житте. Сиңа минем әнидән куркасы түгел. Безгә хәер-фатиха бирүдән башка чара юк аңа. Чөнки без синең белән загслы кешеләр. Син безгә законлы килен булып кайтасың! — дип Фәләх аны туп-туры үз өйләренә алып кайткан иде. Ләкин мәсьәлә ул уйлаганча ансат булып чыкмады. Улы Розага өйләнгәнен белеп алу белән Фәләхнең әнисе секунд эчендә кара көеп чыкты да:

— Миннән рөхсәтсез өйләнгән кеше — минем улым түгел! Теләсәгез кая китегез, бу өйдә сезгә урын жук! — дип ишек бусагасына аркылы басты.

Ризасызлык белдерергә аның бөтенләй үк сәбәбе юк дип булмый, әлбәттә. Ник дигәндә, заманында Фәләхнең әтисе Розаның әнисе Рәйхана ханым белән сөешеп йөргән, хәтта өйләнешергә дә сүз куешкан булганнар. Тик әнисе үзенең кыюлыгы һәм әрсезлеге белән генә Фәләхнең әтисен үзенә карата алган. Бу турыда Фәләх кечкенә чакта әнисе үзе сөйләгән иде. «Безнең улыбыз булып дөньяга килүең өчен иң элек син миңа рәхмәт әйт, улым! Әтиең бик кыюсыз, йомыкый егет һәм ул Рәйханага өйләнергә жөридерие. Үземнең булганлыгым аркасында гына эләктереп калдым мин аны!» — дигән иде ана...

Ләкин бит монда Розаның да, Фәләхнең дә бернинди гаепләре юк. Әти-әниләре арасындагы кайчангыдыр хәлләргә аларның ни катнашы булсын! Рас инде буласы эш булган — Фәләх белән Роза өйләнешеп кайтканнар икән, болай ук ямьсезләнеп торуның бер кирәге дә юк иде аңа. Киресенчә, берни белмәгән атлы булырга кирәк иде Фәләхнең әнисенә. Ләкин аның шуны аңларга башы житмәде.

— Менә, Фәләх, күрдеңме инде? Әйткән идемме мин сиңа! — диде дә бәләкәй чемоданын кулында тоткан Роза, кырт борылып, чыгып китте.

— Туктале, кая барасың? Тукта, әни ялгыш кына кызып китте ул. Хәзер, хәзер... барысы да рәтләнер! — дип Фәләх аның артыннан дәшеп караса да туктамады. Фәләх аны куып житеп туктатырга дип артыннан бара башлаган иде, әнисе бик каты итеп:

— Ишетсен колагың, малай, беркая да бармыйсың! Борыл яхшы чакта! — дип кычкыргач кире керде. Әгәр борылмаса, әнисе урамга чыгып ук сөрән сала башлаячагын ул бик яхшы белә иде...

Ә шулай да ул чакта Розага ияреп китәсе калган икән аңа. Әнисе шул бер тузынып иде дә туктар иде. Аның каравы Роза алдында йөзе ак булыр иде Фәләхнең. Ә менә болай...

Әнисе барыбер тузынды ул көнне. Әй, котырынып та карады инде! «Кемнәргә генә ошап шушылай ахмак булдың син? Адәм хурлыкла-

рына калдырдың бит! Бөтен нәсел-нәсәбебез алдында хараплар иттең! Беткәнне мени сиңа бүтән кыз, шул Рәйханә кызын алмасаң?» — дип тыпырдый-тыпырдый, чәчләрен йолкый-йолкый елады.

Фәләхнең беркайчан да әнисенең болай ук үрсәләнгәнен күргәне юк иде. Шуңа аптырап, ни эшләргә белмичә, тик кенә тыңлап торды. Ә бит аңа алай җебеп төшәргә түгел, киресенчә, нык булырга, үзен ирләрчә тотарга кирәк булган. Яхшымы Розаның әнисе, яманмы, рас кызын Фәләх яратып алып кайткан икән, рас ул аның белән тормыш итәргә ниятләгән икән, инде аны яклый алырлык чамасы юк икән — ул Роза белән китеп барырга тиеш иде. Ә ул, понимаешь, аңгыра сарык шикелле, әнисенең сүзен тыңлап, катты да калды...

Ярый әле шул чакта әтисе кайтып керде Фәләхнең. Ата кеше улының күңеле кемгә төшкәнен алдан ук чамалап йөргән ахрысы. Шулайдыр, шулай булмаса, әнисенең сүзен куәтләп, ул да Фәләхкә ташланган булыр иде. Алай итмәде. Ул кайтып кергәч, әниләре тагын да ныграк елый башлап, Фәләхнең «адәмгә сөйләп, адәм ышанмас ахмаклыгын»нан зарланырга тотынган иде, бик коры гына итеп:

— Булды, әнисе. Житте! Аңлашылды! Бар, өйгә кер дә эшләреңне кара! Малай белән мин үзем сөйләшермен,— дип кырт кисте.

Ә Фәләхне, култыклап, җәйге өйләренә алып керде. Өстәл янындагы ике урындыкның берсенә үзе утырды, икенчесенә Фәләхне утыртты да иплән кенә эшнең ничек-ничек булганын сораштыра башлады.

— Башта минем белән сөйләшергә кирәк иде сиңа, малай,— диде ул мәсьәләнең асылына төшенгәч.— Киңәшмичә ялгышрак иткәнсең. Шулай да мин сине гаепләмим, улым. Ул кызга өйләнүең начар түгел. Турысын гына әйткәндә, мин үзем дә шул баланы күрсәтеп карарга дип йөри идем сиңа. Молодец, кешене таный беләсең икән! Бу яктан әтиеңә ошагансың шикелле күренә.

— Рәхмәт, әти, ышануың өчен,— диде Фәләх.— Ләкин әнине ничек көйлибез инде? Өйгә дә кертмичә куып чыгарды бит Розаны.

— Әйт әле, улым, дөресен генә: яратып, үз теләгең белән алып кайттыңмы син ул баланы?

— Ну инде, әти! Әйттем бит, яратып өйләндем дип. Анысына тамчы да шикләнмә! Шуны өйрәтеп әйт: нишләргә тиеш мин хәзер?

— Синме? Син хәзер, беләсеңме?..— Әтисе нигәдер төртелеп калды һәм, куллары белән шап-шоп суккалап, костюм-чалбар кесәләрен капшарга — тәмәке белән шырпы эзләргә тотынды.

Фәләх бик яхшы белеп тора: инде узган кыш ук тартуын ташлаган иде әтисе. «Үкенечен калдырырлык итмәдем, утыз бер ел рәттән тарттым. Инде булды, житте!» — дип кырт кистереп куйган да бүтән авызына да алмаган. Шуңа үзе дә бик куанып йөри: «Авызкайларымның тәмен шул кабих тәмәке генә алып торган икән. Шул хәерсез аркасында гына йөткереп йөрелгән. Кинәндем хәзер: ютәлнең ни икәнен дә белмим, ни ашасам — шуның тәмен тоеп, рәхәтләнеп ашыйм!» — дип яза иде хатларында...

Менә хәзер әтисенең кинәт кенә тартырга эзли башлавы Фәләхкә сәер тоелды. Дөрес, Фәләх үзе дә тарта һәм инде стажлы тәмәкече: сигезенче класстан бирле. Ләкин кайберәүләр кебек, тәүлегенә утызар-кырыгар тапкыр тартмый. Көненә биш-алты сигарет бик житә аңа.

Ул көнне дә Фәләхнең кесәсендә ярты кап чамасы сигареты бар иде. Анысы барын бар, әтисенең тәчергәләнеп тартырга эзләвен дә бик яхшы күреп тора. Ләкин тәкъдим итәргә йөрәге житеп бетми, чөнки аның әле беркайчан да әти-әнисенә күрсәтеп тартканы юк иде.

Аны бу уңайсыз хәлдән әтисе үзе коткарды. Барлык кесәләрен дә кат-кат тикшереп чыгып та ни тәмәкесе, ни шырпысы булмагач, нигә ярдәм итмисең, ник әтиеңне күрә торып тилмертәсең, дигән шикелле итеп карап куйды да:

— Карале, малай, синдә берәр нәрсә юкмы тартырга? — диде.

Мондый чакта эти кешенең гозерен кире кагу — җинаять эшләү белән бер булыр иде. Аннары килеп, Фәләхнең үзенә дә гомер буе яшереп тартырга димәгән, кайчан да булса барыбер сизенерләр иде.

— Менә, монда дус-ишләрне сыйларга дип Мәскәүдән алып кайткан бер нәрсә бар иде,— дигән булып, Фәләх аңа, кесәсеннән алып, кабы белән сигарет сузды. Моны каян алдың, фәлән-фәсмәтән дип, төпченә башламаса ярый инде дип шикләнгән иде ул. Чөнки этисе бер Фәләхкә карата гына түгел, гомумән кеше кулында үзе өчен ятрак, яңарак нәрсә күрсә, каян алдың, күпме тора, дип энәсеннән-җебенә тикле сораштырмыйча туктамый торган иде. Ләкин бу юлы мәсьәләнең ул ягына бер дә игътибар итмәде. Сигарет кабын улы кулыннан йолкып дип әйтерлек алды да, тарткан чагында өйрәнелгән гадәте буенча, баш бармагы белән генә чиртеп чыгарып, бер сигарет капты һәм тагын кесәләрен капшарга — шырпы эзләргә кереште. Фәләх аңа үзенең газ белән яна торган зажигалкасын кабызып сузган иде, этисе ашыгычлык белән сигаретны фильтрсыз башыннан капканын күреп:

— Булмаган әле бу, эти: кире башыннан капкансың бит! Ярар, монысын ташла да, әйдә, бүтәнен кабыз! — диде.

Ләкин малны әрәм-шәрәм итмәү гадәтенә этисе бу юлы да тугрылыклы булып калды. Ничек кенә ашыкса да, теге фильтрсыз башыннан капкан сигаретын ташламады: ирене тиеп юешләнгән җирен генә өзеп ташлады да, дөрес итеп кабып, ут элдерде. Йотлыгып, яңак итләре бер-берсенә ябышканчы суырып, төтенен эчкә алды. Ләззәтен татып, тын да алмыйча, аны берничә секунд чыгармыйча тотты. Тик шуннан соң гына рәхәтләнеп, озак итеп, авыз-борыннарыннан берьюлы чыгарды. Һәм, гаҗәп хәл, шул арада ул тәмам тынычланган, үз асылына кайткан — сабыр-салмак Мөхәммәткә әйләнгән иде.

— Шәп нәрсә икән бу, улым! — диде ата, кулында төтәп торган сигаретның көлен чәнчә бармагы белән ашыкмыйча гына кагып. Бая Фәләх биргән сорауга һаман әле җавап таба алмыймы, әллә аны инде бөтенләй оныткан идеме, ул хакта бүтән сүз кузгатмады. Сигарет кабызганда кесәсенә тыгып торган капны алды да, бер дә ашыкмыйча һәм бик зур игътибар белән, аңа язылган сүзләрне укый башлады. Анда «Мальборо» дип язылган иде. Фәләхнең этисе аны «мал бара» дип тә, «мал буры» дип тә «мал булыр» дип тә укып карады. Ләкин гомаены бик үк дөрес булмавын үзе дә сизенеп булса кирәк:

— Шәп әйбер апкайткансың бит син, малай! Тегеләрнеке мәллә? — дип, гадәтенчә, төпченергә кереште.

Аның «тегеләрнекеме» диюе — чит илнекеме әллә дигән сүз иде. Фәләхнең этисе ялгыша, тәмәке бер нинди чит илнеке түгел, ә үзебезнең гап-гади «Аэрофлот» сигареты булып, тик кабы гына чит ил сигареты «Marlboro»ныкы иде. Ул елларда Мәскәү студентлары арасында бу сигарет бик модада, аны тик чит ил туристларыннан яки үзләре чит илдә булып кайткан безнең туристлардан гына табып була иде. Аны тарту үзенә күрә бер дәрәҗә санала... Ә бит һәркемнең, студент халкының аеруча, бүтәннәр арасында дәрәҗәлерәк буласы, ни белән булса да, берәз аерылыбрак торасы килә. Бигрәк тә кыз-кыркын алдында. Ләкин әлеге сигаретны табу җиңел түгел. Тапкан тәкъдирдә дә сатып алырга кыйммәт: кабы өч сум. Шуңа күрә студентлар аның кабын гына булса да табарга тырышалар, ә эченә үзебезнең сигаретны тутырып йөриләр. Фәләхкә әлеге капны бер группада укыган Мәскәү егете бүләк иткән иде.

Ләкин Фәләх дөресен әйтеп этисенең күңелен төшерергә теләмәде. Чөнки аның алдында хәл итәсе бик зур мәсьәлә тора. Һәм этисе каршында авторитетын да күтәрә төшәргә кирәк иде. Шуңа ул:

— Әйе, эти, аларныкы,— дип шыттырып җавап бирде.

һәм ялгышмады. Аның этисе — гомер-гомергә үзен товарны бер күрүдә танып алучы дип саный торган, күп кенә әйберләрне, чыннан да, шактый дөрес таный торган кеше — бу юлы да сүзе дөрескә чыккангә бик кәефе килеп:

— Менә, күрәсеңме инде, малай! Авылда яшәсә дә, әйберне таный белә бит атаң, ә! — диде. Тагын бер тапкыр тирән итеп суырып, беркавым рәхәтен татып торды да әйтте: — Ну, эшли дә беләләр соң шул Америкада әйберне! Исләренә хәтле үк бүтән бит тәмәкеләренең. Тамакларга сары май булып ятты, сулышларны киңәйтеп җибәрде!

Фәләх аның бу фикере белән һич тә риза түгел. Чөнки белә: безнең сигаретларның иң очсызлы, иң начар дигәннәре дә американнарның иң шәп дигән сигаретларыннан сыйфат ягыннан бер башка югары тора. Бу — күптән билгеле факт. Башка чак булса Фәләх, әлбәттә, этисенә бу хакта әйтер, кирәк булса, дәлилләрен дә китерер һәм дөреслекне ничек тә аңлатыр иде. Ләкин ул көнне андый вак-төяк нәрсәләр хакында бәхәсләшеп, этисенең кәефен бозасы килмәде. Мондый чакта аның җаен җайлап кына торырга кирәк, чөнки Фәләх алдында кичектерергә һич тә ярамый, шул сәгатендә үк хәл итәргә тиешле чамасыз зур мәсьәлә тора бит.

— Я, әйт инде, эти, нишлим мин хәзер? — диде ул, атасының фикерен сигареттан төп мәсьәләгә юнәлтеп.— Әнине ничек ризалатабыз?

Сүзенең кай тирәдә тукталып калуын этисе чыннан да онытткан иде булса кирәк, гаҗәпсенеп Фәләхкә карап куйды.

— Тәк,— диде аннары һаман әле конкрет кына итеп җавап бирмичә.— Значет, син әйтәсең, яратып өйләндем дисең?

— Соң күпме әйттем бит инде, эти!

— Әйтүен әйттең дә, малай, бик алай ашыкма әле син! Өйләнү дигән сүз — өйгә хатын алып кайту гына түгел ул сиңа. Мәгънәсе бик тирән аның, өйләнү дигән нәрсәнең. Үзеңә гомерлек юлдаш, балаларыңа ана булып, йорт-җиреңне, өстеңне-башыңны гөл итеп тота торган кеше булырга тиеш ул сиңа хатын булган кеше. Шуннан соң килеп, ул әле сине яратып, күзеңә генә карап, син берәр җиргә чыгып киткән чакларда сагынып көтеп алырлык булырга да, сиңа хыянәт итмәскә дә тиеш. Бармы әнә шул сыйфатлар син бик ансат кына, безнең белән киңәш-табыш итмичә генә алып кайткан ул балада?..

Чыннан да, бар идеме Розада шул сыйфатлар? Менә хәзер, ул көннән соң инде җиде ел вакыт үткәч, һич икеләнмичә әйтә ала Фәләх: бар иде! Фәләх өчен үлеп торды Роза. Фатирларын да гөл итеп тотты. Фәләх өчен, кызлары Розалия өчен җанын бирергә әзер иде. Кер юу, кием үтүкләү шикелле эшләрне Фәләхнең кулына да тоттырмады. Аңа бер күлмәкне рәттән ике көннән артык кидермәде — алмаштыра торды. Җәй көннәрендә исә һәр көнне яңа юган күлмәк кидертә иде эшкә. Хыянәт дигән нәрсә турында әйткән дә юк инде, бүтән ир-атка хәтта күтәрелеп тә карамый торган иде. Көнләшә дә белми иде хәтта. Аның өчен дөньяда бер Фәләх кенә бар, шуннан башка аңа беркем дә юк һәм кирәк тә түгел иде.

Дөрес, Фәләх боларын теге чакта, этисе сорау биргәндә, белми иде әле. Болары аның соңыннан, бергә яшәгәндә билгеле булды. Ләкин шул беренче тапкыр килен итеп алып кайткан чакта да Розаның турылыклы юлдаш булачагына шикләнми иде Фәләх. Ни өчен дигәндә дәлилләре бар. Әйтик, авыл мәктәбендә укыган елларда җиденче-сигезенче класстан кызлар егетләр белән хат языша башладылар, ә Роза бер кемгә бер нәрсә язмады. Үзенә малайлар язган хатларны укып та тормый, ертып кына ташлый иде. Унынчыда укыганда бүтән кызлар егетләр белән йөри үк башладылар, ә бу — юк. Институтта шулай ук бер дә андый-мондый нәрсәсе сизелмәде. Аңа егетләр карамаганнан

түгел, теләсә, әллә нинди чибәрләре белән йөри алган булыр иде. Ләкин Роза алай очынып, җилбәзәкләнеп йөрмәде. Розаның аш-су әзерләргә оста икәненә дә шиге булмады Фәләхнең. Ул укуын тәмамлап Мәскәүдән кайткан көнне, әнә, нинди матур итеп табын әзерләп куйган иде. Өчпочмак, пилмән, гөбәдия, хәтта теләңне йотарлык тәмле кияү коймагына хәтле бар иде анда. Әле шуңа да бик үк канәгать булмыйча: «газ плитәсе — газ плитәсе шул инде. Ризыкның шарты бик килми. Менә авыл мичендә пешерсәң иде!» — дип сөйләнгән иде. Ә бит аның урынында бүтән берәрсе булса: «Слушай, Фәләхчик, я страшно есть хочу. Бар, кибеткә чыгып йомырка алып кер дә зажарь хотя бы яичницу. Иди, быстрее мой бэби!» — дип, киерелеп, ул әзерләгәнне көтеп утыруы да бик мөмкин иде ләбаса! Роза, әлбәттә, андый түгел һәм алай булмаячак та иде. Шуңа күрә Фәләх этисенә бер дә икеләнмичә җавап бирде:

— Беренчедән, мин аны син уйлаганча ашык-пошык кына өйләнеп алып кайтмадым, эти! — диде ул.— Роза белән без моннан ике ел элек үк язылышкан идек. Тик әнинең холыксызланасын белгәнгә генә сезгә әйтми йөрдек. Икенчедән.— Ул артык нык дулкынланган, шуңа авызы кибеп калган иде. Нишләвен үзе дә белештермичә: — Каяле, миңа да берне бир әле! — дип этисеннән сигарет сорап кабызды. Шуннан соң гына: — Икенчедән, син әйткән сыйфатлар барысы да бар Розада! Һәм, әйдә, эти, бүтән ул хакта сүз куертмыйк. Югыйсә мин дә чыгам да китәм хәзер һәм бүтән әйләнеп кайтмыйм! — дип әйтә алды. Ләкин этисе, һаман шулай бер дә ашыкмыйча гына, үҗәтләнеп сорашуын дәвам итте:

— Артык төпченә бу эти дисәң диярсең, улым, шулай да сорыйм әле үзеңнән: кайсыгызның инициативасы белән эшләнгән эш бу сезнең өйләнешү?

— Ә аны белү сиңа бик кирәкме? — диде Фәләх, түземе ахырына житә башлавын сизеп һәм сүгенүдән бик авырлык белән генә тыелып.

— Әйе, улым, бик кирәк миңа белү! — диде этисе. Фәләхнең шартлап ярылырга житешкәнен әллә аңламый иде, әллә юри аңламаганга салышты — шайтан белсен.

— Алайса бел: миннән булды инициатива! Я, шуннан?

Этисенең йөзе күзгә күренеп яктырып китте:

— Шулаймы? Алайса, ярый бу, малай!

— Нәрсәсе бар инде аның?

— Хикмәте бик зур аның, улым! — Тагын нидер әйтмәкче иде, ләкин бик хәтәр бакылдашып, ишегалларына бер көтү үрдәк кайтып керде дә игътибары бүленде.— Һәй, туймас тамаклар! Кай арада кайтып життегез әле! — дип, үрдәкләрне орыша-орыша, тагаракларына он белән болгаткан ярты чиләк икмәк илтеп салды. Утын бүкәне янында онытылып калган балтаны алып, келәт коймасындагы җепсәгә кыстырып куйды. Үрдәкләр янында тамак ялгап алырга ниятләп, ләкин ишегалдында кешеләр барын абайламыйчарак килеп кергән күрше этенә утын агачы томырды. Ләкин эт, андый хәлгә беренче генә юлыгуы түгел иде булса кирәк, ялт итеп читкә тайпылып калды һәм, табын яныннан кыйнап җибәрелгән бала сыман, чинап елый-елый чыгып китте.

— Әллә саклап ук тора инде: үрдәкләргә ашарга бирдеңме шул хәерсез җан килә дә керә! Ничек тә бер башына житәм әле үзенең! Югыйсә үрдәкләрнең ярты ризыгын шул имансыз ашап бара. Бу кадәр дә хуҗасына ошар икән,— дип, хуҗасының исемен атамыйча гына, теге этне эт итеп сүгеп ташлады.

Ә эт начар түгел. Гәүдәгә алай әллә ни зур булмаса да, кыяфәт шәп: агы — ак, карасы — чем кара йонлы, клиндерләнеп торган матур

койрыклы, утыртма очлы колаклы, моңсу коңгырт күзле сөйкемле генә бер җан иясе.

— Юкка рәнҗеттең, эти, әйбәт эт иде бит! — диде Фәләх.— Ул гына ашап бетермәс иде әле үрдәкләреңнең ризыгын. Бәлки аны бөтенләй үзебезгә ияләштерергә кирәк булгандыр. Әни белән икегезгә бер иптәш булыр, йортны да саклар иде.

— Һыы, ансат кына икән сиңа, ә! Иптәш булырые, имеш. Юк инде, малай, бер эт җиткән миңа. Әнә, әнкәң гомер буе мине талап килә!— диде этисе, шаярткан булып. Аннары, әниләре чыгып тыңлап тормыймы икән дип шикләнеп булса кирәк, болдыр ягына карап алды. Анда беркем дә юк икәненә ышангач, Фәләхкә тик кенә торырга ымлап, аяк очларына гына басып, дәү өйләренең чоланыннан бер ярты ак белән бер коем казылык алып чыкты. Фәләхкә үзе артыннан барырга ымлады да, кече өй янынnan үтеп, бакчаларына узды. Фәләх тә аның янына кергәч: — Хәзер, улым, хәзер! Барысын да тәртипкә салабыз аның! — дип сөйләнеп, бакчаның капкасын эчтән кела белән генә түгел, йозак белән үк биклән куйды.

Шәп иде ул бакчада! Чәчәкләр, карлыган яфрагы, бөтнек, юкә балы исе һәм тагын әллә нинди хуш исләр аңкый иде анда. Этисенең җиде баш умартасы бар. Көн бик җылы, кояшлы һәм җилсез булганлыктан, кортлар ашыгып-ашыгып бал ташый — бөтен бакча гөж килеп тора иде. Күрәсең чит кеше икәнен сизенептер, алар Фәләх тирәсендә бик хәтәр кайнаша башладылар. Фәләх, үзе дә сизмәстән кулларын селтәп, аларны куа башлаган иде, этисе:

— Алай чапаланма, малай. Син аларның ачуын гына китерәсең. Шәһәр исе килә үзеңнән, шуңа яратмый алар. Хәзер, мин болай итәбез аны,— дип төтенлегән алып килде дә, кабызып җибәреп, өрдерә башлады. Кортлар шундук Фәләх тирәсеннән киттеләр һәм этисе аны бакча эчендәге бакчага — тышкы яктан үскән колмаклар белән капланган зур гына бер бүлмәгә алып керде. Анда аяк башлары матурлап эшләнгән бик әйбәт агач караваt, ике тумбочка, кирәк чагында зурайтып та була торган түгәрәк өстәл, дүрт урындык тора һәм әле тагын унлап кеше танцы итә алырлык буш урын бар иде. Бу яшел бүлмә әле Фәләх өчен яңа нәрсә.

— Кайчан ясадың, эти? — диде Фәләх этисенең эшләклелегенә сокланып.

— Өченче ел ук инде. Нигә, әллә күргәнең дә юк идеме?

— Юк иде шул. Узган ел авылга ике генә көнгә кайтып киттем ич, бакчага кереп торырга вакыт та булмады. Ә куышың шәп, эти!

— Шәп булырга тиеш тә. Мин бит аны килен белән сиңа дип ясаган идем.

— Ясавын ясагансың да, киленне куып чыгардыгыз бит әле.

— Син, малай, сөйләгәндә сүзеңне алай уйламыйча гына әйтеп ташларга ашыкма! — диде этисе, Фәләхнең төрттереп куюын яратмыйча.— Бер минем янда гына түгел, вообщем, бүтән кешеләр арасында да сүзеңне уйлап-үлчәп сөйләргә кирәк. Атаң монда нипричум икәнен белеп торасың, ә үзең... — Ул шулай сөйләнә-сөйләнә тумбочкадан йөз граммлы бәләкәй стакан алды, тутырып аракы салды да, Фәләхкә ымлап: — Синең бу яктан эшләр ничек? Тоткалаганың бармы? Булса — миннән тарсынып торма. Салып куярга мужыш. Чамалап кына, сирәкмирәк кенә зыяны юк аның. Әгәр инде тотканың юк икән — кирәкми. Файдалы нәрсә түгел.

Билгеле инде, Фәләхнең тоткалаганы бар иде. Институтта дуслары күп булды. Кайсының туган көненә, кайсының нинди дер бүтән бер шатлыклы вакыйгага уңае белән оештырылган «капустникларда» катнашырга еш туры килә иде. Кешегә үзең бардыңмы, син дә аны чакырырга тиеш буласың. Шулай итеп, андый мәҗлес-кичәләр ел тәүлегенә

байтакка җыела торган иде. Ә акча мәсьәләсендә Фәләх биш елга бер тапкыр да кытлык күрмәде. Әтисе белән әнисе икесе бергәләп тә, Фәләхкә яхшы атлы булырга теләп, бер-берләреннән яшереп тә, ул җәйге һәм кышкы каникулларга кайткан чакларда кулына биреп тә җибәрәләр, перевод белән дә ай саен диярлек салып торалар иде. Шуның өстенә стипендиясе дә килеп торды. Теләгән чагында Мәскәүнең иң шәп рестораннарына да керә ала, кинотеатрларына да бара ала иде. Салуын да салгалады. Әмма, кайберәүләр кебек, исергәнче эчеп, баш югалтып йөрмәде. Ә менә әтисе алдында әле беркайчан да эчкәне юк иде. Хәзер дә, әтисе кыстап торса да, эчүне кирәк тапмады:

— Ярар, әти, кыстама инде син. Теләсәң үзең тотып куй да, әйдә, киңәшеңне әйт: нишләргә хәзер миңа Роза белән?

Нәкъ шул сүзләрне әйткәнен генә көтеп торган иде бугай — әтисе ялт итеп теге стаканны каплап куйды. Ачысын бетерү өчен, тиз генә бер телем казылык алып капты. Авызы буш булмаганга, кулы белән генә ишарәләп, Фәләхкә дә ашый башларга кушты.

...Казылык күргәч Фәләхнең күз алдыннан теге беренче курста үткәрелгән кичә, группадашлары һәм Наилә чагылып китте. Ул да казылык алып капты һәм әтисеннән җавап көтә иде. Ләкин әтисе һаман әле нигәдер суза. Әллә аның үзенең дә бу мәсьәләдә конкрет кына фикере юк, әллә булып та әйтергә ашыкмый. Фәләхнең нервлары ныклыгын сынап карарга тели идеме — анысын шайтан белгән. Әмма ул теге йөз граммны эчеп куйгач та фикерен әйтмәде. Фәләхнең ачуын китерергә теләгәндәй, тагын бер кат:

— Димәк, тапышлыгыгызның башы синнән башланды дисең? Тугнымы бу, улым? — дип сорады.

— Күпме әйтергә кирәк инде әти, бер сүзне? — диде Фәләх, җен ачулары чыгып.

— Син алай крута алма әле, малай,— диде әтисе гадәтенчә бер дә ашыкмыйча гына.— Әниең белән без сине тудырган, үстергән, белем биргән. Сине кеше итәр өчен күпме борчулы көннәр, күпме йокысыз төннәр үткәргәнбез. Шулай булгач, синең киләчәгеңә дә битараф булып кала алмыйбыз. Ә синең киләчәгең, иң элек, кемгә өйләнүеңә, кем белән тормыш итүеңә бәйле булачак. Рас мин җентекләп сорашам икән, синең киләчәгеңне матур итеп, әйбәт итеп күрергә теләгәннән сорашам. Тагын да конкритрәк итеп әйтсәк, эш менә болай тора: әгәренки ул баланы син үзең яратып, артыннан йөреп алган булсаң, мин синең өйләнүеңә каршы түгел. Хуплыйм да әле мин сине, әгәр шулай булган булса. Ни өчен дигәндә, егет кеше үзе белән бергә тормыш итәрдәй парны үзе сайлап алырга тиеш. Дөрес, тормыш булгач, анда әллә нинди көтелмәгән нәрсәләр дә килеп чыга кай чагында. Ләкин андый чакта син инде бүтән беркемгә дә түгел, үзеңә үпкәләргә тиеш буласың... Син, ихтимал, үзең дә сизенәсеңдер, әниең белән шактый четерекле хәлдә яшибез без. Чит кешеләргә ул, бәлки, беленми дә торгандыр. Аларга без, киресенчә, бик тату, бик яратышып яши торган бәхетле кешеләр булып күренәбездер. Чөнки үзебез шулай күренергә тырышабыз. Ләкин асылда без алай бик үк яратышып тормыйбыз, улым. Сүзем юк, чибәрлеге дә, эшкә уңганлыгы да бар әнкәңнең. Әмма ләкин, әгәр яшьлегемә яңадан кайту, яңадан бер өйләнергә мөмкин булса, мин синең әниеңә түгел, бәлки әнә шул Розаның әнисе Рәйханәгә өйләнер идем! Пусть, ул әниең шикелле чамадан тыш уңган да булмасын, пусть ул азрак хыялыйрак та булсын. Безнең, ихтимал, менә хәзерге шикелле машинабыз да, гаражыбыз да, алпут йорты шикелле зур-зур ике өебез дә булмас иде. Тик барыбер мин аның белән яшәүне артыграк санар идем. Чөнки мин аны чын күңелемнән яраттым... Әйе, Рәйханәнең аты чыккан. Тормышы да әллә ни мактарлык була ал-

мады. Ләкин бит, улым, болар барысы да минем аркада шулай килеп чыкты. Кыз чагында аннан да инсафлы, аннан да тыйнак кыз юк иде авылда. Минем өчен үлеп тора иде ул. Мин дә аның өчен утына да, суына да керергә әзер идем. Ләкин менә шушы әниең арага кысылып, минем башны әйләндерде, улым. Мин синең әниеңә өйләнгәннән ары гына кешеләргә һәм бөтен дөньясына иманы сынды Рәйханә апаңның. Шуннан соң гына ул, барысына да төкереп, бүтәннәр белән йөри башлады. Аның бәхетле була алмавына, барыннан да элек, мин гаепле, улым.— Сөйләвеннән шунда туктап, бераз уйланып торды Фәләхнең этисе. Тагын бер рюмка аракы эчеп куйды. Казылык кисәге алып капты. Әниләре чыгып бакча капкасы буенда тыңлап тормыймы икән дип булса кирәк, койма буен да карап килде. Аннары, кулын Фәләхнең иңенә куйды да: — Ә син, улым, минем шикелле ихтыярсыз булма, ярме! Ниятеңнән чигенмә! — диде...— Рас шундый багалмасы шикелле кызны кулыңа төшергәнсең икән, ычкындыра күрмә! Бар, хәзер үк өйләреңә бар да бая ялгызын гына чыгарып җибәргәнең өчен гафу үтен. Гафу үтен һәм ул ничек дисә — шулай эшлә. Әмма өйгә алып кайтма. Чөнки әниең барыбер кертмәячәк. Ул бала ничек дисә шулай ит. Казанга китик дисә, бүген үк Казанга китегез. Авылда әнисе янында торып торыйк дисә, ял вакытыгыз бетеп эшегез башланганчы аларда торып торыгыз. Минемчә, Казанга китеп баруыгыз хәерлерәк булыр. Икегез дә шунда эшлисе кешеләр, икегез дә яшь белгечләр. Фатирын үк бирмәсәләр дә башта тулай тораактан ничек тә бер бүлмә биреп торырлар әле. Яңа өйләнгән чакта расхут була ул, улым. Мәле, кесәңә салып куй шуны, кирәк-ярагыңа тота торырсың! — дип әтисе Фәләхкә, паспорт тышлыгы арасына кыстырып куйган җиреннән алып, дүрт данә йөзәр сумлык сузды.— Әниеңнән яшереп йөртә торган запастан — без военныйча итеп «НЖ» дибез — незнает жена, була значит бу. Курыкма, ал. Аннары тагын, берәр җаен табып, күбрәк итеп я почта белән салырмын, я үзем илтеп кайтырмын,— дип тә өстәп куйды.

Әтисе хаклы, Фәләхкә акчаның иң кирәк чагы иде. Булган хәтлесен ул башта Мәскәүдә иркенрәк кыланып, аннары Казанга кайткач, Розага кияү бүләге итеп күлмәк алып, бөтенләй диярлек тотып бетергән иде.

Чамасыз озак көттереп, урап-урап йөргәннән, бик нык төпченгәннән соң гына әйтсә дә, этисенең конкрет тәкъдиме ошады Фәләхкә. «Ни әйтсәң дә, ир-ат ир-ат шул, хәлне дөрес аңлады бит. Молодец, картаймагансың икән әле, әти!» — дип күңеленнән рәхмәт укып куйды.

— Ә әниис ничек көйләрбез икән соң? — диде ул этисенә.

Әнисенең бу очракта хаксыз икәнлеген, ничек кенә чәбәләнеп азапланса да, барыбер аныңча булмаячагын Фәләх бик яхшы белә. Әмма шул ук вакытта, аны рәнҗетәсе, каргышын аласы да килми, чөнки, ни дисәң дә, ул бит аны тудырган, кадерләп үстергән, хәзер дә, үзенчә, балам әйбәт булсын, бәхетле булсын, дип борчылып йөри. Әтисе дә шулайрак уйлыйдыр, шулай уйларга тиеш шикелле иде. Ләкин, ни хикмәттер, бу мәсьәләгә аның бер дә исе китмәде:

— Бүтән хәсрәтең булмаса,— диде ул,— аның өчен хәзергә баш ватма. Аның белән бу хакта сөйләшүдән хәзергә файда юк. Тора-бара, менә күрерсең, барысы да үзеннән-үзе җайланыр әле. Бар, улым, киленне зарыктырма!

## 14

Фәләх ашыгып һәм, ни булыр икән дип, бик куркып килеп кергәндә, Роза, юлдан кайткан киемнәрен дә салмаган килеш, диванныарына йөзтүбән капланып елап ята, ә әнисе аның янына утырган да, чәчләреннән сыйпап, юатырга тырыша иде.

Очрашу шушылай буласын башына да китермәгән иде ул. Рәйханә ханым җәйләүдә сыерлары янындадыр, сөйләшү-аңлашу Роза белән икәү араларында гына булыр, дип уйлады. Шуңа хәзер ул тәмам коелып төште:

— Исәнмесез? — диюдән башка ни әйтергә дә белмичә, тегеләрнең ишек төбендә тукталып калды.

Куркуы нигезсез түгел. Рәйханә ханымның талканы бик коры: бер кызып китсә утлар чыгарып, яшеннәр яшьнәтмичә туктамый торган иде ул. Бу юлы да шулай булмагае дип шикләнгән иде Фәләх. Шиге дөрес булып чыкты: әйбәт каршыламады аны Рәйханә ханым.

— Әй, иблис токымы! Тәки кызымның башына җиткәнсең икән! — диде ул, Фәләхнең сәламен дә алып тормыйча. Ефәк косынкасыннан бөркелеп чыгып торган аксыл бөдрә чәчләрен рәтләп алды. Кече якка кереп, зур-зур бизәк төшерелгән чип-чиста сөлге алып чыкты. Роза янына килеп:

— Ярар, кызым, ул кадәр үрсәләнмә. Мә, битләреңне сөрт. Тор, әнә Фәләх килгән анда,— диде.

Роза торырга ашыкмады. Борылып кына карап алды да һаман шулай елап ята бирде. Аның битләре, күз кабаклары шешенеп чыккан, хәтта күзенең зәңгәрлекләренә хәтле тоныкланып калган шикелле иде. Шулай да ул элеккечә чибәр, күңелгә якын. Фәләхнең аны, сабый баланы сөйгән шикелле, битләрен, күзләрен үбә-үбә сөясе килә иде. Ләкин бу әлегә мөмкин түгел. Иң элек аны ничек тә юатырга, көйләргә кирәк. Һәм, әлбәттә, әнисен дә... Ләкин ничек итеп?

— Тор әле, Роза,— диде ул, шуннан да яхшырак сүз таба алмыйча.— Әйдә, сөйләшик!

— Нәрсәсен сөйләшәсең инде аның,— диде Роза, тагын да ныграк елап җибәреп.— Болай да. Һыһ-һыһ,... бөтене... һыһ, һыһ... се... һыһ, һыһ... ачык бит...

Шулай да, акрын гына торып, күз яшьләрен сөлге белән сөртә башлады үзе.

Менә шунда Фәләх бер нәрсәне сизеп алды: Роза аның килүен көтеп кенә елап яткан. Моңа ул бик шат. Ә елавын хәзер болай гына, формасы килсен өчен генә елый иде. Шуны төшенеп алгач, Фәләхнең күңеленә җылы керде. Ул, шактый ук йөрәкләнеп:

— Ник бер дә юкка исең китте? Әни белән яшисе түгел бит сиңа, минем белән яшисе! — диде.

Бу сүзләрне ул Розадан бигрәк аның әнисе өчен әйткән иде. Рәйханә ханым да, эләп алып, әйе шул, кызым, дип Розаны юата башлар дип көткән иде. Ләкин ул эреп китмәде. Бер сүз әйтмичә, каш астыннан гына Фәләхкә карап алды да шуның белән бетте. «Сөйләвен сөйлисең дә бит, мин сиңа барыбер ышанмыйм, егет», дигәнне аңлады Фәләх аның карашыннан. Һәм сөйләшү тактикасын үзгәртергә булды.

— Шулай бит, әби? Дөрес әйтәм бит мин, әйеме, әби? — диде ул, Рәйханә ханым аның яклы булуга һич тә шиге булмаган кеше шикелле итеп.

Бу — Фәләхнең аңа беренче мәртәбә «әби» дип эндәшүе иде. Һәм бу сүз Рәйханә ханымга тиешле тәэсирен ясар: бөтенләй үк эретеп җибәрмәсә дә, күңелен йомшартыр дип өметләнде ул. Әмма алай булмады.

— Әби дип әйтер өчен, башта минем кызыма өйләнергә рөхсәт алырга кирәк иде сиңа! — диде Рәйханә ханым кырыс кына итеп.— Бар, кайт өегезгә дә, бүтән бу тирәгә килеп, әти-әниеннәрнең дә, безнең дә башны әйләндереп йөрмә! Беләм мин синең ананны: Розага да, сиңа да, этиең белән миңа да көн күрсәтәчәк түгел ул. Болай да гомер буе талап килә мине. Кодагый дип мәңге дәшәчәк түгел ул миңа. Үземнең дә кодагый булып аның белән бер табында утырасым килеп тормый. Бар, олан, бар, үз юлыңда бул! Әле эш узмаган: язылышсагыз да, бергә то-

ра башламаган, кешегә фаш булмаган эле сез. Үпкәләмә, үзеңне хөрмәт итсәм дә, кызымны бирә алмыйм мин сиңа.
Энисе шушы сүзләрне әйткәч, Роза түзеп тора алмады: кулындагы сөлге белән битен каплады да җеше як бүлмәгә йөгереп кереп китте һәм тагын, бу юлы инде кычкырып ук, елый башлады. Шуннан соң Фәләхнең бөтен бәгырьләре айкалып китте һәм ул, тиз генә килеп, Рәйхана ханымның иңнәреннән тотты да:
— Эби, давай ачуны чыгарма, яме! Безгә аяк чалма. Без инде Роза белән ике ел торабыз һәм бер-беребезне яратабыз! Син, эби, минем нервларны кузгатма! Ул нерв бер купса, беләсеңме нәрсә булачак?! — диде һәм, нәрсә булачагын үзе дә белмичә, гаҗизләнеп тертелеп калды.
Болай да ачулы, үзен кыенлык белән генә тыеп торган Рәйхана ханымның җенен чыгарырга Фәләхнең шул сүзе бик житте: аның яшькелт-зәңгәр күзләре кысылды, әле генә искиткеч ягымлы һәм кызларныкыча чибәр йөзенә кан йөгереп, кызарып чыкты:
— Яле, я, я!— диде ул, Фәләхкә таба, баласын яклап һөҗүмгә күчкән ана юлбарыс шикелле, ыргылып.— Ни эшләтмәкче буласың мине, алай бик кодрәеп? Синнән дә курка торган булсам, күптән куркып үлгән булырыем инде мин. Күп куркытырга тырышып карадылар инде мине бу дөньяда! Бар, алай бик әтәчләнәсең икән, сыпырт әле моннан тизрәк! — дип Фәләхнең жиңеннән эләктереп алды да өйләреннән ук чыгарып җибәрде.
Фәләх карышып тору түгел, ни булганын абайламый да калды хәтта. Кире кереп, хатын-кыз белән бәйләнешеп йөрү дә килешә торган эш түгел иде.
Тегеләрнең капка төпләрендә япа-ялгыз басып торганда гына өенә килде ул. Үзенең хатын-кыз шикелле вакланып, янауга күчеп, нинди зур ялгышлык эшләвен бөтен тулылыгы белән тик шунда гына аңлады: «Эби буласы кеше белән шулай сөйләшергә тиешме соң инде егет кеше? «Нервымны кузгатма» имеш! Сөекле хатынының энисенә әйтелә торган сүзме инде шушы? Их, егет, егет! Егет түгел, борының тулы җелек икән синең» — дип орышты ул үзен. Һәм бик дөрес орышты.
Хәзер инде яңадан кереп сөйләшеп караудан мәгънә юк. Мондый хәлдә Роза үзе дә энисе сүзеннән чыкмас иде. Э бит Роза аның законлы хатыны да инде. Шулай булгач, кабат кереп сөйләшеп карау әллә ни гайре табигый нәрсә булырга тиеш түгел шикелле иде. Кайбер киявләр, ана, эбиләре белән болай гына кыланамы соң? Тегеләре киявемҗаным дип кенә торсалар да, бер юктан сәбәп табып, кирелек өстәп, эбиләрен гомер буе дер селкетеп тота торган кияүләр азмы бу дөньяда?.. Э Фәләх беркайчан андый хөсетле булмаячак. Кызын ярата икән, ул кызны табып үстергән эбисен дә үз энисе шикелле якын итеп торачак.
Ләкин Фәләх Розаларның капка төбендә торган ул минутларда Рәйхана ханым пәри хатыны булып тоела иде ана. Мангаена мылтык терәп торсалар да, баш иеп, гафу үтенеп аның катына кире керәчәк кеше түгел иде ул. Эмма, берни майтара алмыйча, борылып кайтып китү дә егетлек түгел. Бер Фәләхкә генә түгел, аларның бөтен нәсел-нәсәбе абруена тап төшерү булачак иде бу. Э андый тапны төшерергә һич тә ярамый, чөнки алар нәселе борыннан килә торган атаклы нәсел. Энисе ягыннан бигрәк тә. Заманында бөтен татар дөньясына исемнәре билгеле булган Гарифҗан, Габдуллаҗан, Сабирҗан, Салихҗан хаҗилар токымы ул! Этисе ягында андый укымышлылар булмаган булуын. Ләкин анысылар да кемгәдер бил бөгеп, ялланып хезмәт итеп йөргән кешеләр түгел. Бакый заманнан бирле ат белән, тире белән сату итеп килгән. Мәкәрҗә ярминкәсенә генә түгел, хәтта чит илләргә хәтле баргган алар. Шулай булгач, нигә бер Фәләх кенә ниндидер бер тол хатын алдында җебеп төшәргә тиеш иде әле?!

Уйлана торгач, Фәләх мәсьәләне хәл итү өчен менә мондый компромисслы юл тапты — тегеләрнең урам як бакчаларына керде дә, ачык тәрәзәдән башын тыгып:

— Роза! Әгәр бергә яшәргә теләсәң, әйдә хәзер үк чык урамга. Минем янга! — диде.

Бу вакытта ана белән кыз иске бер диванга утырган килеш, сүзсез генә җылашып утыралар иде. «Минем аркада шушылай күз яше түгә бит инде болар. Дөресрәге, минем әни аркасында. Ул холыксызланмаган булса, без хәзер ике гаилә бер булып, рәхәтләнеп, куанышып утырган булыр идек»,— дип уйлап алды Фәләх. Аның үзенең дә тегеләргә кушылып елыйсы килеп китте. Ләкин аңа, атаклы нәсел вәкиленә, минутлык хискә бирелеп, дәрәҗә төшереп, йомшаклык күрсәтү килешмәс шикелле тоелды. Шуңа ул үзен кулга алды һәм Розаның җавабын да көтеп тормастан:

— Мин сине капка төбегездә көтәм. Ун минуттан чыгып җитмәсәң, үзеңә үпкәлә! — диде дә бакчадан чыкты. Сәгатенә карады: кичке дүртенче унике минут иде. «Егерме ике минут булганда чыкмаса, артык бер секунд та көтмим. Башта ук мәлҗерәп төшеп, дилбегәне кулдан ычкындырырга ярамый»,— дип күңеленнән үзенә-үзе катгый карар кылып куйды да — көтә башлады. Ә көткәндә, бигрәк тә әнә шундый ышанычсыз чакта, секунды — көн, минуты — ел булып тоела икән. Ике-өч минут үткә Фәләхнең болай да чамасыз нык борчылуы күңелләрен болгатып уйнаклый башлады. Ичмаса игътибарын җәлеп итеп, аз гына булса да Розаны оныттырып торырлык нәрсә дә күренми иде урамда. Аптырагач, читлектәге бүре шикелле, капка төбендә арлы-бирле йөрергә тотынды ул. Ашыга-ашыга кесәләрен капшап, тартырга эзләде. Бая, юмартланып китеп, теге «чит ил сигаретын» кабы белән этисенә биреп калдырганы өчен үзен-үзе эт итеп тиргәп алды.

Шул чакта Розаларның бер тавыгы, күрәсең йомырка салып булса кирәк, әвеслек тезмәләреннән очып төшеп, шатлыгын бөтен авылга җиткерергә теләгәндәй бик хәтәр кытаклап, капка астыннан урамга килеп чыккан иде. Фәләхкә ул да ошамады: «Ниемә шул кадәр дөнья бетереп кытаклыйсың, алтын күкәй салмагансыңдыр бит!» — дип аны куып кире кертеп җибәрде. Бу вакытта тегеләрнең этәчләре, әлеге өй каршындагы бакчада нидер тапкан да, «кот-кот-кот» дип, тавыкны үз янына чакыра башлаган иде. Фәләх тавыкны куркытып җибәргәч, этәчнең ачуы чыкты ахрысы: калын һәм ямьсез итеп «крррк» дип кычкырып куйды. Фәләхкә ул «дуррак!» дигән шикелле булып ишетелде. «Син үзең ахмак!» диде аңа Фәләх, җен ачуы чыгып. Ул моны кычкырып түгел, эченнән генә әйткән иде. Ләкин этәч ишетте генә түгел, хәтта Фәләхнең сүзләрен дә аңлаган шикелле: койма буена килеп, башын рәшәткә арасыннан бу якка тыкты да, муенын кыегайтып, кызыл бәбәкле түгәрәк күзен туп-туры текәп, берара Фәләхкә карап торды. Аннары ярыктан башын алып, тирә-якка тузаннар туздырып, гайрәтләнеп канатын какты һәм киерелеп ике тапкыр рәттән «Ки-ке-ри-күүүк!» дип кычкырды. Аның тавышы Фәләхкә «бар кай-тып ки-иинт!» дигән шикелле булып тоелды...

Монысы инде чамадан тыш мыскыллау иде. Фәләх түзмәде: койма буеннан таш кисәге алды да этәчкә томырды. Ләкин андый гына һөҗүмнәрне күп күргән карт этәч, ялт кына сикереп, таштан котылып калды һәм «Кот-кытак!» дип Фәләхне мыскыллап куйды. Аннары, нәкъ шул мәлдә генә бакчадан, карлыган куаклары арасыннан килеп чыккан ак тавыкка таба ташланды...

Күпме генә акрын булса да, вакыт барыбер үтә торды. Фәләх капка төбенә чыкканга инде унҗиде минут үткән, ә Роза һаман юк иде әле. «Тагын нәкъ өч минут көтәм дә, өч секунд та тормый китәм. Һәм бүтән бу йорт ягына әйләнеп тә карамыйм. Алланың кашка тәкәсе түгелдер

әле, андыйны гына табармын!» дип катгый итеп күңеләнә беркетеп куйды Фәләх. Ләкин егерме минут та үтте, егерме биш минут та узды, әмма ул тегеләрнең капка төбеннән һич кенә дә китә алмады. Ниндидер күзгә дә күренми, аңлап та булмый торган бер көч җибәрми тора иде аны. Ул китүгә Роза килеп чыгар шикелле иде. «Ярар,— дип уйлады ул Роза егерме биш минуттан да чыкмагач.— Көткән-көткән ярты сәгать торыйм инде. Бәлки гаеп гел Розада түгелдер — үзе чыгарга теләсә дә, әнисе чыгармыйдыр, бәлки...»

Ярты сәгать үткәч тә чыкмаган иде әле Роза. Өйләрендәге тынлыкка караганда, гомумән чыгар чамасы сизелми иде. Моннан ары да көтеп тору — чамадан тыш түбәнчелеккә төшү булыр, Роза алдында гына түгел, бөтен авыл халкы алдында хурлыкка калу булыр шикелле тоелды Фәләхкә. Чыкмаска булгандыр ахры... Ярар, болай булгач, шунсы әйбәтрәктер дә әле. Әнисе сүзеннән уза алмый торган мондый йомыкый кеше белән барыбер әллә кая барып булмас әле. Ярар, эшләр зурга киткәләгәнче, шушында нокта куярга кирәк. Әни әйтмешли, «аның ише кызны гына тапмаслык егет мени мин?» дип уйлаган иде Фәләх. Тәмам өметен өзеп, тегеләрнең капка төбеннән китеп бара башлаган иде. Шул чакта урам ягындагы ачык тәрәзәдән Розаның да җанга якын тавышы ишетелде:

— Фәләх, торып тор, мин хәзер чыгам!..

Шул көнне ун минуттан китеп бармавы өчен соңыннан куанып бетә алмады Фәләх. Чөнки Розаның үзендә гаеп юк, аның тоткарлануы тик әнисе аркасында гына булган иде.

— Әйт әле, кызым, син ул егетне чын-чынлап яратасыңмы? — дигән әнисе, Роза Фәләх янына чыгар өчен тәкатьсезләнә башлагач.— Соңыннан үкенмәссеңме, балам?

Ә Роза молодец! Күңеленнән шикләнсә дә, әнисенә өздереп җавап биргән:

— Яратам, әнием, бик-бик яратам мин аны! — дигән.— Син борчылма, әнием, үкенмәм! Барысы да әйбәт булыр!

## 15

Фәләх Розаны шул ук көнне туп-туры Казанга алып китте. Аны Мәскәүдә үк Казандагы автотранспорт берләшмәсе карамагына эшкә тәгаенләп җибәрделәр. Аның җәйге ял вакыты бетәргә әле айдан артык вакыт бар, эшкә август ахырында гына чыгарга тиеш иде. Шуңа ул берләшмәнең генеральный директорына кергәндә, нигә болай вакытыннан алдан килдең дип әйтмәсә ярый инде, дип шикләнебрәк кенә кергән иде. Ләкин шиге урынсыз булып чыкты. Генеральный аны нәкъ вакытында килгәнсең, егет, бер кешене бишкә бүләргә йөри торган чагыбыз, халыкның җәйге ял вакыты бит, курорт сезоны, дип бик хуплап каршы алды. Тәҗрибәң җитмәс, булдыра алырсың микән дип тормады, шундук аны зур бер автохуҗалык идарәсенең баш инженеры урынбасары итеп билгеләргә дигән приказ әзерләргә әмер дә бирде. Идарә начальнигы белән идарәнең баш инженерын чакыртып алып:

— Менә, иптәшләр, сезгә күптән көтелгән яшь белгеч. Мәскәүдә укып кайткан. Мәскәүдән безгә беркайчан да начар белгеч җибәрми торганнар иде, монысы да сынатмас дип уйлыйм. Давайте, мин инде приказ әзерләргә куштым, бүгеннән үк эшкә тотынсын,— дип Фәләхне тегеләргә ияртеп үк җибәрмәкче булды.

Ләкин Фәләх аның янына эшкә бик атлыгып торганнан түгел, торыр урыны булмаганга килгән иде бит. Ул шул хакта сүз каткач, генеральныйның әле генә балкып торган йөзе, кинәт теше сызлый баш-

лаган кешенеке шикелле, сытылып китте. Өе биек, өйрәсе сыек дигәндәй, иseme зур булса да, берләшмәдә торак мәсьәләсе иң читеннәрнең берсе, унбишәр ел чиратта торучыларның да әле һаман фатир ала алмаганнары бар икән. «Сине, яшь белгеч буларак, алай ук озакка сузмабыз сузуын,— диде аңа директор.— Алдагы бер-ике елда ничек тә тәэмин итәргә тырышырбыз. Ләкин хәзергә берни дә вәгъдә итә алмыйм — мөмкинлек юк».

— Гомуми торагыгыз бардыр бит? Мин шунда торып торырга да риза.

— Биш йөз урынлы бер тулай торак салып ятабыз. Яңа елга өлгерергә тиеш. Шуннан җаның теләгән бүлмәне үзең сайлап алырсың. Ләкин гамәлдәге тулай торакларның берсендә дә буш урын юк.

— Алайса мин берәр атнасыз эшкә керешә алмыйм. Чөнки без әле генә авылдан килдек. Хатыным урамда көтеп тора. Безнең хәтта кереп кунар җиребез дә юк. Миңа берәр гостиницага урнашып торырга ярдәм итсәгез иде, һич булмаса.

Генеральный Фәләх эшли башлаячак идарә башлыгына, син мине бу бәладән коткар инде, ничек тә үзең урнаштыр шунда, дигән сыман итеп карап куйды. Тегесе аны шундук аңлады һәм:

— Ярар, Андрей Савельевич, хәл итәргә тырышырмын. Киттек, энекәш! — дип Фәләхне директор кабинетыннан алып чыкты да, приемныйдан гына гостиница директорына шалтыратып, ике минут эчендә урын мәсьәләсен хәл итте.

Аннары Фәләх белән Розаны, машинага утыртып, гостиницага илтте. Аларның документлар тутырып, номерга ачкыч алуларын көтеп торды да, Розага:

— Син, сеңлем, үзең урнаша алырсың бит инде? Ирең миңа бик кирәк, син ачуланма инде, яме,— дип Фәләхне идарәгә эшкә алып китте.

Берничә көннән идарәнең баш инженеры ялга китәргә тиеш икән дә, ул киткәнче азрак эш рәтенә төшенә торсын дип, идарә башлыгы шуңа ашыктырган икән...

Идарә башлыгы Галәветдин Зәйнетдиновның баштан ук үз итеп, энекәш дип эндәшүе аркасында шулай булды, ахрысы: пеләш башлы, ачыңаклы, кечерәк кенә чандыр гәүдәле ул агайны Фәләх беренче көннән үк үз абыйсы кебек якын итә башлады. Ул кушкан эшләрнең барысын да җиренә җиткереп, вакытында үтәргә тырышты. Кайберәүләр кебек, эш сәгате бетте дип, кайтып китәргә ашыкмады, кирәк чакта кичләрен калып та эшләде, иртән дә алданрак килә торган булды. Галәветдин агай да, башкалар да Фәләхнең бу тырышлыгын күрделәр, аңа да яхшылык белән җавап бирделәр. Хуҗалык аппаратында инде унар ел эшләп килгән өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк инженерлар булса да, баш инженер пенсиягә киткәч, аның урынына аларны түгел, нибары дүрт ел чамасы гына эшләгән булса да, Фәләхне куйдылар. Ике ел ярым дигәндә, шул ук Галәветдин агай «перспективалы, тырыш кеше» дип, хәтта министрлыкка, шәһәр комитетына кадәр барып җитеп, Фәләхкә өч бүлмәле фатир юллап бирде. Һәм моңа беркем дә гаҗәпләнмәде. Чөнки Фәләхнең гомуми эш өчен тырышып йөргәнен барысы да күреп торалар иде.

Шул ук вакытта Фәләх фәнни эш белән дә арасын өзмәгән, үзе укып чыккан институт каршында читтән торып аспирантурага да кергән иде. Дөресрәге, диплом язганда аның җитәкчесе булган Евгений Андреевич Соломоновны Фәләх Казанга кайтып эшли башлагач кафедра мөдире итеп күтәргәннәр иде дә Фәләхне Евгений Андреевич үзе чакыртып алган иде. «Укырга теләүчеләр булмаганнан чакырган икән дип уйлама. Мине ал да мине ал, дип йөрүчеләр уннан артык. Начарлар да түгел, аспирантураны тәмамлаганда диссертация дә язып өлгертә ала торган сәләтле кешеләр. Ләкин миңа саф галим булу гына җитми. Белемен практик

эштә куллана алырдай кеше кирәк. Менә синең шикелле егет кирәк миңа»,— дигән иде ул Фәләхкә. Кандидатлык минимумын тапшырган чагында исә Фәләхкә кайда ничек итәргә, кем белән ничек сөйләшергә икәнен әйтеп, ә кирәк булганда аның өчен хәтта үзе дә сөйләшеп, ярдәм итеп торган иде. Фәләх үзе дә тәпле белем кирәклеген бөтен җитдилеге белән аңлый. Имтихан тапшыру өчен генә түгел, мәгълүматы артсын өчен, бөтен күңелен биреп укый иде. Әгәр шушы Гасимә белән бәйләнешеп китмәгән булса, ихтимал, инде кандидатлык диссертациясен дә әзерләп бетергән булыр иде. Эшләр шуңа таба бара: аның диссертациясен гыйльми советта тикшереп һәм уңышлы дип табып, бераз төзәткәч, яклауга тәкъдим итмәкчеләр иде. Ләкин... һич тә уйламаганда бөтен планнары чәлпәрәмә килде.

Ә бит, дөресен генә әйткәндә, начар яшәми иде алар Роза белән. Фәләх көткәнгә караганда да акыллырак булып чыкты ул кыз. Бергә яши башлагач ук «үскәнем, акыллым» дип кенә торды аңа. Хәзерге заманның кайбер хатын-кызлары кебек, мин икмәккә барып кайтам, син бәрәңге әрчи тор; мин аш пешерәм, син идән юа тор; мин кер юа торам, син базарга иткә барып кайт; баланы яслегә иртән син илт, кичен мин алып кайтырмын; мин телевизор карый торам, син кызны урамга алып чыгып бер-ике сәгать саф һавада йоклатып кер дип, ялкауланып, эш бүлешеп җанга тимәде. Барысын да үзе эшләде, бөтенесенә дә өлгерә иде. Фәләх аспирантурада укый башлагач, аны бөтенләй алласы итеп күрде. Башкасы турында әйткән дә юк инде, хәтта кичләрен йокы алдыннан аның аякларына кадәр юа торган иде... Шул ук вакытта хөкүмәт эшен дә ярата, хезмәттәшләре арасында да авторитеты бар. Роза Бариевна да Роза Бариевна, дип кенә торалар иде үзенә. Казан көнкүреш комбинатларының берсендә баш бухгалтер булып эшли иде ул. Комбинат директоры аеруча хөрмәт итә һәм: «Инде менә уналтынчы елымны директор булып эшлим, баш бухгалтерның төрлесен күрергә, төрлесе белән эшләргә туры килде, ләкин эшне Роза ханым шикелле күңел биреп эшләгәне юк иде әле. Бәхетле кеше син, Фәләх туган. Бәхетсез кешегә мондый хатын тәтеми. Кадерен белеп кенә яшә!» — ди иде.

Ул агай хаклы: әйе, бәхетсез түгел иде Фәләх. Егерме сигез яшендә үзең зур бер хуҗалыкның баш инженеры, хатының шулай ук зур бер комбинатның баш бухгалтеры булу, шуның өстенә бер-береңне яратып, ярты сүздән аңлашып яшәү, чыннан да, бәхет түгел мени?! Бигрәк тә транспорт башлыгы буларак, ул аеруча дәрәҗәле санала. Казанда гына түгел, бөтен республика Фәләхне шәхсән белмәгән берәр трест яисә идарә җитәкчесе булды микән? Кая гына барса да, күтәреп алырга әзер торалар иде аны...

16

Ике кодагый арасындагы мөнәсәбәтләр, дөрес, мактанырлык түгел иде түгелен. Фәләх әнисенең шушы көнгәчә Розага килен дип тәки эндәшкәне булмады. Ә бит аларның өйләнешүенә быел җиде ел тулган иде инде. Һәй, кая ул сиңа килен дип әйтү, Роза белән күрешеп бер тапкыр сөйләшкәне дә юк. Тәки үз сүзен сүз итте: Розаның өйләренә аяк бастырмады. Казанга килгән чакларында үзе дә Фәләхләргә керми: эшлисе эшен эшли, Фәләхне күреп сөйләшә дә килгән көнендә үк кайтып китә, яки гостиницада тора. Тик ике генә тапкыр кергәне булды аның Фәләхләргә: беренчесе — Фәләх квартира алгач, шуны карарга. Икенчесе — Фәләхнең кызына ике яшь тулгач, аны күреп чыгарга. Һәр икесендә, алдан сөйләшеп куеп, Роза өйдә юк чакны туры китереп керде.

Тәртип, чисталык ярату ягыннан Роза үз әнисенә охшаган. Аларның фатирында бер генә бөртек тузан да булмас. Һәр нәрсә нәкъ тиешенчә, нәкъ кирәк урынына куелган. Кухнядагы тәртипкә үзе дә исләре китә торган иде. Ә бит йорт-җирне шулай гөл итеп тору җиңел эш түгел!

Бервакыт шулай әнисе авырган чакта Роза авылларына кайтып киткән иде. Озакка да түгел, нибары өч кенә көнгә. Ләкин шул өч көн эчендә аларның фатиры яу узганга охшап калды кебек. Фәләх моны юри шулай эшләмәде, әлбәттә. Киресенчә, ул тәртип сакларга тырышты, ләкин юньле эш майтара алмады. Һәм ул шунда хатын-кызлар өстенә төшкән йорт-җир эшенең, чыннан да, тавык чүпләп бетерә алмаслык вак, мәшәкатьле икәнен бик яхшы аңлады. Шуннан соң Розаны ул тагын да ныграк хөрмәт итә башлаган иде... Ә Фәләхнең үз әнисе йорт-җир тәртибенә һәм йорт-җир эше мәсьәләләренә бик артык шаккатып торган җан түгел — аннан-моннан, алдым-бәрдемрәк кенә карый. Элек тә шулай иде, хәзер дә шулай. Кибеттә сату итүне үлеп ярата, ә тәртип, чисталык турында сөйләнергә генә оста. Ләкин шул тәртипне үз кулы белән булдырырга күңеле ятмый. Алай гына да түгел, йорт-җирне артык чиста хатын-кызларның хәтта үзләренә дә кырын карый ул. Мактанчыклар дип саный андыйларны, кулларыннан рәтле эш килмәгәч, кер, идән юу белән күрсәтмәкче булалар үзләрен.

Ә менә әтисе, киресенчә, өйдә чисталык, тәртип булганны ярата. Ярата гына түгел, үз кулы белән эшли дә. Идән юудан, урын-җир җыюдан да тартынып тормый. Кирәк чагында күлмәкләрен дә юып кия. Ләкин ул, барлык ир-атлар шикелле, бу эшләрне хатын-кыз эшләргә тиеш дип саный һәм шул хакта хатынына әйткәли. Ә ул аңа, юк инде, Мөхәммәт, элек кенә шулай булган ул, хәзер заманалар үзгәрде. Барыбызны да тигезләде совет дәүләте, ди. Мин дә нәкъ синең шикелле үк һәр көн хөкүмәт эшендә эшлим. Син почтада үзеңә үзең хуҗа, соңга калып та барасың, баргач та чыгып йөри аласың. Ә миңа, авырып түшәктә үк ятмаганда, бармый калырга ярамый: авыл халкына кибет көн саен кирәк. Сәбәпсез бер генә көн бармый калсам да минем өстемнән жалу язалар. Шулай булгач, минем эш синекенә караганда җаваплырак та, мәшәкатьлерәк тә, ди. Окладым синекеннән әллә ни зур булмаса да, акчаны да мин сиңа караганда күбрәк эшлим! — дип тә өстәп куя. Шуннан ике араларында еш кына тавыш кузгалып китә дә ире Мөхәммәт, нинди сабыр кеше, гарьлегеннән бүртенеп: «Төкерәм мин синең хәрам акчаңа! Барыбер игелеге булмаячак ул малның! — ди.— Миңа синең акчаң кирәкми, син өйне кешенеке төсле итеп карап тот, хатын булсаң. Нирбымны кузгатма, тотармын да ташлап чыгып китәрмен. Рәйханә мине бүген барсам — бүген кочак җәеп каршы алачак!»— ди.

Бу сүзләр Фәләхнең әнисен телдән яздыра. Чөнки аның дөньяда иң курыккан һәм иң сөймәгән кешесе — Рәйханә. Әгәр төрмәгә эләгүдән өрекмәсә, ул аны күзен дә йоммыйча үз кулы белән буып үтерер иде. Ә башкача ул аны бернишләтә алмый. Гайбәткә исе китми Рәйханә ханымның. Үзе дә гайбәтче түгел. Кайчан карасаң да әйбәт киенеп, яшьләрчә чибәр булып, гадәтенчә, горур атлап йөри бирә. Фәләхнең әнисе, инде күптән, Фәләх әле бишенче класста укыган елларда ук, көч белән алдырмакчы булып, бер бәйләнеп караган иде аңа. Ләкин көлкегә генә калды: Рәйханә ханымның үзенә берни булмаган, ә аның сулъяк күз төбенә зур гына «фонарь» кабызып җибәргән иде. Хурланып үлә язды шул чакта. Ләкин, гаеп үзендә — башлап үзе суккан! — булгач, беркая да жалоба бирә алмады.

Менә шуңа бигрәк тә нык күрә алмый аны Фәләхнең әнисе. Анасын дошман иткәч, шул анадан туган кызны да ул, гәрчә Роза аны үз әни-

се шикелле үк якын итәргә әзер булса да, бәйрәм саен посылкалар салып торса да, тәки килен дип танымады. Хәтта Фәләхләрнең яңа фатирындагы чисталык һәм тәртип тә ошамады аңа. «Килеп капкансың икән, улым, дөньяның «җәннәтенә»! — диде ул. Аягындагы резин итекләрен салып тормыйча гына бүлмәләрне ике-өч кат әйләнеп чыкты.— Аяк киемнәреңне ишек төбеннән үк салдырып кертәдер инде ул сине. Теләгән урыныңа утыртмый да торгандыр. Килеп капкансың икән...»

Әйе, әнисе мәсьәләсендә эшләр шәптән тормый иде Фәләхнең. Ләкин үзендә дә, Роза күңелендә дә аңа карата бернинди хөсетлек булмагач, ул моңа артык шаккатмый, барыбер акылына бер килер, барыбер хатасын бер аңлар әле, дип өметләнеп йөри һәм шуңа күрә әнисенә караңгы чырай күрсәтми, аның капризларын үтәп барырга тырыша иде.

Ә Рәйханә ханым белән бик тиз аңлашты алар. Фәләх беренче көнне эшкә килгәндә генеральный директор аңа ярдәм итмәсә дә, автохуҗалык башлыгы Галәветдин агай җаен тапты: Казанның икенче төзелеш тресты управляющие белән сөйләшеп, Фәләх белән Розаны шул трестның тулай торагына урнаштырды. Гостиницада нибары унике көн генә торырга туры килде аларга. Тулай торакка чыгу белән Фәләх, үзләренә кунакка килергә чакырып, Рәйханә ханымга хат язды. Шуны алу белән кияү бүләкләре төяп килеп тә житте әбисе. Шул чакта ул алып килгән чикләвекнең тәме Фәләхнең авызында әле дә булса саклана кебек. Тәмам өлгереп, алтын гәрәбә төсле булгач, сентябрь урталарында гына җыелган һәм төшләре кетердәп торган, телеңне йотарлык тәмле-тук чикләвек иде ул. Рәйханә ханым Роза белән Фәләхнең яратышып кавышуларына шулкадәр шат иде ки, Казанга килгән көнне үк, әле кызына, әле Фәләхкә карап: «Бигрәк тә пар килгәнсез инде, балалар. Тату гына яшәгез дә бәхетле генә була күрегез. Үкенечкә генә булмасын!» — дип куанычыннан елаплар утырган иде.

Ана күңеле шул чакта ук нидер сизенгән, ахрысы. Әйе, үкенечле булып бара бит әле монда хәлләр. Фәләхнең ни кыланып йөргәннәрен белсә,— ә ул аны әлбәттә беләчәк! — Розаның тәртәгә тибәчәген көт тә тор инде. Моңарчы да Фәләхнең кырын эшләрен сизенми түгел иде ул. Тик конкрет дәлиле булмаганга гына түзеп торды.

Роза белән алар җиде ел тордылар. Ләкин шул вакыт эчендә җиде тапкыр да сүзгә килешкәннәре түгел, хәтта бер-беренә караңгы чырай күрсәткәннәре дә булмады быелга хәтле. Фәләх Гасимә белән женләнә башлагач та артык исе китмәгән иде Розаның. Чөнки ул дөньяда Фәләхтән башка бүтән бер ир-атны да күрми дә, күрергә теләми дә, аның өчен җир йөзендә бер Фәләх кенә бар һәм бүтән беркем дә кирәк түгел иде. Фәләх тә нәкъ шулай: аның өчен дә тик бер ул — Роза гына бар, башка хатын-кызга аның күзе төшәргә тиеш түгел, хәтта хатын-кызларның күзе төшсә дә, Фәләх аларга әйләнеп тә карамаячак, дип уйлый иде бугай. Шулай уйлавы гаҗәп түгел иде аның. Чыннан да, Фәләхнең Наилә белән булган хәлләрдән соң чит хатын-кызга беркайчан ымсынганы юк, бик сирәк-мирәк кенә кайберенә игътибар итсә дә, ул аларга Роза белән чагыштырып карау өчен генә игътибар итә һәм андый чагыштыру вакытларында һәрвакыт Роза җиңеп чыга, тегеләр барысы да, ничек кенә ыспай, матур һәм зифа булмасыннар, барыбер Розага житә алмый, тоныкланыбрак калалар иде. Ә менә Гасимә...

## 17

Фәләх аның белән гел дә көтмәгәндә танышты. Дөрес, Гасимәне ул моңарчы да җырларын ишетеп, телевизорда күреп белә иде. Ләкин күз-

гә күз очрашканы юк, очрашырга җыенмый да иде. Тавышын, үзен ошата. Чөнки Гасимә чын эстрада артисты: сәхнәгә елмаеп-балкып килеп чыга, дәрәҗәсен белеп, шул ук вакытта гаҗәеп итагатьле дә итеп, реверанс ясый, музыкантларга карап, сизелер-сизелмәс кенә керфек кага да, тегеләр кирәкле көйне уйный башлауга, кинәт үзгәреп-җитдиләнеп һәм илһамланып җыр башлый. Зал тына. Анда тик бер генә кеше — Гасимә генә хакимлек итә төсле. Моңы белән генә түгел, җыр тактына туры китереп, салмак кына чайкалып куюлары, нәкъ кирәк чагында гына, очарга талпынган аккош шикелле итеп, кулларын җәеп җибәрүләре янсә биеп китүләре белән яулап ала ул тамашачының дикъкатен. Югыйсә тавышы әллә ни көчле түгел аның. Бездә анықыннан бик күпкә көчлерәк тавышлы җырчылар да бар. Мәсәлән, Нәгыймә Вахитова җырлаган чакларда колаклар чыңлап тора. Ә менә шуның моңы һәм сәхнәдә үзен тотышы — әллә ни түгел. Артистның бит аның тавышы гына түгел, бөтен йөреше-торышы, кыяфәте, хәтта күз карашына кадәр — нәфис, затлы булырга тиеш. Монда сүз матурлык турында гына бармый. Барыннан да элек, сулар һава, кабар ризык шикелле үк, эстрада артистына ифрат та кирәк булган хәрәкәт, җанлылык, күз карашлары белән сихерләп, тамашачыларның күңеленә үтеп керә белү җитми кайбер сәхнә осталарына, үзләре хисле, дәртле шаян җыр җырлыйлар, ә күз карашларында сагыш, йөзләрендә, кемгәдер үпкәләгәндәй, караңгылык чалына... Фәләх күңеленнән безнең иң әйбәт дигән артистларыбызны Мөслим Магамаев, Эдита Пьеха, Алла Пугачева, София Ротарулар белән рәттән сәхнәгә бастырып карый һәм, үзләрен сәхнәдә тотышлары буенча безнекеләр тегеләрдән бик күп кайтыш икәнен күреп, чын күңеленнән әрни торган иде...

Гасимәне исә Фәләх тавышы көчле булудан бигрәк, җырчы кеше өчен ифрат кирәк булган әнә шул артистлыгы, сәхнәдә үзен иркен, бәйсез һәм ягымлы тота белгәне өчен ошата иде. Аннары шунысы да бар: Гасимә беркайчан да үзен-үзе кабатламый, хәтта ул бер үк җырны да җырлаган саен яңачарак, аһәңлерәк итеп башкара һәм, гомумән, гел остара бара шикелле иде. Кием мәсьәләсендә дә нечкә, зәвыклы һәм үтә таләпчән.

Әнә шуна хөрмәт итә ул Гасимәне. Ләкин ул аңа гашыйк түгел иде һәм гашыйк булырга уйламый да, чөнки аны үзе өчен буй җитмәслек югары бер изге зат саный. Алай да чибәр булмаса да, Фәләх үзе дә бүтәннәр арасында ким-хур түгел: теләсә нинди хатын-кызның күзе төшәрлек.

Ләкин дөресен әйтергә кирәк, Гасимә өчен бер вакытта да аһ иткәне юк иде Фәләхнең. Гасимә артык горур һәм чибәр булганга гына да түгел. Артистлар бик үк тотрыклы, ышанычлы булмый, бераз җилбәзәгрәк халык алар, дигән сүзләр колагына кергәне бар иде аның. Дөрестерме ул сүзләр, юктырмы — Фәләх анысын тәгаен белми һәм андый гайбәт сүзләр элек-электән сөйләнә килгәнен, аларның меңн н бер өлеше дә дөрес булмавын яхшы аңлый иде. Гасимә хакындагы гайбәтләргә дә бик үк ышанмый иде ул. Кыскасы, Гасимә өчен атлыгып, бер күреп сөйләшергә җан атып тормады. Болай гына, әйбәт артистка булганга гына якын итте ул аны. Ә кайберәүләр шикелле, авы сулары корытып, җыр, театр дигәндә дөньяларын онытып йөргәне беркайчан да булмады. Ә менә Роза андый нәрсәләргә үлә дә китә иде. Бер генә спектакльне дә, бер генә яңа концертны да калдырмый һәм Фәләхне дә алып йөри иде. Быел апрель аенда Казанның спорт сараенда үткәрелгән һәм аны менә шушы кичәге һәлакәткә китерүгә төп сәбәпче булган зур концертка да Роза бик кыстаганга барды. Юкса, диванга кырын ятып, өйләрендә телевизордан рәхәтләнеп хоккей карамакчы иде. Розасы сукыр чебен урынына ябышып

— Бүтәннәрнең ирләре үзләре чират торып билет алып кайта, син үзең дә билет белән дә барырга иренәсең! — дип үпкәли башлагач кына барган иде, әлбәттә.

Ул концертта егермедән артык артист катнашты. Бөтенесе, җидесигез мең тамашачы алдында чыгыш ясауның уен эш түгел икәнен тоеп булса кирәк, үз номерларын әйбәт башкардылар. Ләкин аеруча зур уңышка ирешкәне, ни хикмәттер, Гасимә булды. Әллә нинди бер шашкын дәрт белән җырлады ул. Көй уңаена салмак кына чайкалып киләкилә дә, такт алышынганда кинәт кенә мимикасын үзгәртеп, кырт борылып куя. Шул чакта бер яны ерык күлмәк итәге бик азга гына ачылып китә, ап-ак һәм шалкан шикелле тыгыз итле балтырлары күренеп ала. Әгәр шунда тагын бер кискенрәк хәрәкәт ясап куйса, өстеннән күлмәге бөтенләй төшеп үк китәр шикелле тоела иде...

Ә Розага бигрәк тә нык ошады ул көнне Гасимә. Шул тикле хисләнгән иде, хәтта шуны тыеп тора алмыйча:

— Әй, өздерә дә соң, ә! Сандугачларың бер якта торсын! Каян килә моңа шул тикле моң? — дип, концерт барышында Фәләхнең колагына да пышылдап утырды.

Үземә ошаган җырчыга бирермен дип, Роза колхоз базарыннан бик матур букет алып килгән иде.

— Ярый, акыллым,— диде аңа Фәләх.— Сиңа да ошавы бик әйбәт. Алайса бар, букетыңны шул кызга илтеп бир!

Ләкин Роза якын да килмәде:

— Юк-юк, ни за что бармыйм, чөнки минем киемем аныкы янында югалып калачак. Эштән генә килдем ич мин,— дип, кырт кисте. Шул ук вакытта андый шәп чәчәкләрне нииндидер белмәгән-күрмәгән кешедән бирдерәсе дә килми иде.

— Бар, Фәләх, үзең бир, чәчәк бирү оят түгел ул! — дип Роза кыстый башлагач, әллә тәвәккәллим микән, дип талпынып та куйган иде. Ләкин шөбһәләнеп калды: залда мине белүчеләр дә бардыр, артистларга чәчәк биреп егетләнгән була диярләр... дәрәҗә төшәр, дип уйлады. Әмма алган чәчәкләрне күрә торып әрәм итәсе дә килми, ничек тә Гасимәгә ирештерәсе килә иде.

Фәләх шулай икеләнеп, конкрет карарга килә алмый утырганда концерт бетте. Халык, ташкын булып, ишекләргә ябырылды. Ә букет әле тапшырылмаган, Фәләх аны һаман газетка төргән килеш кулында тота. Ихтимал, чәчәкләрнең өйгә кире кайтасы да булгандыр. Чөнки инде концерт беткән, Гасимә сәхнәдән күптән чыгып киткән иде. Фәләх тә:

— Ярар, матурым, үзең дә аннан бер дә ким түгел. Дөресен генә әйткәндә, бу букетка аңа караганда да лаеграк әле. Чөнки син минем бердәнберем, син минем сөекле кызым Розалиянең әнисе. Бу чәчәкләрне мин сиңа бүләк итәрмен, яме! — дип Розасын култыклап халык артыннан ишеккә юнәлгән иде.

Ләкин бу дөньяда бик күп эшләрнең башы очраклылык белән бәйле бит. Менә шунда тамашачылардан бер теле кычытканы, Фәләх кулындагы чәчәкне күреп:

— Нәрсә, егет кеше, чәчәгеңне бирергә кызгандың мыни? Жальжаль, алданрак күрмәдем. Югыйсә, үзеңнән сатып алып, әнә теге Гасимә дигән чибәр җырчыга биргән булыр идем! — дип әйтеп салды бит каһәр төшкере.

Нахак сүз ишетүдән дә читен нәрсә юк Фәләх өчен. Шул җитә калды. Ул Розага:

— Син мине урамда көтеп тор, яме. Мин хәзер киләм,— диде дә, нишләгәнен үзе дә белештермичә диярлек, сәхнә артына, артистлар бүлмәсенә китте.

Ул барып кергәндә артистларның кайсы кием алмаштыру белән мәшгуль, ә алыштырырга өлгергәннәре бер түгәрәк өстәл тирәсендә кайнашалар иде. Гасимә дә шунда:

— Өлешемне калдырыгыз! Минем дә эчәсем килә! — дип, нәрсәдер дәгъвалап тора. Фәләх аның янына барырга кыймый иде, Гасимә аңа үзе игътибар итте:

— О-о, мәҗнүн! Күрәм, сез кемнедер эзлисез! — диде ул, Фәләх каршына килеп.— Һай, нинди гүзәл чәчкәләр алып килгәнсез! — дип, соклanып букетны иснәп карады.— Кемгә дип алдыгыз шушы кадәр шикарный бүләкне? Әллә миңамы? — дип тә сорап куйды.

Я, хода! Якыннан караганда ул тагын да чибәррәк икән бит! Ә үзе шундый якын итеп, күзләрен мөлдерәтеп карап тора — Фәләхне генә түгел, тәнендә җаны булган теләсә нинди ир-атны һушыннан яздырыр!

— Рәхим итегез! — диде Фәләх, букетны сузып.— Рәхмәт сезгә, бүген искиткеч шәп җырладыгыз, Гасимә ханым!

— Ай-һай матур чәчәкләр! — диде Гасимә. Букетны алып тагын иснәде.— Рәхмәт инде сезгә, бик зур рәхмәт! — диде. Аннары бик гади, бик табигый итеп, ирен очлары белән генә Фәләхнең битен үбеп алды.

Фәләхкә шунда чыгып кына китәсе иде кана. Ә ул, ахмак, шул бер үбүдән дөньясын бөтенләй онытып, тиле кешедәй елмаеп, баскан җирендә катып тик тора бирде. Аны шул хәлендә калдырып китеп бару Гасимәгә дә уңайсыз иде булса кирәк, ул да китәргә ашыкмады. Сүз юктан сүз булсын дигәндәй:

— Сез үзегез кем буласыз соң, абый? Исемегез ничек? Кайда эшлисез? — дип сораштыра башлады.

Фәләх үзенең исемен әйткәч, Гасимә әллә ни зур игътибар итмичә генә үткәреп җибәргән иде. Ә менә эш урынын әйткәч, колагын торгызды:

— Оһо, кара нинди молодец икәнсез! Ә үзегез карап торырга яшь кенә күренәсез! — диде ул, гаҗәпләнеп.

Фәләх аңа, минем әле, чыннан да, картаерга исәпләгәнем юк, димәкче булып авызын ачкан иде, теге түгәрәк өстәл тирәсендә кайнашучы артистларның берсе килеп:

— Әйдә, шәп егет күрдем дигәч тә алай ук онытылырга ярамый. Сине көтәләр анда! — дип җитәкләп алып китмәкче булып, Гасимәне култыклый башлагач, сүзне икенчегә борып:

— Ярый, Гасимә ханым, уңышлар телим сезгә! — диде һәм ишеккә юнәлде.

— Хушыгыз, Фәләх! — дип Гасимә дә тегенең артыннан киткән иде. Ләкин, нидер уйлап, шундук кире килде дә:

— Гафу итегез, сезне алырга машина киләме бүген? — дип сорады.

— Ә ул инде килгән булырга тиеш! — диде Фәләх.

Ләкин аның бернинди дә машинасы юк иде. Чөнки эш сәгате инде беткән. Ә шоферы семьялы, Фәләхкә ата булырлык олы кеше. Фәләхләрне спорт сараена китереп куеп, өенә кайтып киткән иде. Гомумән эш сәгатеннән тыш шофер мәшәкатьләтеп йөртергә яратмый Фәләх. «Ул да, минем шикелле үк, үз тормышы, үз семьясы булган кеше бит. Башлык булудан, властьтан файдаланып, нигә аны кирәгеннән артык тоткарларга?» — дип уйлый иде...

Ләкин бу юлы «монда булырга тиеш» дип ычкындырды бит. Әйтерсең теленнән тарттылар аның! «Юк!» — дип дөресен генә әйтсә ни була инде шунда? Зур, кодрәтле, барысын да булдыра ала торган кеше булып күренәсе килде, имеш!

Гасимә аның шул сүзен эләктереп кенә алды:

— Ә сез кайсы якка кайтасыз? — диде ул, Фәләхнең генә түгел, мортаеп беткән каты күңелле ир-атның да күңелен сары май итеп эретә алырлык итеп елмаеп.

— Танкодромга,— диде Фәләх, баягы ялгышын төзәтергә теләп. Гасимә аңа, миңа Ленин районына кирәк, юл уңае түгел икән, дип әйтер шикелле тоелган иде. Әмма ул көткәнчә килеп чыкмады.

— Мин дә шунда торам бит! — диде Гасимә, кош тоткандай куанып.— Утыртып кайтыгыз, пожалуйста?

Бу юлы инде, ниһаять, Фәләх тә хәйләсен тапты:

— Кызганычка каршы, без дүртәү идек шул, Гасимә ханым,— диде ул, котылам ахрысы бу бәйләнчектән дип сөенеп.— Бик рәхәтләнеп ишек төбегезгә үк илтеп куяр идем, югыйсә.

Ул арада теге артист тагын килеп, Гасимәне үзләре янына әйди башлады. Ләкин Гасимә, аңа бөтенләй игътибар итмичә, Фәләхкә янә бер сорау бирде:

— Джентльмен була аласызмы сез, Фәләх абый?

Андый чакта кем була алмыйм, дип әйтсен инде?

— Әгәр сезгә бик кирәк икән, тырышып карарга була! — диде Фәләх, тегенең коткысына бирелеп.

— Алайса, үзегезне кайтарып куйгач, машинагызны миңе алырга җибәрегез әле, зинһар? — диде теге. Аннары, нидер вәгъдә иткәндәй ягымлы елмаеп:— Әгәр үзегез дә килә алсагыз, бигрәк тә шат булачакмын! — дип тә өстәп куйды.

— Озакка китәр бит. Көтеп тора алырсыз микән без әйләнеп килгәнче,— дип тә караган иде Фәләх. Ләкин Гасимә аңа да җавабын тапты:

— Ничего, көтәрмен! Минем ашыгасы җирем юк. Безнең әле монда бераз гына «эшебез» дә бар,— диде һәм, мәсьәләне инде хәл ителгәнгә санап:— Мин сезне көтәм, яме? — дип, иптәшләре янына китеп барды...

Хәзерге акылы ул чакта булган булса, Фәләх күзен дә йоммас, юк инде, җаным, мин синең арттан алайлар итеп йөри алмыйм, дип уйлар иде дә:

— Булмас шул, Гасимә, минем әле тагын барасы җирем бар,— дигән булып, гафу үтенеп, Розасын култыклап, тыныч кына өйләренә кайтып китәр иде. Ләкин кая анда алай акыл белән уйлап тору!

Фәләх ул чакта тик бер генә нәрсә: ничек итеп булса да машина табып, Гасимә алдында егетлеген күрсәтү хакында гына уйлый иде. Әгәр шунда тиз генә машина таба алмаса, аннан да мокыт, аннан да нучтәк кеше булмаячак кебек иде аңа. Шундый чибәр, шундый шәп артистканың үтенечен үти алмау — иң зур гөнаһ булыр шикелле иде.

Ләкин ул бит үзе генә түгел, аны тышта хатыны көтеп тора. Ни әйтсәң дә, Гасимә белән түгел, үзенең Розасы белән өенә кайтасы иде ләбаса ул!

Ишек төбендә көтеп торган Розасы янына чыкканда каян машина табу мәсьәләсендә Фәләхнең башында конкрет бернинди фикер дә юк иде.

— Киңәш ит әле, Роза, нишлик икән? — диде ул һәм, шактый озак көттергәнгә турсайган Розага авыз ачарга да ирек бирмичә, әлеге хәлне аңлатты.

Дөресен әйтергә кирәк, курка-курка гына әйткән иде ул моны. Розасы: «Озаткан диярләр! Һы, каян килгән алланың кашка тәкәсе! Озаттырырмын менә мин сиңа!..» — дип пыр туза башлар дип көткән иде. Роза шулай бик каты торса, вәгъдәсен үтәми калу егетлек булмаса да, берни эшли алмас, шыпырт кына кайту ягын караган булыр иде. Ләкин... күрәчәгенә каршыдыр инде, Роза Фәләхнең тәкъдимен кире какмады гына түгел, хәтта сөенеп риза булды.

— Бигрәк шәп җырлады бит, шундый артистканың сүзен җиргә салып булмас инде,— диде ул. Шундук машина мәсьәләсен хәл итү юлын да табып бирде:— Шалтырат Ситдыйк абыйга,— диде.— Машина белән тиз генә килеп җитсен. Гаражы ишегалларында гына бит!

— Килешерме соң алай, алтмышка җиткән олы кеше бит.

— Мондый чакта килешерме-килешмәсме, дип торып булмый инде, апаем! Син үзең ярармы, килешерме дип тормадың, ун-унбиш көн элек кенә машинасына запчасть табып бирдең бит әле. Бер дә алтмышка җиттем дип тормыйча, үзенә кирәккә көн-төн чаба бит. Әйдә-әйдә, шалтырат, бер тапкыр ул да ярдәм итеп карасын.

Роза хаклы. Үзләренең бик ерак туганы, отставкадагы майорСитдыйк абзыйга Фәләх һәрвакыт яхшылык эшләп, ярдәм итеп тора. Аннары өе дә ерак түгел — Чехов урамында гына... Барысы да ничек шулай туры килеп торуын әйт әле син аның: кичке якларда аэропорт белән вокзал арасында пассажирлар ташып, «сул» кәсептә дә йөргәләп торган Ситдыйк агай ул көнне өйдә булып чыкты!

...Фәләх Гасимәне алмага кергәндә артистлар, һаман баягыча шаугөр килеп, үткән концерт турында фикер алышалар, көлке сөйлиләр, сыр белән закускалап сыра эчәләр иде. Сыралары әйбәт: пельзинский һәм аны, шәп җырлаганы өчен рәхмәт йөзеннән, Игълан Гарипов дигән артистка бер кибетче алып кергән булса кирәк. Ни өчен дигәндә, артистлар ике сүзнең берендә «яшәсен безнең Игълан!» «Яшәсен аның талантына гашыйк кибетчеләребез!» — дип сөйләнәләр һәм алар исәнлегенә тост күтәрәләр иде. Гасимә дә шунда актив катнашучыларның берсе. «Неужели, тормыш ваклыкларыннан өстен тора алмыйча, болар да сыра эчә? — дип, шаккатып уйлап алды Фәләх.— Дүрт шешә сырага сабый балалар шикелле куанышалар бит...» дип күңеленнән кызганып та куйды шикелле. Ә бит шуңарчы артист ул ниндидер гайре табигый кеше, изге зат дип йөри иде. Фәләх машина алып килергә тиеш икәнен әллә оныткан ук инде, Гасимәнең кайтырга җыенганы бер дә сизелми: кулындагы стаканда әз генә сыра бар, кайдадыр гастрольдә йөргәндә булган бер мәзәк хәл турында сөйли бугай. Көлүчеләр күп... Кыскасы, инде ике-өч минут ишек төбендә басып торган Фәләхне күрмәде ул.

Болай әрсезләнеп торганчы, әллә чыгып кына китәсе инде, дип тә уйлап алган иде Фәләх. Китсә, ак сакаллы карт буласы икән. Ләкин ниндидер бер көч — Гасимәнең сихри тарту көче ахрысы?! — аның ихтыярын тотып тора иде... Ниһаять, аны күрүгә сискәнеп китеп Гасимә:

— Әллә хатынызны илтеп тә килдегезме? — диде. Аның бит алмалары алсуланып кызарып чыккан, күзләренең дымсу ялтыравы арта төшкән иде.

— Без кайтып тормадык,— диде Фәләх.— Теге иптәшләрне шофер үзе генә кайтарып килде.

Гасимәнең балкып-янып торган йөзендә бик азга гына ризасызлык галәмәте чагылып үтте. Ләкин ул моны сиздермәскә тырышып:

— Шулаймы? Ярый, бик әйбәт булган. Шушындый чибәр вә булган егетнең хәләл җефете кем икән, дип уйлаган идем, болай булгач, күрү бәхетенә дә ирешәчәкмен икән! — дип, куанган атлы булды.

Яшь булса да, төрле кешеләр белән аралашып, күп йөреп шомарган Гасимә телгә бик оста һәм юмакай булып чыкты. Машинага кереп утыру белән тәмле телләнеп Розаны мактарга, аны сөйләштерергә тотынды. Үзен мактаганны яратмый торган хатын-кызның әле бу дөньяда булганы юк. Роза да тегенең сандугачлар булып сайравына бөтенләй эреп китте. Гасимәләр турына кайтып җитеп аерылышканда исә бу ике хатын, гомергә бергә йөргән кешеләр шикелле бик нык дуслашып, киләчәктә үзара очрашып, телефон шалтыратышып торырга һәм кунакка йөрешергә сүз куешып аерылыштылар. Роза хәтта Фәләх белән килешеп тә тормыйча:

— Беренче Май көнне обязательно ирең белән безгә киләсез! — дип, көненә хәтле тәгаенләп чакырып калды.

Бу — Розаның иң зур хатасы иде. Әнә шуннан соң башланды инде хәлләрнең хикмәтләләре! Ачык авыз булып, концерттан кайтышлый шул хәтле чишелмәсә һәм үзенең авылча беркатлылыгын күрсәтмәгән булса, әлбәттә, эшләр болай ук тирәнгә китмәячәк иде. Бөтен эшне Роза үзе харап итте. Югыйсә теге кичне аерылышканда Гасимә аларга кунакка килергә өзеп үк вәгъдә бирмәгән ич:

— Минем иптәшем баянчы. Гадәттә бәйрәм көннәрендә аны туйга яки туган көнгә чакыралар. Әгәр ул бергәрсенә вәгъдә биреп куймаган булса, рәхәтләнеп сезгә киләчәкбез. Минем иптәшем мәҗлесләргә йөрүне ярата ул. Ләкин сез бик алай ышанып көтеп тормагыз, яме,— дип, икеле-микелерәк итеп кенә әйтеп калган иде.

Әйе, Роза үзе чат ябышты шул. Икенче көнне үк телефон шалтырата башлады. «Син инде ничек тә килергә тырыш, Гасимә җаным. Кеше күп дәшмибез. Синең җырлавыңны ярата торган солидныйлары гына булыр»,— дип атна буе тукыды.

Тегесе, аның саен әле бер, әле икенче сәбәп тапкан булып, отыры ялындырды. Ләкин килде. Һәм әйткән вакытыннан алданрак килде. Кунаклар Беренче май көнне кичке бишкә чакырылган иде. Ә бу Фәләх демонстрациядән кайтып кергәндә — сәгать икенчедә үк аларда утыра иде инде. Үзе генә килгән. Сәбәбен бик җиңел аңлатты:

— Минем баянчым, бәйрәм җитсә, көненә икешәр туйга барып уйнап кайта. Бүген иртәнге уннан ук алып киттеләр үзен. Мине дә дәшкәннәр иде, сезгә вәгъдә иткән булгач, бармадым. Демонстрацияне тәрәзәдән генә карап торырсың дип, Карл Маркс урамында яшәүче бер таныш хатын кызыбызны кичә кичтән үк үзләренә алып киткән иде. Ул да булмагач, ялгызыма гына күңелсез булып китте дә, туктале, Роза ханымга ярдәм итешә торырмын дип, килдем менә,— диде ул Фәләх кайткач, күгәрчен урынына гөрләп. Бераз кәефләнеп тә алган булса кирәк: күзләре шактый мут елтырый иде.

Роза — уңган хатын. Аш-суны искиткеч оста әзерли. Эшенә бүтәннәрнең катнашуын гомумән яратмый. Фәләх кайткач, аңарчы үзенә комачаулап йөргән Гасимәдән дә бик тиз котылу җаен тапты ул: кунаклар килергә әле иртә, аннары ачыгып та кайткансың, әйдә, бераз тамак ялгап, бәйрәм хөрмәтенә чак кына утырып алыйк дип, бик әйбәт итеп табын әзерләде, үзе дә килеп утырган булды да, беренче рюмкаларын чәкештерү белән үк, гөбәдиям көя бугай дигән булып, кухняга кереп китте һәм кунаклар җыйнала башлаганчы юньләп чыкмады. Тик Фәләх кенә, чит кеше хатыны белән икәүдән икәү утырганга уңайсызланып, аның янына кереп чыккалады. Анда да Розасы, ярар, миңа берниндә ярдәм дә кирәкми, бар, кунак күңелсезләнә күрмәсен, дип чыгарып җибәрә торды. Ә Гасимә исә Фәләх кайткач, Роза барын бөтенләй онытып диярлек, рәхәтләнеп шаярды, көлде, артистлар тормышыннан әллә нинди кызыклы хәлләр сөйләде. Иренен тидереп кенә коньяк капкаларга да онытмады. Утыра торгач, күңеле нечкәреп китеп, семья тормышында бәхетсез булуыннан зарланырга тотынды.

Сөйләвенә караганда, ире Гыйльфан, беренчедән, аңардан ун яшькә олы икән. Икенчедән, дөнья хәлләре белән бөтенләй кызыксынмый, китап укымый, кино-театрларга йөрми, ягъни культурасыз. Өченчедән, эчә... Ә барыннан да аянычрагы шунда — Гасимә аны яратмый икән. Хәзер генә түгел, башта ук яратмаган. Гыйльфан аны алдап, Гасимәнең яшьлек-юләрлегеннән файдаланып кына өйләнгән. Гасимә культпросвет училищесында укыганда булган бу хәл. Гыйльфан шул училищеда җыр дәресләре алып барган. Авторитетлы укытучы саналган. Укучылар да аны бик хөрмәт иткән, үзе дә укучыларны бик яраткан.

Гасимәне исә аеруча якын иткән ул. «Тавышың әйбәт синең, кызый. Мине чын күңелдән тыңлап укысаң, сине менә дигән артист итәм»,— дигән. Ә ул яшь, тәҗрибәсез һәм беркатлы авыл кызы тегенең сүзләренә ихластан ышанган, чөнки артистка буласы бик килгән. Шул ният белән кергән дә бит инде ул культпросветучилищега. Гыйльфанның авызына гына карап торган: тегe ни әйтсә — шуны тыңлаган, ни кушса — шуны эшләгән. Тора-бара Гыйльфан аны дәрестән соң алып калып та җырлата башлаган. «Була, кызый, менә дигән җырчы чыгачак синнән! Менә күрерсең, син атаклы Хәбирә Әгъзәмовадан да уздырып җибәрәчәксең!» — дип мактап торган. Шоколад, конфетлар белән сыйлаган. Аннары миндә тынычрак, иркенләп шөгыльләнербез, дип Гасимәне фатирына да чакыра башлаган. Ә бер көнне, бик озак утырткан да, вакыт бик соң инде, кайтып йөрмә, монда гына кунып кит, дип кунарга калдырган ул аны... Башта Гасимә ул кабихне бөтен дөньяга фаш итеп, судка бирмәкче булган. «Шулай эшләгән булсам, бик шәп буласы икән: гомер буе төрмәдә черсен иде шунда! — дип сөйләде ул Фәләхкә.— Ләкин ул чакта яшь идем, юләр идем шул: унҗиде яңа тулган гына иде. Тәвәккәллегем җитмәде, курыктым. Аны фаш итсәм, үзем дә пычранып калам дип уйладым. Аннары артист булудан мәхрүм калам дип шикләндем. Шуның өстенә Гыйльфан үзе дә: җаның ни тели, шуны эшләячәкмен мин сиңа! Бернинди кайгың булмаячак минем белән булсаң! Ике-өч елда халык артисты итәм мин сине! Тик тавышланып кына йөрмә, тик миңа кияүгә генә чык,— дип, аяк асларыма ятып ялынды. Хәзер булса, авызына гына тибәр идем мин аның. Ләкин ул чакта мин бала гына шул әле. Акылым да, тәҗрибәм дә юк иде. Ә ул...» Кыскасы, аның Гыйльфаны адәм ышанмаслык дәрәҗәдә эгоист һәм кешелексез булып чыккан. Язылышып кайтып, бергә тора башлауларына ай да үтмәгән, бүтән хатын-кызлар белән дә чуала башлаган ул адәм тәганәсе! Җитмәсә, көнләшә икән үзе. Гасимәнең группадаш егетләреннән дә көнләшкән хәтта.

Фәләх ул көнне Гасимәнең хәлен бик яхшы аңлап һәм аны шул тикле кызганып утырды ки, кулыннан килә торган булса, минутында ук Гыйльфанны иң кызу утка ташлап, әйләндерә-әйләндерә яндырырга әзер иде. Шушындый чибәр, шушындый акыллы хатынны кыерсытырга җөрьәт иткән бәндәдән нәрсә көтәсең? Гасимәне җәберләү генә җитмәгән, бердәнбер кызлары Талияне дә бар дип тә белми икән ул алладан җәяүләп качкан нәрсә! Хәтта баланы бала итмәгән бәндәдән нинди рәхим-шәфкать көтмәк кирәк?!

Гасимәнең бу зарын ул көнне Роза да ишетте. Ул да бик нык ачынып ачуланды Гыйльфанны. Ә Гасимәнең үзен бик кызганып: «Андый явыз белән ничек яшисең, дускаем? Мин булсам, бер минут та тора алмас идем! Гомеремдә ир күрмәсәм күрмәм, ну шул хәшәрәтне ташлар идем дә китәр идем!» — дип, күз яшьләре белән үк елый язды.

Чакырылган кунаклары җыйналып, бәйрәм мәҗлесе башланганда Роза аның белән тәмам дуслашып, бер анадан туган апалы-сеңелле шикелле булып беткән иде инде. Өстәл артына да, үзе дәшеп алып, Гасимәне Фәләх белән рәттән утыртты. «Миңа залдан кухняга йөреп торырга туры киләчәк. Өстәлгә син хозяйка булырсың. Фәләхне дә онытма. Ухаживать иткәнне ярата ул безнең Фәләх»,— диде.

Әй, Роза, Роза! Эшнең болайга китәрен башына да китермәде шул ул. Киресенчә, ире артистка белән рәттән утырганга чын күңеленнән куанып, канат куйган шикелле очынып йөрде.

Ә Фәләх соң? Фәләх үзе? Сизендеме эшнең кая таба барганын? Әлбәттә, сизенде! Чын ир булган кеше хатын-кызның үзенә нинди мөнәсәбәттә икәнен аның белән бер-ике авыз сүз алышудан, хәтта күз карашыннан ук аңлап ала белә. Ә Фәләх ул көнне өч-дүрт сәгать буе

сөйләшеп утырды Гасимә белән. Житмәсә тагы икәүдән-икәү генә диярлек утырды бит алар. Кыскасы, сизенергә вакыт бик житәрлек иде. Гасимә аны ошатуын күз карашы белән генә түгел, хәтта телдән дә ачыктан-ачык итеп әйтеп бирде: «Миңа әллә кемнәр симпатизировать итеп йөри. Араларында дәүләре дә бар. Ләкин миңа берсе дә кирәк түгел. Ә менә сезнең белән, Фәләх Мөхәммәтович, бер жилләнеп алырга булыр иде ичмаса!» — дигән иде ул.

Нигә яшереп торырга, Фәләх үзе дә судан ак, сөттән пакь булмады ул көнне. Жае туры килгәндә Гасимәнең кулларын да сыйпалаштыргалады. Убәргә үк йөрәге житмәсә дә, яңагын тегенең яңагына тидергәләп, билләреннән тоткалап та алды. Ә Роза хакында, мәсьәләнең тирәнгә кереп китәре мөмкин икәнлеге хакында башына да китермәде ул. Гасимә белән ике араларында бер-бер хәл була калса да, аны беркем дә сизмәс, бары да шома гына үтеп китәр шикелле иде.

Ләкин ары таба вакыйгалар шундый баш әйләндергеч тизлек белән бөтерелеп китте ки, үзенә ни булганын, ничек алай килеп чыкканын Фәләх сизенми дә калды. Ничектер әйбәт кенә, тигез генә юлдан барган чакта кинәт төпсез упкынга төшеп киткән сыман булды ул. Ябышып калырга да, берәр чара күрергә дә өлгерә алмады. Шоферлар теле белән әйткәндә, тау төшә башлагач кына кинәт тормозы ычкынып китте аның.

## 19

...Бәйрәмнән соң Фәләх эшенә барып утырган гына иде, телефон шалтырады.

— Алло, алло! Фәләх Мөхәммәтович, сезме бу? — диде аңа искиткеч ягымлы тавыш. Бу — Гасимә иде. Ул иртүк борчыган өчен баштан гафу үтенде. Болай гына, бәйрәмнән соң кәефегез ничек икән дип шалтыратуым, дигән булды. Икенче Май көнен бик күңелсез, ялгызы гына өйдә үткәрүен, Фәләхләрне чакырмакчы булып шалтыратып караса да, өйдә туры китерә алмавын әйтте. «Ә минем Гыйльфанны тагын иртүк баяны белән мәжлескә алып киттеләр дә төнге уникеләрдә генә китереп куйдылар. Үзе кайта алырлык хәле дә калмаган иде», — дип ирен яманлады. Аннары: «Ярый, анысы пүчтәк. Сезнең кебек якын дусларым булганда, ничек тә яшәрмен әле. Бәхетемә, ярый әле сез очрадыгыз. Розочка изумительный хатын икән! Нисколько не ревнует!» — дип, үтереп мактауларга күчте.

Ә аннары, барып кайтасы жирем бар иде дип, ояла-ояла гына, бер генә сәгатькә Фәләхтән машина сорады. Фәләхнең бу мәсьәләдә талканы коры: машинасын кешегә бирергә бер дә яратмый иде. Хәтта Роза сораганда да, бик сирәк, чыннан да аны машинасыз башкарып чыгу мөмкин булмаган очракта гына биреп тора. Чөнки начальство хатыннары нәкъ әнә шул ирләренең персональный машиналарында йөреп бозыла. Дәүләт машинасына бөтенләй үзләренеке итеп карый башлыйлар. Шуның аркасында үзләре дә ялкаулыкка өйрәнәләр, ирләренең дә дәрәжәсен төшерәләр, дип саный иде ул. Һәм хәзер дә нәкъ шул фикердә. Әгәр кулыннан килсә, начальствоны, гади хезмәт иярләре кебек үк, эшкә барганда һәм кайтканда гомуми шәһәр транспортында гына йөртер иде. Ә персональ машиналарны тик эш сәгатьләрендә һәм тик дәүләт эше белән йөргәндә генә файдаланырга рөхсәт итәр иде.

Ләкин Гасимә үтенеченә каршы килә алмады Фәләх. Киресенчә, Гасимә үзенә мөрәжәгать иткәнгә куанып: «Ул бит минем нише теләсә кемнән сорый ала һәм беркем дә аның үтенечен кире какмаячак. Ә ул, әнә, бүтән беркемнән дә түгел, миннән сорый!» — дип, горурланып та

куйды әле. Кайчанга кирәк, дип кенә сорады да тегесе хәзер ук, дигәч:
— Булды, Гасимә ханым, сөйләштек. Сез чыкканда машина ишек төбегездә булыр! — диде. Аның белән генә калмады, шоферын чакыртып кертеп, шулай-шулай, сиңа шундый җаваплы бурыч йөкләнә, карааны, Хәкимҗан агай, иплəп кенә йөр, алай-болай дорфалык күрсәтә күрмә, кая кушса — шунда бар,— дип, тулы бер инструкция тукып чыгарды.
Ул көнне «бер генә сәгатькә» киткән машина өч сәгатькә якын йөреп кайтты. «Парикмахерскаяга барып, чәчен ясаттырып иде. Әле тагын каядыр барырга исәбе бар иде, мине бер генә сәгатькә җибәрделәр дип котылдым. Бик тә капризный нәрсә икән. Бүтән аңа тарырга язмасын!» — диде шофер.
— Моннан соң ул инде үзе дә сорамас, Хәкимҗан абый,— дигән иде аңа Фәләх.
Ләкин Гасимә шул ук көнне кичке якта тагын шалтыратып, көндез машинаны озаграк тоткарлаганы өчен кат-кат гафу үтенде һәм, ярты гына сәгатькә, ательега барып кайтыр өчен генә, тагын машина сорады.
Бер сәгатькә биргәч, ярты сәгать өчен ничек вакланып торасың инде. Әллә кемгә мөрәҗәгать итмәгән ләбаса, ышанган, якын иткән кешесенә эндәшә!..
Анысында машина сәгать кичке дүртенче яртыларда киткән иде, җиденче унбиш минутта гына кайтты. Фәләх инде бик нык нервланып, моннан соң елап сораса да бирмәм, дип тә тора иде. Чөнки машинасын Гасимәгә җибәрүгә, бик тиз килеп җитәргә кушып, райкомнан шалтыраттылар. Беренче секретарьга кирәсе иде. Ә анда соңга калып йөрергә ярамый. Җәяү барырга ерак, трамвай белән китсә шулай ук өлгерә алмаячак иде. Фәләхкә, йөзен ертып, директор машинасын сорап торырга туры килде...
Райкомнан кайткан гына иде, министрлыкка чакырдылар. Соңгы вакытларда хуҗалыкның эш темпын киметүе хакында сигналлар килә башлаган икән дә шуның өчен дәштергәннәр иде. Ә бу — турыдан-туры Фәләхкә, хуҗалыкның баш инженерына, кагылышлы мәсьәлә. Темп кимүе дөрес һәм аның сәбәпләре дә билгеле: бердән, бәйрәм арасында эш чыннан да тукталып торды. Икенчедән, хуҗалыкның яңа төзелгән йортыннан квартира алырга өмет итеп йөреп тә алалмый калган шоферларның байтагы, расчет алып, фатир вәгъдә итә торган бүтән оешмаларга эшкә күчте, шуңа аларның машиналары тик торырга мәҗбүр иде. Өченчедән,— монысы иң зур сәбәп — төзелештә эшләгән машиналарның да байтагы ремонтта. Әмма министрлыкта синең ремонтыңны да, шоферлар җитмәвен дә исәпкә алып тормыйлар. Темпны ник киметтең дип, катгый куялар анда мәсьәләне. Әйе, әйе, нигә киметтегез түгел, ник киметтең, диләр. Әйтерсең, бөтен эш бер Фәләхтән генә тора да, әйтерсең, бер ул гына ниндидер сихер белән бөтен эшне тиз генә җайга сала ала!
Бик хәтәр пешекләп чыгардылар аннан Фәләхне. Җитмәсә, әлеге шул машинасы Гасимә белән киткәнлектән, дәшкән вакытларына әлгәшә алмыйча, биш-ун минутка соңарыбрак та барган иде. Һаман-һаман директордан машина теләнеп торып булмый ич инде! Сүзне нәкъ әнә шуннан, министрлык тикле министрлыкка да вакытында килә алмаган кешедән нинди юньле эш көтәсең? Давай, өзеп кенә әйт, арыта эшлисең киләме синең, иптәш Мөхәммәтов, дип башладылар. Хуҗалыкның эше бер Фәләхтән генә тормаганын, артка калуның сәбәпләрен үзләре дә бик яхшы белеп тора инде, югыйсә. Фәләх вакытында килеп җиталгән булса, алар, әлбәттә, сүзне өркетүдән башламаслар, әйдәле, темпны арттыру өчен ниләр эшләп була, нинди ярдәм кирәк, дип киңәш-табыш итүдән башларлар иде. Бүтән чакларда. шулай итәләр иде ич...

Кыскасы, Фәләх министрлыктан (начальство телендә аны «келәмнән кайту», «мунча керту» дип атыйлар) берничек тә аклана алмыйча, шунлыктан каны бик нык кызып кайткан иде. Аның өстенә машинасы да һаман әле кайтып җитмәгәч, тәмам җене чыгып, бу хатын җиллесен җилле дә, ләкин миңа кырысрак булырга туры килер, дип күңеленә салып куйган иде. Ул инде, өстен киенеп, шоферы кайтканын тәрәзәдән карап тора иде. Ниһаять, җиденче ярты житкәндә генә күренде машина.

Начальствоның язылмаган, әмма бөтенесе дә бик яхшы белә торган законы бар: күпме генә ашыкса да, аны шоферга сиздермәскә, ишек төбенә чыгып, машинасын көтеп тормаска, шоферы кереп дәшкәнне яки шалтыратканны көтәргә. Югыйсә, шофер бик тиз эрәеп, мин алып бармасам, беркая да китә алмыйсың, дип уйлаячак һәм гел шулай көттеребрәк килүне гадәткә кертәчәк. Шуңа ул, машинаны күргәч, плащын тиз генә салып куйды һәм бик төчергәләнеп, җитди кыяфәт белән өстәл артына кереп утырды. Ул арада кинәт каерылып кабинет ишеге ачылып китте һәм — я рабби! — көн болытлы булса да, үзенең сихри елмаюы белән бүлмәне яктыртып, Гасимә килеп керде.

— Уффф! — диде ул, модалы җәйге пальтосының төймәләрен чишә башлап.— Кайтып китмәдегез микән дип котым да калмаган иде. Фәләх өстәленнән кәгазь алып бит-күкрәк турыларын җилләтә башлады. Кара җирлеккә орхидея чәчәкләре төшерелгән батнигы аңа шул кадәр килешеп тора — ул үзе зур бер тере букет булып күренә иде кебек. Гәүдәсенә сыланып кына торган ап-ак чалбары аны тагын да чибәррәк — ак фарфор вазага утыртылган чәчәк бәйләме итеп күрсәтә. Фәләх, бердән Гасимәнең шушылай үз итеп, якын итеп килеп керүенә, икенчедән, аның сылулыгына исе китеп, ни уйларга, ни әйтергә дә белмичә торган арада, Гасимә очып кына килеп:

— Ачуланмагыз инде, Фәләх Мөхәммәтович, ательеның шул инде аның — тәртип диган нәрсә чамалы анда, кисүче кеше урынында юк иде, көтәргә туры килде,— диде дә ирен очы белән Фәләхне үбеп алды. Аннан искиткеч тәмле хушбуй исе килә иде. Әллә шуның исеннән, әллә Гасимәнең чибәрлегенә сокланудан булды инде — Фәләхнең башлары әйләнеп, күз аллары әлҗе-мөлҗеләнеп китте. Һәм ул, әле кайчан гына җене чыгып ачуланып утырган кеше, бар ачуын онытып, Гасимә нәрсә әйтсә, шуны үтәргә, ул кая кушса, берсүзсез шунда барырга әзер иде...

Ул арада Гасимә өстәлнең каршы ягына, кергән кешеләр утыра торган креслога барып утырды да, йөзенә ясалма җитдилек чыгарып:

— Фәләх Мөхәммәтович, сезгә бер сорау бирергә мөмкинме? — диде.

— Мин сезнең йөз соравыгызны тыңларга да әзер!

— Юк, минем соравым бер генә булачак. Әйтегез әле, Фәләх Мөхәммәтович, сез бүген миңа ике сәгать вакыт бүлә аласызмы?

— Мәсәлән? — диде Фәләх, тегенең тел төбен аңламыйча.— Кая барырга һәм нәрсә эшләргә кирәк ул ике сәгать?

— Опера театрында чит ил артистларының беренче концертына миндә ике контрамарка бар. Берсен специально сезнең өчен дип алдым. Барабызмы?

— Барсаң зыян итмәс иде. Ләкин бер дә көтмәгәндәрәк килеп чыга бит әле бу. Кызны да яслешдән аласы бар, Розага да әйтмәгән...— диде Фәләх аптырашка калып.

— Ой-ой-ой! — диде Гасимә кинаяле-астыртын елмаеп.— «Утын турыйсым да бар. Учак ягасым да бар. Балам елый, сыер савасым да бар!» — булып чыгамыни инде бу? Әй, Фәләх Мөхәммәтович, Фәләх Мөхәммәтович. Мин сезне оригинальрәк шәхес, чын ирдер, дип уйла-

ган идем бит. Юк икән, ялгышканмын. Сез дә хатыныгыз итәгенә тотынып йөрүче гап-гади бер авыл татары икәнсез! Хатынга әйтмәгән, имеш. Харап булган икән, ходаем. Сез шулай, хатыныгызга әйтмичә, бер нәрсә дә эшләмисез мени? Бәлки әле аңа гына түгел, райкомга шалтыратып, аннан да рөхсәт сорарга кирәктер? Ю-юк, Фәләх абый, болай булгач, ҫезнең белән разведкага барып булмый икән! Ә мин тагы...

Шуннан артыгы кирәк түгел, әйткән кадәресе дә Фәләхнең мин-минлегенә бик әйбәт барып тигән иде. «Ә бит бу хатын хаклы, шайтан алгыры. Бер генә тапкыр яшибез бит дөньяда! Бүтәннәр касса янында чират торып, өчәр сумга билет алып, концертларга йөрүне дә үзләре өчен дәрәҗә саный. Ә менә мин шушындый хатын билет алып килеп, үзе белән рәттән утырып концерт карарга чакырып торганда да ахмакларча икеләнеп утырам», дип уйлады ул һәм:

— Булды, Гасимә, ышандырдың! — диде.— Ә кайчан башлана концерт? Соңгармыйбызмы?

— Җидедә. Хәзер китсәк, бик иркенләп өлгерәбез әле.

— Ә...

— Нәрсә «ә» тагын?

— Кызны яследән аласы иде бит.

— Розага шалтыратыгыз, бер генә көн ул алса да — укасы коелмас.

Фәләх сәгатенә күз төшереп алды: җиде туларга егерме минут иде инде.

— Ул инде эштән китте шул.

— Шоферыгыз кызыгызны таный торгандыр бит?

— Әлбәттә.

— Соң ул алып кайтып куяр инде. Кстати, телен авызында тота беләме ул сезнең?

— Нинди мәгънәдә сорыйсыз?

— Ну, Розага ни дип әйтәсен белерме, дип әйтүем.

— Ә, сез аны сорыйсыз икән! Белер, үзем әйтермен.

— Алайса киттек!

Фәләхнең Гасимә белән килеп чыкканын күргәч ук Хәкимҗан агайның йөзендә канәгатьсезлек билгесе чагылып киткән иде. Гасимә машинага ук кереп утыргач, түзмәде: моны ничек дип аңларга соң инде дигән сыман итеп, гаҗәпсенеп Фәләхкә карап куйды һәм, берни белмәгәнгә салышып:

— Детсадка, Розалияне алырга барабыздыр бит? — дип сорады.

— Бүген маршрут үзгәрәк булачак, Хәкимҗан абый. Башта Җәлил театрына барыйк әле, — диде Фәләх.— Мин шунда калырмын, ә син, зинһар, иренмичә генә Розалияне әнисе янына кайтарып куярсың, яме?

— Нәрсә соң анда театрда, берәр төрле җыелыш-фәлән мени?

Башка вакытта Хәкимҗан агайның болай төпченеп тора торган гадәте юк иде. Фәләх белән икәүдән икәү генә булганда, дөрес, сөйләшә, сораша, әмма машинада берәр чит кеше булган чакта, авызына су капкандай, тып-тын утыра һәм бөтен игътибары гел юлда гына була торган иде. Фәләх өйрәтеп түгел, үзе шундый мәнле, сизгер кеше ул. Ләкин теге көнне Фәләх бик яхшы сизеп торды, гомерендә алай булмаганча, дорфа һәм күп сүзле иде ул. Фәләх тирәсендә Гасимәнең чамадан тыш сырпаланып йөрүен һич кенә өнәмәгәнлеге әллә кайдан күренеп тора һәм ул аны яшерүне кирәк тә санамый, юри шулай дорфа кылана иде. Опера театры янында Фәләхләр машинадан чыккач, гәрчә ни эшләргә кирәклеге инде әйтеп куелган булса да:

— Ә Розага сине кайда калды дип әйтергә? — дип сорады ул.

— Җыелышта диярсең. Унберләрсез көтмәсен.

Машинасын ачулы выжлатып, Хәкимҗан агай шундук китеп барды. Ә Гасимә, күзләрен зур ачып, Фәләхкә текәлде:

— Ул безне алмага киләдер бит?

— Юк. Болай да тоткарланды инде. Аның эш сәгате алтыда ук тулган иде. Розалияне бакчадан алып, машинасын гаражга илтеп кайтканчы тагын байтак вакыты үтәчәк. Ә иртәнге сигезгә мине алырга килеп җитәргә тиеш.

— Ну и что ж? Шоферның эше шул инде аның.

— Ә ул үз эшен бик әйбәт эшли, Гасимә. Әйдә, соңга калып барабыз бит,— диде Фәләх, сәгатенә күз төшереп алгач.— Биш кенә минут калган башланырга.

Ләкин Гасимә һаман үзенекен тукый бирде:

— Сез әйбәтен әйбәт дисез дә, ләкин миңа бер дә ошамады әле ул агай. Минемчә, сез аны артык ирәйтеп җибәргәнсез. Әйтерсең, борынгы Казан бае, әйтерсең, аның үз машинасы — шундый киерелеп утырган була! Ни юньләп сөйләшә, ни кеше төсле итеп шаяра белми.

— Эшен эшләгәч, миңа аның шаянлыгы ул кадәр мөһим түгел.

Алар инде фойега, шыгрым тулы халык арасына килеп кергәннәр һәм бәхәсне туктатырга күптән вакыт иде. Ләкин Гасимә һаман үзенекен сукалый бирде.

— Юк, ни за что килешә алмыйм, Фәләх Мөхәммәтович! Начальствоның шәхси шоферы булган кешегә эшен әйбәт белү генә җитми. Аннан культуралы булу һәм сер тота алу да таләп ителә. Үзегезгә ышанган шикелле үк ышана алырга тиеш сез аңа.

— Ә мин ышанам, Гасимә. Аның әле беркайчан да алдашканы юк. Кайбер җитәкчеләрнең шоферлары шимбә һәм якшәмбе көннәрендә машиналары белән чыгып акча эшләп йөриләр. Алдашалар. Ә башлыкларына кирәк вакытта нигәдер аларның машиналары ватык була. Безнең Хәкимҗан агай андый түгел. Хәтта машинага профилактика кирәк булганда да аны эш вакытында түгел, ә шимбә яки якшәмбе көннәрендә ясый. Һәм бер тиен эш хакы сорамый. Ә мин беләм: кайбер иптәшләрнең шоферлары ял көнендә бер-ике генә сәгать эшләп алсалар да, көнлек эш хакы янсә бер тәүлек отгул таләп итәләр.

— Бәлки шулайдыр. Ләкин, аның каравы, алар хуҗаларын да хөрмәт итә беләләр: күпме кирәк, шул кадәр көтеп торалар. Ял көннәрендә дачаларына илтеп куя, әйткән сәгатендә барып ала. Һәм башлыкларын беркайчан да «сатмыйлар».

— Минем әле дачам юк. Алырга теләмим дә. Шофер «сатардай» кыек юлларда да йөрмим.

— Ой-ой-ой!— диде Гасимә, каһкаһә белән көлеп.— Сезне тыңлап торсаң, изгеләрнең дә изгесе инде. Ә менә хәзер нинди юлда соң без сезнең белән?

— Безме? Без...

Фәләх ни әйтергә белмичә төртелеп калды. Чыннан да, нинди юл соң аның бу юлы? Шоферлар телендә моны «сулга» китү дип әйтәләр түгелме? Концерт карау өчен генә килдеме ул монда? Юк, әлбәттә. Чит ил артистларын моңарчы күрмәде, моннан соң тагын йөз ел күрмәсә дә берни югалтмый иде ләбаса! Барыннан да элек, Гасимә чакыргангә, аның белән сөйләшәсе, аның белән рәттән утырасы килгәнгә, аның якынлыгын тоеп утырырга теләгәнгә килде бит ул! Юк, Гасимәнең маңгайга бәреп әйткән бу хак сүзләрен кире кагу җиңел түгел иде Фәләхкә.

## 20

Ярый әле шул чакта залда ут сүнде һәм концерт башланып китте. Гасимә бөтен барлыгы белән сәхнәгә текәлеп, музыка тыңлый башла-

ды. Җырчының кием шәп, хәрәкәт-кыланышлары искиткеч. Әмма тавыш ул кадәр түгел, безнең өчен ятрак, карлыкканрак тавыш иде. Шуңа булса кирәк, Гасимә тегеләрнең көенә көйләнеп җырлап, үзенчә ярдәм итеп утырды. Әгәр аның үзен сәхнәгә чыгарып әлеге чит ил артисткасы башкара торган җырны җырларга кушсалар, Гасимә яхшырак җырлар төсле иде.

Ә җыр ахырына таба Гасимә шундый хисләнеп-әсәренеп китте ки, янында утыручыларга комачаулык итмәслек итеп кенә үзе дә теге артистка белән бергә җырлап бара башлады. Шунда ул, нишләгәнен үзе дә абайламыйча, Фәләхнең учына учын салды һәм нечкә генә, әмма искиткеч йомшак, кайнар бармакларын аның бармаклары арасына кыстырып, кысып куйды...

Менә шунда тойды да инде Фәләх дөньяда яшәүнең ни кадәр рәхәтлеген! Дөрес, ул үзе дә сәхнәгә карап, бөтен игътибарын артистларга юнәлткән атлы булып утырды. Ләкин ул анда җырланган җырларны, биелгән биюләрне ишетми дә, күрми дә. Аңа ул минутларда менә шушы үзе белән янәшә утырган кайнар куллы, хуш исле Гасимәдән башка нәрсә дөньяда юк та һәм кирәк тә түгел иде. Һәм ул шушы хәләтнең мөмкин кадәр озагракка сузылуын теләде.

Ләкин теләк белән чынбарлык — икесе ике нәрсә шул алар. Театрның тамаша залында алар икәүдән икәү генә түгел, йөзләгән кеше арасында утыралар һәм алар да нәкъ Фәләх белән Гасимә кебек үк, хисләнә дә, уйлый да белә бит. Әнә күрше-тирәдәгеләре кызыксынып һәм гаҗәпсенеп Фәләхләр ягына карап-карап ала. Залда утыручыларның бинокль тотканнары да байтак. Алар ул бинокльләреннән сәхнәгә генә түгел, тамашачыларны да караштыргалап утыралар. Шулар арасында Фәләхне белә торган танышлары да булуы бик ихтимал. Димәк, Гасимә белән кулны кулга бәйләп утыру әйтеп-аңлатып бетергесез рәхәт булса да, ул рәхәтне дәвам итәсе килсә дә, тирә-юньдәге чынбарлык белән исәпләшмичә булмый, чөнки моның көтелмәгән күңелсезлеккә сәбәп булуы мөмкин иде.

«Эшләр болайга бара башласа, гөнаһка кереп китүең дә бар бу шайтаннан яралган нәрсә белән: бер рәхәтнең бер михнәте барыбер булмый калмый аның. Яхшы чакта сыпыртырга кирәк моның тирәсеннән»,— дип уйлап, тәнәфестә театрдан бөтенләй китеп үк бармакчы да булып утырган иде Фәләх. Шулай иткән булса, әлбәттә, бик акыллы эшләгән буласы икән. Әмма кайтырсың анда, бар. Гасимә кармагына бер килеп капкач!

Тәнәфескә звонок булу белән, уф, үләм, тамагым кипте, дип, халык арасыннан гаҗәеп дәрәҗәдә шома үтеп, буфет ягына алып китте ул Фәләхне. Буфетка якын килерлек түгел — чират иде. Ләкин Гасимә анда да юлын тапты: иң алда торучылардан бер танышын күреп алды да, кешеләр арасыннан ыслан шикелле шуып кына кереп, тегенең алдына басты. Чират җиткәч, ике фужер шампански, бер плитә шоколад, ике мороженое сорады. Гасимәнең чиратсыз алуына уңайсызланып, янына барырга кыймыйча тора иде Фәләх. Ә Гасимә аның түләргә акчасы юк дип уйлады булса кирәк:

— Килегез инде, Фәләх Мөхәммәтович. Курыкмагыз, миндә акча бар!— дип бәләкәй сумкасын ача башлады.

Ашханәдә булсын, ресторанда булсын, кино-театрларда булсын, үзе белән бергә кергән хатын-кызларның Наиләдән башкасына акча түләттергәне юк иде Фәләхнең. Бу очракта исә бигрәк тә бурычлы булып каласы килмәде. Ләкин ул бумажнигын кесәсеннән алган арада Гасимә буфетчыга акча сузып өлгергән иде инде. Фәләх каушап-каударланып, юк-юк, мәгез дип, унлык бирмәкче булган иде, Гасимә күзләрен әйләндереп карап:

— Ярар инде, хатын-кыз шикелле вакланмагыз,— дигәч аны бумажнигына кире тыгып куюдан бүтән чара калмады.

Алар фужерларының яртысын гына эчеп куеп, Гасимә сөйләгән кызыклы сүзләрдән көлешә-көлешә мороженое ашап торалар иде, яннарына озын буйлы, кара тут чибәр йөзле, дулкынланып торган бөдрә коңгырт чәчле, өстенә шактый нык керләнгән ак күлмәк, кара жирлеккә нечкә генә ак буй төшкән, ләкин тауышалган импортный костюм кигән, чуар галстук таккан, атлетларча нык, сылу гәүдәле һәм бер каравы белән үк теләсә нинди хатын-кызның һушын алырдай чибәр кеше килеп басты. Гасимә, сүзгә мавыгып, аны күрми тора иде. Теге кеше мыскыллы елмаеп, бер сүз дә дәшмичә карап тора башлады. «Күрәсең, Гасимәнең берәр элекке танышыдыр. Шуңа шушылай астыртын елмаеп тора инде бу»,— дип уйлап алды Фәләх һәм, Гасимәнең игътибарын аңа юнәлтер өчен:

— Сез нәрсәдер әйтергә телисез ахры, иптәш?— диде.

— Әйе шул,— диде әлеге чибәр кеше калын, ягымлы тавыш белән.— Әгәр сез ачуланмасагыз, әлбәттә.

Шуннан соң гына Гасимә күрде аны. Күрде һәм тетрәнеп-каушап китте. Югалып, ни әйтергә белмичә аптырап торды. Йөзе комач шикелле булып кызарып чыкты. Ләкин бу хәл бик аз, нибары берничә секунд эчендә генә булып алды. Аннары Гасимә, берни булмагандай, ягымлы итәргә тырышып елмайды да:

— Баа, син дә монда мыни әле? Ә бала кайда калды?— диде.

— Бүтән кайгың булмаса, аның өчен борчылма, күршеләрдә калды,— диде тегесе иплән кенә, әмма шактый кырыс итеп. Аннары Фәләхкә ымлап: — Бу иптәшне кем дип белик? Ник таныштырмыйсың? — диде.

Ул кешенең үзен тотышы баштан ук сәер тоелган иде Фәләхкә. Үзенә эләктермәкче була ахрысы бу Гасимәне, шуңа калай әтәчләнеп маташа дип, йоны шактый кабарган иде. Инде менә дорфа гына итеп танышлык та таләп итә башлагач, тәмам жене чыкты. Һәм ул тегенә үзе шикелле дорфа итеп «Ә минем сезнең белән танышасым килмәсә нәрсә әйтерсез?» димәкче булган иде. Ярый әле, ходай сабырлык биреп, ычкындырмыйча калды. Теге кеше алданрак әйтеп өлгерде:

— Танып булыйк алайса: мин — Гыйльфан. Мин шушы,— ул Гасимәгә ымлады,— ханымның ире булам,— диде.

Көтелмәгән бу очрашудан Фәләх бөтенләй коелып төште: нишләргә? Алдашыргамы? Әллә исемен дөрес әйтергәме? Кайсылай әйтү Гасимә өчен әйбәтрәк булыр?..

Ул шул хакта баш ваткан арада Гасимә ярдәмгә килде:

— Ә бу — Фәләх Мөхәммәтович,— диде ул, бер дә алай кыеклатып-нитеп тормыйча.— Зур бер автохуҗалыкның баш инженеры. Минем жырларны бик ярата икән.

— Танышуыма шатмын,— диде Гыйльфан. Ул елмаерга тырышты, ләкин елмаюы зәгыйфь һәм кызганыч чыкты.

Ә Фәләхнең башында тик бер уй бөтерелә иде: «Алкоголикка бер дә ошамаган ич бу кеше! Гасимә нигә алдашты икән соң теге көнне?» Гыйльфан, чыннан да, эчә торган кешегә ошамаган. Керләнгән күлмәген, үтүкләнмәгән чалбарларын искә алмаганда, бөтен кыяфәтеннән сафлык, сәламәтлек бөркелеп тора. Тик күзләрендә генә ниндидер арыганлык һәм моң чаткылары күренә иде.

Болай күзгә-күз карашып тору бик тә, бик тә кыен иде Фәләхкә. Күренеп тора, тегеләргә дә жиңел түгел. Һәркем үзен җинаять өстендә тотылган кебек хис итә. Шул кыенлыктан үзен дә, тегеләрне дә коткару өчен:

— Сезнең белән танышуыма мин дә бик шатмын. Каяле, танышлык

хөрмәтенә...— дип буфет ягына караган иде, Гыйльфан аның иңбашына кулын куйды да:

— Кирәкми! Мәшәкатьләнмәгез! Мәгәричләп тормыйк,— диде. Аннары Гасимәгә мөрәҗәгать итеп: — Ярый, мин киттем. Кайтышлый театр янындагы трамвай тукталышында очрашырбыз,— дип китеп барды.

— Солидный кеше икән бит сезнең ирегез,— диде Фәләх. Гыйльфан киткәннән соң икесе дә бераз сүзсез торгач.— Нигә сез аны алай яманлап йөрисез?

— Сез аның кыяфәтенә карамагыз!— диде Гасимә, җавабын алдан әзерләп куйгандай өлгерлек белән.— Мин үзем дә шуңа карап алдандым. Ә эче черек аның!

Шул ике авыз сүз җитә калды Фәләхкә. «Чыннан да, һәр ялтыраган нәрсә алтын түгел бит,— дип уйлады.— Эчкечеләрнең дә карап торырга баһадирдайлары һәм кияү егете шикелле итеп киенеп йөри торганнары юк мыни? Дөресен генә әйткәндә, нәкъ әнә шундый интеллигент алкоголиклар арта бара да бугай әле соңгы вакытларда. Иң күп аерылышучылар да — шулар. Гади, эшче халыкның алай мәхәббәт куертып, аерылышып-кавышып йөрергә вакыты бик калмый аның, агайэне»... Ә шулай да Гасимә иренең андый ук беткән баш булуына ышанасы килми иде Фәләхнең. Ләкин ничек кенә булмасын, тәнәфескә кадәрге хисләре бик нык суынган иде аның. Дөрес, Гасимә үзе сер бирмәскә, берни дә булмаган шикелле күренергә тырышты. Юк кына сүз әйтеп, шуннан үзе кызык табып көлгән итте. Әмма тәнәфескә кадәрге шикелле кул тотышып, бармакка бармак бәйләп утырулар булмады инде. Һәй, кая ул анда кул тотышулар! Фәләх хәтта Гасимә ягына карарга да читенсенеп, икенче якка авышып, кырыйга карап, концертның тизрәк бетүен көтеп утырды. Концерт бетү белән, мин хәзер дип, ирләр тәмәке тарта торган бүлмәгә кереп киткән булды да, тегеңә күренмичә генә, театрдан чыгып китте. Саубуллашып та тормады хәтта.

## 21

Ул кайтып кергәндә Роза да, Розалия дә йокларга ятмаганнар иде әле. Хәтта кичке ашны да ашамыйча көтеп торганнар. Розалия, гадәтенчә, әтисе ишектән керү белән аның кочагына ташланды. Башта аны үзе үпте, аннары, әтисе үпсен өчен, битен үзе куйды. Шундый йомшак, шулкадәр сагынылган һәм шул тикле кадерле иде аның, ике генә яшьтә булса да, зурларча акыллы, тәтелдек Розалиясе!

— Ник бик озак тордың, әтием?— диде сабый.— Ә без сине шундый көттек, шундый көттек...

— Эш күп иде, кызым, шуңа тиз генә кайта алмадым.

Бу — Фәләхнең кызына беренче тапкыр ялганлавы иде. Шуңа аның сүзләре гадәттәгечә үк ышанычлы килеп чыкмады. Ә менә ике бите һәм колаклары уттай янып чыкканын ул үзе дә сизде.

Башка көннәрдә Розасы өйдә булып, ишек ачарга килгәндә, Фәләх иң элек аны пәп итеп ала торган иде. Бүген ул аны Розалиясен кулыннан төшергәч кенә, анда да кыяр-кыймас кына кочаклады. Фәләхнең бу халәтен Роза да сизенеп алган иде:

— Синнән чит хатын-кыз исе, духи исе килә! — дип читкә тайпылды.— Бар, ваннага кереп юынып чык, югыйсә урынга яткырмыйм. Әллә кинди күңелне болгата торган төче ис!

Бусы инде — алар бергә яши башлаганнан бирле Розаның беренче җитди бунты иде. Фәләхнең моңа кадәр дә соңга калып кайткан чаклары бар, хәтта бер тапкыр, үз урынбасарыннан бераүнең туган көнен «билгеләп» йөреп, төнге бер тулганда гына кайтып кергән иде. Шунда

да сүз әйтмәде Роза. Ул чакта да йокламыйча көтеп торды торуын. Әмма «кайда йөрдең?» дип кенә сорауга Фәләх җавап биргәч, бернинди үпкә-фәлән булмаган иде. Ә менә бу юлы...

Андый чакта ир-ат нишли? Күбесенә үзенең «гаепсезлеген» дорфалык һәм усаллык белән «расларга» гына кала аңа.

— Ә кем синең яныңа ятарга җыена әле?— диде Фәләх. Бүген кич буе җыйналып килгән бөтен ачуын шуның белән басмакчы иде. Ләкин ачуы басылмады. Киресенчә, ул үзенең көчсезлеген генә күрсәтте бугай.

Ә Розасы, аңа җавап та бирә алмыйча, үксеп елап җибәрде дә, эпиген кызганып үзе дә елый башлаган Розалияне күтәреп алып, йокы бүлмәсенә кереп бикләнде. Фәләх аны бер дә юкка кимсеткәнен төшенеп, сөйләшеп-аңлашып карарга, кирәк булса гафу да үтенергә ниятләп, ишеккә шакыса да, Роза ачмады...

«Ярар, баш ярылып күз чыкмаган. Гомер иткәндә мондый гына хәлләр була торгандыр инде ул. Ничек тә үтеп китәр әле, аның каравы киләчәктә акыл булыр: чибәр хатыннар тирәсендә саграк булу кирәк,— дип юаткан иде ул үзен.— Ә Гасимәгә бүтән якын да бармам, үзе очраганда да, күрмәмешкә салышып, читкә карап үтәрмен»,— дип уйлаган иде... Шул ук вакытта аны тагын бер күреп сөйләшәсе һәм шунда, җаен табып, тик бер генә тапкыр һәм азга гына булса да, аның кулын тотып торасы да килә иде. Ниндидер, Фәләхкә һич тә аңлашылмый торган тылсымлы тарту көче бар ул хәерсез хатынның! Күңеле гел шуңа ымсынып, алгысып тора иде. «Күрәсең, телепатиясе көчледер инде — дип уйлый иде ул.— Үзе әллә кайда еракта булса да, биотокларын җибәреп торадыр. Баһадир күк ире була торып мине якын итә икән, димәк, мине аннан өстенрәк күрә, димәк, мин аңа күбрәк ошыймдыр...»

Ә ир-ат өчен үзенең көндәшеннән өстенлеген тоюдан һәм әнә шул Гасимә шикелле чибәр, яшь хатынга ошаудан татлырак нинди хис бар икән тагы?..

Кичтән өзелгән контактны ялгамак булып, Фәләх иртән сүз катып караса да, Роза, әйтерсең, телен йоткан иде: актан да, карадан да эндәшмәде. Ашарга әзерләгән иде үзе. Чәен дә кайнатып куйган. Ләкин үпкәләве бетмәгән генә түгел, киресенчә, арта төшкән шикелле. Ул да йокламыйча озак елап яткан булса кирәк: күз кабаклары шешенке, күзләре юеш иде.

Фәләх каты гына итеп:

— Ни булды сиңа, әнисе? Ник болай тузынып йөрисең?— дип кыса башлагач кына, ниһаять, телгә килде ул:

— Миңа берни дә булмады. Син менә үзеңә ни булганын әйт! Нинди сөйрәлчек янында булып кайттың кичә?— диде һәм, тыелып тора алмыйча, тагын тавышсыз гына елап җибәрде.

Аны шул хәлендә калдырып эшкә китәсе килмәде Фәләхнең. Чөнки Розаның эшкә барасы, көн буе кеше арасында утырасы бар. Ул да бит ни житте хезмәткәр генә түгел. Баш бухгалтер ич ул! Әгәр шундый начар кәеф белән эшенә барып керсә — аның кул астында эшләүче бүтән хатын-кызлар ни уйламас та, ни сөйләмәс. Юк, ничек итсә дә итәргә, ләкин Розаны азрак кына булса да юатып-көйләп китәргә кирәк иде. Шунсыз аның үз эшенең дә рәте-чираты булмаячак.

— Син мине кем дип беләсең, Роза, андый юк-бар нәрсәләр белән маташып йөрергә?— диде ул, юатудан, тәмле сүз әйтеп күңелен табарга тырышудан барыбер мәгънә чыкмаслыгын күреп.— Ничек оялмыйсың шул сүзне әйтергә? Мине яратуың әйбәт! Минем өчен борчылуың да бик яхшы! Ләкин чамадан тыш көнләшүең белән җанга тия башладың бит! Нинди чит хатын-кыз исе килергә мөмкин ди миннән? Кичә кич кенә министерстводан, Мәскәүдән, бер кеше килеп төште дә шуны башта кунакханәгә урнаштырып, аннары көен көйләп йөрдем. Хәзер кунакханәләрдә буш урын юклыгын беләсең бит!

— Соң нигә аны кайтып керү белән шулай дип әйтмәдең?— диде Роза, елавыннан туктап һәм шактый йомшый төшеп.

«Була бит болай булса, көйләнә бу! — дип куанып куйды Фәләх. Ләкин дилбегәне кулдан ычкындырмаска, һөҗүмне дәвам итәргә булды:— Һы, ник кичә әйтмәдең, имеш? Ансат кына икән! Мин ярып-талып, бушка үткән кичемне кызганып, сөекле хатыным белә кадерле кызым янына тизрәк кайтып җитим дип ашыга-ашыга кайтып кергәч, син шулай наһак сүз әйтеп, кашыңны-күзеңне җимереп каршы алгач, ничек юньләп сөйләшергә тиеш идем соң? Тузга язмаганны сөйләп бәйләнгәнең өчен ярый әле шунда бер хуттан үзеңне селтәп җибәрмәгәнмен. Шунысына сөен!».

— Алай булгач, нигә соң үзең Хәкимҗан абыйга театрда калды дип әйтергә кушып җибәрдең?

«Я рабби! Розаны ничек җайлау хакында гына уйлап, анысын бөтенләй оныткан иде ул.»

Менә шулай була икән ул бер ялганлый башласаң. Инде ни дияргә соң моңа?.. Тагын ялганласам, тагын тотылырмын, дип курыкты Фәләх. Бөтенләй үк дөресен булмаса да, дөреслеккә якын итеп:

— Ә-ә, син әнә ни өчен кабарынасың икән! Анысы да шул синең артистларга мөкиббән булуың аркасында килеп чыккан нәрсә бит аның. Кичә мин машина белән үтеп барганда синең ахирәт дустың,— соңгы ике сүзне Фәләх ирония белән әйтте,— Гасимә күреп алды да, театрга кадәр генә илт инде дип үтенгәч шунда алып барып куйган идем.

— Ләкин бит үзең дә шунда калгансың!

— Анысын да төпченден мени әле син? Әйе, калдым. Гасимә миңа да билет алып бирәм дигән иде. Ул билет ала алса, әйе, мин дә концертка калмакчы идем. Чит ил артистлары көн дә килеп тормый бит безгә. Син миннән башка үзең генә баргалыйсың бит андый концерт-спектакльләргә. Мин бер сүз дә әйтмим. Гомеремдә бер тапкыр мин дә синнән башка гына концертта утырмакчы идем. Ләкин синең ахирәт дустың вәгъдәсен үти алмады: билет булмады. Ичмаса аңа ышаныл, машинаны да инде җибәргән идем. Шуннан, калган көтү барыбер калган инде дип, кайтышлый кунакханәгә теге Мәскәү кешесе янына сугылдым да, ресторанда ашап чыкмакчы идек, кая анда — бер буш урын да юк! Ачудан коньяк алып аның номерына мендек, буфеттан коры-сары ашап, кузгалган нервларны басар өчен, шахмат уйнарга тотындык. Мавыгып китеп, озаграк уйналган. Ә син, понимаешь, ниндидер духи исләре белән җанга тиеп каршы аласың.

Уф, бигрәк тә читен икән бу алдашу дигән нәрсә! Әлеге нотыгын сөйләгәндә хәтта маңгаеннан тир дә бәреп чыкты Фәләхнең. Әмма тырышуы бушка китмәде: Розаның йөзе сизелерлек яктырды. Дөрес, өстәл янына утырмады утыруын. Розалияне киендерә-киендерә:

— Ә син барыбер алай ук дорфа сөйләшергә тиеш түгел идең минем белән. Мин дә уйнап йөрмәгән бит. Синең шикелле үк, эштән кайтып, аш әзерләгән. Аннары борчылып көтеп торган! Хатын-кызга күп кирәк мени аңа: бер җылы сүз әйткән булсаң — шул бик җиткән иде бит,— дип бар булган үпкәсен әйтеп бирде.

Анысына гына түзәргә була иде.

Ул арада урамда «тут-ту-тут, тут-ту-тутт!» итеп ике мәртәбә машина кычкыртты — Хәкимҗан агай килеп җиткән иде. Киенеп бетеп, үзен көтеп торган Розалияне җитәкләде дә:

— Ярый, әнисе, без киттек. Бүген вакытында кайтырга тырышырмын,— дип, бик зур бәладән котылгандай җиңеләеп чыгып китте.

Ә кичен алар, араларында берни дә булмагандай, бер-берсен сагынып көтеп алып, шаяра-көлешә ашадылар. Аннары Роза кызларының киемсалымын юып кайнаштты. Розалия әнисенә булышып мәш килеп йөрде. Ә Фәләх телевизор карап утырды. Йокларга ятканда кичәге низагны

Роза гел оныткан ук иде инде. «Чак кына зурга китмичә калды бит эш. Әле ярый Гасимәнең ире очрады. Рәхмәт аңа. Югыйсә әллә нинди көтелмәгән бәлаләргә тарыр идем. Артистка, имеш! Без барыбыз да артистлар бу дөньяда. Ә тормышыбыз — сәхнә. Нәкъ театрдагы кебек. Һәркем үз ролен уйный, үзе теләгәнчә, булдыра алганча... Минем мәнә шушы йомшак, кайнар тәнле Розамның, минем өчен җан атып торган Розамның, Гасимәдән кай җире ким?» дип уйлаган иде Фәләх шул чакта. Дөрес уйлаган икән. Моның шулай булуын мәнә хәзер, больницада ятканда, бик яхшы аңлады ул. Үзенең ачы тәҗрибәсеннән чыгып аңлады. Ләкин соңгарак калып аңлады бугай...

Ә ул чакта...

## 22

Нәкъ тау төшкәндә тормозы эшләмәгән машина шикелле булды Фәләх: аска тәгәри бирде, тәгәри бирде. Тукталу турында уйларга да ярамый һәм ярты юлда тукталып калу аңа мөмкин дә түгел иде. Чөнки берни дә эшли алмый: машинаның руле Гасимә кулында, ә ул үзе тулысынча аның карамагында иде.

...Җәлил театрындагы концерттан соң, Гасимә берәр атна чамасы югалып торды. Күрәсең, минем машина белән әлләни күп йөри алмасын чамалагандыр, дип уйлаган иде Фәләх. Шулай булуы бик әйбәт, шулай булырга тиеш тә иде ул, дип сөенгән иде. Ләкин, ни хикмәттер, Гасимәне юксына да иде үзе. Бер күреп сөйләшәсе иде тагын, ниләр сайрар икән, дип кызыксына иде. Әйтерсең, ул хатын аны ниндидер күренмәс җепләр белән бәйләп киткән иде дә, шул җепләрне әледән-әле тарткалап, дөньяда үзенең барлыгын һаман сиздереп тора... Шул ук вакытта Фәләх аның белән очрашырга курка да. Һәрхәлдә ул аңа башлап шалтыратачак та, янына барачак та түгел иде.

Горизонтта Гасимә үзе пәйда булды. Концерт караганнарына атна-ун көн үткәч, Фәләхкә тагын шалтыратты. Гадәтенчә, болай гына, ничек яшисез икән дип, хәлегезне белер өчен генә шалтыратуым иде, дип башлады ул сүзен. Мин инде сезне бик сагындым. Чөнки миңа бертуган абыем шикелле якын тоеласыз, диде.

Әнә шул сүзләре белән Фәләхнең күңелен эретеп, башын әйләндереп җибәргәч, әйтте:

— Сез иртәгә төштән соң эшегездән китә аласызмы, Фәләх Мөхәммәтович?

— Ә нигә бүген үк түгел?— диде Фәләх үзе дә сизмәстән кодрәтләнеп-алгысып китеп.

— Бүген дә ярар иде ул. Ләкин сез теге көнне баланы яслидән аласы бар дип бик борчылдыгыз бит.

— Ә нишләргә тиеш булабыз соң без иртәгә?

— Көннәр бик матурланып китте бит. Бөтен тирә яшәрә торган, шомырт чәчәк аткан чак. Шәһәр читенә чыгып, шашлык кыздырып, азрак табигать белән аралашып кайтырга иде исәп.

Бик хәтәр дә, шул ук вакытта бик ымсындыргыч та иде бу тәкъдим. Әйе, язгы урман һавасы, шашлык зыян итмәс иде. Монысы Фәләхкә бик тә таныш һәм аның күңеленә хуш килә торган нәрсә. Мәскәүдә институтта укыганда һәр елны нәкъ менә шушы вакытларда, группалары белән шәһәр читенә чыгып шашлык кыздырып, ял итеп, күңел ачып кайта торганнар иде алар, ә Казанга кайтып эшли башлаганнан бирле бер тапкыр да шулай чыга алганы юк әле. Һәр елны менә барам, менә барам, дип әзерләнеп йөри дә тәки бара алмый калына иде. «Нигә менә хәзер, форсаттан файдаланып, бер җилләнеп кайтмаска икән?.. Аның шулаен шулай. Ләкин ярый ла барысы да тыныч кына үтеп китсә. Теге көнге шикелле, соңыннан Роза берәр нәрсә сизеп алса? Юк, тиле

хисләргә юл куярга ярамый алай. Андый чаклары үтте инде Фәләх абзагызның».

— Тәкъдимегез бик тә шәп икән, Гасимә ханым. Табигать белән аралашу әйбәт булыр иде. Бигрәк тә сезнең белән. Ләкин, кызганычка каршы, иртәгә минем эш бик тыгыз булачак, ычкына алмам шул.

— Эшеннән ике-өч сәгатькә китеп тора алмаган начальник буламы? Сез бит үзегезгә-үзегез хуҗа. Сезне райкомга, горкомга, совминга, тагын әллә кайларга һәм әллә нинди җыелыш-киңәшмәләргә чакыртырга мөмкиннәр икәнне белергә тиешсез бит, Фәләх Мөхәммәтович!

— Ну-ну-ну, беләм. Акыл өйрәтәсе юк ул мәсьәләдә. Ләкин китеп булганда, китәрдәй вакытта гына шулай итәсең аны. Ә иртәгә минем кичектереп булмый торган эшләрем бар!— диде Фәләх, тегенең чамадан тыш остара башлавын ошатып бетермичә.

Ләкин Гасимә гел үзенекен каерды:

— Беләбез инде андый кичектерергә ярамый торган эшләрне!— диде ул үтергеч итеп.— Берәрсе сизмәгәе дә, авторитетым төшмәгәе дип уйлыйсыз бит. Дөресен әйтергә дә йөрәгегез җитмәде ичмаса. Егет дип уйлаган идем, ә сез әнә нинди куркак икәнсез!

Шулай диде дә трубканы элеп куйды. Авыз ачарга да өлгерә алмый калды Фәләх. Дөресрәге, ачык авызын яба алмыйча калды.

Әнә шундый чакта сынала инде адәм баласы нервларының ныклыгы. Хәтта тумыштан куркак кеше дә үзенә куркак дигәнне һич тә күтәрә алмый. Җене чыга шул сүзгә. Дөньяда бит һәркемнең батыр булып, җиңүче булып күренәсе килә... Шул чакта Гасимәнең «куркак» дигәнен «ну и чтож» дип яисә «ә булса соң», дип, артык игътибар итми генә үткәрсә ни була иде аңа? Юк: әлеге шул мин-минлеге, батыр булып, әллә ниләр эшли ала торган көчле кеше булып каласы килү хисе өскә чыкты Фәләхнең. Аның өчен ул минутта хатыны Роза да, кызы Розалия дә, эше дә, эшендәге авторитеты да юк, ул тик кимсетелгән горурлыгын өскә чыгару, Гасимә каршында куркак булып калмау хакында гына уйлый иде.

Читлеккә ябылган бүре шикелле, кабинетында ишекле-түрле йөренергә тотынды Фәләх. Телефоны язып куелмаган микән дип, кесә дәфтәрен алып актарды. Телефон кенәгәсеннән «З» хәрефеннән башланган фамилияле кешеләрнең бөтенесен барлап чыкты, ләкин Гасимә квартирасы телефонын тапмады. Күрәсең, телефоннары ире фамилиясенә язылган, ә Фәләх аның фамилиясен белми иде. Аптырагач, аннан сорамакчы булып, Розага да шалтыраткан иде. Ләкин бухгалтериядән «объектка китте, кайчан кайтасын әйтә алмыйбыз»— дип җавап бирделәр. Объектка китүнең нәрсә икәнен бик яхшы белә Фәләх: күбрәк очракта кибеткә чыгып киткәндә әйтелә торган сүз ул. Ә кибеттән тиз генә әйләнеп керә алмыйсың — хәтта кием карыйм дисәң дә чират торырга кирәк: кеше күп. Шимбә, якшәмбе көннәрендә, ярый, шулай булсын да ди инде. Ял көннәрендә генә түгел, атнаның теләсә кайсы көнендә дә кайсы гына кибеткә барып кермә — шыгрым тулы халык! Күрәсең, бер Розалар комбинатында да Фәләхләр хуҗалыгында гына түгел, бүтән предприятиеләрдә һәм оешмаларда эшләүчеләр дә эш сәгатьләрендә шулай «объектка» чыгып йөриләр. Кызык өчен, бер дә көтмәгәндә, алдан сиздермичә генә, шәһәрдәге бөтен предприятие һәм оешмаларны берьюлы тикшереп карыйсы иде — күпме кеше «объектта» булып чыгар икән?..

Әнә шуларны уйлый-уйлый, инде нишләргә, каян табарга ул Гасимәнең телефон номерын дип гаҗизләнеп торганда Фәләхнең үз телефоны шалтырады.

— Молодец!— диде ул куанычыннан тавышлары калтырап.— Әүлия икәнсез, Гасимә ханым. Нәкъ сезне уйлап гора идем. Мин иртәгә сез-

нең белән һава сулап кайтырга бара алырмын шикелле булып тора бит әле, әй!

— Юк, мин куркаклар белән эш итмим!

— Әй, әй, әй, чамалабрак кыланыгыз, иптәш Зиннәтуллина! Давай шаяруларны куеп торыйк та конкрет эшкә килик: мин хәзер машина җибәрәм. Шуның белән тиз генә килеп җитәсез дә вылазканың конкрет шартларын билгелибез!

— Ә миңа монысы кирәк түгел инде, Фәләх Мөхәммәтович.

— Нигә кирәк булмасын? Андый җиргә әзерләнмичә генә чыгып була мыни?

— Әзерләнергә кирәк, билгеле. Ләкин аның өчен минем сезнең янга барып, секретарегызга күренеп йөрүем һич тә мәҗбүри түгел. Теге көнне кергәндә дә астыртын елмаеп карады ул миңа.

Кур син аның акыллылыгын! Ничек шулай барысын белергә өлгергән ул яшь кенә көенчә? Ә бит бәләкәй генә, караңгырак кына бер авылда туып үскән үзе. Күрәсең, хикмәт кайда туудa, кайда үсүдә түгел булса кирәк. Мәсәлән, Розаның башына да килмәс иде мондый эшләкле хәйләкәрлек. Хәлбуки Роза югары белемле, баш бухгалтер булып утырса да. Ә бу культпросветучилище белеме белән дә әнә ничек кыландыра...

Күңеленнән шулай уйласа да, уйларын Гасимәгә әйтмәде Фәләх: тагын берәр нәрсә табып, үпкәләп китәр дә бөтен эш бозылыр дип шикләнде.

Алар табигатькә чыгуның конкрет планын билгеләделәр, кайда һәм кайчан очрашу хакында сүз куештылар...

Ә икенче көнне, алар урманнан кайтып, Гасимәне өйләренә илтеп куйганнан соң Фәләх белән Хәкимҗан агай арасында шактый четеректе бер сөйләшү булып алды. Фәләхләр подъездына кайтып җиткәч, машинасын кискен генә туктатты Хәкимҗан агай, моторын да, утын да сүндереп:

— Әйдә, болай сөйләшик, Фәләх энекәш,— диде.— Тегеләй ит тә болай ит, дип мин сиңа акыл өйрәтә алмыйм. Үзең дә, шөкер, балигъ булган инде. Әйдә, син мине иртәгәдән эштән бушат, яме! Бу хикмәтләргә бөтән түзеп тора алмыйм.

— Ярар инде, Хәкимҗан абзый, гомер эчендә бер андый гына нәрсә була инде ул. Баш ярылып күз чыкмаган ич әле. Ачуланма, бүген тоткарланганың өчен иртәгә төшкә кадәр ял итәрсең. Ә менә монысын, машинаңны гаражга илтеп кайткач, аш алдыннан тотып куярсың,— дип Фәләх аңа тегеләрдән калган ярты шешә аракы сузды.

Дөресен әйтергә кирәк, Фәләхнең аңа беркайчан да андый нәрсә биргәне юк. Ләкин белә: эштән соң сыйланып йөреп, озаграк тоткарланган чакларында бүтән шоферларга хуҗалары шулай «чәйлек» бирә һәм бер генә шоферның да аннан баш тартканы юк, киресенчә, рәхмәт әйтеп алалар икән. Ә кайбер шоферлар хәтта, нигә өйгә кайтканчы көтеп торырга, хәзер үк урынына урнаштырып куябыз без аны дип, машиналарын туктатып торып, юлда ук «төчкертеп» куялар. Хәкимҗан агай да әллә кем түгелдер. Ярты шешә «Кристалл»ны бик теләп алыр дип уйлаган иде Фәләх. Ләкин агаебыз алмады гына түгел, хәтта:

— Син кем дип беләсең, энекәш, мине? Эчәсем килсә, минем үземнең өемдә юкмыни?— дип чын-чынлап үпкәләде дә әле.

Фәләхнең аны һич тә үпкәләтәсе килми, чөнки Хәкимҗан агай гаҗәеп дәрәҗәдә сизгер, вәгъдәле, риясыз һәм үз эшен яратып эшли торган кеше. Андый шофер табулары бик җиңел булмавын Фәләх яхшы белә. Шуңа ул, эченнән Хәкимҗан агайга хәтере калса да, сиздермәскә һәм аны ничек тә җайларга теләде.

— Бетте-бетте, алайса, Хәкимҗан агай. Гафу ит, әйттем исә кайттым?— диде ул, мәсьәләне уенга алыбрак. Һәм шуның белән үтеп китәр дип уйлаган иде.

— Бетмәде!— диде Хәкимҗан агай, моңарчы беркайчан да булмаганча үҗәтлек белән.— Бетә торганнан узды хәлләр. Сүзем юк, моңарчы мин сине үз улым шикелле күреп, яратып йөрттем. Ну бүгеннән соң, бигайбә, булмый, йөртә алмыйм. Син, бәлки, китәсең икән — кит, бүтән кеше эшләр, диярсең. Дөрес, шулай да булыр. Мин дә эшсез йөрмәм анысы. Йөз алтмыш биш тәңкәлек эшне хәзер теләсә кайда табып була аны. Автобус шуфирләре, әнә, дүртәр йөзгә кадәр куалар аена. Премиясе белән бишәр йөзгә баскан чаклары була. Эш анда түгел. Синең үзең өчен борчылам мин. Мин сиңа атаң булырлык кеше, әйткәнемә ачуланма: хәтәр юлга кереп барасың син, егет! Бүген сезне алмага барганда, әллә Розаңа да әйтим микән, дип тә уйладым. Тормышыгыз бозылыр дип кенә тыелдым... Ну, әнем, шуны бел: әгәр шул әртисләр белән алга таба да шухыр-мухыр уйнар булсаң — яхшыга алып бармаячак!

Фәләх өчен әллә ни яңа нәрсә юк иде Хәкимҗан агайның бу сүзләрендә. Аның үзен дә шушындый ук уйлар борчый бит. Әммә акыл белән йөрәк — икесе ике нәрсә шул! Гел акыл кушканча гына эш итәлсә, бик әйбәт булыр иде дә соң. Ләкин акылыңны җуйдыра, хисләреңне өермә итеп бөтерелдерә һәм диңгез итеп кайната торган затлар бар әле. Әгәр ул сине шулай сихерләп алса, үзең дә әллә кая бара алмас идең син, Хәкимҗан абзый.

Хәкимҗан агайны тыңлап, Фәләх әнә шуларны искә алды. Ләкин уйларын Хәкимҗан абзыйга әйтмәде. Киресенчә, аны тынычландырырга, күңелен табарга тырышты:

— Алтын сүзләр сөйлисең бит, Хәкимҗан абзый,— диде ул.— Рәхмәт сиңа! Все. Бетте! Бу — элеккесе һәм соңгысы! Тик син дә алай ашыгып тәртәгә типмә әле, яме! Эштән киту турында диюем. Моңарчы аңлашып эшләп килдек бит. Моннан соң да шулай булыр дип ышанам.

— Сүзеңдә торырсыңмы соң?

— Егет сүзе — бер булыр, Хәкимҗан агай.

— Алайса, ярар. Ну, штубы — ни-ни!

— Әйе, ни-ни, Хәкимҗан агай...

Әнә шулай ялынып кына алып калды Фәләх үзенең шоферын...

## 23

...Безне капчыкта яшереп тотып була ди мени? Соңгы вакытларда Роза белән дә мөнәсәбәтләре киеренкеләнгән, чөнки Роза аның Гасимә белән чуалганын инде тәгаен сизенгән һәм Фәләх соңарып кайткан чакларда:

— Тагын шул юха елан янында булдыңмы?— дип каршы ала һәм шуннан ике арада тавыш китә иде. Фәләх андый чакта: «Нинди юк сүз сөйлисең син, әнкәсе? Мине син кем дип беләсең?»— дип акланырга тырышып караса да, Роза барыбер ышанмый иде. Фәләх, нервлануына түзә алмыйча:

— Йөрим шул! Йөрим! Ләкин моның өчен миңа түгел, үзеңә үпкәлә: син таныштырдың бит мине аның белән! Синең ахирәт дустың ич ул!— дип тә җибәргәли иде. Соңгы ачуланышуларында хәтта:— Житте сиңа! Тукта яхшылык белән! Җенемне кузгатсаң, тотармын да өйләнермен шуңа!— дип тә ычкындырган иде.

— Бар, олак! Хаҗәтең бер тиен. Алма агачының төбеннән ерак төшми, этисе шикелле аумакай булмас микән, кызым, әллә аңа бар-

мыйсыңмы дип, бигрәкләр белеп әйткән икән әнием-җан кисәгем! Тыңламадым бит аның шул алтын сүзләрен,— дип үкси-үкси елады ул көнне Роза.

Әлбәттә, Фәләхнең Гасимәгә өйләнергә уенда да юк. Ул моны ачуы бик килгәнгә генә әйтеп ташлаган иде. Ләкин шул көннән салкынаеп калган мөнәсәбәтләре тәки җылына алганы юк! Роза һаман Фәләхкә шикләнеп карый иде. Инде менә бу хәлләрне дә белсә, ни эшләр ул? Их-их-ииих!

Бигрәк тә ахмакларча килеп чыкты шул бу соңгысы.

## 24

...Җомга көн иде. Эш бетәргә нибары бер сәгать кенә калып бара. Иртәдән кичкәчә чамасыз эссе булды. Шуның өстенә тагын Фәләхнең эшендә дә күңелсез хәл килеп чыкты: гаражда эшләүче бер слесарьның, КамАЗ кабинасыннан төшкәндә, егылып аягы сынган иде. Андый хәлләр тормышта булып тора. Тип-тигез урамнан барганда ялгыш басып аяк имгәтүчеләр дә аз түгел. Ләкин эш урынында андый очракка мөнәсәбәт башка: техника куркынычсызлыгы тиешенчә куелмаган дип карыйлар. Фәләхне дә шуның өчен чакыртып аңлатма сораганнар иде. Ә бу инде күңелле нәрсә түгел. Моның хакында бөтен инстанцияләрдә һәм төрле киңәшмәләрдә сүз күп булачак әле...

Шуңа Фәләх ул көнне бик арып, нервланып, эш сәгатенең тизрәк бетүен көтеп утыра иде. Эштән соң бик шәпләп мунча керә, атна буе җыйналып килгән тән һәм җан керен юып чыга да, өйләренә кайтып, таралып, рәхәтләнеп бер туйганчы йокларга ниятләнеп тора. Мунча директорына шалтыратып, номер сөйләшеп куелган. Атна ахыры булгангадыр, йомыш белән керүчеләр әллә ни күп түгел. Ләкин эше күп: үткән атна эшләрен йомгаклап, киләсе атнаныкын билгеләп утыра иде. Шул чакны аны кинәт сискәндереп телефон шалтырый башлады. Гасимә шалтырата икән.

— Фәләх Мөхәммәтович, синме?— диде ул ашыгып.— Бу мин әле. Районнан шалтыратам, шуңа начар ишетеләдер... Мин сине яхшы ишетәм. Ни хәлләр бар Казанда?.. Минем эшләр начар түгел. Шефлык концертлары бирергә чыккан идек... Дүртесе үтте инде. Бик әйбәт кабул иттеләр. Кызу эш өсте булуга карамастан, заллар шыгрым тулы булды. Көндезләрен кояшта кызындык, ял иттек. Бүген соңгы концертыбыз. Иртәгә — Казанга. Ләкин минем сине бүген үк күрәсем килә. Ничек итепме? Бик ансат аны эшләве, тик теләк кенә булсын... Алайса, сезнең анда эш сәгате бетеп килә, әйдә, гомерегезгә бер тапкыр егетлек эшләп, килегез әле бүген авылга да бергә кайтыйк әле... Ерак түгел. Питрәч районында гына. Бер сәгатьлек юл. Авылымы, хәзер әйтәм... Әйе, Питрәчтән өч-дүрт чакрымда гына... Розагамы? Аңа шул инде, срочный командировка килеп чыкты диярсең... Ә син ашыкма. Әле кызыңны бакчадан алып, хатыныңа әйтеп килергә вакытың бар. Безнең концерт төнге унберләрдә генә бетә. Шул чакка килеп житсәң бик әйбәт була. Карале, Мөхәммәтович, син, пожалуйста, теге противный шоферың белән килә күрмә, ямме!.. Аны күрсәм, нервым бозыла минем. Шымчы шикелле тоела ул миңа... Сөйләштек алай булгач, әйеме?.. Ярый, көтәм, җан кисәгем. Чао!..

Менә шул. Әллә сихере үк бар иде инде ул хатынның. Ник каршы килеп бер сүз әйтә алсын Фәләх! Кара син аны ничек итеп китереп каптырды бит: «Күрәсем килә», имеш! Андый чакта ничек каршы килә аласың инде? Бик теләп тәвәккәлләргә булды Фәләх.

Уйлана торгач, Розага әйтергә сәбәбен дә тапты. Шулай ял көннәрендә үзе кебек житәкче иптәшләр белән балыкка янсә ауга чыккалый

торган гадәте бар иде аның. Дөрес, анда балык тотып мәшәкатьләнмиләр. Су буена утырган районнарның берәрсендәге балыкчылардан яисә турыдан-туры складтан гына балык шулпасына да, өйләренә алып кайтырга да җитәрлек итеп алалар да калган вакытларын су коенып, кояшта кызынып, рәхәт күреп кайталар. Ауга барганда, дөрес, алай ук ансат булмый. Анда һәркемнең үзенә кәсеп итәргә туры килә. Тик анда да, гади шәһәр аучылары шикелле, кош-кортны һәм киек-җәнлекне кайда туры килсә шуннан эзләп йөреп азапланмыйлар. Җирле аучылар белән алдан бәйләнешкә кереп, кош-корт һәм җәнлек-киек күбрәк булган, аларны бүтән аучылар өркетмәгән җирләргә, ә кайчакларда хәтта район ау инспекторларының үзләре белән бергәләп, ау гомумән тыелган зоналарга ук керәләр. Беркайчан да буш кул белән кайтмый торганнар иде.

Аннары килеп Роза үзе дә, кызлары Розалия дә балык, ит яраталар. Шуңа күрә Роза Фәләхнең балыкка, ауга баруына каршы килгәне юк. Карап кына йөри күр инде, атасы, хәвеф-хәтәргә юлыга күрмә, дип кисәтеп, хәерле юл теләп кала иде.

Хәзер август башы — балыкның иң тәмле чагы. Ләкин, күңеле нидер сизенә иде ахрысы — ул кичне Роза аяк терәп каршы төште.

— Бармыйсың — и все! — диде ул.— Иртән — пожалуйста! Теләгән җиреңә кит. Ләкин кичтән җибәрмим, Фәләх!

— Ничек инде җибәрмисең? Мин бит үзем генә түгел. Иптәшләр белән. Алдан ук сөйләшеп куелган. Мин бармасам, алар да бара алмый кала бит! Шундый ук эгоист булырга ярамый ич инде, кызый!

— Ничего, бер тапкыр эгоист булудан гына дөньяң җимерелмәс. Балыкка бармый калганнан гына иптәшләреңнең дә маңгаена мөгез үсмәс. Хатыннары шатланыр гына!

— Роза, син ни сөйлисең, ә? Бөтен планны җимерәсең бит безнең! Районга да шалтыратып куелган: безне көтеп торалар. Я инде, акыллым, «бар» дип әйт, ә?

— Сорама да, Фәләх, әйтмим дә! Әгәр инде бик-бик атлыгасың икән, ул чакта, әйдә бергә барабыз!

— Бик алыр идем, җаным. Син барсаң уханы да үзең пешерер идең. Ну, нишлим соң, алмакаем, дүртәү барабыз бит без. Урын юк бит машинада!—«Әйе, син генә кирәк идең анда!» дип уйлап әйтте.

— Берегез калып торсын! Икенче юлы барыр.

— Алай булмый инде ул, энисе! Кешеләр бар да әзерләнгән-җыенган бит. Ничек итеп берсен генә аерып калдырасың?

— Жирәбә салабыз!

— Роза! Нинди хәлгә куясың син мине иптәшләр алдында! Алар бар да солидный кешеләр. Берсе гастроном директоры. Берсе — горисполкомнан. Берсе — Татсоюздан. Ләкин үз машиналары юк.

— Сиңа хатының кадерлеме, гастроном директорымы?

— Роза дим! Нишләдең син бүген? Ник шул тикле үзсүзләнәсең?

— Бүген минем сине нигәдер җибәрәсем килми, Фәләх. Бер дә бүтәнгә түгел, фәкать кадереңне белгәнгә генә шулай үзсүзләнәм.

Моннан ары да ялынуның барыбер файдасы булмаячак иде. Ничек кенә ашыкса да, Гасимә янына баруны иртәгәгә калдырудан башка юл калмады. Ә анда Хәкимҗан агайны алып бару турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Хуҗалыкта башка шоферлар да бар иде барын. Ләкин андый юлга якыннан таныш булмаган кеше белән чыгу — алдан ук үзеңне бөтен дөньяга фаш итеп кую белән бер булачак иде.

Әнә шуларны уйлаганнан соң Фәләх бер үзе генә тәвәккәлләргә булды. Институтта укыганда аларга шоферлык правосы да бирелгән иде. Ләкин машина йөртү практикасы бөтенләй юк диярлек. Кулында

дәүләт «Волга»сы һәм аны йөртүче персональ шоферы булганлыктан, бензин әрәм итеп, мәшәкать арттырып этисе белән әнисе бүләк иткән үз «Жигули»ында йөрүнең аңа һич кирәге юк. Тик ауга, балыкка барган чакларында, анда да сирәк-мирәк кенә. Хәкимҗан агай урынына рульгә утырыштыргалап караганы бар иде дә гомерендә бер тапкыр үз машинасы белән Зеленодольскига барып кайтты. Анда да, кызыл утка ялгыш барып кергәне өчен штраф түләттеләр һәм талонны тиштеләр. Шуннан соң «Жигули»ына бөтенләй утырганы булмады.

Ләкин бу юлы аның бүтән чарасы юк. Гасимә янына тик үз машинасы белән генә барырга мөмкин иде. «Башкача ярамый, чөнки Гасимә белән теләгәнчә йөреп булмаячак. Ә болай ичмаса иркенләп, курыкмыйча йөрермен!»— дип уйлаган иде ул һәм эштән кайтышлый Хәкимҗан абзый белән гаражга барып, үз машинасын ала ук кайткан иде. Ә хәзер менә, Розага сиздермичә генә, аны кире илтеп куярга кирәк инде. Өй янында калдырырга һич ярамый — берәр нәрсәсен чәлдереп яки бөтенләй урлап ук китүләре мөмкин. Андый яңа машинага кызыгучылар күп ул. Әле күптән түгел генә Фәләхкә таныш бер инженер-химикның унбиш ел буе тиенләп акча җыеп алган өр яңа «Волга»сын ярты сәгать эчендә ишек төпләреннән урлап киткәннәр иде. Ике көннән соң Оргсинтез ягындагы урманнан милиция табып биргән бирүен. Ләкин өр яңа машинаның кузовы белән моторы гына калган, алып булырдай бөтен частьләрен алып, хәтта көпчәкләренә кадәр салдырып алып киткәннәр... Гаражы өй янында булмаган кешегә машина тотуның әнә шундый хәтәр яклары бар аның. Фәләхнең дә әлегә гаражы юк, машинасын ул автохуҗалыклары гаражында тотарга мәҗбүр. Ә ул гараж ерак — Ленин районында ук. Машинага утырып каядыр барып кайтам дип, ничек итеп Горкидан анда кадәр барып йөрмәк кирәк? Үз машинасы белән йөрмәвенең сәбәбе тагын әнә шуңа да бәйле иде. Үзең торган йорт тирәсендә гаражга урын алу — сират күперен кичүдән ким түгел икән ул. Мәсьәлә алдагы бер-ике айда хәл ителергә тиеш иде. Ике Ватан сугышы инвалидына, шулар белән бергә Фәләхкә дә, үзләренең өй каршында гына урын биреләчәк, тик кайбер формальностьларын гына хәл итеп бетерәсе калган иде. Ә урыны булса, гаражны ул иң оста ташчыларны дәшеп, ике көн эчендә төзетеп куячак. Инде кирпечләренә хәтле яздырып, акчаларына тикле түләп куйган иде... Ләкин хәзер гаражның кирәге калмады инде болай булгач. Машинасы тәмам эштән чыккан бит һәлакәт вакытында... Ә бит өченче көн, Розага балыкка барам дип ялганлап, ашыга-кабалана Гасимә янына авылга китәргә йөргәндә мондый аянычхәлләр булырын уена да китермәгән иде ул. Аның әле машинасы да өр яңа һәм аны ничек тә гаражга илтеп куярга кирәк иде.

— Ярар, алайса, синеңчә булсын: бүген бармыйм!— диде ул, ни тырышып та Розаны ризалаштыра алмагач.— Ләкин миңа иптәшләрне кисәтеп куярга кирәк. Интегеп юкка көтеп тормасыннар,— диде ул һәм тиз генә машинасын гаражга илтеп кайтты да ятып йоклады.

Иртән, Роза аны-моны уйламасын өчен, юри ашыкмыйча:

— Бүген баруның ни кызыгы калды инде менә? Балыкның юньлесе бит аның иртән чиртә,— дип сукрана-сукрана гына, сәгать сигезләрдә генә өйләреннән чыгып китте. Чөнки авылда туып үскән ул, белә: анда концерт төнге унбер-уникесез бетми. Бер килгәндә туйганчы күреп калыйк үзләрен дип, авыл халкы артистларны кат-кат чакырып җырлата. Шуңа концерт озакка сузыла. Концерттан соң алар гадәттә, бергә җыйналып, ашап-эчеп, һәркайсы үзенең тәэсире белән уртаклашып, сәгать төнге берләргә-икеләргә тикле утыралар. Чөнки, авыл халкы шикелле, сәгать дүрттән-биштән торып эшкә китәселәре юк.

Менә шуна күрә Фәләх, Гасимә йокысыннан уянгалаганчы бары-бер барып җитәм әле мин аның янына дип, йокысын туйдырып, соңлап кына кузгалды. Ул барып җиткәндә Гасимә инде күптән торган һәм, нервланып үзе фатирга кергән йортның капка төбендә арлы-бирле йөренеп тора иде...

## 25

Шуннан ары ниләр булганы — инде билгеле. Күпме генә үкенсә дә, ни кадәр генә өзгәләнсә дә, Фәләх хәзер бер нәрсәне дә кире кайтара да, үзгәртә дә алмый. Бу һәлакәте өчен ул бүтән беркемне дә гаепли алмый, чөнки барысына да үзе, тик үзе генә гаепле иде. Һәм бу һәлакәт очраклы килеп чыккан нәрсә генә түгел, бәлки күптәннән әзерләнеп килгән котылгысыз фаҗига иде. Моның шулай икәнлеген Фәләх менә хәзер, больницада төн буе уйланып ятып, бөтен тормышын күз алдына китергәч аңлады. Һәм аңа аеруча кыен, аеруча үкенечле булып китте.

Аның хәзер тик бер генә өмете бар: үзе таптаткан мотоциклчы егетнең исән калуын тели иде ул. Әгәр шулай булса, Фәләх аны ничек тә, әтисенең машинасын биреп булса да, җайлаячак. Ә башка якларын ул дус-ишләре, таныш-белешләре ярдәмендә барысын да бик тиз рәтләячәк. Һәм моннан соң ул инде болай юләрләнеп йөрмәс, йөз мәртәбә акыллырак булыр, гомерендә бер тапкыр да гаделсезлек эшләмәс, башкаларның гаделсезлегенә дә юл куймас иде...

Ләкин мотоциклчы егетнең бу дөньяда инде юклыгын, аңына килә алмыйча, төнге сәгать икенчедә вафат булганын ул әле белми иде.

*1979—1981*

## Салисә Гәрәева

# УРАЛ ДӘФТӘРЕННӘН

### Прокат цехында

Рольганглар[1] буйлап прокат ага —
Янып сала юлын ак ялкын.
Пролетларга көчле ирләр хуҗа —
Эшли алмый монда кыз-хатын.

Маңгайларга кунган тир тамчысы,
Кыю, кырыс йөзләр — чын бакыр.
Улларыңның, Урал, батырларын
Прокат цехларына син чакыр!..

Ут елгасы янып, ярсып ага —
Нинди тылсым тауны эреткән?
Вальцовщиклар хуҗа бу һөнәргә,
Урал, синдә элек-электән...

Ялкын сере, металл, руда сере
Аталардан күчә улларга,
Рольганглар буйлап прокат ага —
Маяк булып килер елларга.

### Корыч авазы

Мартен мичләрендә эретелгән,
Күксел төскә кергән корыч мин;
Музейларда тарих өне булып
Урын алган булат кылыч мин.

Дөньядагы бөтен машиналар
Минем сабыр тәннән уелган.
Җылы куллы эшче, минем сүзне
Чыгарма син һич тә уеңнан:

— Кешеләргә үлем китерүче
Коралларны миннән уймагыз!
Корыч — тыныч хезмәт коралына,
Сугыш өчен түгел. Уйлагыз —
Коралларны миннән уймагыз!..

---

[1] Рольганг — металл аккан улак-конвейер.

## Миллионлы шәһәрдә

Миллион кеше яши бу шәһәрдә —
Һәр кайсысы төгәл исәптә.
Һәммәсенә кагылыр өчен җаным
Өзгәләнә миллион кисәккә...

Таш урамнар, биек тәрәзәләр
Ачылганнар кояш нурына.
Шәһәр җылы! Миллион кайнар йөрәк
Тибүеннән чөнки җылына.

Кою цехларында яшен-утлар
Бер елкылдап ала, бер сүнә.
Күптән гашыйк минем йөрәгем дә
Батырларның шунда берсенә.

Тимер тыны, тимер чыңы монда:
Корыч коя Урал, кырыс ул —
Миллионнарга газиз тынычлыкны
Саклар өчен кирәк корыч ул.

## Бурап-бурап кар яуса да

Кар көртләрен себерә җил,
Куа Урал түренә.
Кара буран арасыннан
Якты утлар күренә.

Минем завод. Цехларында
Бөтен җирнең картасы.

Шул цехларда минем тормыш —
Йөрәгемнең яртысы.

Бурап-бурап кар яуса да,
Бүленми юлым аңа:
Шул цехларда минем өчен
Меңләгән йолдыз яна...

## Манзара

Завод бакчасына ялга чыктым,
Файдаланып бер буш вакыттан.
Алмагачлар сыгыла алмалардан,
Миләш тәлгәшләре — якуттан;

Сары кунган яшел агачларның
Яфраклары коела берәмләп.
Бар агачлар боек. Чыркылдашкан
Чыпчыкларда гына күрәм дәрт.

Бар агачлар боек. Озакламый
Алар талыр кышкы йокыга;
Төшләренә ямьле язлар керер,
Утырганда төренеп сыкыга...

Алмагачлар җиргә алма коя,
Җәй балкышын күрәм аларда.
...Миләшләрнең алсу күз яшьләре
Менә-менә тора тамарга.

## Тауларда кояшны сагыну

Урал урманнары, таулар, күлләр...
Югарыдан аккан болытлар
Моңсу бүген: әллә аларда да
Үзгәрүчән минем холык бар?

Тауга менсәм, җилләр елый бүген,
Наратлыкка керсәм — ылыслар;
Болытлардан елак яңгыр ява,
Биек таулар гына тынычлар...

Ташлы сукмак, биеккәрәк меник —
Болытлардан өскә үрел син!
Нуры белән юып моңнарымны,
Миңа кояш балкып күренсен!..

## Чуен күпер

Чуен күпер, чуен челтәр күпер,
Шөреп белән кыскан җөйләре;
Бер ягында вокзал, бер ягында
Күп тәрәзле шәһәр өйләре...

Мин вокзалга киләм: юлларның ул,
Шәһәрләрнең бәйли арасын.
Җыйган вокзал безнең язмышларны,
Сагышларны, йөрәк ярасын.

Болыт түгел — өстә аерылуның
Очып йөри кебек аһ-зары;
Бәрелешә кеше хәлләтенең
Җәе, кышы, көзе, язлары...

Син, күперем, шәһәргә илт мине —
Өзелмәсен монда үзәгем:
Вокзалда мин аңлашылмас әче
Бер сагыштан көчкә түзәмен...

## Усал кыш бураны

Тышта буран. Тәрәзәмә учлап-учлап
Кар сибә дә Урал кышы усалланып,
Сызгыра да кырын салып ак бүреген,
Үз тавышын тыңлап тора хәйран калып...

Тагын сибә тәрәзләргә йолдыз-карлар,
Шул карлардан бизәк ясый кызып-кызып.
Өсләренә чыршы кунган чал кыялар
Басып тора, ак башларын күккә сузып.

*Чиләбе*

## Ләис Зөлкарнәев

# ЯКТЫ КҮЛӘГӘЛӘР

●

Гөл илендә якты күләгәләр.
Яшим монда борын-борыннан.
Бал кортлары һаман гөлгә куна,
Ә мин гасырларга орынам...

Сабырлана төште ярсу холкым,
Дәрт-дәрманны әмма җуймадым.
Гөлдән гөлгә кунган бал кортыдай
Авырая бара уйларым.

Ачы тәҗрибәләр мирас миңа,
Яшим кебек борын-борыннан.
Ачы тәм ул китми... сагаеп, мин
Яңа гасырларга орынам.

●

Кара яллы аргамакта үткән тарих.
Төшкән гөрзи, очкан сөңге, атылган ук...
Дастаннарның алыпларын хәтерләтеп,
Канлы ташлар җиргә иңгән тубыктан ук.

●

Башлар гына түгел, ташлар китә,
Китә кайчак туган иленнән.
Кайгы кебек авыр балбал китте
Илдәшләрнең канлы иңендә.

Кара утта хәят. Яга дошман.
«Аһ»ларың ни аңа, зарың ни...
Кол дип, богау салган кул-аякка,
Әмма җанга зынҗыр бар мыни!

Мөһаҗирләр китә баш бирмичә.
Өелеп-өелеп кала байлык, мал.
Мал табылыр. Җәрәхәтле иңдә
Бабаларның рухы — таш балбал.

Иңгә баса, авыр, түзәлмаслык.
Ләкин арта бара инану:
Авырлыктан йөрәк кысылса да,
Ташламаска җиргә иманны!

Ташламаска! Юкса, бер көн килеп,
Киләчәгең алыр бугазлап.
Җиңеллеккә илтер авырлык бу,
Азатлыкка илтә бу газап!

...Балбал авырлыгын тоям иңдә.
Юлым ерак. Алда — бар әле...
Туган халкым бара чорлар аша,
Иңнәрендә — тарих. Яралы.

●

Бетәшми тын, бөрешми җан —
Бәгырьләргә җил бәрә.
Чүп булып оча күңелләр —
Вакыт безне җилгәрә!

Суырылып ук төшәбез бит,
Сутлылар без — гәрәбә.
Бу мизгелдә безнең уйлар
Орлыкларга бәрабәр.

Ныклыларны сайлый вакыт.
Гайрәтле иңнәребез.
Заман йөген күп күтәреп,
Каты җиргә иңәрбез.

Канәгатьлек булмаса да,
Язмышка үпкә калмас.
Тәннәр җиргә сыйсалар да,
Тик җаннар сыя алмас!

Киләчәкнең һәр иманe
Безнең хакта хәбәрдар.
...Мәңгелек өчен безнең җан
Орлыкларга бәрабәр...

●

Мәңгелектән исә җил.
Күк, куркып, төнне коча...
Ай — бу җилдә тузганак,
Җиһанга тузгып оча...

## Көз

Дөрләп янып йөгереп үткән
Кызыл төлке эзләдем.
Куак төбе саен икән
Сибелеп калган эзләре.

Ут койрыгын җиргә кысып,
Болыннарга елышкан.
Берән-сәрән яшел каурый...
Тик шул калган Җәй-коштан.

Эзләренә тузак салмыйм —
Сунар түгел ниятем.
Эзе буйлап киләм менә
Ап-ак кәчек иятеп.

Тәүфикъ Әйди

# АТАЛАР ҺӘМ УЛЛАР

## Беренче үр

Мәскәү. Бөтенсоюз читтән торып укыту политехника институтына фәнни конференциягә җыйналучылар пөхтә итеп киенгән, көлсу чәчле ир трибунага таба атлаганда бер мәл: «Нигъмәтуллин!» — «Нигъмәтуллин үзе!» дип гөжелдәп алдылар.

Залда утырган яшь галимнәр, электр станциясе директорлары һәм баш инженерларының байтагы профессор Нигъмәтуллин шәкертләре иде. Алар пленар утырышта доклад ясаучы остазларының конференциядә секциягә җитәкчелек итәчәген, атом энергетикасындагы яңа техника турында кызыклы фикер әйтү ихтималлыгын алдан ук чамалап торалар һәм шул мәҗлескә әлегергә план коралар иде.

— Искәндәр Нигъмәтуллович моннан егерме еллар элек үк тепловоз двигателенең яңа сызымын тәкъдим иткән булган икән,— диде конференция делегатларының берсе. — Әмма аны ул чакта кабул итмәгәннәр. Шушы арада министрлыкның фәнни-техник советында тузан кунып беткән проектны кире алып карагач, бер үк үлчәмдә катнаш двигательне шуннан да куәтлерәк итеп башкача ясап булмаслыгына ышанганнар. Профессорның исәп-хисапларын файдаланырга карар биргәннәр. Заманында проектка каршы чыккан кеше: «Бу сызым дөрес булган икән» дигән.

«Хәзерге заман төш реакторлары», «Җылылык энергетикасының киләчәге», «Атом электр станцияләре», «Атом электр станцияләрен биологик ышыклау». «Төш реакцияләре»... Болар — исеме ерәкларда билгеле булган шул профессорның китаплары. Бирәдә бик азы гына саналды әлбәттә. Аларның аңлаешлы төстә гади укучыларга атап язылган, кайсы студентларга билгеләнгән, озын-озын тигезләмәләр, сызымнар белән чуарланганнарына исә бары тик белгечләр теше генә үтәрлек. Бу хезмәтләрдә күтәрелгән мәсьәләләргә заманча караш хас. Атом куәте, реактор төзелеше, термотөш синтезы — ул һәрвакыт әнә шундый саф техник мәсьәләләргә күмелеп яши. Әйтерсең шуларның зур белгече буразна арасында тәгәрәп үскән игенче малае түгел!

Искәндәр Нигъмәтуллин хәзерге Башкортстанның Благовар районы Каргалы авылында 1908 елда туган. Комсомолга кергәч ул аның авыл оешмасын җитәкли. Үткен егет совет властен ныгыту эшенә чын күңелдән бирелеп хезмәт итә. Бераздан аны комсомолның Тамьянкатай кантоны секретаре итеп сайлыйлар, аннары Аргаяш кантонына җибәрәләр.

1926 елда Искәндәр башкалага килә һәм Мәскәү университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Бер үк вакытта үзе дә укыта — татар мәктәпләрендә гуманитар фәннәрдән дәрес бирә. Рабфакны тәмамлагач, аны университетка керергә өндиләр, әмма Искәндәр техник уку йортында белем алырга хыяллана. Бу чорда Мәскәүдә Бауман исемендәге Югары техник училище арада атаклы булганлыктан, ул шунда юл тота. Анда укуын уңышлы тәгәлләгәч, 1935 елда аспирантурада калдыралар һәм, өч

ел узуга. Нигъмәтуллин Югары техник училищеда кандидатлык диссертациясен яклый.

Сугыш чорында Нигъмәтуллин да фронтка китә. Башта ул алгы сызыкта полк командиры урынбасары буларак сугыша, аннары хәзерге Лихачев исемендәге Мәскәү заводына хәрби вәкил итеп билгеләнә. Дошман тар-мар ителгәч, яңадан яраткан хезмәтенә әйләнеп кайта.

Бу елларда Искәндәр фән дөньясына аерым бер үҗәтлек белән аяк атлый. Гыйльми хезмәтләрен язар өчен иртәдән алып төн уртасына кадәр мавыгып утыра, вакыт-вакыт кына тәнәфес ясап, дачасында җир казу, кагу-сугу белән шөгыльләнеп «ял» итеп ала. Институттагы кабинеты суык булганлыктан, костюмын, җил тимәсен өчен, эчке ягына газета кыстырып кия. Аның шулай ун-унике градус салкында да тыныч кына эшләп утыруына хезмәттәшләренең исе китә. 1954 елда Искәндәр «Зур егәрлекле кораб, тепловоз двигательләре конструкцияләүдә яңа сызымнар» дигән темага докторлык диссертациясен язып тәмамлый. Бер-бер артлы яңадан-яңа монографияләре, китаплары чыга, гыйльми журналларда мәкаләләре басыла.

И. Нигъмәтуллин фәнни эшен һәрвакыт укыту белән бергә бәйләп алып бара — соңгы вакытта ул Мәскәү Бөтенсоюз читтән торып укыту политехника институтында җылылык һәм атом электр станцияләре кафедрасына җитәкчелек итә. Мәскәү институты шушы тармактагы югары уку йортларының терәк базасы санала, аның үзендә генә дә кырык мең студент белем ала. Шунлыктан профессор Нигъмәтуллин дәреслекләр, төрле кулланмалар язуга аеруча әһәмият бирә, методик ярдәмлекләр чыгару, уку планнары төзүдә дә актив катнаша. Техник фәннәр докторы И. Нигъмәтуллинның вузларда укыту стажы дүрт дистә еллап инде. Һәм шулар өстенә тагын Бөтенсоюз һәм халыкара фәнни конференцияләрдә ясаган докладлары белән чыгышлары күпме! Егерме яшендә партия сафына баскан, совет фәнен, халык хуҗалыгын үстерүгә күренекле өлеш керткән бу эшлекленең тормыш юлы һәм эшчәнлеге илебезнең аякка басу һәм ныгу тарихыннан аерылгысыз.

## Атасы юлыннан

1971 елда Мәскәү университетының гыйльми советында илебезнең күренекле галимнәре игътибарын җәлеп иткән бер докторлык диссертациясе яклана. Дулкынлы механика табышмакларын чишкәндә математик ысулларны файдалану, анализ процессларын тигезләмәләргә салу, мондый тигезләмәләр төзүнең гомуми алымнарын эшләү һәм, аеруча кызыксыну уяткан сыйфаты — классик юлдан башка вариантларны табу, исәп-хисапларны электрон-санау машиналары ярдәмендә башкару белән хезмәт күпне күргән гыйлем ияләрен дә сокландыра. Доктор булырга җыенучы Роберт Нигъмәтуллинның әле генә утыз яшьне тутыруы исә тагын да тансыграк яңалык була. Мондый җитди, гадәти булмаган диссертацияне алар инде, әлбәттә, фән кырында үрмәли-үрмәли «тоз ашаган», тир түккән чал чәчле тикшеренүче генә язуы мөмкин, дип уйлагандыр. Хәер, чал чәч дигәннән, тал чыбыгыдай төз буйлы, озынча йөзле диссертант егетнең башында да көмеш бөртекләр юк түгел.

Механикага тансык яңалык китергән фәнни хезмәт. Әйдәгез, без дә аңа беразкүз салып алыйк әле.

«Фән — әйберләр арасындагы бәйләнешләрне, аларның законнарын һәм үзара тәэсир итешүләрен ача торган көч»,— ди А. И. Герцен.

Роберт яраткан язучысы, саф гуманитар кеше әйткән сүзләрне техник тармакта-механикага яңалык китергән фәнни хезмәте белән раслый.

...Төрле составлы тирәлек су-газ динамикасы хәзерге вакытта һаман киңрәк кулланыла торган сыеклыклар, газлар, плазмалар физика механикасында иң әһәмиятле өлкә булып тора. Бу тармакта информация язгы ташкын шикелле үсүгә карамастан, төрле составлы тирәлекләр механикасының төп казанышлары һәм аларны хәзерге заман техникасының гамәли бурычларын үтәүдә куллану буенча безнең көннәргә кадәр тезек һәм системалы мәгълүмат биргән бер генә җитди теоретик хезмәт тә юк иде. Робертның «Гетероген тирәлекләр механикасы мәсьәләләре» дигән докторлык диссертациясе нәкъ менә шундый яңа, оригиналь хезмәт булып чыга. Гомуми теоре-

тик яктан фундаменталь һәм методик яктан әһәмиятле тикшеренүен йомгаклап, автор шул теориясен үтә мөһимлеге шик уятмый торган аерым мәсьәләләрне хәл иткәндә эшкә дә җигеп күрсәтә.

Бүгенге техника иң кителмәгән күп фазалы катнашмалар белән эш итә. Җылылык энергетикасы җайланмаларында эшче матдә буларак еш кына пар һәм кайный торган су катнашмасы хезмәт итә. Реактив двигательнең яну камерасыннан һава агымына аралашкан ягулык кисәкчәләре дә ургылып чыга. Шуңа күрә белгечләрне катлаулы тирәлек механикасы, аның хәрәкәт законнары, төрле тәэсирләр вакытында компонентларның үзара мөнәсәбәтләре кызыксындыра. Нигъмәтуллин нәкъ менә төрле күп фазалы системаларның гомуми математик модельләрен төзү һәм тикшерү белән мавыга.

Күмер шахталары һәм тегермәннәрдәге очраклы нәни шартлау гына да коточкыч җимерү көченә ия булуы билгеле. Чөнки яна торган кисәкчәләр аралашкан һавада бәрмә дулкын таралганда шартлау үз көчен әлеге кисәкчәләр яну энергиясе хисабына арттыра. Бу һәлакәтле күренеш серләрен ачу гадәттән тыш әһәмиятле. Әмма бәрмә дулкын тәҗрибәләрен ясау үтә катлаулы һәм читен. Шунлыктан акыл көче белән тәҗрибә ясау аеруча җитди әһәмияткә ия. Робертның математик хисаплаулары катлаулы физик күчешләрне аңлауга ачыклык кертеп кенә калмый, ә хәвефсезлек техникасын камилләштерүгә дә ышанычлы җирлек бирә.

Бәрмә дулкын авызлыкланырга тиешле җимергеч көч кенә түгел, техникада кеше файдалана алырлык куәтнең тылсымлы чыганагына да әйләнә ала. Мәсәлән, нык тимер җитештерү өчен металлны мең градус чамасы кызуда чыныктырырга туры килә. Моның өчен махсус цехлар төзү, күп ягулык тоту һәм башка чыгымнар ясау кирәк була. Әгәр басымны 150 мең атмосферага җиткерсәң, тимерне түбән температурада тагын да көчлерәк ныгайтып була. Каты җисемнәрдә югары тизлектә таралучы бәрмә дулкын миллионнарча атмосфера басым барлыкка китерә. Димәк, металларны катылаңдыру өчен бәрмә дулкынны файдалану бигрәк тә кителмәгән нәтиҗәләр бирә ала икән. Аны техникада кулланыр өчен исә бәрмә дулкын табигатен яхшы белү таләп ителә. Робертның ЭВМ санау машиналарындагы хисаплаулары бу күренешне дә тәгәл һәм ачык итеп күз алдына бастыра.

Электр станцияләре эше, атом энергетикасы үсеше, канал казу, нефть, мәгъдән чыгару кебек халык хуҗалыгының күп кенә тармаклары өчен гаять кирәкле һәм актуаль тикшеренү җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Чөнки Робертның теоретик ачышлары гамәл өчен бик әһәмиятле күрсәтмәләр бирергә, фаразлар ясарга һәм тәкъдимнәр кертергә мөмкинлек тудыра. Физика-математика фәннәре докторы Л. Ю. Якимов, СССР ФА член-корреспонденты Ю. Н. Ильюшин, академик Ю. Н. Работнов диссертантка күп кенә сораулар бирә һәм канәгатьләнерлек җавап ала. Ахырда академик Л. И. Седов:

— Фәннең бер өлкәсендә традицияләр җимерелә, тоташ тирәлек механикасына яңа параметрлар кертелә, аларга яңа тигезләмәләр төзелә. Хәзерге заман мәсьәләләрен менә шулай чишәргә кирәк тә, бу — кыю һәм дөрес юл. Бик әйбәт диссертация! — дип чыгыш ясый.

Физика-математика фәннәре докторы исемен казанган Роберт Нигъмәтуллин бу вакытта Мәскәү университетында шундый дәрәҗәгә ия иң яшь галим була. Утыз яшьтә моңа ирешү, гомумән, сирәк очрый.

1973 елда Робертның фәнни хезмәтләре дәүләтебез тарафыннан тагын бер тапкыр билгеләп үтелә.

«Бу хезмәтләр җыелмасында иң әһәмиятлесе — күп компонентлы, күп фазалы тирәлекләрнең гомуми модельләрен ачык, гадәттән тыш анык итеп төзү,— дип яза РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, СССР дәүләт премиясе лауреаты профессор Л. Г. Лойцянский. Нигъмәтуллин эшләгән алымнар шул кадәр камил ки, алар су динамикасы буенча уку кулланмаларына кертергә лаек. Мин инде аларны үземнең дәреслегемдә файдаландым да.

Барлык нәтиҗәләрне санап тормастан, төп фикерне белдерсәк, казанышлар мөһим һәм алар җылылык энергетикасында, шул исәптән, төш энергетикасында, ракета һәм авиация техникасында, химия промышленностенда, махсус технологиядә, яңа техниканың башка өлкәләрендә дә кулланылыш табачак».

Галимнәрнең фикере бердәм була — Роберт 1973 елда Ленин комсомолы премиясе белән бүләкләнә.

Бу уңышларга ничек килгән соң ул?

...Биш хуҗага бер уртак кухня, анда керосинкалар, примуслар. Нигъмәтуллиннар биш җан булып, заманында буйдак Искәндәргә бирелгән нәни генә бер бүлмәдә яшиләр. Мич буенда утыны, бәрәңгесе тора. Сугыштан соңгы елларда мунчага чират зур булганлыктан, Галия ханым еш кына су җылытып, малайларны мич буенда юындырып ала. Дәрес әзерләгәндә бер-берсенә комачауламасыннар өчен, бердәнбер өстәлне сызгыч белән өч өлешкә бүлеп куя. Шунда ук әтиләре фәнни хезмәтләрен яза, әниләре тегү тегә. Җәйләрен врач Галия ханым, балаларга һава булсын дип, ыбыр-чыбырны җыя да Башкортстанның хәзерге Салават районындагы Янган Тау санаториена эшкә китә.

1957 елда Роберт Бауман исемендәге Югары техник училищега укырга керә. Әмма зирәк егет физика, математиканың шул кадәр күп өлкәләре белән кызыксына, яңадан-яңа гыйлем хәзинәләрен үзләштерергә сусавы шул хәтле көчле була, аны инде бер генә җирдә уку канәгатьләндерми. Робертның теләгенә институтның ректоры да каршы килми һәм аның юллавы белән училищеның дүртенче курс студенты Нигъмәтуллин параллель рәвештә укырга Мәскәү университетының беренче курсына кабул ителә. Ике көймәнең койрыгын тотар өчен иртән өйдән чыгып киткән Роберт укудан төнлә генә кайта торган була.

1963 елда ул Югары техник училищены бик яхшы билгеләр алып тәмамлый һәм шунда ук инженер итеп калдырыла. Аңа училище аспирантурасына керергә тәкъдим итәләр, әмма теоретик эзләнүләр белән мавыккан егет берәүләрне дөнья каласын алгандай сөендерерлек мөмкинлектән файдаланмый, форсат чыгу белән, Мәскәү университетының механика институтына кече фәнни хезмәткәр булып урнаша, мехмат факультетында укуын дәвам итү белән икеellык инглиз теле курсларына йөри башлый.

Институтта аңа тикшерү өчен берничә тема тәкъдим итәләр. Нигъмәтуллин шартлауларга бәйле мәсьәләне өйрәнергә керешә. Әмма Роберт, 1965 елда университетны тәгәлләгәч үк, башлаган эшләрен туктата. Бу вакытта инде аны күп фазалы тирәлек механикасы кызыксындыра. Тармакның яңа бүлегендә эшләнгән эшләр дә була, әмма әле башлангыч нәтиҗәләргә генә ирешелгәнлектән, бу өлкә куәтле үсеш кичерә, Робертка бик перспективалы күренә. Яшь галим «Ике фазалы тирәлекләр механикасының кайбер мәсьәләләре» темасын тикшерә башлый һәм тиз арада үзәк журналларда берничә мәкалә бастыра. Бәхеткә каршы, ул бу юлы заманыбызның иң күренекле механикларыннан исәпләнгән Үзбәкстан ФА академигы Хәлил Рәхмәтуллин һәм академик Седов кулы астына эләгә. Алар Робертның эзләнүләрен хуплый һәм урынлы киңәшләре белән Нигъмәтуллинга беренче адымнарын атлап киткәндә ныклы һәм ышанычлы таяныч була.

Сәләтле булса, үз көченә лаек максатлар куеп эшләсә, кеше югалмый. Билгеле, фикер алышу, бәхәсләргә керү, чигенүләр, яңа эзләнүләр котылгысыз. Яңа чишелеш юлны һәрвакыт җиңел ярмый. Француз академигы Сен-Венан, мәсәлән, бер проблеманы яңача хәл иткәч, шул кадәр тәнкыйть ителә ки, ул үз ачышыннан баш тартырга мәҗбүр була. Бары берничә ел узгач кына Сен-Венан чишелешен аңлыйлар һәм аның тикшеренүе классик эш буларак танылa.

Роберт та тикшеренүендә яңа юллар эзли. Шул рәвешле гадәти үк булмаган чишелеш нигезендә язылган бер мәкаләсен «Сыеклыклар һәм газ механикасы» журналына җибәргәч, редакция рецензенты аның яңалыгын аңламый һәм мәкаләгә тискәре фикер белдерә. Соңыннан бу рецензент үзенең ялгышканын аңлый, әмма аны ышандыру өчен барыбер байтак бәхәс алып барыла һәм вакыт сарыф ителә... Робертның кандидатлык диссертациясе 1967 елда хупланып каршылана, галимнәр аның өчен авторга фәнни дәрәҗә бирергә, дигән карар чыгаралар.

1967—70 елларда беренче уңыш белән канатланган Нигъмәтуллин эзләнүләрен тагын да киңәйтә һәм докторлык диссертациясен язарга керешә. Аның перспективалы эзләнүләре тиешле яклау таба — 1970 елда Робертны өлкән фәнни хезмәткәр итеп күтәрәләр, колачны тагын да җәебрәк эшләр өчен махсус группа оештыралар һәм Нигъмәтуллинга аның җитәкчесе булу тапшырыла. 1973 елда Роберт группасы

секторга әйләнә, анда фәнни хезмәткәрләр саны арта. 1974 елда ул институтның дулкынлы механика кафедрасы профессоры итеп сайлана.

Утыз яшендә үз мәктәбеңне булдыру бик сирәк галимнәргә генә насыйп була. Роберт Нигъмәтуллин — шундыйларның берсе. Ул башкала һәм Башкорт дәүләт университетларында лекцияләр укый, Мәскәү университетының механика институтында колачы зур секторга җитәкчелек итә. СССР Фәннәр Академиясенең Башкортстан филиалында Роберт мәктәбенең филиалы — күп фазалы тирәлекләр механикасы лабораториясе дә бар ич әле. Нигъмәтуллин, елына өч-дүрт мәртәбә Уфага барып, аларга ярдәм күрсәтә. Монда аның егетләре нефть эшкәртүдә торбалар тыгылу, утыру күренешен өйрәнеп, аны булдырмау өчен тәкъдимнәр әзерлиләр. Робертның Бакудагы шәкертләре — ике әзербайҗан аспиранты исә катламның нефть бирүен арттыру юлларын тикшерә.

Нигъмәтуллин җитәкчелегендә кандидатлык яклаган тугыз кеше арасында төрле милләт яшьләрен очратырга мөмкин. Якташларыбыз Әмир Гобәйдуллин, Наил Әхмәдиев, Наил Хәбиев, Шәйхулла Шиһаповлар да әнә шул егетләрнең бер өлеше. Хәзер галимгә тагын унике аспирант беркетелгән. Гадәттә фән докторының биш кенә аспирантка җитәкчелек кылуын истә тотсак, Нигъмәтуллинның кадрлар әзерләүгә нинди көч түгүе ачыграк аңлашылыр.

Агитатор, комсорг, институтның ВЛКСМ бюросы члены, бүлек профсоюз бюросы рәисе, институт месткомы председателе — Роберт һәрвакыт берничә җәмәгать эше алып бара. 1973 елда партия сафына алынган Нигъмәтуллин кичке марксизм-ленинизм университетын тәмамлый. Рәсеме «Мактау тактасы»на куелган Робертка бүген дә төрле вазифалар йөкләнгән. Сайлау комиссиясе председателе, механика институты парткомы әгъзасы, химия технологиясендә агромеханика казанышларын файдалану буенча Бөтенсоюз фән-техника комиссиясе члены. Шундый күп төрле эшкә күмелүенә карамастан, ул инде кыска гына вакыт эчендә йөзләп фәнни хезмәт бастырып өлгергән. Шуларның икесе — саллы, күләмле монография. Мәскәүнең «Фән» нәшрияты 1978 елда чыгарган «Гетероген тирәлекләр механикасы нигезләре» дигән калын китап кибет киштәләрендә күренүгә көне белән сатылып бетә. Аны җибәрүне үтенеп, авторга мөрәҗәгать итүчеләр, Робертның нәшрият планына кертелгән икенче хезмәтен дә ала алмый калудан куркып, алдан ук заказ рәсмиләштерәләр икән инде! Димәк, галимнең хезмәтләре чыннан да актуаль, димәк, аларда принципиаль яңалык бар.

— Балаларны үстергән чакта еллар авыр килде,— диде аның әнисе Галия ханым.— Өс-баш ягына да кытлык иде. Әле ярый үзем тегәргә остардым. Уфага кунакка кайткач:

— Ай-һай матур күлмәк, чалбарлар кидергәнсең, кайдан алдың? — дип сорашалар.

— Импорт! — дип көлә идем.

Бу сүзләр Робертның иркен фатирына килеп кергәч искә төште.

Китап шкафыннан Л. Ландау, К. Трусделл, Ц. Цянь — миңа таныш түгел авторларның саллы томнарын алып карыйм. «Сыеклыклар динамикасына кереш», «Пластикалык теориясе нигезләре», «Теоретик су механикасы» — китапларның исемнәре үк Робертның гыйльми дөньясын күзаллатырлык иде. Шунда ук Герцен, Тукай, Хемингуэй, Бунин, Гамзатов томнары, сүзлекләр...

— Боларны укырга кайчан өлгерә соң ул? — дип сорыйм Робертның хатыны Венерадан.

— Бөртекләп тормый, диагональ буенча эләктереп ала. Матур әдәбиятка, әтисе шикелле, төнге унбердән соң гына тотына. Чит илләргә баруы турында Роберт үзе өйттеме әле? Болгариядә халыкара конгресста доклад сөйләде. Мисыр, Мексикага баручы яшьләр делегациясе составына кертелде, Югославия, Япония чакырган халыкара конференцияләрнең оештыру комитетларына сайланды...

Роберт, Венера белән бергәләп, гарәп әлифбасын өйрәнгән, Еники әсәрләрен укыган, пианинода Бетховенның «Ай сонатасы»н, Чайковскийның «Ел фасыллары»н, Бородин, Даргомыжский әсәрләрен уйный икән.

— Без кайчакта Габдулла Сәгыйдуллин, Рәшит Сүнәев, Ревнер Ганиевләр белән җыйналышабыз,— ди Венера.— Алар да фән докторлары. Бик күңелле була. Габдулла оста җырлый, Роберт уйный. Беләсезме, Робертның энеләре — Булат белән Рәис

әле дә, энеләренә үпкәләп, «Сез Робертны гына музыка мәктәбенә йөрткәнсез», диләр. Асылда исә, балачакта үзләре теләмәгәннәр икән...

— Әй минем хатыным! — дип кәлә бу сүзләрне ишетеп алган Роберт.— Бөтен серләрне чишеп бетермә инде. Менә хәзер энекәшләр килгәч әләгер әле үзеңә!



## Бер-бер артлы

Нигъмәтуллин Мәскәүнең 57 мәктәбендә белем ала. Аннары Бауман исемендәге Югары техник училищега керә, бер үк вакытта Мәскәү университетының механика-математика факультетында да лекцияләр тыңлый. Ике уку йортын да бик яхшы билгеләр белән тәмамлый, институттан кендеге өзелгәч, ике еллык инглиз теле курсларына йөри. Күп составлы системалар механикасын өйрәнеп, 1971 елда диссертация яклый...

Тагын Роберт турында сөйли икән дип уйлый күрмәгез, монысы, 1944 елда туган Булатның тормыш юлы. Әйе, аларның биографияләре охшаш, әмма ике галим арасында аермалар да шактый ук.

1971 елда Роберт докторлык диссертациясен яклаганда Булат әле фән кандидаты исеменә генә лаек була. Роберт университетта эшләсә, Булат Ф. Дзержинский исемендәге Бөтенсоюз җылылык техникасы институтында фәнни-производство берләшмәсендә хезмәт итә. Роберт теоретик булса, Булат — тәҗрибәче. Роберт секторга җитәкчелек итсә, Булат инде — лаборатория мөдире.

Теоретикның төп эш урыны — язу өстәле, аның ачышлары — каләм очында. Тәҗрибәче галим исә мәңгелек хәрәкәттә. Булат эшчәнлеге моңа менә дигән дәлил: Ленинград, Минск, Киев, Ереван, Новосибирск — ул лабораториясе өчен җиһазлар юнәтергә кайларга гына юлга чыкмаган да тәҗрибәләре нәтиҗәсен кайларда гына уртаклашмаган. «Бөек экспериментатор шул хәтле тынгысыз, кызу канлы, йөремсәк, хәтта тәҗрибәләренең нәтиҗәсен чыгарырга, бераз анализ белән шөгыльләнергә дә вакыты юк»,— дип кәлә Роберт. Ялкын хәлен боз кайдан белсен?!

Булатның бушка кайнашмавын галим эшчәнлеге белән якыннанрак танышкан һәркем күрә ала. Аның «Төрле диаметрлы каналлар аша су-пар агымнары узганда су хәрәкәте һәм җылылык процессларын тикшерү»гә багышланган диссертациясен белгечләр уңай бәяли.

Мәгълүм булганча, атом электр станцияләрендә җылылык генераторы — җылылык чыгара торган актив зона бар. Ул җылылыкны су-пар катнашмасына сеңдереп, даими рәвештә алып китеп тору кирәк. Җылылык алмашуның иң кулай режимын каналлардагы процессларны җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә генә билгеләргә мөмкин. Моның өчен модельләр һәм тәҗрибә стендлары төзелә һәм шулар мисалында хисаплаулар үткәрелә. Ул тәҗрибәләрне уздыру өчен төрле җайланмалар ясарга, җиһазлар булдырырга туры килә. Шунлыктан тәҗрибәче галимнең тикшеренү эшләре яхшы приборлар табуга да бәйләнгән. Кирәкле әйберне вакытында юнәтү, инженер һәм фәнни хезмәткәрләрнең сәләтен, тырышлыгын дөрес файдалану, тәртип һәм оешканлыкка ирешү, иптәшләрендә күзәтүчәнлек, җаваплылык хисе тәрбияләү уңыш казануда хәлиткеч әһәмияткә ия. Менә шуңа күрә Булатка еш кына бик үк фәнни булмаган эшләр белән дә шөгыльләнергә туры килә.

Бервакыт, дүртенче класста укыганда Булат әнисеннән:

— Кинога барыйм әле? — дип рөхсәт сорый.

— Җибәрмим. Бүрекне бияләй итеп, бокс уйныйсың икән.

— Алайса бөтен савыт-сабаларыңны ватам!

— Аннары нәрсәдән ашарбыз соң!

Галия ханым үзе кухняда кайнашса да, колагы гел бүлмәдә була. Нишли икән кинде малае? Боксчы бияләе бик алып бирерләр иде дә, көрәшкәндә башына зыян килер дип куркалар. Ә ул хәзер, әнә, нинди әмәл тапкан! Кызганыч та, көлке дә, җәзасыз калдырырга да ярамый. Ниһаять, ул түзми, сиздермичә генә бүлмәгә күз салырга була. Караса — бөтен табак-савыт идәнгә чыгарып тезеп куелган!

Галия ханым елмая гына һәм артыгын күзәтми. Ватмый икән, болай булгач, әмәлсез малай түгел... Үсә-үсә акылы утырыр әле, аһ итмәскә кирәк дип уйлый.

Бүген Булат карамагында егерме биш кешелек галимнәр коллективы. Роберт кебек, ул да аспирантларга җитәкчелек итә, аларның өчесе инде кандидатлык диссертациясен яклап, остазлары белән бергә яңа мәсьәләләрне тикшерергә керешкәннәр.

— Тәүлегенә ун-унике сәгать эшлим, әмма барыбер планлаштырганны үтәргә өлгерә алмыйм,— ди Булат.— Ял көннәрендә дә китап-журналлар карап, мәкаләләр язып утырырга туры килә.

Атом электр станцияләрендәге җылылыкның физик-техник процессларын тикшерүче лаборатория башлыгы Булат Нигъмәтуллин матбугатта утыз бишләп фәнни хезмәт игълан иткән инде. Мәшәкатьле, катлаулы тәҗрибәләр нәтиҗәсенә таянып язылган монографиясе дә төгәлләнеп килә. Димәк, аны фән докторы булуы белән котларга күп калмаган инде!

1978 елда Бөтенсоюз җылылык техникасы институтында Рәис Нигъмәтуллин техник фәннәр кандидаты дәрәҗәсен казану өчен диссертация яклагач, Мәскәү галимнәренең берсе сокланып: «Механика фәнен Нигъмәтуллиннар кавеме басып алды!» — дип шаярта.

Бу вакытта механиканың янәшә тармакларында эшләүче Искәндәр Нигъмәтуллин һәм аның өч улы хезмәтләре башкала галимнәренә генә түгел, Мәскәүдән еракларда, шул исәптән, чит илләрдәге хезмәттәшләренә дә яхшы таныш була. «Нигъмәтуллиннар нәселе», «Нигъмәтуллиннар токымы» дигән сүзләр дә торган саен ешрак кабатлана.

Телгә кергән фамилиянең дүртенче иясе — Рәис тә мәктәпне абыйлары шикелле бик яхшы тәмамлый, абыйлары кебек, баскетбол секциясенә йөри һәм ярышларда катнаша, әмма ул спорт белән аларга караганда күбрәк мавыга!

Галия ханым Рәиснең өч яше тулган чагында уеннан уймак чыгара язганын хәтерли: шкаф артына аулакка кереп утырган да малай, урын-җиргә ут төрткән. Чүпрәкләр төти башлагач, ярамаган эш эшләвен чамалый да сүндермәкче булып әй тәкерә, әй тәкерә икән!..

Рәис абыйларыннан аермалы буларак, Югары техник училищега түгел, Мәскәү университетының физика факультетына укырга керә. Аны бик яхшы билгеләр белән бетерә дә, абыйларыннан аермалы буларак, шактый иртә өйләнеп кияү һәм бала үстерә. Менә шуның аркасында ул кандидатлыгын абыйларына караганда дүрт елга соңарып яклый.

Аспирантураны Рәис җылылык техникасы институтында уза һәм атом реакторындагы җылы чыгару элементларын камилрәк тикшерүне максат итеп куя. Аңа кадәр атом реакторында җылылык агышын каналның бөтен озынлыгында бердәй дип карап модельләштерәләр. Рәис исә каналның төрле өлешендә җылылык ташкыны төрлечә дип карый. Бу вариант хакыйкатькә якынрак булганга, тикшерену атом-техникасы өчен конкрет һәм төгәлрәк тәкъдимнәр эшләргә мөмкинлек бирә.

Рәис матбугатта әлегә унлап кына гыйльми мәкалә бастырган. Әмма ул бирешергә уйламый. Докторлык эше башлаган, эзләнүләрен дәвам иттерә. Абыйлары уңышы— аңа юл күрсәтә һәм гел дәртләндерә торган яхшы үрнәк, якты маяк. Аннары... ул хәзер үзе сүндерә ала торган һәм фән өчен кирәк дип тапкан нәрсәгә генә «ут» төртә бит!

## «Кече гыйльми совет»

Гадәти гыйльми совет утырышына бер дә охшамаган иде бу мәҗлес. Монда теләсә нинди темага чыгыш ясарга, фикер алышуны туктатып, бер мәл зәңгәр экранга карап алырга да, пәрәмәч белән сыйлана-сыйлана кофе эчәргә дә мөмкин иде. Кворум булсын өчен мин бу мәҗлестә шул көннәрдә Алма-Атада аспирантура тәгәлләп йөргән Рәис хатыны Айгөл урынын алдым. Утырышта алдарак таныштырылган затлардан тыш Булат хатыны врач Сания, аларның кызы Ләйлә, Роберт улы Таһир да «тавыш бирү» хокукы белән катнашты.

Гыйльми совет башлыгы белән мине Бөтенсоюз Комсомол премиясе лауреаты Роберт таныштырды:

— Гаеп итмәгез инде, бездә туган-тумачалык көчле. Утырышта, гадәттәгечә дилбегәне бу юлы да ир, әти, каената, дәүәти гыйльми дәрәҗәләренә дә ия профессор Искәндәр абыегызга тапшырабыз.

Мәҗлесне өченче класс укучысы Таһир Нигъмәтуллин ачып җибәрде.

— Мин бүген рус теленнән дүртле алдым! — диде ул тантаналы төстә.

— Профессор улына әзрәк шул бу.

— Менә Ләйләнең эше җиңе-ел! — диде Таһир Сания апасына.— Профессор кызы дип аңардан берәү дә артыгын өмет итмәс.

Ленинград кино инженерлары институтын тәмамлаганнан соң кино-фототасмаларның сыйфатын яхшырту буенча тикшеренүләр алып барган, хәзер Мәскәү университетында фәнни фотография нигезләрен укытып йөргән Бөгелмә кызы — техник фәннәр кандидаты Венера Нигъмәтуллина репликасыннан соң мәҗлес кызып китте, мин утырышның барышын тулысынча теркәргә өлгерә алмый башладым. Чыгыш ясаучыларның фикер алышуын кыскача бирсәк, ул болай дәвам итте:

Булат. План һәм отчетлар белән күмделәр әле. Фән белән шөгыльләнергә вакыт та юк. Ул аспирантлар тагын...

Искәндәр. Робертта алар ике тапкыр күбрәк. Шулай да абыең өлгерә. Бер мәкаләсе, әнә, «Астронавтика акта» журналында чыкты, яңаларын ГФР, АКШ матбугаты басарга әзерләгән.

Венера. Роберт та аспирантларына артык күп булыша. Һәрберсе ике, ел ярымда кандидатлыгын яклагач, билгеле, аңа әләгергә тырышучылар буа буарлык. Үз монографиясенә вакыты калмый да.

Искәндәр. Әнәс абый Нурихан Фәттах кичәсенә чакырды. «Этил суы ака торур» тарихи романын тикшерәчәкләр.

Роберт. Укырга абсолют вакытым юк хәзер.

Искәндәр. Милләтнең шатлык-юанычын, кайгы-хыялын язучы чагылдыра. Кичәгә автор да киләчәк. Анда бармый калырга һич тә ярамый...

Гыйльми совет утырышын кыңгырау тавышы бүлде. Кичке сәгать ун тулганда Робертның чираттагы шәкерте — Кыргызстан Фәннәр Академиясенең өлкән хезмәткәре М. Г. Палин киңәш алырга килгән. Галим микроэлементларны терлек азыгы белән аралаштыруны өйрәнә икән.

— Австралиядә сарыкларны баштанаяк криолин эремәсендә коендыралар. Без сынап караган идек тә хайваннар эремәдә батып тончыга, үлә. Сез моның сәбәбе хакында да уйлагыз әле,— диде ул җитди төстә.

Механикка менә нинди «башваткычлар» белән дә шөгыльләнергә туры килә икән! Роберт Нигъмәтуллин аны игътибар белән тыңлап торды да пианино алдына утырды. Чөнки, А. Эйнштейн әйтмешли, «фәнни фикерләүдә һәрвакыт шигърият кисәкчәсе катнаша, чын фән һәм чын музыка бердәй фикерләү процессын таләп итә». Уйлануын чынлап та бүтән дөньяларга күчеп дәвам итәргә ниятләдеме, әллә әдәбиятчыны механика карурманнарына кереп адашудан гына коткарасы килдеме, техника профессоры, яңа кунак Палин белән мине таң калдырып уйный-уйный, Бородинның «Князь Игорь» операсыннан Кончак ариясен җырлап җибәрде.

— Бусы,— башны ял иттерер өчен,— диде ул аннары, урыныннан торып.— Ярар, уйларбыз, эзләнербез, туганкай!

Мәҗит Рафиков

# ЯЗМЫШЛАР

## Су буенда бер урам

*Туган өен белмәгән*
*Туган авылын белерме?*
*Туган авылын белмәгән*
*Туган илен белерме?..*



Илебезнең бүгенге биеклегеннән халкыбызның үткәннәренә әйләнеп, ата-бабаларыбызның тормыш-язмышларына караш ташлаганда, Бөек Ватан сугышының бөтен авырлыкларын үз җилкәләрендә кичергән якынрак буын кешеләрен күз алдына китергәндә, хәзерге яшь буыннар алдындагы якты юлларны күреп торганда, күңел күзенә гаять киң һәм җанлы бер күренеш ачылып китә — язмышлар панорамасы, тарихка күчә барган тере язмышлар сурәте. Күпме чуарлык бу зур мәйданда, никадәрле капма-каршылык!..

Үзебезнең туган язмышлар лабаса бу, үзебезнең җанлы тарих. Күрим дисәң күрерлекләрең, уйланыйм дисәң уйланырлыкларың...

... Минем туган авылым — Күгәрчен. Җидеболак Күгәрчене. Элек Оренбург губернасының Оренбург өязенә караган. Совет чорында исә, үзе болай район үзәге үк булмаса да, Башкортстанның зур гына бер районына исем биргән авыл ул. Язарга алынганым шул кечкенә авылыбызның элек «Аскы урам» дип йөртелгән кыска-кечкенә бер урамы. Капкаларын су буена ачып тезелешкән җиде-сигез генә өйле сыңар яклы урам иде ул. Туып үскән урамым. Әмма, кечкенә булса да төш кенә. Әйтерсең, язмыш үзе шулай кушкан: шушы җирдә тугансың, кешеләрен, су буйларын, тауларын, кырларын-болыннарын яратасың, алар турында гел уйланып яшисең, әйдә, яз гына! Тормыш барышларының рухи ягынамы, матди ягынамы кагыласың — сәбәпсылтаулары бер-бер артлы килеп кенә тора... Хәзер инде аның өйләре дә күбәйде, «Бакча урамы» дигән исеме дә, өй чатларында сугылган саннары да бар.

Элекләрен Аскы урамның югары очында челтәр манаралы яшел мәчет бар иде. Шуның күләгәсендә югалып кына мәдрәсәсе дә утырган булган. Япон сугышы, беренче рус революциясе елларында минем әти буласы Мәгъсүм атлы бер малайга да ул мәдрәсәдә ике-өч кенә ел уку тәтеп калган. Анда да әле кышкы көннең зәмһәрирендәме булсын, йомшаграгындамы, ул малай сабакка барыбер карлы юлдан ялан тәпи чабып барган, чабып кайткан. Атасыз ятим гаиләнең бишенче баласы. Абыйларының дүртесенә укуның андые да эләкмәгән.

Совет чорында исә әти, җәй саен курсларда укый-укый, үзе дипломлы укытучы булып китте. Яраткан эшендә чын-чыннан бәхетле иде ул! Өстәвенә әле үзе агитатор да, пропагандист та, колхозның ревизия комиссиясе председателе дә, төрле җыелышларда — оратор да, кичәләрдә — артист та... Кызыл шимбә, кызыл якшәмбе өмәләренә әни белән бергә яңа тәпи баскан энебезгә кадәр барыбызны да ияртеп алып чыга иде. Ындырда чыбык белән чыпчык куса да файда, янәсе. Педагог!

Хәзер безнең урамның ул югаргы башында — урта мәктәп биләмәләре: уку биналары, спорт мәйданы, җимеш-җиләк бакчалары, ат абзары, гараж, тоташ бер квартал, кыңгыраулар шалтыратып, шау-гөр килеп яшәп ята. Урта мәктәп ачылуына 25 ел

тулуга аны тәмамлап чыгуҹылардан 120 ләп кеше вуз дипломнары алган белгечләр булып өлгерде: агрономнар, зоотехниклар, укытучылар, врачлар, хуҗалык, производство җитәкчеләре, партия эшлеклеләре...

Урамның түбәнге очы исә Өч тирәккә кадәр сузылган. Ул тирәкләр Җидеболакның дугайланып борылып килгән бер җиренең аргы як яр башында биек булып калкып утыралар иде (Бөек Ватан сугышы вакытында аларны берәм-берәм утынга екканнар). Урамның ул Өч тирәккә терәлеп торган түбәнге очы 1921 елның яман каты ачлыгында тәмам диярлек ачтан кырылган булган икән. Без, бер урам малайлары, Фатих, Хәким, мин, Заһидуллалар, ул хәлне белми идек, тик тынып, саңгырауланып калган урам юлының ике ягындагы ниндидер чокырлар, таучыклар, анда котырып үскән кычыткан, тигәнәк, шайтан таяклары безнең ише ялтыр борыннар күңеленә дә авыр бер шом салып тора иде. Үле оч... Фатихның әнисе Минҗамал җиңги ул очны «җенле», «зәхмәтле» җир ди иде, безгә анда уен корып йөрмәскә куша иде.

Колхоз оешканнан соң ике-өч ел үтте бугай, менә бер вакытны авылның ир-аты, хатын-кызы, бәйрәмчә шау-гөр килеп, Өч тирәкнең тирә-ягын ул шайтан таяклары джунглисыннан әрчеп, таллык-куаклыкларын төпләп, чистартып, сөреп ташладылар да, бераз өстәрәк инешне буып, ике як ярның икесенә дә канаулар казып су җибәрделәр. Бирге якта ел саен кәбестә, кишер, помидор, кыяр, суган түтәлләре буйлап су агып ята башлады, аргы якта — карлыган, кура җиләге, крыжовник куаклары буйлата... Шомлы, куркыныч җир менә дигән матур бер яшелчә, җимеш-җиләк бакчасына әйләнде дә куйды. Безнең яклардагы беренче колхоз бакчасы! Әти-әниләр түгел, без, каткан тезләр дә, бу бакчаны колхозыбызның бик зур бер мактанычы икәнен бик белә идек: колхоз булмасак, «җенле» урында шушындый оҗмах почмагыдай бакча каян килсен иде ди!..

Ике оч арасында — үзебезнең күрше-күлән була инде. Яшел мәчет янәшәсендә элек мәхәллә мулласы яшәп яткан, тик мин белгәндә аның нигезе буш иде инде, анда Мыр-мыр Сәлахи абзый бәрәңге үстерә иде. Сәлахи абзыйларның түбән як күршеләре ветеринар Хәснулла абзыйлар иде — Заһидулла дусның әтисе. (Хәснулла абзый Бөек Ватан сугышында һәлак булган — 1942 елны, Дон суы буенда.) Алардан тыкрык башы аркылы гына Рәхмич абзыйларның яртысы кабык, яртысы кызыл калай түбәле өе җыен салам түбәләр арасында күз явын алып, әллә каян күренеп торыр иде. (Рәхмәтулла абзый сугышта артиллерист булган, Җиңү көнен Австриянең башкаласы Вена янында каршылаган, Виенерштадта.) Аның түбән ягында җиде балалы гаилә, иске-москы җыючы, вак товар сатучы Миңгали абзый белән Маһирәттәйләр торды. (Миңгали абзый да сугыштан әйләнеп кайта алмады.) Бер-ике буш ихата аша минем Фатих дуслар тора иде, Газиз абзый белән Миңҗамал җиңгиләр. Боларның олы уллары, читтә йөргән Фәезхан абый да Бөек Ватан сугышында баш куйган; икенче уллары Сәлим абый, артиллерист, соңгы тапкыр Чехословакиядә яраланып бер аяксыз кайткан. Кайткач, үзебезнең колхозның ревизия комиссиясе председателе булып та эшләде ул, аннары бухгалтер итеп куйдылар, партоешма секретаре итеп сайладылар, КПСС райкомы инструкторы итеп күтәрделәр, үзебезнең яңа берләштерелгән колхозның председателе булып озак эшләде. Өченче уллары минем дус Фатих була инде. Тормышның төрле хәлләре аның белән мине кечкенәдән үк гел аера тора, әмма безнең дуслык, моңа карамыйча, гел ныгый, тирәнәя генә бара. Мин ун яшьлек күрше авылга русча укырга киттем, Фатих үзебезнең Күгәрчендә укыды; мин елга кайткан саен сагынышып күрешә идек. Җиденчене бетергәч, икебез дә шәһәргә җыена идек, укырга. Мин киттем, Фатихның кинәт әтисе вафат булып, ул, өй эчендә бердәнбер ир заты буларак, йорт терәге булып калды. Сәлим абыйсы да өйләнеп башка чыккан иде инде, Маһисәрвәр тәтәсе дә кияүдә, сеңелесе Зөләйха бала гына иде әле. Мин фельдшерлыкка укыганда, Фатих тракторчылар бригадасында сабанчы, прицепщик булып эшли башлады. Бөек Ватан сугышында миңа немец илбасарлары белән сугышырга туры килде, Фатихка — японнар белән. Мин университетта укып, шәһәр кешесе булып калдым, Фатих армиядә озак кына хезмәт итеп кайткач, авыл хуҗалыгы техникумында укып, үзебезнең колхозда агроном булып эшли башлады, читтән торып институтын да ерып чыкты, инде чирек гасыр үзебезнең туган басулардан ел саен район күләмендә югары уңышлар ала. Аралар ерагаеп, күрешүләр сира-

гәйсә дә, күңелләр якынайганнан-якыная: икебезнең сабый чаклардан башланган дуслык ИПИ белән СҮЗ берлегенә әйләнеп бара.

Әйбәт күршеләр булдык! Фатихлар белән безнең бакча арасында бер читән бар иде барын, тик без аның аша атлап кына йөрешә идек. Нигә дип урам яктан әйләнеп йөрергә!

Әти салган, әни җылытып, тәрбияләп тоткан өебез istә. Салам түбә, дүрт тәрәзә, шкаф асты почмагында — кызыл бозау. Габделмөәмин бабам нигезе...

Тыкрык аръягында тагы ике хуҗа яши иде әле. Берсе Маныфис Насыйбулла (кушаматы «манифест»тан килә, моның социаль мәгънәсе бар). Икенчесе Мортаза абзый Халитов иде («Чатан Мортый»), бу аксак агай сугышка хәтле үзебездә колхоз председателе булып эшләде, сугыш чыккач, авыл Советы председателе булып киткән иде...

Менә шушы урам була инде язганым, аның кешеләре, аларның характерлары, язмышлары.

Хәзер бу урамда йортлар саны егермеләп. Түбәнге, ягъни элеккеге «Үле очта» зур-зур, матур-матур йортлар хәтта кара-каршы тезелеп басканнар. Биек нигез, алты почмак, пыялалы веранда, калай яисә шифер түбә, якты тәрәзәле йортлар. Эчләрендә электры, газы, түбәләрендә биек-биек антенналары. Кешеләре дә — тормыш-көнкүрештә ни кирәк булса, шуны үз кулы белән «әтмәли» торган «универсал» куллы крестьяннар түгел, һәркайсы — укып, һөнәр-белем алып үскән белгечләр: шоферлар, механизаторлар, бакчачылар, терлекчеләр, сыер савучылар... Атказанган укытучылар да бар безнең урамда, фельдшер да, агроном да, райпо хезмәткәре дә, һәр гаилә, һәр йорт соңгы бер ике-өч буын гомерендә гаҗәеп олы бер яңару кичергән.

Мин малай чакларда көч-куәт иясе саналган ирләрнең күбесе инде дөньядан киткән, яшьли утка кергән безнең буын да сирәгәя. Дөнья яшьләр кулына күчә бара. Барысы да — үлгәннәре дә, исәннәре дә — минем күңел дөньяма керә киләләр, минем хәтеремә, вөҗданыма, намусыма күчәләр. Кайсын алма, һәркайсының холкы-фигыленең, тормыш юлының үзенә күрә бер гыйбрәте бар, һәркайсы игътибарга, яхшы сүзгә лаек. Миңа бертугандай якын, аңлаешлы язмышлардыр болар — Ил язмышыннан аерылгысыз язмышлар, Бөек Октябрь күтәреп, яктыртып җибәргән язмышлар.

Минем Фатих дус безгә икмәк үстерә, мин исә авылдашларым турында сүз әйтергә тиешмен.

## Мыр-мыр Сәлахи

Ул абзыкайны бөтен авыл «Мыр-мыр» дип йөртә иде. Олысы-кечесе. Гәүдәгә бәзык кына, нык кына үзе, холкы-фигыле белән шактый кыюсыз, карарсыз кеше. Әмма бәләкәйдән күнегеп үскән крестьян эшләрендә җанвардай җитез, оста, уңган иде. Үз өен үзе бурап кергән, сәке, өстәл, утыргычлар ясаучы балта остасы да ул, сукалап җирен сөрүче, учлап иген чәчүче, ураклап уручы, чабагачлап сугучы да, үз йортында үзе ат караучы да, терлек-туар асраучы да, урманга барса, юкә каезлап, чабата ясаучы да, салабаш салып, чыпталар, каплар сугучы да, күмер ягучы, дегет кайнатучы да булган ул, үзе өчен үзе камытчы-эшлияче, дуга бөгүче дә, юлга чыкса, олаучы да, базарга барса, билгеле инде, крестьянча беркатлы «дипломат» та... Әмма үзе ише «универсал» куллы авылдашлары арасында иң йомшак табигатьле, иң телсез-тешсезе, бүтәннәр арасында югалып кына яшәп ятучы иң кыюсызы, иң йомыкые, мөгаен ул булгандыр.

Озын гомер кичерде ул. Картаеп, күзләре караңгыланып шактый тора торгач, дөнья куюына ун-унбиш еллар бардыр.

Елмаюы әле дә күз алдымда. Йомшак аксыл чыраена ябыштырып куелгандай, йоклаганда да йөзеннән җуелмас бер елмаю. «Ә? Ни эшләргә?.. Э-э, хәзер үк, хәзер үк... Була ул, була...» дип торган сыман елмаю. Ярым югалып калучан, ярым яраксынучан, ни кушсаң, шуны эшләргә торучан җан иясе елмаюы. Үзе болай ирексез дисәң, ирексез дә түгел кебек, үзенең хәйлә-мәкерсезлеге, күңел сафлыгы кыяфәтеннән үк күренеп тора, әмма кеше арасында кыюсызлыгы, үтә дә басынкылыгы,

ярдәмсезлеге анык, күрәсең инде канына сеңгәндер. Ул барысына әзер, тик аңа кычкырмасыннар да кул күтәрмәсеннәр...

Дөрес, безнең колхоз көч-хәл алып, тормыш байый, матурлана башлагач, Сәлахетдин абзыйның елмаюына да якты өмет нуры, үз-үзенә ышану төсмерләре кердә. Юк, янәсе, бу тормышта сине алдамыйлар, җәберләмиләр, элекке чакларның дошманлашу, үчләшү, урлашулары, мескенлек, хәерчелекләре, аяусыз урам хөкемнәре бетте инде.

Картаеп, йомшак зәңгәр күзләренең нуры сүнә барганда да әле, тотып-капшап булса да, бригада өчен камытлар-эшлияләр төзәтте ул, дилбегә иште, тырмалар яңартты, кибән өючеләргә өч япьле озын сәнәкләр ясады. Тамга салып, пенсиясен алды...

Бер кайтуда мин авыл картларыннан анык турында сораша башладым. Үзебезнең Аскы урам кешесе бит. Ул, мәрхүм, үзенең кайсы ыру, кайсы нәсел, кемнәр баласы икәнен белмичә дөньядан да киткән икән!

Моннан бер йөз еллар чамасы элек, кайсыдыр елның яман бер ачлыгында ата-анасы, туган-тумачалары ачтанмы, вабаданмы кырылып, тулы ятим калган ул. Ниндидер бер могҗиза белән, үлмичә, безнең авылның хәллерәк бер йортына «малайлык»-ка эләккән. Зурларның бер әйтүе белән көче җитәр-җитмәс эшкә ябышкан. Тырышлыгы, йомыш тыңлаучанлыгы, сабырлыгы-чыдамлыгы, рәнҗү-үпкә тотмаулары — барысы да шул хуҗаларына тамак туклыгы белән өй җылысы өчен сукыр бер рәхмәтеннән...

Хуҗаның кече улы Сәлахетдингә яшьтәш туры килсә дә, ятим малай аңа «абый» дип дәшкән — буйсыну, баш бирү билгесе.

Солдатка каралырга да Сәлахетдин шул «абыйсы» урынына барган. Волость идарәсендә авыл егетләре моны әкрен-әкрен генә алгарак этәреп чыгарганнар икән дә, менә бер вакытны офицер көтмәгәндә моның йөзенә бәреп кычкыра: «Как фамилия?» Сәлахи югалып кала: «Ниткән нәстә сорый ул?..» «Атаңның исемен әйт»,— диләр моңа. Ә ул әтисен белми. Каушавыннан: «Әллә тагы, безнең күрше-тирә гел Халитовлар булган диләр ие...» — дип мыгырдый. Офицерның вакыты тар: «Ладно, Халитов так Халитов, марш в строй!» Менә шуннан Халитов булып атлап киткән ул.

Халитовлар безнең Күгәрчендә әле дә күп, тик чынлыкта исә Сәлахетдин абзыйны бөтенләй безнең авыл кешесе түгел ул, аның чын фамилиясе Мәҗитов булырга тиеш диләр. Мәҗитовлар безнең күрше Үргә Сәз башкортында электән бар барын, тик безнең Күгәрчендә булганы юк. Менә әйт инде хәзер, кайсы авылның кем баласы булган ул Сәлахетдин исемле ятим бала, кайсы милләттән?.. Исеме дә ата-аналары куштырган исемме, икенчели кушылганмы? Каян, ничек килеп эләккән ул безнең авылга?..

Җавапсыз-карусыз, күндәм ул малайның сынык күңеленә ялгыз башы тоташ ятлар арасында кимсенеп, үзен-үзе таба алмыйча йомылып, югалып яшәү хисе аны шундый холыклы иткән булса кирәк. Кем белә, бәлки, гомере буе әле тәртә башы, әле ыңгырчак баулары белән авыз эченнән генә «мыр-мыр» килеп тыктаусыз сөйләшеп йөрүләре, кечкенә туры биясе, сөзгәк үгез бозавы белән, урманда юкәгә-карыска кисәсе яшь юкәләр белән, ызанындагы вак башаклы арышы-бодае белән «тел алмашып» эчтән генә гәпләшү-серләшү гадәтеннән, бәлки, ул үзенең ятим күңеленә ниндидер бер таяныч, юаныч тапкандыр.

Крестьян тормышының бөтен эшләрен үзенчә әйбәтләп башкара белгән ул. Бәлки әле бүтән кайберәүләрдән икеләтә-өчләтә артык та эшләгәндер. Әмма кайда булмасын, патша хезмәтендә дә, юлда-олауда да, тыгыз табында утырган балтачылар артеле арасында да иң тыйнагы, иң тавышсыз-тынсызы шул Сәлахетдин булган. Тормыш исә аны барыбер аяусыз суккан да кыйнаган. Офицер перчаткасы белән булмаса, байлар-хәллеләрнең хәйләсе, алдавы белән үзәгенә үткән, үзенең надානлыгы, томаналыгы белән дә иза чиккән ул. Нинди генә хәл туры килмәсен, Мыр-мыр гел күмәкләр арасына кереп югалу ягын чамалаган, бүтәннәр кая тайпылса, ул да тизрәк шулар күләгәсенә чумып күздән югалырга тырышкан — ул-бу бәладән котылу юлы, имеш.

Колхозга кергәндә дә кешедән яздырып, кесәсендә керле кулы белән авалап бетергән ике юллык гаризасын, төрле имеш-мимешләргә карап, өч-дүрт тапкыр кире

алган ди ул, тик соңгысында гына, я ходай, бутәннәр ни күрсә, шуны күрербез диган сыман бер кыяфәт белән өстәлгә куеп чыгып киткән ди. Элекке властьлардан нинди дә булса яхшылык күреп өйрәнгәнмени ул? Аның өчен бит бөтен дөнья гел үз йортыихатасы, үз тормышы, үз мал-туарлары тирәсендә әйләнә килгән ләбаса. Хосусый милекче!

Үзенең мескенлектә үткән тормышы турында, аны үзгәртеп, яхшыртып кору хакында, үзенең кешелек горурлыгы, Иле, Ватаны турында, югары социаль идеаллар, аларга ирешү, алар өчен көрәшү турында нинди уйлар, нинди фикерләр йөртә алган дисең аны?..

Ә бит аның озын гомеренә Россия тарихының олы-олы вакыйгалары туры килгән: япон сугышы, 1905—1907 еллар революциясе дә, Беренче бөтендөнья сугышы, патшаның төшерелүе, Бөек Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, НЭП еллары, коллективлашу; данлы беренче бишьеллыклар да... Бөек Ватан сугышында Сәлахетдин абзый өйләнгән, башка чыккан улын югалта, оныкларына ярдәмләшә. Алтмышынчы елларны, бездә совхоз тәртипләре кергәч тә әле, әйткәнемчә, эшсез ята белмәде... Ә соң ил кичергән олы тарихи үзгәрешләрне аңлап яшәгән дисеңме аны?

Илдә Совет властен урнаштыру өчен көрәләтә үлемгә каршы барган батырлар арасында Сәлахетдин абзыйның яшьтәшләре дә аз булмаган — алар аңлы рәвештә безнең илнең якты киләчәген иҗат итүчеләр, исемнәре тарих сәхифәләреннән төшмәс батырлар. Ә бит алар белән Сәлахетдин абзый арасы — җир белән күк арасы кебек. Менә нинди нәрсә бит ул гражданлык аңлылыгы.

Сәлахетдин абзый, эзсез югалган бер соры шәүлә кебек кенә дөньядан китеп онытылыр да иде... әгәр балалары булмаса. Зур кызы Хәтимә бакчачылар бригадиры Галиулла абзыйда кияүдә иде, ире Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булгач, биш баласын аякка бастырып кеше итте, барысы да үз урынында, берсенә-берсе яман сүз әйткән кеше юк. Икенче кызы Фәтхия, бакчачылар бригадасы ударнигы, сугыштан соң үрге очтан бер фронтовик егеткә кияүгә чыкты, хәзер оныклар әбисе. Өченче кызы Нәкыя генә Бөек Ватан сугышы алдыннан медучилищега кереп өлгергән иде, тырыш, чыдам булды, фельдшер дипломы алып эшкә кайтты. Сәлахетдин абзыйның кече уллары Хәсән белән Әгъзамның уку елларын сугыш кисте: Хәсән инде күп еллар буе төзүчеләр бригадасында танылган балта остасы, Әгъзам терлекче — холкыфигыле белән нәкъ әтисе кебек диләр... Барысы да тормыш корып җибәргәннәр, балалары үсә, кеше була, үзебезнең урта мәктәпне тәмамлыйлар да җаннары теләгән белгечлеккә укыйлар, эшлиләр.

Нәкыяне хәтерлим. Бәләкәй чакта бергә укыдык. Аз сүзле, пөхтә, җыйнак, җитди генә зәңгәр күзле бер кызыкай иде. Әйбәт укыды. Хәзер инде — хезмәт ветераны. Үзебезнең Октябрь совхозы үзәге Мәкъсүт авылында фельдшер. Район газетасында мактап язалар үзен. Медицина яңалыкларын укып-белеп бара, авыруларга ярдәмгә дәшсәләр, көн дип, төн дип тормый, чыгып чаба, саф күңелле, кешелекле, игътибарлы. Ире, Мөхәммәди Казбулатов Башкортстанның атказанган укытучысы, тарихчы, тәҗрибәле пропагандист. Зур кызлары Наилә университет тәмамлаган, урта мәктәптә химия укыта, укыту-тәрбия эшләре буенча директорның урынбасары, мәктәпнең партия оешмасы секретаре, ата-аналар комитеты председателе... Уллары Гали авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, хезмәт юлын башлап җибәрү чорын кичерә. Кече кызлары Рәилә пединститутта укый.

Нәкыя белән Мөхәммәди балаларының уку-үсү юллары — безнең тормышта яшьләр алдында ачылган киң мөмкинлекләрнең матур бер күренеше ул.

Моннан йөз еллар элек ачтан кырылган бер гаиләдән исән калган Сәлахетдин исемле бердәнбер малай, тормышны дәвам итә килеп, менә хәзер инде үзе яңа бер нәсел атасы дәрәҗәсенә чыккан. Сәлахетдин ыруы. Оныкларының балалары дөньяга килә. Әгәр хәзер хыял, фантазия куәте белән ерак еллар арасын якынайтып, бу яңа ыруның атасы Сәлахетдин белән аның бүгенге оныкларын — ясле, бакча балаларын, октябрятлар, пионерлар, комсомоллар, яшь белгечләрне барысын бергә китереп, кара-каршы куеп карасак, нинди дә гыйбрәтле күренеш булыр иде бу! Бер якта — ялан тәпи бер ятим малай тора: өс-башы ямау да ертык, аяк-куллары сыдырылгантырналган, үзе кояшта янып, авыз-борыннары кубалакланып беткән, үзе туйганчы ашауны, тәти күлмәк дигәнне белмәс, уку-язу дигәннәр уена да килмәс бер асрау

малай, аның каршысында исә — безгә яхшы таныш бүгенге колхозлы-совхозлы авыл балалары, бүгенге авыл яшьләре... Ике арада — нинди аерма, нинди үзгәрешләр булып узган! Бер нәселнең ике-өч кенә буыны эчендә шундый да гаҗәеп яңарыш! Ә бит бу бөек яңарыш бөтен Ил мәйданында булып узган күренешнең чаткысы.



## Кешелеклелек хакыйкате

Үзем белгән төрле буын кешеләре турында, аларның тормыш юллары, язмышлары хакында уйланган саен мин әйтеп бетергесез олы бер хакыйкатькә чын күңелдән ныграк, тирәнрәк инана барам. Ул хакыйкать — безнең җәмгыятебезнең олы хәрефләр белән язарлык кешелеклелеге, миһербанлылыгы, чөнки социалистик стройның табигате шундый.

Безнең авылларның патша чорындагы тарихын ачыклый башласаң, тетрәткеч бер күренеш күз алдына килә: фәлән елны чәчәк авыруыннан кемнәрдер үлгән, кемнәрдер шадраланып, сукыраеп калган; төгән ел коры килгән, игеннәр тамырында янган, берәүләр ярты гаилә, икенчеләр бөтен гаиләсе белән ачлыктан кырылган, теләнчеләр күбәйгән, урлау-талаулар чыккан, фәлән кешене, кеше базына төшкәне өчен, урам уртасында дүрт санынннан тотып җиргә бәреп, үләр хәлендә ташлап калдырганнар; фәлән елны халыкны ваба кырган, төгән елны терлек-туар үләте килгән... Тигәнәк, кычыткан, шайтан таяклары баскан буш өй урыннарына карап, халыкның үлү-бетү куләмен күрерлек булган. Безнең Күгәрчендә дә: «Ачлыкка хәтле безнең урам озын булган ул, әнә тегендә хәтле сузылып яткан...» дигән шомлы сүзләр ишетелә иде. Авыл халкының тәңредән яңгыр сорап ялварулары әкият түгел. Әле без, малай-шалай да, яңгыр тама башлау белән, яшен сугудан курка-курка булса да, урамга теләк теләргә йөгереп чыга идек:

> Яңгыр, яу, яу, яу!
> Ашлык, үс, үс, үс!
> Безгә ачлык килмәсен...
> Халык ачтан үлмәсен,
> Ваба-үләт чирләрен
> Бер кеше дә күрмәсен!..

Иң югары идеалыбызны сурәтләгәндәй:

> Тәти кашык базарда,
> Майлы ботка казанда!

— дип тә җибәрә идек. Ә инде:

> Быкыр-быкыр ботка пешә,
> Килгән кунак безгә төшә,
> Безгә төшми, кемгә төшсен,
> Бездә майлы ботка пешә!

— дип тә сикеренеп алсаң, тормышның муллыгын, өй эчендә бәхет тулып торуын күңелләрнең бик хушлыгын әйтеп бирергә шул үзе дә бик җитә иде.

Уңдырышсыз еллар әле дә кабатлана килә. Табигатьнең үз климат цикллары бар. Һәр елның килеше үзенчә. Әмма иң коры елларны да ризыкларның ризыгы — ипи безнең табыннардан өзелми, иң арзан бәя белән сатыла тора.

Менә хәзер, киредән килеп, күз алдына китереп карыйк: ел үтә дә коры килеп, игеннәр, үләннәр җәй башыннан ук корып янды ди; инде, элекке тормыштагыча, байлар, кулаклар, спекулянтлар барлы-юклы ашлыкны келәтләренә бикләп, торган саен бәясен күтәрә башласа, гади хезмәт халкы нишләр иде? Янә ачлык, янә үлемнәр, янә теләнүләр, урлау-талаулар, аусыз урам хөкемнәре башланмас идеме!

Ата-бабалар кичергән ачлыклар, вабалар, үләтләр барысы да чын, тик без, бәхетлеләр, үз башыбызга төшмәгәч, ул хәлләрне белмибез, яки оныткanбыз гына. Үз чорыбызда андый хәлләрнең булмавына күнегелгән, бу безнең өчен бик табигый күренеш. Һәркайсыбызның күңеленә, рухына сеңгән халыклар дуслыгының, ленинчыл интернационализм принципларының бөтен илкүләм яшәешебездә гамәлгә тирәнтен керүе шулкадәр табигый булып күренә ки, без инде бу хәлнең безне нинди үлемжитемнәрдән, нинди бәла-казалардан аралап алганы турында уйлап, үз-үзебезгә исәп биреп тә тормыйбыз, хәтта алдыбыздагы ипинең кадерен белеп тә җиткермибез бит кайчакта. Тормыш проблемаларына җиңел карау түгелме соң бу? Юк, ирешелгән бәхетнең бәясе төшми, әлбәттә! Тик, бүтән максатлар, бүтән идеаллар белән мавыгып, без аны онытабыз гына. Ләкин үткән-булганнарны белми, уйламый торып, бүгенгене дә, киләчәкне дә дөрес үк аңлап булмый. Илдә туклык казанышы бик зур казаныш ул, аның өчен дә күпләр батыр, күпләр корбан булган.

Бөек Октябрь минем авылдашларымны да байлар, кулаклар, базарчы спекулянтлар изүеннән коткарып, ярлылык, хәерчелектән сыйнфый тигез тормышка алып чыккан, минем якташларым да коллектив хезмәт бәхетенә ирешеп, иртәгәсе көннәренә якты ышаныч белән карый башлады.

Безнең авыл халкы да Совет властен үз власте күреп кабул итте, колхозлашуның файдасын да тиз аңлап алды. Безнең әтиләр кыр эшләренә чыкканда бәйрәмчә ак чабаталар киеп, кызыл флаг күтәреп, тальян тартып, яңа җырлар җырлап чыктылар:

Яшәсен Совет власте,
Рәхәт аның дөньясы!

Авыл кешесе дә үзен яңа, бәхетле тормыш төзүче оптимист итеп хис итә башлады, тормышны революцион рухта үзгәртеп кору аның гражданлык хисләрен уятып, күңелен күтәреп, рухын яңартып җибәрде. Совет власте аерым хуҗалыкларны кумәкләштереп, колхоз эшләрен киң күләмдә фәнни планлаштыру юлына кучерде. Мырмыр Сәлахиләрнең күп һөнәрле «универсаллыгы»на алмашка техник белем, специальләшү, механизаторларның осталыгы килде, махсус белемле белгечләр хәзер хуҗалыкның һәр тармагында эшне промышленность нигезенә күчерәләр. Безнең бүлекчәнең бер комбайнчысы Әхәт Вәлитов, исәпләп карасаң, бәлки бер сезонда да Сәлахетдин абзыең үз иманасыннан ун гомере буена да ала алмас ашлык җыядыр?!

Минем авылдашларым да элеккеге милли чикләнгәнлектән арынды, социалистик илебезнең барлык халыклары белән дуслык, тугандашлык хисләре, югары социаль максатлар, коммунистик идеаллар уртаклыгы безнең эшләребезгә олы мәгънә сала.

Минемчә, милли чикләнүгә омтылу, шовинизм кебек нәрсәләр хезмәт халкына гомумән хас түгел. Россиянең тарихи язмышлары безгә элек-электән ят булмаган. Ерак бабаларыбыз Бөек Петрның хәрби походларында да катнашканнар, Россиянең хәрби флотын булдыруга да күп көч куйганнар, 1812 елгы Ватан сугышында да батырлыклар күрсәткәннәр. 1877—1878 елгы төрек сугышында минем ырудашым Мөхәммәтша бабай Насыйров та батырларның берсе булган. Ул сөйләгән «Төрек бәете»нең өзекләрен Кугәрчендә әле дә картлар хәтерли.

... Ак мәчетне алган чакта
Җиде көн урап яттык...

... Кызыл тауга менгән чакта
Төрекләр килә каршыга:
— Кяфер мәлгунь килә! — диеп
Кычкыралар барсы да...

Төрек сугышчыларының «кяфер мәлгунь» дигәнен ишетү рус солдатлары белән бер сафта дошман крепостьларын штурмлап, болгар халкын коллыктан азат итешеп йөрүче безнең мөселман бабайларга шактый сәер ишетелгән булса кирәк.

Безнең ата-бабалар тирә-күрше рус, башкорт, чуваш, мордвалар белән гел ара-

лашып яшәгән. Бүтән милләтләрдән әйбәт таныш-белешләрең, «ызнакумнарың» булу үзе бер дәрәҗә саналган. Халыкның җырларында да шулай диелә бит.

Кая гына барма, дус-иш кирәк,
Капка ачып каршы алырга.

Гомеремдә иң бәхетле көнем — 1935 елның 17 сентябре булган: ул көнне әти мине ун яшьлек күрше башкортлы-руслы-чувашлы Үрге Саз авылына русча укырга җибәргән иде. Үзенең укытучы дусты Тарас Иванович Мотин белән сөйләшкән дә... («Ишгилде» дигән повестемдәге укытучы нәкъ шул Тарас Иванович үзе була инде.) Рус теленең, рус җырларының, бөек рус әдәбиятының шигъри куәтен малай чаклардан ук татып белмәсәм, рус теле ярдәмендә дөнья классикасы белән таныша алмасам, һичшиксез, күп нәрсәне югалткан булыр идем.

Рус теле аркылы безнең авылга Маркс, Энгельс килеп керәләр, рус теленнән Ленин әсәрләре, Ленин партиясе идеяләре безгә килеп ирешә, рус теленнән безгә Ломоносов, Менделеевлар, Максим Горький, Маяковский, Твардовскийлар киләләр, рус теле аркылы авыл Тарас Шевченко, Якуб Колас, Расул Гамзатовларны танып белә. Безнең Тукай, Җәлилләр, башкортның Мостай Кәриме, чувашның Сеспельләре бөтен совет укучыларына шул рус теле аркылы таныш. Рус телен белү безнең авыл яшьләренә фәннең, производствоның, сәнгатьнең иң югары казанышларына юл ача.

Безнең мәрхүм Сәлахетдин абзыкай эшләрнең төрлесеннән үз күңеленә ошаганын-ошамаганын аерып, сайлап тора алган дисеңме? Юк, билгеле. Ул бит эш дигәннең теләсә ниндиенә алынырга мәҗбүр булган, тик эше тамакны туйдырсын да өс-башны бөтәйтсен. «Атлы-тунлы» булу, тамак туклыгы белән өс бөтенлеге ата-бабаларыбызның иң югары идеалы саналган! Ул заманнарны безнең авыл агайлары үз балаларының һәркайсының үзенә күрә күңеле тарткан, җаны теләгән, үзе генә тансык күргән берәр төрле эше-һөнәре бардыр дип, шул һөнәргә укытып, өйрәтеп үстерә алганнармы? Юк. Аларны бит ничек тә ачтан үлмәү, җан асрау кайгысы баскан. Алар дөньяда яшәүнең иң түбәнге баскычы — биологик тереклек баскычыннан ары күтәрелә алмаганнар. Безнең Кугәрчендә дә булганнар ул алтын куллы балтачылар, һөнәр осталары, гармунчылар, гаҗәеп моң иясе җырчылар, артист җанлы тапкыр телләләр, саф намуслы иҗатчылар — такмак, җыр, бәет чыгаручылар. Әмма бөтен булган сәләтләре-талантлары әлеге бер биологик тереклек ихтыяҗларына сеңеп кала барган, берсе дә халык казанышы, ил даны, ил горурлыгы дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган.

Совет чорында исә партия, хөкүмәт яшьләрне һәрьяктан гармоник рәвештә үстерүгә гаять зур игътибар бирәләр. Хезмәттә, иҗатта һәр совет кешесенең иң яхшы сәләтләре-талантлары ачылуы — кешенең үзе өчен дә зур бәхет, ил өчен дә, барлык халык өчен дә казаныш. Бу безнең социалистик стройның табигый бер ихтыяҗы да, үсеш закончалыгы да. Минем авылдашлар да моның кадерен бик яхшы белә: Кугәрчен яшьләреннән ел саен ким дигәндә бишәр-алтышар кеше төрле югары уку йортларына укырга китә, техникумнарга, училищеларга керүчеләр аннан да күбрәк.

Социалистик стройның кешелекле өстенлеген барлык хезмәт иясе халыклар сәламәтлек саклау һәм тормышның бүтән сфераларында эшнең куелышыннан да шулай ук ачык күрә.

Империализмның сугыш чукмарлары дөньяның әле тегә, әле бу почмагында яңа сугыш уты чыгарырга торганда, безнең хөкүмәтебез һәм туган партиябез ныклы, принципиаль рәвештә Тынычлык программасын үткәрә һәм бөтен дөнья халыклары бу программаны таный, хуплый, йөрәгенә якын итә. Без горурланып әйтә алабыз: юк, ашкынып кораллану, бүтән илләрнең байлыкларына кул сузу, корал белән янаулар, сугыш дипломатиясенең мәкерле, пычрак алымнары беркайчан да безнең илдән чыкмый һәм чыкмаячак. Без Тыныч Хезмәт иле, безнең ил — бөтен дөнья мәйданында Тынычлык терәге. Бу безнең һәркайсыбызның олы горурлыгыбыз, кешелеклелек дәрәҗәбез. Безнең куәтле, барча социалистик илләр белән бергә ныклы оборонасы тәэмин ителгән дәүләтебез колониализм богауларыннан ычкыныр өчен, яңа бәйсез тормыш кору өчен көрәшүче халыкларга ярдәм итә икән, бу да безнең революцион гуманизмыбызның гамәлдә чагылышы, бу да безнең кешелек һәм гражданлык горурлыгыбыз.

Безнең һәркайсыбызның көндәлек хезмәте — үзебезнең шәхси ихтыяҗларыбызны гына канәгатьләндерү өчен түгел, бәлки илебезнең экономик, фәнни, культура, хәрби җәһәтләрдән дә тагын да алга китүе, үсүе өчен дә кирәклеген без яхшы аңлыйбыз. Безнең намуслы хезмәтебездә Ватаныбыз киләчәге өчен, бөтендөнья социализм системасы язмышлары өчен, планетада тынычлык өчен җаваплылык хисләребез дә чагыла. Без моның белән дә горурланабыз һәм киләчәккә якты өмет, тирән ышаныч белән карыйбыз.

Әмма арабызда үз эшенә, үз вазифасына җавапсыз карау, хезмәттә тәртипсезлек, эрәмтамаклык, хулиганлык, урлашу кебек күренешләрнең дә әле булуы совет кешеләренең вөҗданына кара тап төшерә торган рухи бер гариплек икәнен дә яхшы беләбез без. Болар коммунистик рухта тәрбияләнүче кешеләргә гомумән чит-ят нәрсә. Социаль мөнәсәбәтләрнең кешелеклелеге исәбенә яшәп килгән бу паразитлык шытымнарына каршы көрәш шуңа күрә дә көннән-көн җитди рәвештә көчәйтелә.

Инде йомгаклау тәртибендә бер-ике сүз.

Туган авылым, урамым миңа үзенең кешеләре, өйләре, су буйлары, бакчалары, хәтта тыкрык буендагы әрекмәннәре белән дә якын һәм үз. Ләкин минем өчен иң кадерлесе — шушы авыл, шушы урам тормышында кыска гына бер чор эчендә булган, иҗат ителгән искиткеч олы яңарышлар. Кешеләр тормышының һәм матди һәм рухи җәһәттән тулы бер яңаруы. Алар кичергән тормыш, алар узган көрәш юлы кырыс та, авыр да булды, бу юлның батырлары да, корбаннары да аз түгел, әмма бу юл — безне бөек социаль казанышларга алып килгән гүзәл бер тарихи юл. Минем авылдашларым да, үз тормышын гына кайгыртып яшәүче тар күңелле, надан, хосусый милекчелек психологиясеннән арынып, яңа тормыш төзүче якты, оптимистик карашлы гражданнар дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Алар арасында аңлы, актив энтузиастлар күп, алар күңелендә коллективлык хисе көчле, алар үз эшләрен барлык күршекүләм, бөтен район, республика һәм бөтен ил алдында торган олы бурычларны уйлап башкаралар. Аларга социалистик Ватан хисе, дөнья язмышы, бүгенге көннең сугыш һәм тынычлык проблемалары — барсы да, барсы да якын.

Идеологик, политик тәрбия эшләрен яхшырту турында уйланганда мин шундый бер ихтыяҗ сизәм: безнең яшь буын укучылар социалистик Ватан язмышын, эш, иҗат мәйданында үз урыннарын, үз вазифаларын тирәнтен аңлап үссеннәр өчен, аларның күзен якын тирә-як тормышка да киңрәк ачарга, аларны ата-аналарының, әби-бабаларының гыйбрәтле тормыш юллары, язмышлары белән дә тирәнтен кызыксындыра белергә кирәктер.

Нур Гыйззәтуллин

# ЯҢА ТОРМЫШ, ЯҢА ӘДӘБИЯТ ХАКЫНА

Гражданнар сугышы чорында һәм егерменче еллар башында татар совет әдәбияты үзенең геройлары һәм темалары, идея-эстетик эчтәлеге белән яңа тип милли культураның — революцион культураның гаять әһәмиятле бер өлеше булып формалаша башлый. Әдәбиятка килгән яшь язучылар һәм шагыйрьләр, Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал һәм башка өлкән буын язучылар белән бер сафка басып, Бөек Октябрь идеяләрен тормышка ашыру өчен актив көрәшкә кушылалар.

Бу яшь язучылар арасында соңыннан күренекле прозаик, шагыйрь, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган, үзенең бөтен иҗат гомерен совет халкына, Коммунистлар партиясе эшенә багышлап, купьяклы һәм бай иҗаты белән татар совет әдәбияты тарихында якты эз калдырган Кави Нәҗми дә бар иде.



Кави Нәҗми (Габделкави Һибәтулла улы Нәҗметдинов) 1901 елның 15 декабрендә Сембер губернасының Курмыш өязе Петряск волосте Красный Остров авылында (хәзер Горький өлкәсенең Петряск районы) туа һәм ачлык-хәерчелектән котылу өчен илнең төрле якларына күченеп, бәхет эзләп йөргән семьяда үсә. Ниһаять, 1910

елда Һибәтулла абзый Актүбә шәһәренә килеп урнаша. 1912 елда унбер яшьлек Кави Актүбәдәге алты еллык рус-татар мәктәбендә укый башлый.

Аның әдәбият белән ныклап кызыксына башлавы да нәкъ шушы мәктәптә укыган елларга туры килә. Шул елларны искә алып, Кави Нәҗми соңыннан: «Ул чагында инде мин Тукайның йөрәк тетрәткеч ярсулы тойгы белән язылган «Эштән чыгарылган татар кызына» исемле шигырен яттан белә идем. Мәҗит Гафуриның «Татар хатыны», Миргазиз Укмасыйның «Килен»е, Шәриф Камалның «Сулган гөл»е — революциядән элек татар хатын-кызларының ачы язмышын сурәтләгән бу әсәрләр шулай ук таныш иде» [1], — дип яза.

1917 елның башында, бер-бер артлы әтисе һәм әнисе үлеп киткәч, Кави ике энесен һәм сеңелесен әтиләренең туганнары янына, Красный Островка алып кайта. 1919 елда Сембердәге педагогия курсларында укый, үз авылларына кайтып берничә ай башлангыч мәктәптә укыта. Шул ук елның августында Коммунистлар партиясенә керә, ноябрь аенда үзе теләп Кызыл Армиягә китә...

Кави Нәҗминең 1918—1920 елларда «Эшче», «Эш», «Таң», «Кызыл Армия» газеталарында басылган беренче шигырьләрендә үк инде изүче сыйныфларга тирән нәфрәт хисе, революцион көрәш пафосы чагыла. Аларда революция тудырган яңа идеяләр нигездә традицион формалар белән биреләләр. Шуның белән бергә, давыллы елларның җанлы сулышы аның шигырьләренә дә митингларда, күп халык алдында сөйләү интонациясен һәм ритмын кертә, аларның динамик көчен үстерә бара:

**Без кызыл утлар ягып чыктык көрәшкә-бәйгегә.**
**Канлы бәйгегә, богауларны өзәргә мәңгегә,**

— ди ул 1921 елда язылган «Кызыл бәйрәм» шигырендә.

Яңа чынбарлык әдипләр алдына революцион сәнгатьнең эчтәлеге һәм формасы ничек булырга, ул нинди юллар белән үсәргә тиешлекне ачыклау бурычын бик кискен куя. Нәкъ шушы мәсьәләне аңлауда кайбер яшь шагыйрь һәм язучылар, иске тормышны инкяр итү пафосын культура мирасына мөнәсәбәт өлкәсенә дә күчереп, зур каршылыкларга килеп керәләр. Кызу бәхәсләр кузгала. Бу бәхәсләрнең нигезендә яңа тормышка мөнәсәбәт һәм яңа әдәбият нинди булырга тиеш дигән сорау ята.

Татар матбугатында футуризм, символизм, имажинизм кебек әдәби агымнарның яралгылары да шул елларда күренә башлый. Реалистик сәнгатькә чит булган бу агымнарны Кави Нәҗми, мәсәлән, «Революциянең машинный хәрәкәте белән аерылмаслык рәвештә бәйләнгән яңа шигърият» [2] барлыкка китерү өчен мөмкинлек бирә дип ялгыша; имажинизмны: «Иске әдәбиятның, иске шигърияtенең форма, мөндәриҗә, стиль ягыннан җимерелүен тизләтүче инкыйлаби агымнарның берсе» [3], — дип белдерә.

Әмма ачык әйтергә кирәк: бу еллардагы татар әдәбиятында төрле формалистик агымнар йогынтысында барлыкка килгән шаукымлы, ләкин кыска гомерле «изм»нарның аерым төсмерләре генә күренеп кала. Аларның берсе дә безнең әдәбиятта ачык платформалы һәм тулысынча формалашкан агым булып җитлекми. Мондый «изм»нарга ияреп алган кайбер яшь язучыларың бу чор иҗатын вакытлы күренеш дип кенә бәяләргә мөмкин. 1932 елда үзенең шигырьләр җыентыгына язган сүз башында Кави Нәҗми болай дип искә ала: «Октябрь революциясе, гражданнар сугышы тудырган темаларны яңа әдәби калыпка салып язу өчен әллә ничә төрле тәҗрибәләр эшләп карадым. Ул чакта әле мин форма һәм стильдәге яңалык мәсьәләсен хәзерге көндә дә бик киң җәелгән «Зиләйлүкчелек»не (8—9 иҗек белән язуны) җимерү, бетемнәрдәге тавыш охшашын элекке кысан рамкасыннан чыгару төсендә генә аңлап килдем. Шулай аңлау, форма һәм эчтәлекнең бердәмлеге мәсьәләсен үзләштереп җитмәү аркасында, минем бик күп шигырьләремдә әсәрнең форма ягы белән мавыгу — образларны бер ноктага тыгызлап өю, образлар белән реаль күренешләрне алмаштыруга хәтле барып җитү кебек ялгышлар күренделәр» [4].

---

[1] Нәҗми К. Әдәбият дөньясында. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 148 б.
[2] «Безнең байрак», 1924, 29 февраль.
[3] «Кызыл Татарстан», 1923, 5 декабрь.
[4] Нәҗми К. Әдәбият дөньясында, 96 б.

Ләкин ничек кенә булмасын, язучы беренче иҗади адымнарыннан ук илдә яңа тормыш төзүне җитәкләгән эшче-крестьяннар власте ягында, Коммунистлар партиясе ягында була. Ул халык бәхете өчен көрәшүчеләр сафында кала, бөтен көче белән революция казанышларын үстерүгә хезмәт итә.

1923 елда ул, Мәскәүдәге Югары хәрби-педагогик институтны тәмамлагач, Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбендә укытучы, аннары комиссар булып эшли башлый, 1927 елда «Кызылармеец» газетасының редакторы итеп билгеләнә.

Тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе үсү белән бергә, аның шигырьләрендә сизелеп үткән төшенкелек мотивлары да, формализмның зарарлы йогынтысы да югала бара. Ул пролеткультлык рухындагы ялгыш карашлардан да баш тарта. 1927 елның февралендә «Кызыл Татарстан» газетасының дүрт санында рәттән басылып чыккан һәм күп кенә бәхәсләр күтәргән мәкаләләрендә (алар «?.. ?.. ?..» билгеләре белән генә исемләнгән) язучының әдәби-эстетик карашлары инде шактый үзгәргәнлеге күренә. Татар әдәбиятчылары арасыннан беренче буларак, ул укучылар составын социологик планда да өйрәнү кирәклеген, укучыларга нинди әсәрләр тәкъдим итү дөрес булуын күтәреп чыга. Замандаш язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатына үткен күзәтүләр ясап, әдәбияттагы аерым кимчелекләрне конкрет дәлилләп күрсәтә. Совет әдәбиятының классик әдәбияттагы прогрессив традицияләр белән бәйләнеше мәсьәләләренә махсус тукталып, ул болай дип белдерә: «Матур әдәбиятта күчереш — преемственность дигән хасият бар. Кешеләр дә яңа, җырлар да яңа. Тик бу җырларның иҗтимагый моңы үткәнгә тамырланган. Ул тарих белән бәйләнгән. Ләкин бу бәйләнеш аңа яңаны тудырырга, үз чорының тормышын гәүдәләндерергә комачауламый...»[1]

Кави Нәҗминең шагыйрь буларак үсешенә, татар поэзиясенең иң яхшы үрнәкләрен өйрәнү белән бергә, рус совет поэзиясе әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү дә нык ярдәм итә. Бу аның үз әсәрләренең дә идея һәм сәнгатьчә эшләнеш ягыннан яхшыра баруына китерә.

Егерменче елларда Кави Нәҗми Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында әдәбиятка килгән яшь язучыларны әдәби күмәкләргә оештыруда актив катнаша һәм озакламыйча аларның иң эшлекле җитәкчеләреннән берсе булып таныла, әдәбиятта буржуаз милләтчелеккә, милли чикләнгәнлеккә каршы иң актив көрәшүчеләрнең алгы сафына баса. Шул чакта язган күп санлы мәкаләләрендә ул яңа әдәбият һәм культураның актуаль проблемаларын күтәреп чыга. Дөрес, әлеге мәкаләләрдә бәхәсле урыннар да очрый. Бу бәхәсләрнең күбесе шул чорга бәйле карашлардан килеп чыга. Әмма Кави Нәҗми мәкаләләрендә яңа әдәбият — совет әдәбияты өчен көрәш идеясе, халыклар һәм әдәбиятлар арасындагы дуслыкны ныгыту турындагы фикерләр, укучыларның сәнгатьчә зәвыкларын үстерүгә кайгырту алгы планда тора. Аларда язучының эстетик карашлары һәм идеаллары, шулай ук татар әдәбиятының шул чордагы үсеш процессы шактый тулы чагыла.

Әлеге үсеш процессы һәм иҗат эволюциясе бигрәк тә Кави Нәҗминең хикәя һәм повестьларында ачык күренә. Ул үзенең хикәяләрендә дә гади хезмәт иясе кешесенең яңа тормыш өчен көрәшен, аның гражданнар сугышы фронтларындагы батырлыгын күрсәтүне беренче максат итеп ала. «Иң соңгысы» (1925) хикәясендәге Әптерүш образы ярдәмендә, мәсәлән, язучы гади халык вәкилләренең азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәштә һәртөрле батырлыкка сәләтле булуын исбатлый. Бу хикәядә совет әдәбиятының шул чордагы үсеш этабы өчен характерлы булган бер үзенчәлек — шәхси батырлыкларга артык зур басым ясамыйча, революцион массаның гомуми батырлыгын күрсәтергә омтылу чагыла.

Ватанны дошманнан азат итү өчен барган героик көрәштә халыклар дуслыгының тагын да ныгуы — «Шобага» (1926) исемле хикәянең төп мотивларыннан берсе. Татар кызылармеецы Хәйрулла белән украин крестьяны Трофимның дуслыгы бигрәк тә әсәрнең соңгы бүлегендә символик мәгънә ала. Менә 1924 елның салкын гыйнвары килә. Бөтен илдә матәм рухы. Мәскәүгә илнең төрле якларыннан бөек Ильич белән соңгы тапкыр хушлашырга килгән кешеләр арасында моннан берничә ел гына элек «Сандугачлар монастыре»нда булып узган фаҗигането ике шаһите — Мәскәүнең «Богатырь» заводы эшчесе Хәйрулла белән бөтен волостьтан берүзе шобага буенча

[1] Нәҗми К. Әдәбият дөньясында. 36 б.

килгән Трофим очрашалар һәм даһи Ленин эшенә мәңге турылыклы булырга ант итәләр. Әнә шулай, Кави Нәҗми прозасында беренче тапкыр Ленин һәм халыклар дуслыгы темасы яңгыраш ала.

1928 елның 3 августында Казан хезмәт ияләре әле күптән түгел генә Италиянең Сорренто шәһәреннән Советлар Союзына кайткан А. М. Горькийны зур тантана белән каршы алалар. Пролетариатның бөек язучысы килү бөтен Татарстан хезмәт ияләре һәм бигрәк тә язучылар өчен зур бәйрәм була. Шул көннәрдә Кави Нәҗми Горькийга «Шобага»ның русчага үзе тәрҗемә иткән кульязмасын бирә. Горький аны игътибарсыз калдырмый — Мәскәүгә кайту белән озак та үтми, хат яза: «Әгәр дә рөхсәт итсәгез, мин Сезгә гадирәк язарга киңәш бирер идем. Чын матурлык һәм акыллылык һәркайчан да гадилектә... Сүзләр дә гади һәм ачык, аңлаешлы булырга тиешләр...»[1]

«Аның үз кулы белән язылган бу киңәш-тәнкыйть хатын алу,— ди Кави Нәҗми,— минем өчен әйтеп бетергесез сөенеч булды. Мин үземнең һәрбер хикәямне кат-кат тикшереп, әллә никадәр кимчелекләремне актарып чыгардым һәм шулардан ничек котылу юлын яхшырак аңлый башладым»[2].

«Яр буендагы учаклар» (1928) повестенда инде язучының элекке хикәяләрендә еш очраган урынсыз публицистик чигенешләр, вак детальләр белән төп сюжет сызыгын катлауландыру юк. Повестьның теле җиңел, образлары аңлаешлы һәм аларның характерын ачуга ярдәм итә торган лирик чигенешләр дә сәнгатьчә аклана.

Кави Нәҗми үзенең беренче әсәрләре белән үк хезмәт ияләре өчен кирәкле һәм аларны сыйнфый рухта тәрбияли торган әдәбиятны яклап чыга. Матур әдәбиятның төп бурычын билгеләү белән бер үк вакытта уңай герой мәсьәләсен дә ачык аңлый. Әнә шул уңай геройның күп кенә сыйфатлары «Чыныгу», «Иң соңгысы» хикәяләрендә, «Яр буендагы учаклар»да сурәтләнгән образларда чагыла башлыйлар. «Кырлар буенча» (1924), «Боерык», «Без әле түзәрбез!» (1927), «Таштугайга кайтмыйбыз!», «Үзебезнекеләр» (1928) кебек әсәрләрдә, эскиз хәлендә булса да, революция көрәшчеләренең матур сыйфатлары күренеп үтә.

Язучы, гражданнар сугышы еллары вакыйгаларын сурәтләүне туктатмыйча, үзе яшәгән чордагы тормышны, нэп вакытларындагы хәлләрне дә читтә калдырмый. «Башланды...» (1925), «Редактор» (1927), «Суфый» (1928) кебек хикәяләрендә сатирага мөрәҗәгать итә, мещаннарның һәм дин әһелләренең чын йөзен ачып сала. «Кашыклы җырчылар» (1928) исемле хикәядә ул ятим балалар тормышы вакыйгаларын сурәтли. 1921 елгы ачлык вакытында Казан шәһәрендәге бер балалар йортына оялаган караклар компаниясенең эшләрен фаш итә.

Нинди генә материалны алып һәм нәрсә турында гына язса да, Кави Нәҗминең бөтен иҗат юлы буенча сузылып килә торган үзәк темалар һәм мотивлар бар. Аның күпчелек хикәяләре һәм повестьлары, шигырь һәм поэмалары, публицистик мәкаләләре революция һәм гражданнар сугышы вакыйгаларына килеп бәйләнәләр, тарихи-революцион теманы ачуга багышланалар.

Әдипнең егерменче еллар прозасы татар совет әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора. Бу чорда ул иң популяр хикәячеләрнең берсе булып таныла, хикәяләре әдәби җәмәгатьчелекнең фикерен кузгата. Моның төп «сере» язучының әле татар әдәбияты өчен шактый яңа темаларны һәм вакыйгаларны күтәреп чыгуында, аларны көчле революцион пафос белән сурәтләвендә генә түгел. Ул үзенең иҗат практикасында татар демократик прозасының традицион сурәтләү стилен хис-кичереш һәм хәрәкәт киеренкелеге белән баета. Тормыш вакыйгаларын хәрәкәтчән сюжетка салып бирү, үткен, хәтта беренче карашка бигүк табигый булып күренмәгән чагыштырулар, яңа эпитет һәм метафоралар, катлаулы тормышның оста тотып алынган җанлы детальләре — болар барысы да әлеге хикәяләренең үзенчәлекле стилен билгелиләр.

Күмәк хуҗалыклар төзү чорының яңа шартлары Кави Нәҗми иҗатындагы төп тематикага үзгәреш кертә. Егерменче еллар ахырында ул авылдагы зур яңалыклар белән ныклап кызыксына башлый, Татарстанның берничә районында була. Бер төр-

[1] Горький М. Собрание соч., том 30. М., 1955, 101 б.
[2] Нәҗми К. Яшәсен Горький! «Совет әдәбияты», 1936, № 6.

кем татар язучылары белән бергә, 1929 елда Дагстан, Әзербайҗан, Грузия һәм Украинага оештырылган экскурсиягә катнаша.

Шул чорны искә алып, ул үзе соңрак болай дип яза: «Бу — илдә бөек борылыш елы иде. Идел буенда һәм Закавказьеда, Кырымда һәм Украинада колхозлар барлыкка киләләр, эре фабрика һәм заводларның нигезе салына. Бөтен ил тыныч социалистик төзелеш пафосы белән чолганып алынган. Без яңа тормышның идеология өлкәсендә дә нык каршылык күрсәтүче капитализм калдыкларына каршы кискен көрәштә тууын күрдек. Горький маршруты буенча үткәрелгән экскурсиядән соң татар язучылары тарафыннан барлыкка китерелгән яңа китаплар әнә шул вакыйгаларның җанлы яңгырашы булдылар. Татар авылындагы кискен көрәш материаллары нигезендә мин шул чакта кулак калдыкларына һәм буржуаз милләтчеләргә каршы юнәлгән «Якты сукмак» һәм «Кояшлы яңгыр» исемле әсәрләремне яздым»[1].

Әйе, «Якты сукмак» (1929) һәм «Кояшлы яңгыр» (1930) повестьларында язучы колхозлашуның башлангыч чорындагы авылны, андагы сыйнфый көрәшнең драматик күренешләрен үтә кискенлек белән сурәтли, крестьян психологиясендәге үзгәрешләрне тормышчан образлар, катлаулы язмышлар аша табигый һәм җанлы итеп тасвирлап бирүгә ирешә.

Язучының элегрәк язылган аерым хикәяләрендә вакыйга һәм эпизодларның тиз алмашынып торуы, еш кына сюжет сызыгына сыеша алмаулары күренә. Ул үзе дә тормышның катлаулы эчтәлеген мондый юл белән сурәтләп бирү мөмкин түгеллеген аңлый. Аның иҗат үсешендә күренекле урын тоткан әлеге повестьларда исә геройларның психологиясе һәм холык-фигыль үзенчәлекләре тулы ачыла, вакыйгаларның агышы ныклы эздән бара.

Утызынчы еллар башында Кави Нәҗми, күп төрле җәмәгать эшләре алып бару (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясендә, Татлокафның — Литературное объединение Красной Армии и Флота — татар бүлегендә җитәкчелек итү, «Атака» журналының редакторы булу h. б.) белән бергә, күп санлы әдәби-публицистик мәкаләләр яза, шигырьләр һәм хикәяләр бастырып чыгара һәм нәкъ шушы елларда татар хезмәт ияләренең революцион көрәш тарихын аерата тырышлык белән өйрәнүен дәвам итә.

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1932 ел, 23 апрель карары белән Совет язучылары союзы оештырыла. Кави Нәҗми бу карарны Татарстанда да тормышка ашыручыларның алгы сафында була. 1933 елда ул Татарстан совет язучылары союзын оештыру комитетында эшли башлый һәм бер үк вакытта «Совет әдәбияты» журналының редакторы итеп билгеләнә. 1934 елда Бөтенсоюз совет язучыларының Мәскәүдә уздырылган I съездында ул татар әдәбияты турында доклад ясый. Бу съездда Кави Нәҗми СССР Язучылар Союзы идарәсенең члены һәм шул ук елда Татарстан совет язучылары союзы идарәсенең председателе итеп сайлана. Шундый зур һәм җаваплы эшләр белән бергә, әдип үзенең иҗади хезмәтен дә бик актив алып бара.

Бөек Ватан сугышы елларында Кави Нәҗминең әдәби эшчәнлеге тагын да киңрәк колач ала. Аның «Тупчы Сөләйман» (1941), «Таныш урын» (1942) кебек хикәяләрендә, шигырь һәм поэмаларында, публицистик мәкалә һәм очеркларында совет халкының героик көрәше белән горурлану, фашизмга көчле нәфрәт хисе чагыла. «Азатлык сугышы» (1941), «Намус эше» (1943), «Тереклек бирүче көч» (1945) һәм башка публицистик мәкаләләрдә исә татар һәм рус халкы арасындагы тарихи дуслык мотивлары көчле яңгырый. Һәм бу — бик табигый күренеш. Халыклар дуслыгы идеясе язучының гражданнар сугышы елларын сурәтләгән шигырь һәм хикәяләрендә дә, колхозлашу чорын чагылдырган повестьларында да алгы планда тора. Гомумән, татар халкының социалистик революциягә килүе һәм халыкларның революцион дуслыгы — Кави Нәҗми иҗатындагы иң төп тема дип билгеләргә мөмкин.

Кави Нәҗминең сугыш елларында язган мәкалә һәм очеркларына тарихилык сыйфатлары аерата хас. Фактларга һәм документаль материалларга нигезләнеп язылган ул әсәрләрдә очерк стиле белән хикәя алымнары аралаша. Алар шул чорда ук сугышчан партиялелек рухы белән сугарылган татар совет публицистикасының матур үрнәкләре булып танылa.

[1] Наджми К. Повести и рассказы. М., 1957. 168 б.

Бөек Ватан сугышы елларында язучы Татарстан радиокомитетының әдәби тапшырулар бүлеге редакторы булып эшли, татар халкының фронтовик улларына язган хатны төзүдә актив катнаша, Татарстаннан киткән фронтовиклар — Советлар Союзы Геройлары турында «Батырлар китабы» исемле очерклар җыентыгын эшләүне оештыра һәм төзеп чыгара.

ВКП(б) Үзәк Комитеты 1944 елның 9 августында кабул иткән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы карарда татар тарихчылары һәм әдәбиятчылары алдына чит илләрдән килгән илбасарларга, патша хөкүмәтенә һәм алпавытлар, капиталистлар изүенә каршы татар халкының рус һәм башка халыклар белән бергәләп көрәшүләре тарихын тирән өйрәнү һәм яктырту бурычы куела.

Үзенең бөтен иҗат гомере дәвамында татар хезмәт ияләренең азатлык өчен сыйнфый көрәше, халкыбызның социалистик революциягә килүе һәм яңа тормыш төзи башлавы белән нык кызыксынган Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» исемле тарихи-революцион романы партия чакыруына җавап була, һәм ул үз вакытында ук шулай бәяләнә дә. Язучының тормыш тәҗрибәсе һәм әдәби осталыгының иң югары дәрәҗәдә чагылуын күрсәткән бу роман 1948 елда «Совет әдәбияты» журналында чыкты. 1949 елда ул аерым китап булып басылды, бераздан төзәтелеп, үзгәртелеп эшләнде һәм 1950 елда рус телендә Мәскәүдә һәм Казанда басылды. «Правда» газетасы романны «татар әдәбиятының иң күренекле әсәре» дип бәяләде һәм аның «бөтен тугандаш әдәбиятлар үсеше өчен дә тирән принципиаль әһәмияткә ия икәнлеген»[1] билгеләде. «Большевик» журналы исә аның турында: «Эшчеләр сыйныфының революцион үткәнен, патша самодержавиесе шартларында аның героик көрәшен шулкадәр тирәнлек белән чагылдырган әсәрләр безнең әдәбиятыбызда күптән булганы юк иде»[2],— дип язды.

Кави Нәҗми үзенең бу романы өстендә егерменче елларның ахырында ук эшли башлый. Аның аерым кисәкләре «Гарнизон», соңрак «Туган ил» романыннан өзекләр дигән искәрмәләр белән, төрле исемдәге хикәяләр рәвешендә, 1933 елдан башлап газета һәм журналларда басылып килә.

Романда сурәтләнгән вакыйгаларның төп өлеше 1905—1907 еллардагы Беренче рус революциясе белән 1917 елгы Бөек Октябрь социалистик революциясе арасында Казан пролетариаты алып барган революцион көрәш тарихына карый. Бу әсәрдә татар халкының революцион аңы үсүе, егерменче йөз башы җәмгыятенең катлаулы сыйнфый каршылыклары, татар һәм рус пролетариатының патша самодержавиесенә һәм буржуазиягә каршы бер сафта торып көрәшүе үзәк проблемалар итеп алына.

Сурәтләнгән чорга хас нечкә детальләрне дә сизеп эш иткән Кави Нәҗми әсәрнең сюжет сызыкларын һәм шулар ярдәмендә төп образларны революцион көрәш вакыйгалары белән гаять тыгыз бәйли. Зур тарихи чорны, шул чорның иҗтимагый-политик тормышын һәм революцион хәрәкәт тарихын озак еллар дәвамында игътибар белән өйрәнү язучыны төрле милләт хезмәт ияләренең туганнарча дуслыгын дөрес чагылдыруга китергән. Тормышның нәкъ үзендәгечә, революцион хәрәкәт төрле милләт хезмәт ияләренең үзара берләшү ноктасы һәм алар арасындагы дуслыкның җимерелмәс нигезе итеп бирелә.

1905 елгы революция чорының политик шартлары турында В. И. Ленин: «Изелгән, урта гасыр торгынлыгында кыргыйланган йөз миллионнарча халык яңа тормышка, кешелекнең иң гади хокуклары өчен, демократия өчен көрәшкә уянды»[3],— дип язды. Мостафаның революцион көрәш юлына басуын язучы нәкъ шул юнәлештә ачып бирә. Ул Мостафа характерының үсеш-үзгәрүен ышандыргыч күренешләрдә тасвирлый. Башта сыйнфый көрәшкә шикләнеп кенә караган, аннан бер читтә калырга тырышкан Мостафа, Андрей Петрович, Алексей Халявин, Хәсән Айвазов кебек большевиклар йогынтысында, революцион көрәшкә көннән-көн ныграк якынлаша. Чынбарлык үзе аны табигый рәвештә бердәнбер юлга — революцион көрәш юлына китерә. 1917 елның октябрь көннәрендә Казан Кремлен штурмлау вакытында үлем җәрәхәте алган Мостафаның кызыл байракны улы Гәрәйгә тапшыруы да

[1] «Правда», 1951, 30 март.
[2] «Большевик», 1951, № 7.
[3] Ленин В. И. Әсәрләр, 19 том, 66 б.

бик тирән мәгънәле. Бу күренештә «Сәүбановлар нәселенең революцион намусын кер кундырмый саклырлык улы барлыкка горурлану тойгысы» яңгырый. Мостафаны, һич икеләнүсез, Кави Нәҗми әсәрендәге образларның иң көчлесе, аның прозасының эпиклык көчен күрсәткәннәрдән иң уңышлысы дип һәм, гомумән, бөтен татар совет прозасында беренче урынны тоткан геройлар галереясы вәкиле дип бәяләргә нигез бар. Автор романда Октябрь алдындагы Казан тормышының бик күп якларын сурәтли. Ул төрле социаль катлауларның революция алды елларындагы тормышын чагылдыра. Бу эштә бигрәк тә А. М. Горькийның киңәшләре әһәмиятле роль уйный.

1951 елда басылып чыккан «Совет язучыларының әдәби остазы» исемле мәкаләсендә Кави Нәҗми А. М. Горький белән бер очрашуы турында болай дип язды: «Ул чагында әле мин үземнең романда Казан фабрикантларына, купецларына аерым образлар төсендә урын бирү турында уйламаган идем. Горький моны аңлап алгач та, башын чайкап, миңа сорау бирде: «Ничек итеп сез шундый зур әсәрне буржуйлардан башка гына ерып чыгарга уйлыйсыз? Ул чагында безнең бу китапта сыйнфый көрәш рәтләп күренмәячәк бит!»

Һәм ул Казан буржуазиясе арасыннан үзе күреп белгән купец һәм фабрикантларның портретларын шунда ук, беседа барышында, җанлы штрихлар белән күз алдыма бастырып сөйли башлады. Соңыннан, тимерче Мостафа белән фабрикант Вәлишинның бәрелешүен сурәтләп, «Язгы җилләр» романының хәзер инде укучыларга билгеле бүлекләрен язган чагымда, миңа Алексей Максимович һаман янымда утырадыр һәм үзенең үткен акылы белән миңа тормышны тагын да яктырак, көчлерәк, җанлырак итеп сурәтләргә булышадыр төсле тоелды»[1].

Әсәрдә сурәтләнгән буржуазия вәкилләре арасында бигрәк тә Юныс бай образы характерлы. Эре сәүдәгәр һәм фабрикант Юныс Вәлишин байлыгын үстерү юлында бернинди пычраклыклар алдында да туктап калмый. Юныс Вәлишинның кызы Суфия һәм улы Идрис мораль йөзләре, намуссызлыклары белән әтиләреннән артык аерылмыйлар. Иманкол хаҗи, купец Хизбулла, пүнәтәй Камали, буржуаз милләтче Гайфи Иҗбуллиннарны эшчеләр сыйныфына дошманлык, революцион көрәштән курку берләштерә. Революциянең үсүе аларны калтырата, төрле милләт хезмәт ияләре арасында дуслык хисләренең көчәя баруы аларны котырындыра. Бу персонажларның бирелешендә Кави Нәҗми иҗатындагы төп тенденцияләрнең берсе — Совет власте дошманнарын кискен сатирик камчылау тенденциясе — үзенең югары чагылышын тапты. Ә Мостафа һәм Гәрәй Сәүбановлар, Нәсимә һәм Хәсән Айвазовлар йөзендә Бөек Октябрь социалистик революциясе көннәрендә иске тормышны җимереп яңага аяк баскан татар пролетариатының гомумиләштерелгән портреты бирелә.

«Язгы җилләр» башта аерым китап итеп уйланган булса да, анда сурәтләнгән вакыйгалар һәм геройлар язмышының эчке логикасы әдиптән шуңа ук бәйләп яңа әсәр язуны таләп итә, шуңа этәрә.

«Язгы җилләр»не тәмамлау белән ук, әдип шуның өстендә эшли дә башлый. Ул 1948 елда СССР Язучылар союзының генеральный секретаре А. Фадеевка язган хатында моның өчен үзен «Совет әдәбияты» журналының редакторы хезмәтеннән азат итүне һәм «роман сюжеты өчен кирәкле объектларны ныграк өйрәнү» максаты белән берничә айлык иҗат командировкасына җибәрүне сорый. Шул ук хатта тагын болай дип өсти: «Яңа романның образлары мине бик күптәннән дулкынландыра. Бу әсәремдә индустриализация фонында, безнең илебез үткән вакыйгалар, бәрелешләр, көрәшләр фонында ленинчыл милли политиканың тантанасын тасвирларга телим... Ул минем «Язгы җилләр» романыннан органик төстә килеп чыга, чөнки бу романда миңа тәмам якын булып киткән кайбер геройларым яңа вакыйгаларда, тагын да катлаулырак шартларда үзләренең язмышлары хәл итәлә торган сынаулар аша үтәргә тиешләр»[2].

Кави Нәҗми үзенең соңгы көннәренә кадәр «Тирән агым» дип исемләнгән шул романын (трилогиянең икенче кисәген) яза. Бу әсәрдә гражданнар сугышы һәм сугыштан соңгы беренче еллардагы Казан эшчеләре, яшьләре тормышы сурәтләнә.

---

[1] Нәҗми К. Әдәбият дөньясында. 145—146 бб.
[2] «Советская Татария», 1961, 15 декабрь.

Романның аерым бүлекләре «Дружба народов» (1957 ел, 5 нче сан), «Совет әдәбияты» (1957 елның 11 нче саны, 1961 елның 12 нче саны) журналларында, Кави Нәҗми «Әсәрләр»енең III томында (1959) басылып чыкты. Әсәр реализмы, гади стиле, уңай герой образларын тасвирлаудагы матур лиризмы белән көчле. Сурәтләү чараларын, диалогларда һәм геройларга характеристика бирүдә да автор яңа буяулар таба. Язучы биредә яңа геройлар кертү белән бергә «Язгы җилләр» романында сурәтләнгән Нәсимә, Хәйбуш карт һәм башка образларны яңа иҗтимагый-политик шартларда күрсәтә. Төрле вакыйгалар һәм геройлар, типлар белән бәйләнештә Рөстәм исемле егет образы ачыла бара. Аның язмышында язучының үз биографиясе белән дә шактый уртак моментлар булуы сизелә...

Ләкин әдипнең 1957 елның 24 мартында кинәт үлүе сәбәпле бу әсәр тәмамланмыйча калды.

Кави Нәҗминең бөтен тормышы — коммунист язучы һәм көрәшче тормышы. Ул — революция җырчысы — үз иҗатында халыкның тарихи язмышын киң колач белән күрә һәм күрсәтә алды. Ул язучылык хезмәтен иҗтимагый-политик эшләрдән аерып карамый. Үзенең соңгы көннәренә кадәр Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, Тынычлык яклаучыларның Татарстан комитеты председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе члены һәм башка вазифаларны чын намус һәм бирелгәнлек белән үтәп килә. Совет хөкүмәте аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Хезмәттәге батырлык өчен», «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында батыр хезмәт өчен» медальләре һәм «Язгы җилләр» романы өчен СССР Дәүләт премиясе белән бүләкләде.

# *ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ*

Гөлсинә Мөхәммәдова,
филология фәннәре кандидаты

## ФИДАКАРЬЛЕК

Кайнар йөрәкле, йомшак табигатьле кеше, бөтен гомерен партиягә һәм халыкка хезмәт итүгә багышлаган, тынгы белмәс язучы Габдрахман Әпсәләмов бай әдәби мирас калдырды. Аның китапларының гомуми тиражы берничә миллион данәдән артып китә.



Г. Әпсәләмов публицист, күп санлы очерклар авторы, тәрҗемәче буларак та танылды. Аның ялкынлы публицистикасын бергә тупласаң, берничә том җыелыр иде. Язучылык эшчәнлеге чорында ул А. Фадеевның «Яшь гвардия», Э. Казакевичның «Одерда яз», Н. Тихоновның «Ленинград хикәяләре», А. Новиков-Прибойның «Герой корабль» әсәрләрен, Д. Мамин-Сибиряк, А. П. Чехов, В. Короленко, М. Пришвин, Джек Лондон, Мопассан хикәяләрен тәрҗемә итә.

Үз иҗатында Г. Тукай һәм һ. Такташ, Г. Ибраһимов һәм Ш. Камаллардан килгән матур традицияләрне дәвам итеп, Г. Әпсәләмов татар әдәбияты мәйданында гына чикләнеп калмады. Аның геройлары илебезнең төрле милләт кешеләре йөрәгенә кыю үтеп керде. Татар язучыларының рус телендә чыккан басмалары саны ягыннан Г. Әпсәләмов әсәрләре, Г. Тукайдан кала, икенче урында тора. Аның романнары СССР халыклары һәм күп кенә чит ил халыклары теленә тәрҗемә ителде.

Украина Коммунистлар партиясе органы «Рабочая газета» редакциясе СССРның 50 еллыгына багышлап «Халыклар дуслыгы — әдәбиятлар дуслыгы», «Тугандаш әдәбиятлар безнең тормышта» дигән тематика белән киң катлау укучылардан анкета тутырткан иде. Нәтиҗәдә Украинада әсәрләре укыла торган 117 тугандаш республика язучысы арасында иң популяр китаплар Әпсәләмовныкы булуы ачыкланды.

Г. Әпсәләмов гомер буена китап укучылардан хатлар алып тора һәм бер генә хатны да җавапсыз калдырмый. Сорауларга җавап бирү белән бергә, әдәбиятның язмышы, мәктәпләрдә әдәбият укытуны яхшырту хакындагы уйларын, фикерләрен дә уртаклаша ул. Әпсәләмов китапларының геройлары арасында укучылар үзләрен, үз язмышларын да танып алалар. Шул чакта инде алардан килешмәүчән яки кыю киңәш төсендәге хатлар килә. Кайберәүләр якын дуслары белән киңәшләшкән кебек иң яшерен серләрен уртаклашалар. Шуңа күрә бу язышу Әпсәләмов өчен

кадерле була. Ул җанлы, эчкерсез сөйләшү төсендә бара. Укучылардан килгән хатлардан язучы рухи күтәренкелек, җан азыгы таба.

Язучы катнашында күпме китап укучылар конференцияләре үтте! Аудиториядә нинди милләт кешеләре утыруына карамастан, алар бик җанлы була торган иде.

Габдрахман Әпсәләмов иҗаты Бөек Ватан сугышы елларында таныла башлый. Сугыш алдыннан аның «Бәхет кояшы» дигән бер җыентыгы чыгып калса да, чынлап торып әдәби эшчәнлеге «Төньяк балкышы» исемле хикәяләр җыентыгыннан башлана. Бу хакта язучы үзе дә болай ди: «Аңача мин эзләнгәнмен, күңел төбендә яткан кайбер үрентеләр зәгыйфь кенә баш күтәргән, ләкин үземнеке дип әйтерлек төп сызык булмаган. Сугыш уты эчендә мин шул төп орлыкны — туган ил романтикасын тапканмын».

Татар әдәбиятында героик тема зур урын алып тора. Аны Муса Җәлил гаять югары күтәрде. Бу теманы прозада баетуга исә Г. Әпсәләмовның өлеше чиксез зур. Бөек Ватан сугышы материалларында ул патриотизм, аңлы каһарманлык, ныклык үрнәкләрен ышандырырлык итеп, сәнгатьчә оста сурәтләде. Асылда бит аны сугыш вакыты, героик көрәш чын мәгънәдә олы язучы итә.

Ләкин барыбер аның да әдиплек тамырлары балачак һәм яшьлек хатирәләренә, беренче тәэсирләргә барып тоташа. Ул әйләнә-тирә дөньяны, туган халкының телен, җырларын, үзенчәлекле образларын, характерларын күңелдә сеңдереп калдырган җуелмас һәм кабатланмас кичерешләрдән башлана. «Язучының иҗат фантазиясе, әсәрләре никадәр генә катлаулы һәм мавыктыргыч булмасын, күктән төшми, түшәмнән алынмый. Ул күзгә күренмәгән, бик нечкә, ләкин гаҗәеп җепләр белән халык тормышына барып тоташа»,— ди язучы үзе дә.

Габдрахман Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә элекке Пенза губернасының Краснослободск өязе Иске Аллагол авылында крестьян семьясында туган һәм балачагы да шунда үткән. Хәзер бу авыл Мордва АССРның Рыбкин районына керә.

Габдрахман үткен зиһенле, кызыксынучан бала булып үсә. Җыр, әкият тыңларга ярата. «Хәзер мин ул әкиятләрнең күбесен оныткanмын, ләкин аларның сихри музыкасы колак төбемдә, хәзер ачык итеп әйтә алам: халык иҗаты, халык җырлары минем язучы булып китүемдә бик зур роль уйнады,— ди язучы бу хакта. Балачактан ук аның йөрәгенә Тукай кереп кала.— Аның «Туган тел» шигырен, мөгаен, йөз кат укыганмындыр». Үз якларының җырларын, бәетләрен Тукай йогынтысында отып ала бәләкәй Габдрахман. Бу бер. Икенчедән, әнисе белән бертуган абыйсы Ибраһим гомерлек солдат була икән. Бала, дөньясын онытып, шул солдат хикәяләрен тыңлый, хыялында аның белән окопта ята, атакага бара, пулеметтан ата... Архивында саклана торган автобиографиясендә ул болай яза: «Хәзер уйлап карыйм да, минем иҗатымдагы сугыш романтикасы орлыклары шуннан шыталар түгелме, дип куям. Билгеле, үзем сугышта катнашмасам, бу балалык тәэсирләре сүнгән дә булырлар иде, үзем бөтенләй яңа шартларда сугышта булгач, күрәсең, карт солдатның тылсымлы хикәяләре минем йөрәгемдә чәчәк атканнар. Күп вакытта без әлеге күренешнең, теге яки бу вакыйганың тирән тамырларын казып мәшәкатьләнмибез, өстә яткан, бар кеше дә күрә торган гомуми якларын гына алабыз. Хәлбуки, гомуми яклардан тыш һәр кеше күңелендә иҗат серләренең үз тамырлары бар, алар болай бик ерак яшеренеп ятсалар да, мәгълүм шартларда, өметле яшел үрентеләр бирәләр. Ибрай абзыйның солдат хикәяләренә мин үзем шулай карыйм. Билгеле, хәзер аларның күбесе онытылган, эзләре дә калмаган кебек. Ләкин мин Ибрай абзыйның ничек утыруын, тавышын ишетәм шикелле, кайчак теге-бу хикәянең әлеге эпизодлары җанланалар. Аның сөйләгәннәре мин балачакта укыган хәтсез күп китаплардагы вакыйгалар белән бергә кушылганнар һәм соңыннан бик катлаулы бер эретмә булып өскә калыкканнардыр, дип уйлыйм».

Булачак язучының үсмер чагы һәм яшьлек еллары Мәскәүдә үтә. Ул анда Фазыл Исхаков (ана теле һәм әдәбият укытучысы), Нури Йосыпов, Җәлил Хәсәнов (математика һәм физика укытучылары) кебек әйбәт педагогларда укый. Бу тирән белемле, бай күңелле, эчке дөньялары гүзәл кешеләрне Г. Әпсәләмов олыгайгач та эчке дулкынлану, соклану белән искә ала. Язучының эстетик идеалы мораль, әхлак ягыннан үтә пакь, үзләрен бөтенләе белән яраткан эшләренә, җәмгыятькә

багышлаган кешеләр дибез икән, бу идеал туута һәм формалашуга әлеге остазларның роле булу бәхәссез. Алар белән аралашу язучы өчен эзсез калмаган.

Мәскәүдә Габдрахман беренче әдәби дәресләрне дә ала. Ул елларда Муса Җәлил балалар журналы редакторы була, татар китапханәсе каршындагы әдәби түгәрәккә җитәкчелек итә. Габдрахман Әпсәләмов бу түгәрәккә мәктәптә укыганда да, соңрак, заводта эшли башлагач та йөри. Хикәяләр һәм пьесалар яза башлый. Соңрак Муса Җәлил аңа Әдәбият институтына керергә рекомендация бирә, әдәби



*Сулдан уңга: Әхмәт Исхак, Гази Кашшаф, Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, рәссам Павел Радимов*

эшчәнлеген киләчәктә дә күзәтеп тора. Җәлилнең «Ике Әпсәләм» шигыре нәкъ менә шул хакта инде. Бу шигырь 1937 елда «Совет әдәбияты» журналында яшь әдипнең «Мәһинур» исемле хикәясе чыгу уңае белән язылган. Муса Җәлилнең мөлаемлыгы һәм гадилеге Габдрахман Әпсәләмов күңелендә тирән эз калдыра.

Аннары — Бөек Ватан сугышы еллары, солдат-журналист булып үткән данлы, авыр юллар. Сугыштан соңгы гомере аның Казан белән бәйле: ул шунда төпләнә һәм актык көннәренә кадәр шунда яши, эшли, иҗат итә. Шунда күренекле җәмәгать эшлеклесе булып таныла: СССР Верховный Советы депутаты буларак зур эшләр башкара, КПССның XXII съездына делегат итеп сайлана.

Татарстан язучыларының IV съездындагы докладында Г. Әпсәләмов иҗаты турында Мирсәй Әмир болай диде: «Тормышның үзеннән илһам алып яза. Менә шул нәрсә аңа әдәбиятта яңа сүз әйтергә мөмкинлек бирә».

Жанрлары нинди булуга карамастан, Г. Әпсәләмов әсәрләренең нигезендә тормыштан алынган факт ята, ә геройлары замандашларыбыз була. Күп санлы очерклар гына түгел, «Газинур», «Мәңгелек кеше» романнары да документларга нигезләнеп язылган. «Алтын йолдыз», «Сүнмәс утлар», «Ак чәчәкләр» романнары шулай ук тормыштагы күзәтүләр тәэсирендә иҗат ителә.

Әлбәттә, әлеге китапларның яратып кабул ителүе күпчелек геройларның тормыштан алынган булуы белән генә түгел, ә аларның һәркайсында язучының үз уйлары һәм гомумиләштерүләре белән дә аңлатыла. Иҗат эшендә иң кыены прообраздан образга күчү, дип исәпли язучы үзе дә. Тормыш материалы белән иҗат

фантазиясен бер эретмә итеп коюда автор карамагындагы сәнгатьчә сурәтләү арсеналының әһәмияте зур. Хәрәкәтчән, динамикалы сюжет, төп фикерне чагылдыручы художество алымнарын дөрес сайлау — Г. Әпсәләмов әсәрләренең бер үзенчәлеге әнә шунда.

Г. Әпсәләмовның иҗат энергиясе берничә агым булып юл яра: ул бер әсәре өстендә эшләгәндә икенчесе өчен материал туплый, күңелендә инде икенче тема өлгереп килә. 1950 елда «Газинур» романы басылып чыга. «Газинур» турында мин сугыш елларында уйлый башладым,— дип сөйләгәне бар язучының.— Газинур Гафиятуллинга, үлгәннән соң, Советлар Союзы Герое исеме бирелү турындагы Указны укыгач туды ул уй. Гази — җиңүче һәм, шуңа өстәп: нур. Җиңүче нур. Менә шушы «җиңүче нур» күкрәге белән амбразураны каплап һәлак була. Бу табыш иде. Романның исемен шунда ук билгеләдем. Шушы уй һәм романның исеме күңелдә йөрде».

«Газинур» романында автор беренче мәртәбә әсәр текстына җыр, бәет кертә, төп герой образын тудыру өчен алардан оста файдалана. Газинур романга үз табигате кебек тирән, киң агышлы җыр белән килеп керә. «Җырчы бирелеп, бөтен күңеле, бөтен йөрәге белән җырлый». Җырлары белән Газинур туп-туры укучы йөрәгенә юл ача.

Биографиясеннән мәгълүм булганча, язучы бәләкәй чакта ук әйләнә-тирәсендәге кешеләр холкындагы якты, калку сыйфатларны табарга ярата. Фронтта чагында ул замандашларының уңай якларын данлый, романтика белән өретә. «Газинур» романында авторның бурычы герой характерындагы матур сыйфатларны формалаштырган хис-фикер чыганакларын сәнгати тикшерүдән гыйбарәт. Язучының үз сүзләре белән әйтсәк, геройның тормышы һәрвакыт шаулы дулкыннар өстендә итеп сурәтләнә.

Г. Әпсәләмовның иҗади эшчәнлегендә кызыклы үзенчәлек күзәтелә. Язучыны сокландырган теге яки бу вакыйга аның хәтерендә уелып кала. Аннары шуның тирәсенә берничә ел дәвамында бөртекләп материал туплана. Кагыйдә буларак, утырып әсәр язар өчен бу әле җитми, аңа тормыштан алган тере прототип кирәк. «Мәңгелек кеше» романын язу өчен язучыга Бухенвальд лагеренең бөтен дәһшәтләрен үз җилкәсендә татыган Бакый Назиров белән танышлык этәргеч була. Соңгы елларда бөтен көчен туплап язган «Агыла болыт» романында да ул үзенең көрәштәш һәм каләмдәш дусларын мәңгеләштерә. Романның төп геройлары Муса Җәлил һәм Гази Кашшафны язучы яхшы белә, аларның кешелек сыйфатларын югары бәяли. «Алтын йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше», «Агыла болыт» романнарын язуда Әпсәләмовның сугышта катнашуы, хәрби корреспондент булуы, фронт көндәлекләре язып баруы һәм гаять күп кичерешләре, күрелгәннәр аша туган хисләре хәлиткеч роль уйнаганлыгын да әйтергә кирәк.

Врачларга карата олы мәхәббәт хисен язучы сугыш елларында ук кичергәне хәрби көндәлекләрдән билгеле. Беренче тапкыр врачлар кулына ул Карелия фронтында эләгә. «Ак чәчәкләр» романының тамырлары да ерак Карелия фронтына барып тоташа,— дип яза автор.— Роман алтмышынчы елларга караса да, врачларга булган кайнар мәхәббәт шул ук Карелиядә уянды. «Алтын йолдыз»да, аннары «Газинур»да врач образларын төрле яклап бирергә омтылу әнә шуннан килә. Ләкин бу әсәрләрдә генә медицина турындагы уйларымны әйтеп бетермәгәнмен, аларны әйтер өчен «Ак чәчәкләр»не язарга кирәк булган».

Язучы «Сүнмәс утлар» һәм «Ак чәчәкләр» романнарының уй-ниятен еллар буе күңелендә йөртә. «Маһинур», «Бәхет кояшы» хикәяләре хезмәт темасының язучыны яшьтән үк кызыксындырганлыгы турында сөйлиләр. «Сүнмәс утлар»да бу тема бик нык үстерелә. Г. Әпсәләмов әлеге әсәрен язу белән үзен җитлеккән реалист художник итеп танытты. Ул монда эпик киңлекне психологик анализ тирәнлеге белән куша алды. Татарчасы чыгуга бер ел үтәр-үтмәстән романның русчасы Мәскәүнең «Советский писатель» нәшриятында дөнья күрде. Шуннан бирле татар, рус телләрендә берничә кат басылды, СССР халыклары телләренә тәрҗемә ителде, болгар һәм швед укучысына барып иреште. «Сүнмәс утлар» романы өчен Г. Әпсәләмовка республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Сөләйман Уразмәтов белән Хәсән Мортазинның чәкәләшеп китүе аша роман-

ның төп конфликты ачыклана. Беренче карашка алар арасындагы конфликт көнкүрештә, гаиләдә чыга торган конфликт кына кебек. Ләкин язучы шәхси низаглар җирлегендә зур иҗтимагый проблемалар ятканлыгын күрә алган.

Сугыш елларындагы очерклары һәм хикәяләреннән үк Г. Әпсәләмов иҗатының бер үзенчәлеге күзгә ташлана: ул, гадәттә, герой характерындагы бер якны, аны башкалардан үзгә шәхес итеп куя торган үзәкне таба. Шул ук вакытта автор геройларның тышкы характеристикасына нык игътибар итә, килеш-килбәтләрен күз алдына җанлы итеп бастыра белә. Бу сурәтләү геройның рухи халәте, эчке тойгылары һәм аңа бүтән персонажларның мөнәсәбәте белән тулыландырыла. Димәк, автор бәясенә бүтән геройның субъектив бәясе дә өстәлә.

Герой күңелендәге үзгәрешләрне күрсәтә барып, автор аның кул һәм йөз хәрәкәтләрен, холык-фигылендәге теге яки бу сыйфатлар чагылып китәрлек кыланышларын, рухи халәтен эләктереп ала. Автор үз героеның эчке дөньясын берничә штрих белән ача. «Күз карашында, хәрәкәтләрендә дуамаллык ташып торган Сөләйманны халык арасында ул ерактан ук күрде». Матвей Погорельцев карашыннан бирелгән бу портретта Сөләйман Уразмәтов табигатенә хас үзенчәлекле бер «көлтәгә» җыйналган. Сөләйман кешеләрнең шатлыкларын да, кайгыларын да йөрәгенә якын ала, үз дөньясына гына бикләнеп яшәми. Менә шушы сыйфат аны тәкәббер Хәсән Мортазин белән бәрелештерә дә.

Зур әдипләрнең иҗаты һәрвакыт бербөтен була. Г. Әпсәләмов әсәрләрен берберсенә күзгә күренмәс җепләр бәйли. Теге яки бу тема һәр яңа әсәрдә киңрәк ачыла, әйтерсең, автор, чынбарлыкны киңрәк колачларга омтылып, элек кузгатылган темаларны бергә туплый. Образлар белән дә шул ук хәл.

Тормышка битараф мөнәсәбәтне кабул итми торган горькийча гуманизм, Сөләйман Уразмәтов характерындагы эшлекле, актив кешелеклелек Әбүзәр Гәрәевич Таһиров образында тагын да тирәнрәк чагыла. Яңа материалның, яңа тормыш сөземтәләренең характеры автор алдында һәр юлы яңа чишелешләр мөмкинлеген ача. Менә шуңа күрә идея инанулары ягыннан кардәшләр булган Сөләйман Уразмәтов һәм Әбүзәр Таһиров кеше типлары буларак бер-берсенә бик якын торалар, шул ук вакытта алар гуманизм төшенчәсенә автор концепциясен төрле аспектлардан ачалар. Тормыш материалы үзе тиешле сыйфатны сайларга, шуңа басым ясарга мөмкинлек бирә. (Актив, һөҗүмчән, гаделсезлекне күтәрә алмаучы Сөләйман Уразмәтов һәм йомшак табигатьле, кече күңелле, тирә-юньдәгеләргә карата игътибарлы профессор Таһиров). Әгәр Хәсән Мортазин образында автор үзен җәмгыятькә каршы куйган, ләкин эшчеләр коллективына эләккәч, үзенең индивидуализмын җиңә алган шәхесне күрсәткән булса, Янгура образында комсызлык һәм мин-минлек чире тирән урнашкан кешене фаш итә. Героеның эчке дөньясын энә күзеннән үткәреп, аның үз-үзен тотышындагы сыйфатларның асылына төшеп, әсәрләрендә мещанлык психологиясен фаш итеп, Г. Әпсәләмов татар әдәбиятында А. М. Горький традицияләрен дәвам итә. Профессорның чын йөзе укучыларга тиз генә ачылмый. Язучы Янгураның һәр хәрәкәтен, һәр адымын барлап тора. Бу кеше өчен эгоизм һәм салкын исәп-хисап бөтенесен алыштыра. Янгура кебек кешеләргә акыл, талант, кеше арасында үз-үзеңне тота белү яхшы фикер тудыру өчен корал гына. Хәйләкәрлек, икейөзлелек артына алар чын йөзләрен яшерәләр. Янгура, бу эш аңа дан һәм авторитет китерә дип уйлаганда кыю да, тәвәккәл дә була, әгәр инде шушы тәвәккәллек нәтиҗәсендә җәмгыятьтәге урыны какшар кебек тоелса, ул шунда ук сүлпән, җансыз кешегә әйләнә.

Сөләйман Уразмәтов образыннан соң бу — Г. Әпсәләмов тудырган образларның иң шәбе. Рәссамнар теле белән әйтсәк, аның палитрасында яңа буяулар барлыкка килде, ә рәсеме тагын да нәфисләнде. Янгураны без йөз процент тискәре дип тә әйтә алмыйбыз. Әйе, ул тормыш позициясе белән тискәре герой, ләкин шул ук вакытта аның талантын, белемен һәм, ниһаять, чын күңелдән яратырга сәләтле булуын күрми кала алмыйбыз. Ул Гөлшәһидәгә чын йөрәктән гашыйк.

Гөлшәһидәне исә саф хисләре өчен Мансур белән «бүләкләү» аллә ни куандырмый, чөнки Мансурның аңа мәхәббәте берничек тә сизелми. Романның мәхәббәт сызыгында образлар автор ихтыярына буйсынмый башлыйлар, үз тормышлары белән яшәп киткәләр кебек.

«Ак чәчәкләр» романында лирик агым көчәя. Сүзләр һәм кичерешләр аша характерлау осталыгы арта. Элек еш кына күләгәдә кала килгән икенче пландагы персонажлар бу романда ышандырырлык һәм тулы канлы итеп сурәтләнгәннәр. Мәдинә ханым, Асия, Николай Максимович һ. б. лар, хикәяләү үзәгендә тормаслар да, яратып, тормышчан итеп бирелгәннәр. Шул ук вакытта Әбүзәр Таһиров һәм Гөлшаһидә автор характеристикасына күмелеп, төссезләнебрәк калган кебек.

Язучы Гөлшаһидәнең йөрәк кичерешләрен бик җентекләп күзәтә. Бу сюжет линиясе ышандыра. Ләкин Гөлшаһидәнең иҗтимагый эшчәнлеген сурәтләгәндә, аналитик күзәтүләрдән бигрәк гади санап чыгулар өстенлек итә. Мортазинның гаебен йөзенә бәреп әйтергә курыкмаган Мәрьям образы аша язучы яңа җәмгыять шартларында татар хатынына хас үзгәрешләр турында күбрәк әйтә алган иде бит. Нигә болай соң әле бу? Гөлшаһидә кылган эшләр типик түгел мени? Бөтен хикмәт образларның художестволылык дәрәҗәсендә. Образларны сәнгать чаралары белән өйрәнү җитмәгәндә типиклыкка да зыян килә. Эчтәлек белән форма арасындагы гармония бозыла, нәтиҗәдә образның кыйммәте кими. Мәрьям бары бер генә адым ясый, ләкин аңа зур җирлек хәзерләнгән. Бер яктан алганда, татар хатыны гомер-гомергә карусыз, басынкы булган. Мәрьям дә юл куючан һәм йомшак табигатьле. Шуңа күрә аның завод директорына гына түгел, гаиләләренең якын кешесенә дә каршы чыгуы аеруча көчле яңгыраш ала.

Милли мөнәсәбәтләрнең социалистик интернационализм нигезендә үсүе — социализмның мөһим факторы. Интернационализм тормышыбызның һәр өлкәсенә үтеп керә, аның әһәмияте җәмгыять алга барган саен арта бара.

Тормышны пролетар интернационализм позицияләреннән торып сурәтләгән беренче язучы А. М. Горький булды. Милли геройны тасвирлауда Горький традицияләре, аның идея-художество принциплары соңыннан күп милләтле совет әдәбияты язучылары тарафыннан уңышлы дәвам иттерелде.

Татар язучылары инде 20—30 нчы елларда, совет әдәбиятының таңында ук, үз милли кысаларында бикләнеп калмадылар. Алар кешеләр арасында яңа мөнәсәбәтләр тууны, төрле милләт халыкларының, тулы хокуклы членнар булып, зур, тату совет гаиләсенә керүен сурәтләргә тырыштылар. Бу бигрәк тә Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, К. Нәҗми иҗатларында нык чагылды. 40 нчы елларда һәм соңрак язылган китапларның геройлары инде яңа шартларда — совет кешесенең социаль-экономик хәлендә генә түгел, ә бәлки көнкүрешендә, гадәтләрендә, психологиясендә дә тамырдан үзгәрешләр ясалган шартларда яшиләр.

Г. Әпсәләмов тормышта барган бу үзгәрешне нечкә сиземләгән һәм конкрет характерлар аша чагылдыра алган язучыларның берсе. Опанас Грай («Ак төннәр» повесте) разведкага киткән дусты Исмаилҗан өчен борчылып хәтта кошлар тавышын аермас була. «Мәңгелек кеше» романында төрле милләт кешеләре бер-берләренә сүзләре, карашлары, кылган эшләре белән ярдәм итешәләр. Сөләйман Уразматов белән Матвей Погорельцев дуслыгының тамырлары ерак тарихка китә («Сүнмәс утлар»). Сөләйман бервакытны Матвей өчен завод хуҗасы Яриковны мичкә ыргыта яза. Хәзер дә ул кияве Хәсәнгә каршы «атака»га үз үпкәсе янсә улы өчен түгел, ә Матвей дусты өчен ташлана.

Г. Әпсәләмов үзенең әсәрләрендә киң колачлы темалар күтәрә. Хикәяләү үзәгенә тарихи шәхесләрне куя. Аның иң соңгы әсәрләреннән берсе булган «Күк күкрәр» романының нигезенә В. И. Ленин Казанда яшәгән чор алына. Төп идеяне әсәрнең исеменә салу — язучының бер үзенчәлеге. Бу романда автор бөтен художество компонентларын бер максатка — Россия тормышындагы яшенле яңгыр көтелгән чорны сурәтләү, революциягә китерәчәк потенциаль көчләрне барлау максатына буйсындыра. Г. Әпсәләмов тарихи-революцион темага беренче тапкыр мөрәҗәгать итсә дә, роман аның моңа кадәр иҗат ителгән башка әсәрләре белән аһәңдәш. Төрле чор, төрле темалар, ә шулай да «Күк күкрәр» баштагы китапларда күзгатылган сөйләшүнең тирәнәйтелгән дәвамы.

Г. Әпсәләмов берәүләрне революциягә, икенчеләрне таркалуга, мораль череклеккә китергән тормыш агымын, аяусыз тарихи процессны әхлак һәм әдәп позицияләреннән торып тасвирлый. Татар авылының сыйнфый катламнары арту, капита-

листик мөнәсәбәтләр барлыкка килүне геройлары язмышы аша сурәтләп, бу тарихи процессның кешеләр холкында, әхлагында ничек чагылуын да күрсәтә.

Хикәяләү контрастка корыла. Болай эшләү язучыга кешенең үз-үзей тотышында, кыланмышында биологик нигез түгел, ә кайсы сыйныф вәкиле булуы, нинди социаль чыгыш ята диган фикерне үткәрергә мөмкинлек бирә. Шушы яктан алганда әсәрнең актуальлеге күзгә бәрелеп тора, чөнки буржуаз социологлар кешеләрнең яшәү рәвешен аларның сыйнфый чыгышларыннан аерып карарга, капитализм белән социализм дөньясындагы идея һәм мораль аермаларны шомартырга маташалар.

Ике Салабаев: Исмәт һәм Әбелмәних мисалында автор татар авылына капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керү аркасында халык массаларының ничек бүлгәләнүен күрсәтә. Материаль хәлләре аерылу белән бергә, калын кисәле сыйныф сафына баскан кешеләрнең әхлагы, холкы да тамырдан үзгәрә бара. Байлык тупларга омтылу аларны иң түбән адымнарга да этәрә. Акчаның исе юк диган принципны алга куеп, капиталларын ишәйтеп, алар котылгысыз рәвештә рухи хәерчелеккә, бушлыкка тәгәриләр.

Исмәт тә, Әбелмәних тә бер төптән, алар икесе дә Салабаевлар, ләкин бу кәүсәләр төрле якка авышып үскән. Исмәт Салабаев — исеме шаулаган Мәскәү сәүдәгәре, Әбелмәних — аның кучеры. Бу гаиләләрдә тормыш төрлечә агыла. Сәүдәгәр Исмәт өендә бәхет юк. Туганлык хисләрен алыш-биреш мөнәсәбәтләре алыштырган. Мораль тотрыклылыгын югалткан гаилә таркала бара. Җәннәт — яшь, чибәр, бай. Ләкин тормышының куанычы юк, чөнки бар күңеленә бер нәрсә — баю теләге дыңгычланып тула.

Бу романда көнкүрешне тасвирлауга зур урын бирелгән. Бирелә көнкүреш — геройның характеры ачыла ала торган типик дөнья. Характерларны ачу исә үзмаксат түгел — халыкларның тарихи язмышларын күрсәтү өчен кирәк. Карышкан кызлары буын-буынга горур һәм буйсынмас кызлар диган дан алган. Авылның бәренче байлары Хикмәй Салабаев һәм Шома Азюгы чибәр Айтүтәнең күңелен яуларга йөриләр. Кара эчле Шома Азюгы Айтүтәнең үзен түгел, ә ярлы-ябагайлар башлыгы малае Әбелмәнихне сайлавын еллар үткәч тә кичерә алмый, форсат чыгудан файдаланып, Әбелмәних Салабаев гаиләсен авылдан кудыртуга ирешә.

Шулай итеп, көнкүрештән башланган вакыйгалар сыйнфый мөнәсәбәтләргә әверелә. Вакыт җитү белән сыйнфый бәрелешләрнең большевиклар партиясе җитәкчелегендә бөтенхалык хәрәкәте дәрәҗәсенә җитүе, моңа төп шарт булган халыкның горур табигате романда, нигездә, хатын-кыз образлары аша тикшерелә. Монда без сәнгатьчә үткенәйтү элементын күрәбез. Айтүтәнең кызлары да кияү сайлаганда бары үз хисләре белән генә исәпләшәләр. Исмәт сүдәгәр гаиләсендә исә кызларны сөйгән кешеләренә түгел, алтын капчыкларына бирәләр. Вакыйгаларга салынган шушы фикерне тагын да куәтләр өчен Карышканнар нәселеннән бер кыз турында риваять сөйләнә. Риваятьтә аларның табигатенә хас сыйфатлар: кыюлык, хөр күңеллек, сөя белүләре сурәтләнә. Эшче Вали, Айтүтә, Җәннәт образлары да зур осталык белән иҗат ителгәннәр.

Романда сурәтләнгән вакыйгаларга динамика хас. Лирик чигенешләр тормышның гел үзгәреп торуын аңлатырга ярдәм итә. Тирән фәлсәфи публицистика да шушы ук фикерне үткәрүгә буйсындырылган. Каршы кую алымы да уңышлы кулланыла. Мәсәлән, Җәннәт өендәге күренеш. Ата белән кыз байлыкны бүлешә алмыйча бер-берсенең бугазларына ябышалар, ә бу вакытта табигатьтә яз тантана итә. Исмәтнең нәселе корыган, ә шул көнне эшче Валинең улы туа.

Киная алымы, табигатьне сурәтләү фәлсәфи яңгыраш белән сугарылган. Бу романның фәлсәфәсе — революциянең котылгысыз җиңүенә ышану.

Романның икенче кисәге әлеге фикернең логик дәвамы булып тора. Бу кисәктә инде Ульяновлар гаиләсе, рус интеллигенциясенең гомерләрен революциягә багышлаган менә диган уллары һәм кызлары турында сөйләнә. Ленинның әнисе образын автор бик яратып, зур җылылык белән иҗат итә. Ул Ульяновлар гаиләсендә хөкем сөргән үзара ихтирамны, җылылыкны оста сурәтли алган. Әбелмәних кучер гаиләсе һәм Ульяновлар гаиләсе үзләренең рухы, үзара теләктәш, сак кайгыртучан мөнәсәбәттә булу белән якын. Революционерларны халык белән интереслар уртаклыгы, көрәш максатының берлеге, уртак мораль сыйфатлар берләштерүен язу-

чы ышандырырлык итеп күрсәтә. Ленинның массалар белән элемтәсе турыдан-туры да, читләтеп тә ачыла. Ленин һәм аның әнисе образында халык характерының иң күркәм сыйфатлары чагыла.

Революционерларны сурәтләгәндә, язучы безнең игътибарны иң элек аларның халык бәхете өчен көрәш юлына аңлы рәвештә басуларына юнәлтә. Моны Эшче Вәли һәм башкалар мисалында күрсәтеп, Володя Ульянов мисалында иң зур художество югарылыгында бирә.

Идея-фикернең сурәтләнә торган материал характерына һәм язучының художество методына туры килүе — иҗади эшчәнлекнең бик мөһим ягы. Бу җәһәттән алганда, Г. Әпсәләмов материалны тоя һәм аны укучыга ничек тәкъдим итәргә кирәген нечкәләп белә торган язучылардан. Авторның Владимир Ильич Ленинның Казанда яшәгән чорын тасвирлап, аның революционер буларак формалашуын күзәтергә тырышуы тарихи позициядән дә, сәнгати күзлектән дә дәгъва тудырмый. Утыз еллык иҗат чорында формалашкан художество методы Г. Әпсәләмовның җитлеккән әдип булуын дәлилли.

Шул ук вакытта, әсәрнең идея төбәлеше дөрес булса да, аны, нигездә, автор хикәяләве һәм диалог аша гына үткәрү, Владимир Ульянов образының художество кыйммәтен берникадәр кимәтә төшә. Тарихи дөрес эчтәлек тулы канлы сәнгатьчә яңгыраш ала алмаган. Безнең карашка, моның сәбәбе — ихтыярсызданмы, түгелме, язучының документаль материаллар әсирлегеннән котыла алмавында. Романның соңгы өлешендә документальлек язучының иҗади күзаллавын, хыял ачышын басып киткән.

Ә тулаем алганда, «Күк күкрәр» — хәзерге татар прозасында вакыйга булырлык роман. Бөек юлбашчы образын, үз халкының тарихи үткәнен сурәтләүгә Г. Әпсәләмов яңача, атап әйткәндә, тарих сабаклары позициясеннән килә. Автор Россия тормышын сурәтләгәндә революция алды чорын, ул чактагы иҗтимагый стройның кешелексезлеген ачу, шул стройны җимерәчәк көчләрне барлау позициясенә баса. Бөтенсоюз ленинианасына Г. Әпсәләмов керткән яңалык, безнең карашка, Ленинның, революционерларның татар халкының иң яхшы вәкилләре белән бәйләнешын нәкъ менә әхлакый аспектта ачудан гыйбарәт.

Г. Әпсәләмовның иҗат юлына анализны йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: нигездә документаль материалга таянып язылган бу әсәрләр әдәбиятны, аның сыйнфый эчтәлеген һәм милли формасын үстерү чыганагы булып чынбарлык үзе хезмәт итә дигән фикерне раслыйлар.

Һәр язган әсәр вакыйга була алмый. Ләкин язучының Бөек Ватан сугышында халык батырлыгын мәңгеләштерә алуы, ә Сөләйман Уразмәтов һәм Янгура образлары аша хәзерге җәмгыятьнең эчен-тышын бөтен чынлыгында, уңай һәм тискәре яклардан сурәтләве Әпсәләмов турында үз иҗатында заманының төп тенденцияләрен ачкан зур язучы дип әйтергә мөмкинлек бирә. Ә хатын-кыз образлары! Аның китапларында татар хатын-кызы бөтенләй яңа яклары белән балкыды: бәхет ташып торган, шат күңелле Нурия, тәвәккәл һәм принципиаль Мәрьям, үз йөрәгендә утлар дөрләгәндә дә башкаларга карата ягымлы, киң күңелле булырга көч таба алган Гөлшәһидә һ. б. лар...

Г. Әпсәләмов иҗаты күп милләтле совет әдәбиятына сизелерлек өлеш булып керде. Яңа җәмгыять кешесен, аның рухи үсешен күрсәткән әлеге әсәрләр, беренчедән, күтәргән проблемаларының актуальлеге һәм тормыш материалларының киңлеге ягыннан, икенчедән, басылган китапларының тиражы, тәрҗемәләр саны ягыннан һәм, ниһаять, күп укылулары белән милли әдәбият кысаларына гына сыешмый.

Г. Әпсәләмов иҗатының матур традицияләре хәзерге татар язучылары әсәрләрендә дә дәвам итә. Көн таләбен, тормышның төп үсеш тенденцияләрен яхшы аңлап, замандашларыбызның рухи дөньясын баетуга, кешеләр арасындагы яңа, матур мөнәсәбәтләр тантанасына алар үз өлешләрен кертәләр.

Ринат Мөхәммәдиев

# БАШКА БЕРНИ ДӘ КИРӘКМИ

Имештерме-юктырмы, күбәләк кар явып торган кышкы бер кичтә, эңгер-меңгер чак булдымы икән, шагыйрь Сибгат Хәким Казанның елга читенә елышкан тын урамнары буйлап һава сулап йөри икән. Табигый инде, башын бераз кырын салып, югарырак чөеп, үз алдына шигырь сөйләп бара чакн:

**Туып үскән шушы җирнең ямен**
**Алыштырмый икән һичнәрсәң.**
**Башка берни дә кирәкми...,**

Ул да булмаган, арттан килгән берәү Казан мехчылары теккән җылы, йомшак бүрекне аның башыннан салдырып алган. Ә шагыйрьнең моңарга исе дә китми янәсе, көйләп үк җибәргән:

**Башка берни дә кирәкми,**
**Үзем чапкан печәннәрне**
**Бер түйганчы иснәсәм...**



һәм шунда гына, башын бора төшеп, самими һәм мөлаем бер елмаю белән: «Ша-ярт-ма Хәсән...»,— дип әйтеп әйткән ди. Артыннан куып җиткән Хәсән Туфан шулай шаярта дип уйлаган инде. Ныклабрак караса, ни күрсен, бүрек тоткан бер яшүсмер инде күздән үк югалып бара имеш...

Мондый хәлнең булуыннан булмавы яхшырактыр. Әмма шул хакта сорап сүз кузгаттыңмы, шагыйрьнең күзләреннән нур бөркелә, рәхәтләнеп бер елмаеп куя ул. Чөнки әлегедәй мәзәкләрне бер дә юктан гына уйлап чыгармыйлар. Җырның сүзләре, моңы күңеленә кермәгән кеше болай шаяртмас. Димәк, аның күңелендә бөреләнгән хисләр башкалар күңелендә урын тапкан. Шагыйрь өчен шуны тоюдан да рәхәтрәк ни булырга мөмкин.

Ә ул әсәр исә С. Хәким өчен гадәти бер шигырь генә түгел. «Шагыйрьнең гомер буе күңелдә йөрткән, үзенә бик кадерле хисләре була, алар туып-үскән җирең-туфрагың белән бәйле хисләр. Күңелне алар һәрвакыт җирсетеп тора, бигрәк тә туган якта, бигрәк тә июнь печәннәре җиткән вакытларда ул хисләр җирси, болын чәчәкләре өстеннән йөгергән дулкыннар аз гына кагылу белән күңел ташый... Минем шундый җырларның берсе — «Башка берни дә кирәкми»,— дип яза автор.

«Башка берни дә кирәкми»... Хисләрнең агышын, юк, әйтерсең гомернең агышын кинәт туктата-туктата уйланырга мәҗбүр итә торган юллар... Үзең чапкан печәннәрнең исе, үзең тапкан чишмәләрнең суы һәм дусларның җылы карашы... Бик аз белән канәгатьләнмиме соң шагыйрь, җыр җыйнак чыксын, рифмасы, ритмы төзек булсын өчен генә сайлап китерелмәгәнме болар? Әлеге әсәрне укыганда янсә ишеткәндә минем күңелгә дә бер генә килмәде мондый уйлар. Шагыйрьгә болар гына аз, шагыйрь күңеленә бөтен дөнья, Җирнең, кешеләрнең барлык борчу-проблемалары сыйсын дип, сөрән саласы килгән чаклар да булмады түгел. Әлбәттә, сыярга тиеш! Печән исе, чишмә суы тәме, дусларның җылы мөнәсәбәте белән генә канәгатьләнеп яшәгән кеше була ди мени, адәм әйтеп кеше ышанмас!..

Ә әлеге җырның, шигырьнең көче, илаһилыгы шунда ки, шагыйрь анда гадәти һәм гади генә сүзләр, детальләр аша кеше җанын Җиргә, Туган илгә, туып үскән якларга һәм халыкка бәйләп, тартып торган рухиятне ачуга ирешкән. Иң гадәти детальләр аша гаять олы гомумиләштерүләргә юл салынган. Җанга рәхәт биреп борыннарны кытыклаган коры печән исе туган җирнең, Идел һәм Кама буйларының ямьлелеген һәм җанга якынлыгын сынландыра түгелмени. Урман һәм болын киңлекләрендә покосларда яткан печән йөрәкләргә, беләкләргә дәрт өстәп канатландыргандай итә. Ирексездән, карашлар югарыга — каурый болытларга янсә алга — офыклар киңлегенә юнәлә. Иминлек һәм изгелек, ихласлык һәм сафлыкның бар нәрсәдән өстенрәк булуын шул чакта аеруча кискенрәк тоясың. Җиләк яфракларын һәм покосларны гына түгел, бөтен Җирне, зәңгәр күкне кочаклыйсы, сыйпап узасы килә шул чакны. Һәм алай гынамы әле...

Җыр һәм шигырь юлларына салынган тирән хисләрне шулай прозага күчереп, өлешчә генә булса да шәрехләргә омтылган өчен, әлбәттә, гафу үтенәм. Сүз, барыннан да элек, шигырьнең һәр очракта да шигъри хискә нигезләнгән булырга тиешлеге хакында бара. Шигырьнең нигезе шагыйрьнең җанында, хисләрендә, сүзләр аша чагылыш тапкан ихлас тойгыларында. Нәкъ менә шуңардан чыгып та күптөрле тема һәм проблемаларга турыдан-туры мөнәсәбәттә булган олы иҗатны — С. Хәким шигъриятен һичнинди төркемнәргә таркатмыйча бербөтен буларак күзалларга мөмкин. Һәм шул очракта сүзебезнең башы булган «Башка берни дә кирәкми» шигыренең шагыйрь өчен нинди әһәмиятле әсәр булуы аңлашылса кирәк. Бөтен юллар да Римга илтә дигәндәй, шагыйрь күңелендәге бөтен кайнарлык һәм хисләр ташкыны да туган як болыннарындагы печән, аңа гомере буе шифа булган салкын чишмә һәм җанга якын дусларына барып тоташа. Төп чыганак шуларда. Туган җиргә, Ватанга һәм бөтен кешелеккә булган сөю хисләренең башлангычы ничек кенә булмасын әлеге дә баягы яшьлек таңында чабылган печәннәргә, сабый чаклардан ук татыган чишмә суларына, үсмер елларның тәүге дусларына кайтып төшә.

**Бер тирәдә гел әйләнде гомер,**
**Бер тирәдә шуңа — бар моңым...**

— кебек юллар да нәкъ шул хакта сөйләп, шагыйрьнең ихластан ачылуы булып тора.

Шул урында укучы күңелендә сорау туарга мөмкин: Сибгат Хәким шәхес буларак та, иҗатында да тынгысыз шагыйрь — өзлексез эзләнә, гомер юлы да гел Казан артында гына үтмәгән... Ә без аның иҗат колачын тар рамкаларда чикләп куймыйбызмы? Әйе, шагыйрь иҗаты үзенең ябалдашларын гаять киң җәйгән, ул КамАЗ, нефть якларын колачлый, Татарстан чикләрен үтеп тугандаш халыклар яшәгән социалистик Ватан кырлары буйлап еракларга китә. Ул гына да түгел, Ржев урманнарында, Курск дугасында утта чарланган шагыйрь сугыш эзләре белән Берлинга, Германиягә ук барып чыга — бөтен Европага мөрәҗәгать итә. Үзе исеменнән генә түгел, батырлыкны кәрәштә аулаган халкы исеменнән, Җәлил, Кутуй, Ф. Кәрим, Н. Баян кебек каһарман каләмдәшләре исеменнән дә. Ябалдашлар киң, шактый киң җәелгән, әмма тамырлар — Казан артында, шагыйрьне чиксез зур дөньяга чыгарган Күлле Киме авылында. Шагыйрь бөтен булганы белән шул җиргә, туып-үскән якларга берекккән — «башка берни дә кирәкми»:

**Мин синеке, авыл, мин синеке,**
**Мин синеке туган көнемнән...**

Ябалдашларның киң һәм ныклыгы да әлеге тамырларның тирән һәм таза булулары белән аңлатыла, димәк. Масштаблы шәхес, күңеленә дөнья һәм кешелекнең бар борчу-мәшәкатен сыйдыра, колачлый алган шәхес тема хакында уйлап карамаганда да корыны бушка кайтарып маташмас. Гомере буе туган авылы турында, үзенең шәхси кичерешләре хакында язып та ул беркайчан да кабатланмас. Чөнки туган җирнең булсын, шәхеснең булсын, әлегәчә ачылмаган моң чишмәләре чиксез, аларны табарга һәм чумырып ала белергә генә кирәк. Сибгат Хәким, барыннан да элек, нәкъ менә үз-үзенә, туган-үскән җиренә булган шундый тугрылыклылыгы белән сокландыра.

Каршымда өстәл өсте тулы китаплар. Бай тормыш һәм иҗат юлын намус белән үткән өлкән шагыйрьнең шигырь һәм поэмалары. Язылу еллары төрле-төрле — иҗатның төрле этапларында, татар шигъриятендә төрле агым һәм тенденцияләр өстенлек иткән вакытларда туган әсәрләр. Әдәби камиллек ягыннан да үсеш, үзгәреш ачык тоемлана. Әмма, ничек кенә булмасын, ул әсәрләрнең бер үк каләм аша иканлеге, бер шагыйрь йөрәге аша үзганлыгы күзгә ташланып тора. Туган якны өзгәләнеп ярату бар нәрсәдән өстенрәк. Иң самими һәм ихлас юлларны шул хис тудыра:

**Әкият кебек матур Казан арты... [1938 ел]**

**Уяна иркен болыннар,**<br>
**Ачыла гөл керфекләре;**<br>
**Тибрәнеп яфрак өстендә**<br>
**Уйный чык бөртекләре... [1947]**

**Монда да язмасаң: сихри көч**<br>
**Ургыла, туктатып буламы;**<br>
**Җиремнең төбенә тоташкан**<br>
**Мин эчкән чишмәнең улагы... [1961]**

**Баш куеп искән җилләргә,**<br>
**Йөрим кырда куанып;**<br>
**Йөрим арышларым белән**<br>
**Мин бергә дулкынланып... [1974]**

Туган җир һәм аның кырыс та, юмарт та була белгән табигате... Ул шагыйрьне берөзлексез иҗатка рухландырып, шигърияткә, шигъри җанлы туган халкына якынайтып тора кебек. Шуңадыр, шагыйрь күңелен нинди генә хис һәм борчулар биләмәсен, ул кайтып-кайтып аңарга мөрәҗәгать итә. Үз иткән табигате, урманы һәм кырларыннан башка яшәве һәм иҗатының да яме булмас кебек. Әмма шул ук вакытта Сибгат Хәкимне шигърияттә пейзажчы дип тә әйтеп булмас. Чөнки аның әсәрләре арасыннан бары табигать гүзәллеген сынландыруга, урман-кырларның шигъри матурлыгын аерым алып сурәтләүгә кайтып калган этюдлар табу җиңел түгел. Табигать кочагында да шагыйрь үзенең шигъри хисләреннән аерым яши алмый. Бер читкә елышып тын гына, тып-тын гына дөнья матурлыгын күзәтергә тынгысыз йөрәк ирек бирми — һәр мизгелдә аның тибеше сизелеп тора. «Тугайларга барсам, тургай кебек җырым очар төсле пырхылдап» сыман юллар, мөгаен, табигатька булган әлеге мөнәсәбәтне чагылдыралар.

Сүз иярә сүз чыгып, шагыйрьне «тынгысыз йөрәкле» дигелгән. Сибгат Хәким хакында гадәттә сабыр, тыныч холыклы дип язалар иде. Әледән-әле урынлы-урынсыз кулланылышта булган бу сүзтезмага мөрәҗәгать итеп ялгышмадыммы икән?.. Мөгаен, юктыр. Тормышта бер карашка артык сабыр һәм тыныч кына булып тоелган шагыйрь иҗатта, чынлап та, туры мәгънәсендә тынгысыз йөрәкле. Моңарга мисалны үтелгән юллар һәм кичерелгән борчу-уйлардан күпләп китерергә мөмкин. Шагыйрьнең кайсы гына әсәрен алып карама, анда ирешелгән белән канәгатьләнүнең чыраен да күрмәссең — туган якта, илдә һәм планетада борчуларының чиге юк. Шуңадыр табигатьне дә ул тын чагында, моңсу вакытта түгел, кагыйдә буларак, шаулап-гөрләп торган җанлы, тулы канлы дөнья халәтендә үз итә, ярата төшә:

Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Селкенмәгән агач калмасын;
Сукмакларын уят, аланнарын,
Кошчыкларын уят аннан соң...

Сабыр һәм тыныч холыклы шагыйрь йөрәге табигатьнең генә түгел, дөнья һәм тормышның иң кайнар ноктасында, чор борчуларының кыл уртасында булырга күнеккән. Нәкъ менә шуңа да Казан арты кырлары, урманнарын җырлап туймас күңел Туган ил һәм республиканың индустриаль районнарына, заман проблемалары әверуча кискен рәвештә очрашкан төбәкләргә ашкына. Һәм шул очрашулар, яңа тәэсирләр нәтиҗәсе буларак яңа, җитди әсәрләр языла. Әйтик, Татарстан нефтьчеләренең фидакарь хезмәте һәм алар тапкан нефтьнең илебез чикләрен үтеп башка халык һәм дәүләтләргә җылылык бирүе шагыйрьне «Үрләр аша» поэмасы һәм күп кенә шигырьләр язарга рухландыра. Республикабызда автомобиль гиганты КамАЗ төзелә дигән хәбәр шулай ук шагыйрь күңеленә җитди бер чакыру, халык һәм партия наказы булып керә. Арча кырларында башакланып килгән арышларын калдырып, хыялында бәлки аларны да алып, шагыйрь чал Кама ярларына — Чаллыга барып чыга. Хисләрнең, тойгыларның чиге юк. Монда тарих белән заман кавышкан, кырлар белән гигант төзелеш янәшә булган җирдә, йөзләгән милләт вәкиле бер максат, бер омтылыш белән янган җирдә инде яшәү һәм иҗат ритмы күптән формалашкан өлкән шагыйрь югалып ук калыр төсле.

Терелде күк Чаллы туфрагы,
Гасырларның данлы туфрагы:
Чаллы, чалгы, печән исте чагы,
Арышларның, камышларның шавы...

Әмма вакыйга һәм күренешләрнең тирәнлегенә, асыл мәгънәсенә төшми туктала, җанына тынгылык таба белмәгән әдип бу очракта да үзенекен итеп максатына ирешә. Нәтиҗәдә, Сибгат Хәким һәммә каләмдәшләреннән элегрәк, яшьләрдән дә өлгеррәк булып «Дәверләр капкасы» поэмасын тәмамлый. «Дәверләр капкасы»...— әсәрнең исемендә үк тирән мәгънә, күп кырлы шигъри ассоциацияләргә нигез булырлык шигъри җегәр бар. Ул җегәр ташып тора. Шуңадыр поэма, конкрет еллар проблемасына төбәп язылган булуына да карамастан, тоныклана, шигъри тәэсир итү көчен югалта бармады, вакыт томаннарын таратып бүгенге көн һәм КамАЗ белән бергә туктаусыз алга хәрәкәт итте. Әлеге дәвамлылыкның асылы шагыйрьнең иҗат эшенә булган мөнәсәбәте, әлеге дә баягы ихласлылыгы белән аңлатылса кирәк. Күңелдән чыккан гына күңелләргә барып җитә дигән хакыйкать үзенекен итә.

Юк, С. Хәкимне бүгенге индустрия шагыйре дип исбатларга җыену түгел бу. «Үрләр аша» һәм «Дәверләр капкасы» поэмаларының бу өлкәдә вакыйга булган әсәрләр икәнлеген таныган тәкъдирдә дә андый нәтиҗә ясау хата булыр иде. Шагыйрь бөтен барлыгы белән авылныкы, әйтерсең, туган-үскән якларына бәйләп куелган, иген кырларын, тугайларын бер генә минутка да онытып тора алмый. Зур төзелеш һәм ерак җирләрдән ул туп-туры җырлап туймас үз төбәгенә яңадан кайтып төшә. Шунда, бары шунда гына үзенең табигый халәтенә ирешеп, кырлар белән, игенче якташлары белән бер булып иҗат дөньясына чума. Ул — шушы кырларның хуҗасы, гражданины. Ә кырларга, иген кырларына күп, бик күп нәрсә сыя. Икмәк үскән җирдә, иген иккән кешеләр арасында ил һәм Ватанның һәр адымы үзгә бер әһәмияткә ия вакыйга сыман кабул ителә. Монда бөтен дөнья, кешелекнең борчуларына урын бар. Башаклар шавы һәм зәңгәр рәшә уйнаган кырларга сыйган җыр һәм моң күңелләргә сыеша алмый бәреп чыгадыр төсле. «Бөтенләем белән Җирнеке мин, минем барлык нәсел-нәсәбем — игенчеләр. Җирдән тертеп чыга һәрбер юлым, һәрбер әсәрем»,— дип очраклы рәвештә генә язмый шагыйрь. Һәм ул үзенең иң изге бурычы итеп шушы буыннан буынга мирас булып килгән изге хезмәт — игенче хезмәтенә тугрылыклы калуны саный. Шуңа да аның тормышчан һәм тулы канлы образлары арасында авыл хезмәт ияләре — бөтен тормыш-көнкүреше җир белән, туган җир язмышы белән тыгыз бәйләнгән язмышлар гади һәм гыйбрәтле

булулары белән аерылып тора. Игенче белән янәшәдә авыл өчен бигрәк тә характерлы һөнәр ияләре — көтүче, сыер савучы, балта остасы һәм бакчачы кебек гадилекләрендә гүзәл булган образлар аз очрамый С. Хәким әсәрләрендә. Һәм ул аларны ниндидер сырлау һәм купшы охшату, ялтыравык эпитетлар ярдәмендә түгел, үзләре кебек үк гади, шул гадилекләрендә тирән мәгънә йөрткән сүзләр аша күз алдына китереп бастыра.

Гыйльметдин ясый ул
Тәрәзә рамнары,
Керә дә утыра
Авылның таңнары.

Югыйсә, гадәти бер җөмлә кебек кенә. Ритм да гади сөйләмдәгедәй, рифмалашучы сүзләр дә табигый рәвештә очраклы гына туры килгәндер сыман. Ә образ, тәрәзә рамнары ясаучы оста образы гөлт итеп күз алдына килеп баса. Аның үз һөнәре остасы булуы һәм кеше буларак та кояшлы авыл иртәседәй ачык йөзле, киң күңелле зат булуы тоемланып өлгерә.

Гыйльметдиндәй беренче очрашуга ук күңелгә кереп калган җанлы һәм типик образлар С. Хәким әсәрләрендә очраклы күренеш түгел, билгеле. Шулар арасыннан тагын, укучы буларак, миңа аеруча кадерле тоелган, үз булган Сәләхине искә алып узасы килә. Күләм ягыннан җыйнак кына «Сары капкалы йорт» поэмасыннан ул Сәләхи. Аның язмышы бер карашка гадәти һәм икенче карасаң гыйбрәтле дә: яшьлек елларында туган авылында колхоз төзүгә җан атып йөргән, тәвәккәллеге һәм дуамаллыгы да җитәрлек булган, мутлыктан да коры калмаган авыл егете, җир хуҗасы. Яшәүнең төмен, дөньяның ямен дә таный белгән шул егет өзелеп яраткан кызы артыннан китеп авылдан, кырларыннан читтә яшәргә мәҗбүр була. Ә инде яңадан авылына әйләнеп кайткач, югалткан мәхәббәтен юксынып мы, сары капкалы йорт җиткереп тормыш итә башлый. Үз язмышын туган-үскән якларыннан башка күз алдына да китерә алмаган Сәләхи соңыннан Ватанын саклап башын сала. Гадәти язмыш, әмма сокландыргыч һәм тетрәндергеч образ!

«Сары капкалы йорт»ны укыганда әлеге җор табигатьле авыл кешесенең гомеренә туры килгән вакыйгаларны кичереп күңелгә моң тула. Ил намусы һәм бәйсезлек өчен үлгән солдат турындагы истәлеккә сары төскә буялган капка өстәмә бер сагыш төсмере биреп тора. Һәм шул сары капка, сагыш һәм моңнан да көчлерәк булып күз алдына келт итә дә Сәләхи, яши һәм сөя дә белгән авыл кешесе килеп баса. Сагышһардан күп тапкырлар көчлерәк, өстенрәк булып килә аның образы:

Өй артында, ындыр читәненә
Башын куеп үсә арышлар...
Сәләхинең үзен биергә дәш:
Аягыннан оча галошлар,
Җиргә оча иңгә элгән пинжәк.
Бии ярсып, бии... оекчан.
Төрле очтан, төрле тыкрыклардан
Кил, монда кил, ялгыз боексаң...

«Кызык кеше... гаҗәп матур кеше, үзеннән ямь җиргә өстәгән... Сөер кеше... гомердә бер тапкыр рәсемгә ул хәтта төшмәгән...» бары шушы образы, шушы моң һәм күңел җылылыгы белән өртелгән якты һәм нурлы поэмасы өчен генә дә С. Хәкимне шагыйрь, халык күңеленә үтеп кергән шагыйрь дип санарга мөмкин булыр иде...

Халык күңеле дигәннән, шагыйрь бу яктан чын мәгънәсендә сирәк очрый торган бәхеткә ия. Чөнки аның сүзләренә язылган җырларны халык, кагыйдә буларак, яратып һәм үз итеп каршы ала гына түгел, ә күңеленнән чыккан үз сүзләре сыман йөрәгенә сала. Әйтик, «Юксыну», «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда», «Кем уйлаган», «Әнкеләр» шундый олы ихтирам һәм бәхеткә лаек әсәрләр. «Иң бәхетле җыр — шагыйрьдән халык арасына күчкән җыр,— ди шагыйрь үзе дә.— Авылда мин күпме таңнар аттырдым, күпме җыр тыңладым. Минем иҗатымда тирән эз калдырган нәр-



*Сибгат Хәким (уңда) һәм Әхмәт Фәйзи.*

сә авылның табигате, киң күңелле кешеләре булды. Мин шул беркатлы, нечкә хисле гади кешеләрне яраттым, җырларын яраттым. Халкыбызның бөтен әйтергә теләгән сүзе — аның җырларында».

С. Хәкимнең халыклашып киткән янсә халык арасында киң таралган әлеге һәм башка күп кенә җырларына һәркемнең үз мөнәсәбәте булырга мөмкин. Кемнәрнеңдер тормыш юлында ул җырлар билгеле бер эз калдырып, истәлекләр чыганагы рәвешендә дә яшәве бик ихтимал. Шагыйрь үзенең бер язмасында күңелләренә хуш килгән җыр хөрмәтенә авылдашларының салкын сулы бер чишмәгә Фазыл чишмәсе дип исем кушуы хакында язган иде. Бу факт очраклы рәвештә генә кызыксыну уятмады миндә, чөнки Казан артыннан шактый читтә булган туган авылым Кече Кирмәндә дә шигъри матурлыкка ия яр буеннан бәреп чыккан шифалы суны Фазыл чишмәсе дип атыйлар иде. Һәм без, яланаяклы малайлар, җиләктән кайтканда шул чишмә читенә утырып хәл ала, җыйган җиләкләребезне күрсәтеп мактаныша һәм тамак ялгый идек. Фазыл чишмәсенең суын йотлыгып-йотлыгып эчкән авылдашлар шул исемдәге җырның да нәкъ безнең авылда чыгарылган булуына һәм нәкъ менә шул чишмә хакында икәнлегенә аз гына да шикләнми иде кебек. Соңрак, бу җырның сүзләрен шагыйрь С. Хәким язганлыгын белгәч тә, берара моның шулай икәнлегенә ышанасы килми йөрдем. Ничек кенә булмасын, әле дә «Фазыл чишмәсе»н ишетүгә күз алдына туган авылымның шул шигъри почмагы келт итеп искә төшә дә куя. Һәм, миңа калса, шундый ук исем белән аталып йөртелгән чишмәләр әле байтак булсалар кирәк, чөнки шигырь һәм җырга аеруча сизгер һәм игътибарлы халкыбыз күңеленә кергән моңны элек-электән мәңгеләштерергә һәвәс булган. Ә «Фазыл чишмәсе» исә татар халкының шигъри табигатен, оптимистик рухын һәм сүнмәс дәртен чагылдырып килүдә чынлап та әйтеп бетергесез тирәнлеккә ирешкән әсәр. Бу урында мисал итеп аның сүзләрен китереп тору да кирәкмәстер, алар берсе артыннан икенчесе тезелешеп безнең күңелләрдә үк чылтырап ага түгелмени...

Һәр җырның язылу тарихы булган кебек үз язмышы да була, күрәмсең. Шул уңайдан С. Хәким сүзләренә язылган «Сагыну» җырының, фольклорчылар раславына караганда, халык арасында 32 варианты яшәве билгеле. Бу исә ул әсәрнең чын мәгънәсендә халыклашып, телдән-телгә, күңелдән-күңелгә күчеп йөргән җәүһәргә әйләнүе турында сөйли торган факт. Һәм шунысы характерлы, әлегедәй фактлар шагыйрь иҗатында ялгыз түгелләр.

Мисал өчен, С. Хәким иҗатында калкулык булып торган икенче бер әсәр — «Күңелем Ленин белән сөйләшә»не хәтергә алмый узу мөмкин түгел. Әһәмиятле һәм житди темага язылган җыр. Һәм, ни гаҗәп, сирәк очрый торган популярлык казанган җыр. Монда тема, халыкның даһи Ленинга булган мөнәсәбәте да үзенекен итәдер, бәлки. Әмма җырның популярлыгы моңарга гына кайтып калмый, әлбәттә. Шул изге темага язылып та әллә ни уңыш казана алмаган әсәрләрнең булуы да яшерен-батырын түгел ич. Хикмәт — темада түгел, шагыйрьнең әлеге изге темага булган мөнәсәбәтендә. Ә ул мөнәсәбәт, барыннан да элек, халык рухына нигезләнгән шигъри ихласлылыктан гыйбарәт.

**Казан әле, Казан уянмаган,**
**Яфрак белән яфрак серләшә.**
**Йөрим таңда Ленин урамында**
**Күңелем Ленин белән сөйләшә...**

Бу юлларның тәнкыйть мәкаләләре һәм хезмәтләрдә, мисал буларак, беренче тапкыр файдаланылуы түгел, билгеле. Алар, ирексездән, үзләре үк күңелдән сирпелеп торалар, шуңа да яңадан кайтып-кайтып көйлисе, искә аласы килеп тора ул җырны.

Һич икеләнми расларга мөмкин, «Күңелем Ленин белән сөйләшә» — татар ленинианасының иң камил үрнәкләреннән берсе. Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы белән бер сафта искә алына торган әсәр. Дөрес, шушы урында «Ленин фәрманы белән», «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты», «Баһавиның моңы» кебек поэмалар һәм байтак кына шигырьләрне истә тотып, даһи Ленин темасының шагыйрь иҗатында зерым игътибарга лаек үзгә бер урын алып торуын да искәртү урынлы булыр. Һәм әлеге әсәрләрнең һәммәсенә характерлы булып, аларны бергә туплап торган сыйфат — ул, әлеге дә баягы, халык рухына нигезләнгән ихласлылык. Юк, мин дә Ленин турында языйм әле дип кенә алынмаган шагыйрь, бөтен гомер юлы дәвамында күңеленә тыңгылык бирмичә тупланып килгән хисләре сыеша алмый үзләре ташып чыккандыр кебек. Ленин исеменең бөеклеген раслау, мең кабат исбатланганны кабатлау да түгел, үзе һәм авылдашлары исеменнән, якташлары һәм халык исеменнән аның даһи образына булган ихлас мөнәсәбәтне ачып бирүдә шагыйрьнең максаты. Бу очракта да ул үзенә югары пьедесталлар дәгъва итми, авыл һәм кырлар җырчысы, Күлле Кимедә тамыр җибәргән татар шагыйре булып кала. Ә бит уйлап карасаң, чынлап та шагыйрь өчен бернинди өстәмә ясану, гражданин буларак, ихласлыктан тыш, үзе әйткәндәй, «башка берни дә кирәкми» икән...

Сибгат Хәким иҗатын тулаем күз алдына китергәндә, әйтеп кителгәнчә, шагыйрьнең даһи Ленин образына булган игътибары бер калкулык сыман үзенә җәлеп итеп тора. Һәм шунда ук, янәшәдә генә Тукай калкулыгы... Шагыйрь иҗатында һәм тормышында Тукай шигърияте һәм шәхесенә ни дәрәҗәдә зур әһәмият бирелүе, бу исемнең С. Хәким өчен ни дәрәҗәдә мәгънәле булы хакында шулай ук күпне әйтергә мөмкин булыр иде. Әмма бу очракта шагыйрьнең үз фикерләрен китерү бермәбер уңышлырак булыр кебек: «Тукай мине халык рухына алып керде, үз җиремә, үз телемә бик нык бәйләде... Тукайлар минем өчен бары тема гына түгел...» Әйе, Тукай образына булган даими игътибар да турыдан-туры шагыйрьне иҗатка рухландырып торган төп чыганак, үзәк тамырга барып тоташа. Туган якка бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт, туган җир һәм Ватанга, халыкка ахыргача бирелгәнлектән гыйбарәт булган шул нигез Тукай һәм Җәлил, Такташ һәм Туфаннар яшәү үрнәгеннән аерылгысыз.

**Әти — Әтнә базарыннан.—**
**Бәйрәм!**
**Чана башын тизрәк актардым.**
**Ат печәне, салам арасыннан,**
**Арасыннан чиста ак карның**
**Көмәч чыкты, китап — Тукай чыкты.**
**Әкиятләре белән, кар белән**
**Тукай керде өйгә, казанда аш,**
**Бөтен дөнья тулган пар белән...**

Әнә шундый чын мәгънәсендә җаныңны үзенә тартып алырга сәләтле юллар белән башлана шагыйрьнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы, әнә шундый җылы һәм якты истәлек булып сакланган шагыйрь күңелендә Тукай шигырьләре белән тәүге очрашуы. Һәм бу очрашу шул кадәр урынлы, озын гомерле булып чыга — әле дә булса С. Хәким үзенең һәр адымын Тукай белән үлчи дисәк һич арттыру булмас. Үзен халык рухына алып кергән остазы исеме шагыйрь өчен туган җир, Ватан, халык һәм шигърият кебек изге төшенчәләрдән аерылгысыз яши.

**Анда ул.**
**Анда ул утларның**
**Тукайлар яшьлектә якканы.**
**Кайда да нәрәкта, нәрәкта,**

Төшләргә гел кереп йөдәтә,
Нигә соң,
Нигә соң бу Кырлай яклары!

Шушы юллар безне яңадан шагыйрьләр бишеге булган Казан артына — Кырлай һәм Кулле Киме якларына алып кайта. Анда бер карашка гадәти генә, хәтта кырысрак та тоелган табигать шартларында ил тоткасы — иген өчен көрәш дәвам итә. Кырда комбайннар, юлда тузан, һаваларда тургай. Офыкларда зәңгәр рәшә уйный:

Үрләре дә зәңгәр дулкын-дулкын,
Ул үрләрнең чиге кайда соң!
Башка берни дә кирәкми...

Колак төбендә генә яңгырап алган җырның көе һәм сүзләре дә хисләрнең тәмам төйнәлеп җиткән шул төшендә, кадерле, газаплы, татлы хисләрнең нәкъ шул төшендә кискен борылыш ясый, аннан тагын туган җир кырлары, болыннары буйлап салмак кына агыла башлый. Җыр дәвам итә...

# ЗӨБӘРҖӘТ, АЛТЫННАРЫҢ!..

Сибгат ага Хәким «Зөбәрҗәт, алтыннарың» исемле шигырендә (1938 ел) болай дип язган иде:

Йолдызлар булып кабынды
Мәхәббәт ялкыннары.
Кирәкми, бер якта торсын
Зөбәрҗәт, алтыннарың.

Бер строфада күпме шигърият: йолдыз, кабыну, мәхәббәт, ялкын, зөбәрҗәт, алтын. Алар җирдәге мәхәббәт турында җырлый һәм шул ук вакытта синең күңелеңне дә йолдызлар иле белән бәйли. Бу мәхәббәт хисе барлык зөбәрҗәт, алтыннардан кыйммәт — чөнки шундый ихлас, кайнар сөюне Ватан биргән. Әнә кайда шагыйрь җырларының чишмәсе-хәзинәсе. Поэтик көч, һәр сүзнең эчке мәгънәсен, стилистик-эмоциональ төсмерен, образлылык, сурәтлелек нигезен, эстетик сыйфатын аңлау җәһәтеннән караганда, әлеге чагыштыру әсәр тукымасында матур бизәк, тышкы эффект өчен кулланылмаган. Бу традицион образ-символ ясаучы тел чаралары шагыйрьнең күңел поэтикасын, рухи халәтен, эчке дөньясын күрсәтү өчен файдаланылган. «Кирәкми, бер якта торсын»,— дип, гади генә әйтүдә дә күпме шигърият, тирән мәгънә!

Табып әйтелгән сүз алтыннан ким булмас, ди халык. Сүзне халык зөбәрҗәт, энҗе-мәрҗән, гәүһәр кебек затлы әйберләр белән чагыштыра. Поэзия әнә шул «алтын», «зөбәрҗәт», «энҗе-мәрҗән»нәрне эзләп, табып, акыл һәм йөрәк белән анализлап, аннары әсәр тукымасына җыйный белүдән туа. Бер тел чарасына «яшел чирәм» җәеп, икенчесенә каш җыерып, түбәнсетеп карау ярамый. Мәсьәлә телнең барлык элементларына, беренче карашка хәтта шигърият зәвыгына туры килмәс кебекләренә дә, әсәр тукымасында хаклы урын бирә белүдә. Моның соклангыч үрнәкләрен поэзиядә Г. Тукай эшләгән иде. С. Хәким дә теләсә нинди тел чарасын поэзия рухына килештерә белә. Тикмәстән, үткәргәчтен, түнгәләгән кебек сүзләр аерым алганда поэзия өчен һич тә отышлы түгел кебек. Әмма «Мине сөйсәң», «Пар ат», «Кысла һәм бака» исемле әсәрләрендә С. Хәким аларга бик лаеклы стилистик «паспорт» бирә. Бу телебезнең ерак гасырлар төпкелендә туган, хәзер инде «модадан» чыгып баручы тел формаларына да зур ихтирам, кадер-хөрмәт, гаҗә-

еп бер мөкиббәнлек белән караудан килә. Сүзләрне грамматик мөнәсәбәткә кертеп, мәгънә бөтенлеген тәэмин итүче килеш кушымчалары да С. Хәким поэзиясендә шигъри ритм, рифманы искә алып кулланыла. Телебезнең эчке хосусияте нечкәлекләрен дә искә ала шагыйрь. Зур поэзия хакында сүз йөрткәндә, болар вак мәсьәлә булып күренергә мөмкин. Әгәр ташчы бер генә кирпечне дөрес салмаса да, аның төзелеш эше эстетикасын әле бөтен күңеле белән аңлап җиткермәве күренә. Моның өчен ул мастердан шелтә ала. Поэзиядә бер генә грамматик чара әсәр рухына яраклашмаганлыгын сиздерсә дә, аның эстетик сыйфаты күпкә кими. Шуңа күрә нәфис сүз сәнгате осталары телнең һәр «вак» элементына зур игътибар итүчән. Тел материалын үзенчәлекле куллана белү нәтиҗәсендә индивидуаль стиль барлыкка килә. С. Хәкимнең үзенә генә хас индивидуаль стиле бар. Бу яктан ул күпләргә үрнәк остаз.

«Шагыйрьнең бала чагы» поэмасындагы:

**Мин геолог түгел, тик шулай да**  
**Катлаулы һәм нечкә эшем бар,**  
**Йөрәкләрдә яткан энҗеләрне**  
**Эзләп таба торган көчем бар,**

— кебек юлларны укыгач, бу фикер тагын да ныграк раслана.

Халык йөрәгеннән алган энҗене аның үзенә яңадан бик күп мәртәбәләр матуррак итеп кайтарып бирергә кирәк. Бу осталык поэтик телнең сәнгатьлелек дәрәҗәсен аңлап эш итүгә бәйләнгән. Өстә күренеп яткан алтынны алу дан түгел. Идея-эчтәлек, образлылык, сәнгатьлелек өчен сүз сайлаганда С. Хәким шул принцип буенча эш итә. Күзгә бәрелеп тормаган сүзләрне эзли, аларны шигыренә төрле стилистик-эмоциональ төсмерләр бирү өчен файдалана.

Шигъри әсәр өчен ят тоелган, гади сөйләм теле булып исәпләнгән төрле сүзләрне куллану борынгыдан килә. Алар Болгар чоры шагыйре Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха», (т а р т у — ү л ч ә ү урынына), Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъярның «Төхфәи Мәрдән», «Нуры содур» (гарык булу) поэмаларында да бар. Бу типтагы сүзләр белән (капшау, маташу) Г. Тукай иркен эш итте. Аларның эчке мәгънәсе, стилистик мөмкинлеге С. Хәким әсәрләрендә дә көтелмәгән яктан ачыла. Й ө з ч ы т у, с а н г а с у к м а у, э л ә к т е р ү, й ө з е к а р а, п ы р т у з д ы р у, т ә р т ү, т е ң к ә г ә т и ю, м а г а р ы ч кебек сүзләр «зәбәрҗәт», «алтыннар»га кулага төшерер кебек. Ләкин һич тә алай түгел. Киресенчә, алар «алтын», «зәбәрҗәт»ләрдәге бизәкләр белән бик нпле аралашып киләләр. Я ш е л, з ә ң г ә р, а л, к ы з ы л, к ө р ә н кебек сыйфатлар белән чагыштырганда, мәсәлән, с о р ы ның поэтик бизәклелек дәрәҗәсе түбән кебек. Икенче төрле әйтсәк, ул матур төс түгел. Ә менә Г. Бәширов «Намус» романында шул сыйфат ярдәмендә сурәт ясый: «...Соры тасмадайborгаланып узган язгы җепшек юл...» С. Хәким «Курск дугасы» поэмасында бу сыйфат белән сугыш картинасын күз алдына китереп бастыра:

**Син сорыйсың, агай, тормышыңны**  
**Өйрәндең дип каян башларга.**  
**Ә мин, озак, озак итеп карыйм**  
**Төтен сеңгән соры ташларга.**

Т ө т е н с е ң г ә н с о р ы т а ш л а р Курск дугасындагы коточкыч дәһшәт, сугыш фаҗигасе турында сөйли. С о р ы сүзен алып ташласаң, сурәт югала. Рус (связной, заявление, питомник, правление) һәм гарәп (мәгърур, шөһрәт, мәшһүр) сүзләре, төрле фразеологик әйтелмәләр (күз явын алу, тел ачылу, күңел нечкәрү, йөрәк әрнү, иза чигү, тел очында тору, бил сыгылу, җан өзелү) билгеле бер стилистик максатта кулланылып, шагыйрьнең гомум эстетик концепциясенә буйсына.

Сүз сүзне матурлый, дип тә әйтә халык. Бу очракта да телнең тыштан ялтыравы түгел, эчке матурлыгы, мәгънә бөтенлеге күздә тотыла. Г ә ү һ ә р я ш ь дип әйтелә «Йосыф вә Зөләйха»да. Бу эпитет эчке матурлыкны белдерә. А ч ы я ш ь дип С. Хәким «Югалган эзләр»дә, яшь кешене көйдергән кайгы-хәсрәтне, моң-зарны белдереп.

Гомумән, каләм осталары аз сүз белән күп мәгънә аңлата алалар. «Володя ант итә» дигән шигырьдә С. Хәким Россияне бер җәенке эпитет белән бирү осталыгына ирешкән:

Изелгән киң рус кырлары
Тынып калдылар,
Гүя зур юллар өстендә
Утлар яндылар.

Киң рус кырлары безгә мәгълүм. Ә менә изелгән сүзе иске Россия халкының авыр, караңгы, михнәтле тормышта яшәвен күз алдына китереп бастыра.

Шагыйрь һәр поэтик бизәкне әсәренең идея-эчтәлегенә туры китереп, анда чагылдырылган чорның рухы, үзенчәлегенә карап файдалана. Укыганда аларның барын да сизмисең. Чөнки тасвирлау бизәкләре шигырьнең эчке мәгънәсе белән аерып алгысыз дәрәҗәдә табигый мөнәсәбәткә керә. «Дала җыры» поэмасында, мәсәлән, бөкерәеп җиргә утырган картның кайгысы безгә болай да аңлашыла. «Күтәрә алмаслык кайгы» дип тә әйтә халык. С. Хәким бу төшенчәне «Борчулы төн ике иңен баскан» дигән метафора белән аңлата. Яки аның «Егерме бишенче август» («Казан утлары», 1981, № 1) исемле шигыренең беренче строфасына игътибар итик:

Якты, шатлыклы, борчулы —
Төрле көн бар язмышта;
Мусаның канлы шәүләсе
Калка һәр ел августта.

М. Җәлил турында күп язылды. Шуларның барысыннан соң әнә ничек — язмыш төшенчәсен: «Мусаның канлы шәүләсе Калка һәр ел августта»,— дигән метафора белән конкретлаштырып әйтә шагыйрь.

С. Хәким традицион образ-символлар белән иркен эш итә. Җил образы, мәсәлән, халык иҗатыннан, «Йосыф вә Зөләйха»дан ук килә. Анда бу образ хәбәр йөртү вазифасын башкара. «Көзге җилләр» шигырендә Тукай аны капиталистик җәмгыятьтәге авыр тормышны чагылдыру максатында файдалана. Җил һ. Такташта, Г. Ибраһимовта искелекне җиңүче символик көч буларак кулланыла. М. Җәлилнең «Ана бәйрәме» исемле шигырендә исә җил батыр көрәшчеләр образын символлаштыра. С. Хәким «Верховой» шигырендә җил ярдәмендә эшченең какшамас көчле образын сурәтли. Кыш. Кырда буран. Якындагы вышканы да күреп булмый. Сызгырып искән җил верховойның көчен сыный, аны йолкып алып ташларга тели. Мондый каты, көчле буранга вышка да чыдамас төсле. Әмма кеше түзә. Барлык табигать көйсезлекләренә каршы оста көрәшә: «Тау өстеннән җил сызгырып исә, дулый, әйдә, көчен сынасын. Верховойны йолкып ташлый алмас, вышкаң гына тузган, чыдасын». Бу эшчедә давыллы елларда чыныккан ныклык чагыла кебек. Ул җил образы катнашлыгында бирелә.

Чорга, әсәрнең идея-эчтәлегенә бәйле рәвештә туган яңа сурәтләү чаралары да С. Хәким поэзиясендә шактый. Ләкин шагыйрьнең сүз сәнгате остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелүе — һич тә поэтик бизәкләр белән мавыгуда түгел. Гадилектә. Пушкин, мәсәлән, чагыштыруларны яратмаган. Толстой гади генә сүзләр белән күп мәгънә белдерү, җанлы картина тудыру, сәнгатьлелеккә ирешүне хуплаган. С. Хәкимнең:

Хезмәттән соң камыл тәпләрендә
Йоклый изерәп җәйнең тынлыгы,

— кебек юллары да шуңа тартым. Көне буе эш кайнаган кырлар тынып калган. Шушы тынлыкны шагыйрь берничә сүз белән сурәтләү осталыгына ирешә.

Шагыйрьнең үзенә хас индивидуаль стилен билгеләүдә бер юл бар. Ул туган тел хәзинәсендәге бөтен байлыкны поэтик юлларда үзенчәлекле куллана белүгә бәйләнгән. Шагыйрьләр бер-берсеннән дә өйрәнә. Бу күренешне Агыйдел белән Каманың

кушылуына охшатасы килә. Алар, берсен-берсе озак эзләп кавышсалар да, әдәплелек саклап торган кыз белән егеттәй, һаман кушылмый агалар әле. Агыйдел ягында — ак, Кама ягында — каракучкыл су. Искиткеч матур, поэтик картина! Тора-бара алар Идел-ана куенына аерылгысыз «җаннар» булып барып керәләр. Поэзиядә дә шулай бит. Тукай рус һәм Көнчыгыш поэзиясеннән өйрәнгән. Аның стилендә Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Кандалый һ. б. шагыйрьләр йогынтысы сизелә. Ул йогынты С. Хәкимдә дә бар. Аның кайбер юлларын укыганда «Йосыф вә Зөләйха», «Тәхфәи мәрдән», «Нуры содур»лар искә төшә. Тукай җилне — өй түрендә, С. Хәким «Татарлар елмаеп үлделәр»дә өй янында елата («Өемнең янында җил елый»). Аерым юлларны укыганда Такташ, Җәлил шигырьләре күңелгә килә. Шагыйрьгә Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Есенин йогынтыларын сизү дә кыен түгел. Ләкин, барыннан да да бигрәк, аның стилендә Тукай һәм Такташлар моңы аралашып киткә кебек. Әмма әлеге аралашу — Агыйдел белән Кама елгасының бер-берсенә тәмам кушылып бетүе кебек үк. С. Хәким үзенә чаклы булган шагыйрьләрнең стилен сиздерми дәвам итә. Бу аның осталыгына гына түгел, традицияне үзенчә үстерә, камиллештерә белүенә бәйләнгән.

С. Хәкимнең шигъри хәзинәсендә зөбәрҗәт, алтыннар күп. Шуңа күрә аларны тулысынча бәяләп бетерү һич мөмкин түгел. Шагыйрьнең поэтик теле махсус тикшерүгә мохтаҗ. Соңгы сүз итеп шуны әйтәсе килә: зөбәрҗәт, алтыннарың һаман артсын, халкыбызның рухи байлыгына кушылсын, Сибгат ага!

**Суфиян ПОВАРИСОВ,**
филология фәннәре кандидаты

# ЗӘКИ НУРИГА 60 ЯШЬ

Гариф Ахунов

# КӨРӘШТӘ ЧЫНЫККАН ПОЭЗИЯ

Зәки Нурины мин үзем каләм тота башлаганнан бирле беләм. Аның иҗатына карата иркенрәк сүз әйтергә туры килгәне юк иде әле. Менә җае да чыкты: каләмдәшебезгә быел алтмыш яшь тула. Шушы шактый озын гомеренең кырык биш елы поэзиягә багышланган. Күп гомер, ихтирам итәрлек хезмәт!



Без әдәбиятка килгәндә, Зәки Нури әдәбият йөген төпкә җигелеп тарта иде инде. Озын буйлы, чибәр, яшь кешене, өстәвенә юморга да бай булган көләч кешене, илленче еллар башында һәркем әллә ни арада яратып өлгерә, яшьләр гел аңа тартыла, аксакаллар да, йомышлары төшеп, әледән-әле аңа киләләр иде.

Ул чагында, ихтимал, моның сәбәпләрен бирәү дә уйламагандыр. Кояшның нигә ягымлы, яңгырның нигә шифалы, туфракның нигә уңдырышлы булуын без бит адым саен уйлап тормыйбыз. Шулай тиешле дип карыйбыз һәм ул юмартлыктан рәхәтләнеп файдаланабыз.

Менә бүген Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдиновка — шагыйрь Зәки Нурига алтмыш яшь тулган көннәрдә югарыда әйтелгәннәрнең чыганакларын эзлисе, сәбәпләренә төшенәсе килә. Хикмәте шулдыр: әдәбият мәйданына ел саен яңа яшьләр — сәләтле егет һәм кызлар килеп тора. Зәки Нури кебек әдәбиятта җигелеп эшләгән, җәмәгать эшләрен һичбер авырыксынмыйча, теләп башкарган юмарт күңелле иптәшнең тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе аларга да бик кирәк.

Без фән һәм техника бик нык алга киткән заманда яшибез. КамАЗ кебек, Идел буендагы автомобиль заводы кебек производство гигантларында утызар яшьлек инженерлар дан казана, ил күләмендә танылa. Әдәбиятта исә утыз яшьлекләр әле һаман да башлап язучы, күп дигәндә — яшь язучы булып йөриләр. Сәләт җитмәгәнгәме? Юк. Белем җитмәгәннәнме әллә? Юк. Сәләтләре дә, белемнәре дә җитәрлек. Тормыш тәҗрибәсе җитмәү, ил өчен, аның бүгенге көне һәм киләчәге өчен, аның конкрет бер коллективы өчен җаваплылык хисен өстеңә алмау, тормышны матурлыгы һәм ямьсезлеге белән, шатлыгы һәм кайгысы белән берьюлы күрә белмәү — менә нәрсә яшь әдипләрне озак вакытлар җитлектермичә тота. Татар әдәбияты кебек күп гасырлы традициясе булган бай һәм җитди әдәбиятта үз юлыңны табу җиңел эш түгел, күрәсең.

Ә менә Зәки Нури утыз яшенә җиткәндә инде илнең аркылысын-буен йөреп чык-

кан, сугыш ялкыннарында көйгән, урман хуҗалыгында һәм совет органнарында эшләгән, матбугат белән җитәкчелек иткән әдип иде. Төгәлрәк итеп әйтсәк, ул 1934 елдан — Лубян урман техникумында, 1938 елдан — Амурдагы Николаевск шәһәрендәге төзелештә урман бүлеге мастеры, 1940 елдан — Чувашстанның Шемурша урманчылыгында лесничий ярдәмчесе, 1941 елдан — Бөек Ватан сугышы солдаты (башта Хәрәкәттәге Армиядә артиллерист, аннары Белоруссиядә, атаклы Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар берләшмәсендә разведка отряды башлыгы), 1944 елдан — Белоруссиянең Орша шәһәре советы башкарма комитетының председатель урынбасары, 1946 елдан — Буа шәһәрендә урман базасы директоры, 1947 елдан — леспромхоз директоры, 1951 елдан — «Татарстан яшьләре» газетасы редакторының урынбасары...

Утыз яшькә күбрәк түгелме болар?

Ә бит әле шагыйрь Зәки Нуриның хезмәт исемлеге аның белән генә бетми. Мин хәзергә аның утыз яшенә җиткәнче нинди урыннарда эшләвен, нинди җаваплылыкны үз өстенә алганлыгын укучыларыбызга күрсәтер өчен фактик материал гына бирдем. Уй-фикер йөртеп, чагыштырып карар өчен.

Чүпрәле районының Татар Төкесе авылында 1921 елның 24 декабрендә крестьян гаиләсендә дөньяга килгән малайның сугыш алды елларында нинди зур ашкынулар белән мәктәпкә йөрүен, унөч-ундүрт яшендә чагында ук «Яшь ленинчы» газетасында беренче шигырьләрен бастыра башлавын, урман техникумында уку елларын, бик яшьләй Ерак Көнчыгышта эшләвен, авыр сугыш елларында партизан учаклары янында узган кайнар яшьлеген исәпкә алсак — болар барысы яшьләр өчен дә, күп меңләгән укучылар өчен дә гыйбрәтле хәлләр. Аның гыйбрәте бигрәк тә шунда: егерме беренче елгылар, коточкыч корылык, ачлык елында туганнардан бездә биш кенә әдип торып калган — Гамил Афзал, Геннадий Паушкин, Юныс Әминов, Әдип Маликов һәм Зәки Нури. Аларның кордашлары — бик күп талантлы яшьләр, әле беренче китаплары да дөнья күрмәс борын, сугыш кырларында һәлак булдылар. Зыя Мансур, Әнвәр Давыдов, Шәрәф Мөдәррис кебек сәләтле шагыйрьләр фронттан кайтсалар да, сугышта алган яраларыннан мантый алмыйча, кырык-илле яшьләрендә вафат булдылар. Димәк, сугышта һәлак булган яшь каләмнәр өчен дә, сугыштан соң арабыздан вакытсыз китеп барган каләмдәшләре өчен дә иҗат итү, «котып йолдызын маяк итеп йөргән разведчикларны», салкын окоплар, саз камышлары һәм куе урманнарның моңын халыкка җиткерү алар өстендә иде...

Зәки Нури беренче шигырьләр җыентыгын 1945 елны бастырып чыгара. 1951 елны аны СССР Язучылар союзына член итеп алалар. Сугыштан соңгы ун ел вакыт эчендә аның «Шигырьләр» — 1945, «Безнең яшел дустыбыз» — очерклар (1949), «Дан юлы» — поэма (1949), «Без яшибез Иделдә» — шигырьләр (1951), «Диңгез ясалган якта» — шигырьләр (1953), «Син мәктәпкә йөрисең» — балалар өчен шигырьләр (1953), «Төп юнәлештә» — очерклар (1954), «Чын күңелдән сөйләшү» — шигырьләр (1955) исемле китаплары басылып чыга. Күрәсез, автор өзлексез яза, ел саен я шигырь, я поэма, я очерк китабы бастырып чыгара. Ә сыйфат ягы ничек?

1951 елда Зәки Нурины СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим иткән Сибгат ага Хәкимне тыңлап карыйк:

«Шагыйрь Зәки Нуриның иң характерлы шигырьләре 1955 елда чыккан «Чын күңелдән сөйләшү» исемле җыентыкка тупланган. Әдәбиятка үз юлы белән килгән, халыкка әйтер сүзе булган язучы кадерле. Зәки Нури — шундыйларның берсе. Аның 1941—42 елларда язылган «Партизан учаклары» җылы, сине үзенә тарта, алар тирәсендә утырган кешеләрнең йөзендә тирән кайгыру, ил язмышы өчен борчылу сизелеп тора. Учаклар үзләре генә түгел, шушы олы җанлы кешеләре белән бергә сиңа якын. Автор Ватан азатлыгы өчен барган көрәшләрдә турыдан-туры үзе катнашканга күрә аның язганнары да күңелгә ятышлы, тормышчан, аларның ышандыру көче зур. Шушы әйбәт сыйфатларны Зәки Нури иҗатында торган саен үстерә барды һәм татар совет поэзиясенә үз тавышы белән килеп кушылды».

Бөек Ватан сугышыннан соң Зәки Нури илнең бик күп вакыйгаларына багышлаган шигырьләрен иҗат итте, аларда шагыйрьнең януын, үзенең мөнәсәбәтен ачык күрәсең, мондый шагыйрьләр иженче бераүләрне кабатларга яратмый.

Зәки Нури шигырьнең формасы, техникасы өстендә бик нык эшли. Бу мәсьәләдә ул татар һәм рус поэзиясенең бай традицияләреннән туктаусыз өйрәнә. Шигырьләре аның образларга бай, тирән фикерле, аралаш рифманы ул табигый рәвештә шигырьләренә кертә бара, бу да аның рус шигырь техникасыннан өзлексез өйрәнүе турында сөйли.

Зәки Нури — безнең поэзияне үстерешүгә киләчәктә зур өлеш кертә торган талантлы шагыйрь».

Моннан нәкъ өч дистә ел элек үк Сибгат Хәким шагыйрьнең поэзиядәге урынын һәм киләчәген ачык бәяли.

Әмма да ләкин, кызганычка каршы дип әйтик, профессиональ тәнкыйтьчеләребезнең Зәки Нури поэзиясенә нигезле, әтрафлы бәя бирүчеләре юк. Моның сәбәпләрен аңлавы да, аңлатуы да кыен. Шулай да мин, үзем аңлаганча, моны укучыларга әйтеп карыйм. Зәки Нури бик күп еллар буе Язучылар союзы йөген тартты: җаваплы секретарь, председатель, «Казан утлары» журналының баш редакторы булды. Гадәттә, мәгълүмдер ки, йөк атын мактамыйлар, йөк атын гел камчылап кына тора торган булалар. Шлея-чуклар таккан, җиз тәңкәләр белән бизәлгән купшы атлар, җилдәй җитез аргамаклар, кешеләрне кунакка йөртә торган юртаклар күбрәк күзгә ташланучан була...

Сибгат ага Хәким Зәки Нуриның беренче иҗат дәверенә зур бәя биргән икән — рәхмәт аңа. Бу аның яшьләргә булган ягымлы җылы карашыннан да, татар совет поэзиясенең киләчәге өчен борчылуыннан да килә. Бу бәянең никадәр гадел икәнен шул дәвердәге бер-ике шигырь белән дә раслап була.

Әйтергә теләгән уем укучыларга тизрәк барып җитсен өчен, «Каршылау» исемле шигырьне тулысынча китерәм:

**Өй каршында туктады олау.**<br>
**Бирәү менә биек баскычтан.**<br>
**Ана чыга җылап шатлыктан...**<br>
**Нинди бәхет улны каршылау!**

**Ул аяусыз, ярсып көрәшкән,**<br>
**Күп җырланган поход, юл җыры.**<br>
**Күкрәгендә ике ордены**<br>
**Үсеп чыккан кебек йөрәктән.**

**Һич кирәкми сорап торырга,**<br>
**Кичергәне ачык һәммәсе:**<br>
**Чәчләренә кунган чал бәсе**<br>
**Үзе сөйли барысы турында.**

**(1945)**

Язылган заманыннан башлап бер генә сүзе дә үзгәртелмәгән бу шигырьне, нибарысы өч куплетлы шигырьне, Бөек Ватан сугышы буыны шагыйрьләренең тыныч тормышка аяк баскандагы гимны дип әйтергә була. Сүзләр төгәл, кырыс. Образлар монументаль. Өй каршына туктаган олау һәм биек баскычтан күтәрелгән чал чәчле яшь солдатны, аны каршылаган ананы теләсә кайсы рәссам илебезнең иң зур күргәзмәләрендә урын алырлык полотно итеп яза алыр иде. Һич икеләнми әйтәм, андый сәнгать әсәре язылса, ул академик Лактионовның «Фронттан хат» әсәре белән янәшә куелыр иде.

Тыныч көннәр бәхетен күрүгә ирешкән яшь шагыйрьнең икенче бер шигыреннән тагын дүрт юлны китерик:

**Чәчәк ата кебек үзе күңел,**<br>
**Таң шикелле хис саф, уй якты.**<br>
**Мине бүген бомба шартлап түгел,**<br>
**Сандугачлар сайрап уятты.**



*Сулдан уңга: алгы рәттә — М. Львов, З. Нури, С. Хәким, икенче рәттә — Р. Гәрәй һәм Г. Сабитов.*

Югарыда китерелгән «Каршылау» шигыре белән «Күгәрченнәр гөрләп оча җимгә» шигыреннән китерелгән әлеге өзектә Зәки Нуриның алгы көндәге поэтик программасы ачып бирелгән. Шушыннан соң шагыйрьнең иҗаты ике тармак буйлап үсәчәк. Берсе аның — совет солдаты узган юл, окоплар, партизан учаклары, җиңү тантанасы; икенчесе — соры шинельне комбинезонга алыштырган совет кешесенең ил иминлеге, дөнья иминлеге хакына, Икенче бөтендөнья сугышы йоткан 20 миллион совет кешесенең изге хатирәсе хакына армый-талмый эшләү. Гигантлар кору. Иген үстерү. Җимерелгән-тапталган илне планетада беренче урынны тоткан державалар сафына бастыру.

Иҗат, әлбәттә, эзләнүләр аша бара. Табышлар һәм югалтулар аша. Бу мәсьәләдә Зәки Нури да, башка барлык җитди шагыйрьләр кебек үк, тигез юлдан гына бармый. Мең газаплы, сикәлтәле, казылмалы юлдан, тормыш сукмакларыннан атлый. Шуңа күрә мин аның иҗатында, барыбыздагы төсле үк, плюслары белән минуслары да булуны табигый дип саныйм. Әмма аның иң яхшы шигырьләре, «Үлгәннәр дә үч алды» исемле документаль прозасы, бөек төзелешләрдән язган очерклары илебезнең әдәби елъязмасына өлеш булып керәләр, шул елъязманы яңа бизәкләр белән баеталар.

Яшьлек елларында ук килеп кергән урман образы, урман шавы Зәки Нуриның тулаем поэзиясенә юлдаш. Чөнки бу кемнәндер прокатка алып торган образ түгел, урманчы үсмернең күңел түреннән килеп туган образ. Өстәвенә язмыш аңа урманлы Белоруссия урманнары рәвешендә дә әзерләп куйган икән әле. Шуңа күрәдер шагыйрьгә яшьлек — «шаулап үскән куе урман» кебек, урман өстендә сызылган алсу офыклар төсле, урман күлләре, урман елгалары төсле тоела; берданкасын кысып, таңгы эшенә ашыккан әти дә, дозорда төн буена имәннәр шавын тыңлап яткан партизан егет тә, «ишкәк терәп этеп яр комына, икенче як ярдан колхозына аяз иртә күчергән балыкчы егет тә» — барысы, барысы җанга якын, үз һәм газиз. Гомумән «урман образлары» Зәки Нуриның сугыш поэзиясен дә, тынычлык поэзиясен дә нурландырып торалар.

Сугыш поэзиясе дигәннән, Зәки Нуриның «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан калын бер томлыгын җентекләп укыдым. Бөек Ватан сугышы чорында язылган шигырьләр анда аз урын алган. Алар бәлки күп тә булганнардыр. 1980 елны чыккан җыентыкка шагыйрь аларны бик сайлап кына керткән. Сугыш чорында Зәки Нури иҗат иткән шигырьләр чынлыклары, төгәл образлары, Ватанга тугрылык хисен зур итеп сурәтли белүләре белән дә, лирик-драматик киеренкелекләре белән дә Фатих Кәрим шигырьләренә авазлаш. Рухлары белән авазлаш. «Ватандашка» булган чакыру авазын шагыйрь: «Салкын окопларда кунсаң да, таптасаң да сазлар камышын, кайсы якта, дускай, булсаң да, җитсен иде сиңа тавышым!» — кебек кайнар сүзләр белән башлый. Сугыш кырында башын салган яшь-яшь егетнең сурәтен җаннарны айкап алырлык итеп, бер-ике куплетта әйтеп бирә:

**Көрәшчеләр туктап тып-тын калды**
**Баш очында якын иптәшнең.**
**Яктыруын әллә көтеп таңның,**
**Уйланамы иптәш — ник дәшми!**

**Юк, ул ята ташка башын салып,**
**Җирдә яшәп туймаган егет,**
**Идел ярларында калган талын**
**Һәм иркәсен уйлаган кебек...**

**(«Бөркетебез калды». 1942)**

Үзәк өзәрдәй моң-сагышы белән, үкенече белән бергә, бу шигырь гаять табигый итеп, Белоруссия җирен азат итү өчен башын салган Идел егетен сурәтли. Һәм, ул әйтергә кирәк, Зәки Нуриның сугыш чоры поэзиясенә дә, тынычлык поэзиясенә дә хас булган өченче бер хасиятне — илебез халыкларының какшамас дуслыгын җырлауны башлап җибәрә. Зәки Нури иҗатында дуслык хисе күп төрле, күп бизәкле булып чагыла. Партизан учаклары янында. «Йөрәк ярасы» исеме белән язылып, немец иленә адресланган хат-поэмада. Муса Җәлил турындагы уйлануларда. Сталинградгидрострой дәфтәрендә. Иделдә, Кама буйларында, Донда барган бөек төзелешләр репортажында. «Өй туе» дигән әдәби-музыкаль күренештә. Сүз уңаеннан әйтик, «Өй туе» чын мәгънәсендә халыкчан, Кәрим Тинчурин комедияләрендәге кебек, халык тамашаларына корылган дәртле әсәр. Зур төзелештә барган дуслыкны — Түбән Кама төзүчеләренең туганлык тойгыларын тасвирлау өчен матур форма тапкан шагыйрь. Ул өй котлау сюжетына салып, төрле милләт халыкларының уртак тойгыларын әйтеп бирә. Биредә татар, рус, казакъ, украин, белорус җырлары, шул халыкларның культура традицияләрен өйрәнеп һәм белеп язган җырлар, биюләр бар. Әсәрнең максаты — бөек Ватаныбызда яшәгән төрле милләт халыкларының хезмәт батырлыгына, фидакарьлегенә, дуслык тойгыларына дан җырлау. Мин моны әйбәт нәрсә дип карыйм. Мондый матур сюжетлы, халыкчан дәртле һәм тапкыр әдәби-музыкаль композицияләрне, фольклор үрнәкләренә таянып, сугыштан соңгы чорда Нәкый ага Исәнбәт тә иҗат иткән иде. Сабантуйлар, өй котлаулар, уңыш бәйрәмнәре талантлы каләм иясенең кулы тигәч, янә бер мәртәбә чын көмештәй ялтырап киткән иде. Бик борынгыдан — каз өмәләреннән, тула сугу, өй күтәрү өмәләреннән үк килә торган халыкчан бу традицияне безгә бүгенге көндә дә онытмаска кирәктер, ил буйлап йөри торган филармония артистлары, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле аларны бик тиз халыклаштыра алыр иде.

Зәки Нуриның мәхәббәт һәм табигать лирикасы Сибгат Хәким, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев кебек шагыйрьләрнең мәхәббәт һәм табигать лирикасыннан шактый нык аерыла. Зәки Нури лирикасы табигать авазларына, кошлар моңына, күңелдәге талгын уйларга корылган лирика булудан бигрәк, поездлар тукылдавы һәм сандугачлар сайравын да үзенә сыйдыра алган хәрәкәтчән актив лирика. Моның сәбәпләре дә бар: шагыйрь туктаусыз юлда — Днепр ярларында, Белоруссия урманнарында, Енисей тугаенда, Җаек далаларында, Такташ узган Тамбов урманнарында, Нева төнендә,— кыскасы, шагыйрь һәм партизан Зәки узган иксез-чиксез илебезнең хезмәт

герелтесе, сугышчы Зәкинең шул хезмәткә мөнәсәбәте, уңышларыбызга шатлануы чагыла бу лирикада, сандугачлар моңын һәм офык алсуларын дәһшәтле сугыш ялкыннары аша күрү сизелә. Публицистика кушылган һөҗүмчән лирика бу.

Юмор-сатирага килгәндә, Зәки Нури бу өлкәдә әзлексез эшли. Тормышчан, чын юморы, яшен яктысы төсле күзне камаштыра торган, вакыт-вакыт усал гына тешләп тә ала торган юморы аның мәсәл рәвешендә дә, сатирик шигырь рәвешендә дә, усал һәм шаян такмаклар рәвешендә дә, пародия рәвешендә дә кәгазьгә төшә килә. Уңышлылары күп. «Шул да булдымы юмор?» — дип әйтерлекләре дә очрый. Мин моны Зәки Нуриге гел мәдхия укып тора бу дип әйтүдән куркып түгел, аның белән бергә озак еллар кулга-кул тотынып эшләгән кеше буларак, бергә иҗат иткән дуслар буларак әйтәм. Ә бит дөньяда дуслык хокукыннан да зуррак хокук юктыр ул. Юмор-сатира — әдәбиятның бик авыр жанры, теләсә кемнең кулыннан килми торган жанры, безнең әдәбиятта бүгенге көндә бу жанрда Гамил Афзал, Шәукәт Галиев, Фаил Шәфигуллиннар уңышлы гына эшләп киләләр. Зәки Нуриның тормыштагы, телдәге юморы ничектер халыкчанрак, күңелгә ятышлырак, үтемлерәк кебек тоела миңа. Ул булган җирдә — көяшлы көн кебек якты, күңел күтәрерлек шатлыклы, рәхәт була. Кәгазьгә төшкән, иҗат булып туган юморы чүп-чарны бетерергә, искелек калдыкларын себереп ташларга ярдәм итә.

Зәки Нури — әдәби тәрҗемә өлкәсендә иң күп эшләгән шагыйрь. Татар теленә ул Лермонтов һәм Некрасовның, Шевченко һәм Мәхтүмколыйның, Есенин һәм Твардовскийның, Гафур Гөләм һәм Якуб Коласның, Педер Хузангай һәм Расул Гамзатовның һ. б. аерым әсәрләрен тәрҗемә итте. СССР халыклары әдәбиятыннан, чит илләр әдәбиятыннан Ленин темасына махсус китаплар әзерләде. «Дуслык букеты» сериясендә рус, украин, әзербайҗан, белорус, казакъ, кыргыз, таҗик, төрекмән, үзбәк — кыскасы, барлык Союздаш республикалар поэзиясеннән иң яхшы шигъри үрнәкләрне тәрҗемә итеп бастырды. Дөнья халыкларының акыллы сүзе һәм юмор-сатирасы белән татар укучыларын таныштыруда да хезмәтләре зур һәм ул хәзер тагын активрак дәвам иттерелә.

Зәки Нуриның үз шигырьләре кырык биш еллык иҗаты дәверендә үз ана телебездә, рус һәм башка тугандаш халыклар телендә күп мәртәбәләр басылып чыкты.

Мәкаләнең башында ук әйткән сүзләргә — Зәки Нуриның җәмәгать эшләренә әйләнеп кайтам. Җәмәгать эшен яратуны тәрбияләп була, әммә аны көчләп эшләтеп булмый. Зәки Нури исә җәмәгать эшен, үзенә йөкләнгән вазифаны җыр кебек башкара ала торган бәхетле әдип.

Иң кыен чакларда да, ай-һай авыр бит, дип әйткәнен ишеткәнем булмады аның. Егерме ел буена Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре, соңыннан председателе, ун ел буена «Казан утлары»ның баш редакторы булу өстенә, ул әле РСФСР Язучылар союзы идарәсе члены, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, партиянең өлкә комитеты һәм Казан шәһәре комитеты члены, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, президиум члены булды. Татарстан Язучылар союзында яшьләр белән эшләү комиссиясен җитәкләде. Гомумән дә, яшь язучыларга, яшь шагыйрьләргә ул гел ярдәм итеп, булышып килде. Өлкән әдипләребез дә, урта буын язучылар һәм яшьләр дә аңар юмарт күңелле, ярдәмчел булуы, авыр чакларда теләсә кайсыбызга булышырга атлыгып торганы өчен рәхмәт әйтә алалар.

Совет хөкүмәте аның сугышчан батырлыгын һәм иҗаттагы уңышларын югары бәяләде. Ул Ватан сугышы һәм Почет билгесе орденнары, күп кенә медальләр һәм Почет грамоталары белән бүләкләнде. Белорус халкы, Бөек Ватан сугышындагы һәм тыныч хезмәттәге батырлыкларын ихтирам итеп, шагыйрьне Орша шәһәренең почетлы гражданины итеп сайлады.

Коммунист язучы, ялкынлы публицист һәм халыкка танылган шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Зәки Нурины олы бәйрәме көнендә, чын күңелдән котлап, сәламәтлек, көр күңел, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез. Иң беренче чиратта, әлбәттә, сәламәтлек!

# ОРШАДАН ХАТ


*Исәнме, сугышчан дустыбыз Зәки Шәрәфетдинович!*

*Ул елларны тагын хәтерлик әле. Моннан кырык ел элек, 1941 елның 22 июнендә, фашистик Германия сөекле Ватаныбызга вәхшиләрчә бәреп керде. Ил өстендә үлем куркынычы туды.*

*Йөрәгең кушканга һәм партия чакырганга күрә, син туган йортыңны, яраткан әшеңне ташладың һәм изге сугышка киттең.*

*Саубуллашканда атаң, анаң кочагыннан нинди кыенлык белән аерылганыңны искә төшер әле... Сөйгәнең һәм хыялың белән хушлашуыңны хәтерлә.*

*Ватан-Ана илебезне саклар өчен изге көрәшкә чакырды һәм бу чакыру бар нәрсәдән дә көчлерәк иде.*




*Сугышның авыр елларын хәтерлә, иптәш. Ерткычланган фашист илбасарлары алга ыргылдылар, ә син аларның юлына аркылы төштең һәм фронтта да, дошман тылында да туган илебезнең һәр карыш җире өчен аяусыз сугыштың.*

*Хәтерлисеңме, пулеметка нибары 5—10 патрон, тупка 1—2 снаряд кына калган чагында, фашистлар атакага күчтеләр... һәм син, иптәшләрең белән соңгы патроннарны бүлешкәндә, аның берсен үзеңдә калдырдың...*

*1418 көн һәм төн дәвам иткән утлы бәрелешләрдә син җиңүләр ачысын да, Бөек Җиңү шатлыгын да татыдың.*

*Ә фронт юлларында күпме сугышчан дусларыңны югалттың? Үзеңнең исән калуыңа да озак вакытлар ышанмый йөрдең. Тәнеңдә сугыш күпме яра эзләре калдырды?!*

*Синең Бөек Ватан сугышында катнашуың — хәрби антка тугрылык, Ватаныбызның бәйсезлеге, намусы һәм азатлыгы өчен көрәштә батырлык үрнәге күрсәтү ул. Туган ил моның өчен сиңа рәхмәт белдерә.*

*Балаларга һәм оныкларга шушы батырлыклар турында сөйлә.*

*Безнең бу өчпочмаклы хатыбыз сугыш елларын һәм яу юлларын хәтерләтсен, тик андый чаклар беркайчан да кабатланмасын.*

*Сиңа һәм синең якыннарыңа, сугышчан дустыбыз, нык сәламәтлек, иҗади уңышлар, яхшы кәеф һәм тыныч таңнар теләп калабыз!*

*Сугышчан сәламнәр белән,*

*с у г ы ш  в е т е р а н н а р ы.*

*Орша шәһәренең революцион, сугышчан һәм хезмәт даны клубы председателе, отставкадагы майор — П. М и н ч е н к о.*

*Клуб Советы секретаре, отставкадагы подполковник — И. Ж а р к е в и ч.*

*Июнь, 1981 ел. Орша шәһәре.*

## Гыйлемдар Рамазанов,

башкорт шагыйре

### Урманчы

Шаулый-гөрли Орша урманнары,
Чупрәледә шаулый урманнар.
Белорус һәм татар акланнары —
Әйтерсең лә, игезәк туганнар.

Чупрәледә үскән көләч егет
Чаганнарга гашыйк, имәнгә,
Саклый микән тиле яшьлек эзен
Урман техникумы Лубян да?

Кем уйлаган тау-тау авырлыклар
Ябырылыр дип безнең каршыга,
Чупрәленең бөдрә каеннары
Күчеп килер диеп Оршага?

Дус Неманда туган Идел буен
Күкрәк белән ул да каплады.
Яклады ул Орша урманнарын,
Ә урманнар үзен саклады.

Йөри, диләр, карурманнар буйлап
Дастаннары хәтәр чакларның:
Заслоновта, диләр, разведкада
Бер шонкары булган татарның.

Үч һәм сөю аны яуга илткән,
Нәфрәтенә кушылып җыр ташкан,
Чупрәле һәм Орша урманнары
Җырчы күңеленә тоташкан.

Үтәмени яшьлек мәхәббәте —
Сагынып кайтты туган кырларын,
Минем дустым һаман бер урманчы —
Үстерә ул җырлар урманын.

Шаулый-гөрли Орша урманнары,
Чупрәледә шаулый урманнар,
Көйли кебек алар дуслык җырын,
Тыңлагызчы шуны, туганнар [1].

---

[1] «Илле яшьтәгеләр» исемле китаптан. Башкортстан китап нәшрияты, Өфе, 1975.

# Семен Данилов,

*якут шагыйре*

## Шагыйрь дуска

Үтә гомер чәчкә чаллар сирпеп,
Ә күзләрдә шул ук гаҗәпсенү:
Солдат юлындагы засада күк,
Юбилейга юлыгу хаҗәтмени?!

Котылгысыз ләкин. Шулай да мин
Раслый алам: чәчтәмени тылсым...
Картлык килсә килсен, тик туган ил
Мәңге яшь һәм мәңге гүзәл булсын.

Аңладык без ул тылсымлы хисне,
Озын буйлы дустым — син бит, җаным, —
Кара урманнарын Беларусьның
Айкап йөргән татар партизаны.

Егетләрең төрле яктан иде.
Дәһшәт салып фашист йөрәгенә,
Шымчыларның котын алып көн дә
Куптәнме соң әле йөргәнеңә.

Син сукмакта — иңдә автоматың,
Каенлыкта туктап кетәсең дә,
«Тел» аласың. Землянкага кайткач
Шигырь туа төнлә туган телдә.

Идел егете, синнән үлем үзе
Курка иде бугай. Суык чакта
Җылыта иде дусны шаян сүзең.
Илгә антың уяу торды сакта.


Ара ерак, ләкин син янәшә,
Һәм янәшә безнең дуслык һаман.
Сине күргән саен еллар аша,
«Дусларымнан уңдым!» дип куанам.

Гомер үткәненә һич үкенмик,
Алда әле байтак дәртле еллар.
Солдат юлындагы засада күк
Сагаласын, әйдә, юбилейлар [1].

Әхмәт **РӘШИТОВ** тәрҗемәсе.

---

[1] «Җир авазлары» исемле китаптан. «Огонек» журналы китапханәсе сериясе, 15 сан, 1977 ел, Мәскәү, «Правда» нәшрияты. Русчага Илья Фоняков тәрҗемәсе. Якут телендә «Хотугу Сулус» («Төньяк йолдызы») журналында басылган.




*Хәсән Туфанның З. Нурига автограф белән бүләк иткән китабы.*

●

Мәскәүдә «Советский писатель» нәшрияты 1975 елда бастырып чыгарган «Дуслар-полкташлар» («Други-однополчане») исемле зур китапта илебезнең ике йөз әдибе турында шигъри парчалар (пародия, портретка штрихлар, эпиграмма, теләк һәм киңәш сүзләре һ. б.) тупланган. Аларны күренекле рус шагыйре, Бөек Ватан сугышы елларында безнең Казан авиация заводында эшләгән, хәзер «Крокодил» журналы редколлегиясе члены Сергей Васильевич Смирнов язган. Ә рәссам Наум Лисогорский исә парчаларның һәркайсын китапның аерым битенә басылган төсле шарж-портретлар белән тулыландыра. «Шундый четерекле эшкә алынып,— дип язалар алар китапка керештә,— безнең каләмдәш дусларыбыздан берсенең дә алар инде күптән казанган авторитетын какшатмабыз дип ышанабыз. Чөнки китапның исеме үк безнең изге ниятебез турында кычкырып тора».

Полкташлар турындагы шул китапта шагыйрь Зәки Нурига багышланган сәхифә дә бар. Түбәндә шуннан «Дифирамбическое» дигән парчаның тәрҗемәсе бирелә. Туган телебездә бу шигырь, болай яңгырарга тиеш дип уйлыйбыз:

**— Кем ул җырлап таңны зурлый!**
**— Зәки Нури!**
**— Кем явызларга шәп чәпи!**
**— Нури Зәки!**
**Төрле итеп оста язсын,**
**Гомере бушка үтмәсен,**
**Илһам чишмәсе дигән бер**
**Изге Чишмә кипмәсен!**

## Зәки Нури

# СССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ V СЪЕЗДЫНА ӘЗЕРЛӘНГӘН ЧЫГЫШ

*Июль, 1971 ел*

„Бөтен гомерең максатлы үтсен. Яшәвеңнең һәр минутына, сәгатенә, атнасына, аена, елына, тормышыңның билгеле бер чорына максатың булсын»,— дип язган Лев Толстой.

Бездә һәр сәнгать кешесе гражданлык намусы кушканча, партия һәм халык алдында талантлары һәм иҗатлары өчен зур җаваплылык тойган хәлдә, нәкъ менә шундый ачык максат белән иҗат итә. Язучының максаты — халык һәм заман турындагы сәнгатьчә белем хәзинәләрен кешеләргә биреп, тормыш-яшәешебезне баетырга омтылу.

Тормыш белән бәйләнеш, яңа бишьеллык эшләрендә язучының урынын билгеләү, заманыбызның эзләнүчән һәм көрәшүчән геройларына ничек һәм кайсы яңа яктан якын килү — безнең съезд тикшергән төп мәсьәләләр менә шулар.

Кешенең матурлыгын без, гадәттәгечә, барыннан да элек хезмәттән эзлибез, хезмәттә күрәбез. Файдалы хезмәт — тормышның төп максаты. Чын шигърият хезмәт булган җирдә генә була ала. Димәк, без хезмәтне, Горький аңлаганча, сәнгать итеп аңларга өйрәнергә, хезмәт процессында үскән кешене төп герой итеп алырга тиешбез.

Безнең әдәбиятларның төрле чорында хезмәтне матурлык, тормыш поэзиясе итеп тасвирлаган әсәрләрнең әйбәт үрнәкләре бар.

Татарстан язучыларының да тормышның күп төрлелеген, кешеләрнең катлаулы язмышларын чын сәнгатьчә образлар аша югары осталык белән тасвирлаган китаплары киң җәмәгатьчелеккә билгеле. Болар — классикларыбыз Галимҗан Ибраһимов белән Шәриф Камал романнары һәм хикәяләре, Гомәр Бәшировның авыр сугыш елларында татар хатын-кызлары хезмәте турындагы романы, Габдрахман Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» һәм «Ак чәчәкләр» романнары, Фатих Хөснинең игенчеләр турындагы повесте, Гариф Ахуновның Татарстан нефтьчеләренең зур фидакарь хезмәтенә багышланган әсәре, Сибгат Хәкимнең нефтьчеләр, бакчачылар турындагы һәм Ленин темасына поэмалары.

Үз вакытында яшь Һади Такташ искиткеч шәп шигъри картиналар иҗат иткән иде. Әле утызынчы елларга аяк басканда ук киләчәк заман кешеләренә, коммунизмда яшәячәк кешеләргә багышлап, ялкынлы хатларын язды ул. Аның лирикаһы халыкның гомуми тормышы белән ныграк бәйләргә чакыруы безнең йөрәкләребездә хәзер дә чын яңгыраш таба.

Шагыйрь үзенең каләмдәшләрен тормыш дәреслегенә ирешергә чакырды: шигырь һөҗүмчән, нәтиҗәле, тәэсирле һәм матур булырга тиеш. Муса Җәлил һәм башка танылган шагыйрьләрнең әле сугышка кадәрге үк иҗатлары да шундый ук тормышчан рух белән сугарылган иде.

Бик күп остаз әдипләр һәм язучы булырга омтылучы яшьләр замандашларыбызның эше һәм тормышы турындагы әсәрләрен булачак геройлары арасында яшәп, эшләп язуны иҗат кануны итеп алдылар. Мәсәлән, дистәләп татар язучысы нефтьчеләр турында язар өчен нефть чыккан җирләргә күчеп киттеләр. Әйбәт кенә урнашып, шунда яшиләр, эшлиләр, иҗат итәләр, әсәрләренең иң яхшылары еш кына рус теленә тәрҗемә ителә. Европага кара алтын илтүче «Дуслык» нефть үткәргече башланган Әлмәт шәһәрендә РСФСР Язучылар союзы үзенең яңа бүлеген ачты. Хәзер бу бүлек язучылары иҗат командировкалары сорап беркайчан да, беркемне дә борчымыйлар. Иҗат командировкасы — ул суга батудан саклый торган резин боҗра киеп, тормыш диңгезенең өстеннән генә йөзеп үтү дип кәләләр дә әле.

Туган туфрагына тамырларын тирән җибәргән агач кына ябалдашлары белән күккә үрелә һәм мул итеп җимеш бирә ала. Чынбарлыкның тирән каршылыкларын сизгер күзәтеп, заманның зур вакыйгаларын дулкынланып, бөтен күңелләре белән кичерүче совет язучылары гына заманыбызның алга барышы турындагы иң яхшы китапларын яздылар һәм язалар. Бу әсәрләрдә тормыш өчен әһәмияте зур булган проблемалар сәнгать алымнары белән анализлана. Халыкның табигый тормышы көн саен яңа геройлар тудыра, коллектив һәм шәхес арасында яңа мөнәсәбәтләр барлыкка килүен раслый, көндәлек тормышыбызга хезмәткә бәйле бөтенләй яңа традицияләр кертә. Менә бер мисал. Тугызынчы бишьеллык план буенча илебездәге иң зур автомобиль заводы төзелә торган безнең Чаллыда Вәзыйх Мәүликов бригадасы эшли. Герой-шагыйрь Муса Җәлил — бу бригаданың почетлы члены. Мусаның эш нормасын бригада членнары көн саен кимендә 150 процентка үтәп баралар, ә акчасы Тынычлык фондына, көрәшүче Вьетнамга ярдәм фондына, культураны үстерүгә китә.

Һәрбер яңа китап шушындый яңа үсентеләр өчен игелекле туфрак булырга тиеш. Югары художестволы һәм бары тик шушындый проблемалы китаплар белән генә без алдан билгеләнгән схема буенча, әллә кайчан булып үткән вакыйгаларны сурәтләүче иллюстратив әсәрләргә юлны бикли алабыз. Юкса андый китаплар тегермәнне инде агып узган су белән әйләндерергә маташуны хәтерләтер иде.

Карл Маркс буш вакытны шәхеснең төрле яктан үсүе өчен иркен җирлек дип атады. Хәзер, атнага ике көнлек ялга күчү сәбәпле, совет кешеләренең елына йөздән артык ял көннәре бар. Бу бит, иптәшләр, җәмгыять өчен әйтеп бетергесез байлык. Зур эчтәлек белән тулган ялның бөек культурасын җырлау, шәхесне рухи яктан баетучы ял вакытындагы замандашны күрсәтү — хәзер безнең үткен проблемалы икенче бурычыбыз. Ә безнең көлү, безнең сатира ял вакытларын акыллы, матур, файдалы итеп үткәрә белмәүче кешеләрне каты чыбыркыларга тиеш.

Совет әдәбияты тагын да катлаулырак һәм күпьяклырак мәсьәләне — совет кешесен интернациональ гаиләдә күрсәтү бурычын чишәргә тиеш. Хәзер кискен чикләнгән милли кысаларда гына яшәүче шәхес турында сүз әйтү бик читен. Бу мөмкин дә түгел. Брест крепостенда утыз сигез милләт хәрбиләре сугышты. Татарстан нефтьчеләренең күпмеңле коллективы илледән артык милләт вәкилләреннән тора. Безнең бораулаучы һәм промыселчыларны нефть табу һөнәренә руслар, украиннар, әзербайҗаннар һәм башка осталар өйрәтте. Алар җитәкчелегендә зур хезмәт һәм интернациональ тәрбия мәктәбе үткән элеккеге шәкертләр инде үзләре Мангышлак һәм Белоруссия нефтьчеләренә ярдәм итәләр. Алар Төмән һәм Иркутск өлкәләрендәге нефтьле җирләрдә дә төрле милләт вәкилләре белән бик тиз уртак тел таптылар. Составы буенча күпмилләтле мондый коллективларда, КПССның XXIV съездында әйтелгәнчә, шәхеснең яңа, социалистик сыйфатлары формалаша, дуслык, туганлык һәм иптәшләрчә ярдәмләшү сыйфатлары барлыкка килә.

Интернационализм — бу безне рухландыручы идея, яшәеш нормасы, безнең дөньяга карашыбыз.

Бер-берсен үзара тулыландыручы «интернациональ» һәм «милли» дигән төшенчәләрне без күптән инде образлы рәвештә бер көймәнең ике ишкәге итеп күзаллыйбыз. Бер ишкәк белән генә ишсәң, алга китә алмыйсың да алмыйсың, ә кыек юлга борылуың бик мөмкин.

Бу тема белән бәйләнгән нәрсәләрнең әле күбесе безнең иҗатта чагылдырылмаган, сәнгатьчә ачылмаган. Бирегә сүз бер милләт язучысының үз әсәрендә икенче милләтнең улын яки кызын сурәтләве турында гына бармый. Моңа без Пушкин һәм Толстой, Короленко һәм Горький, Шевченко һәм Галимҗан Ибраһимовларның бөек үрнәгендә өйрәндек һәм өйрәнәбез.

Хәзер безнең җәмгыятьнең төп ячейкасы булган күп милләтле коллективлар, төрле читенлекләрне җиңеп, психологик киртәләрне җимереп ничек формалашканнар һәм формалашалар соң? Ничек итеп төрле милләт кешеләре бергәләшеп үзләрендә уртак патриотик һәм интернациональ горурлык тойгылары тәрбиялиләр? Шәхескә коллективның тәэсире нинди? Шушындый һәм башка бик күп сорауларга җавап бирердәй китаплар аз әле бездә. Юк-юкта кайбер интернациональ коллективларда башка милләт кешеләренә югарыдан гына карап, үз милләтенең, янәсе, гадәт-

тән тыш икәнлеген искәртергә яратучы мактанчыклар да очраштыргалый. Менә шундыйларга язучының үткен каләме белән чәнечкеле сүзне кыюрак әйтергә кирәк. Кызганычка каршы, мондый зарарлы мавыгулар әдәбиятта да күренгәләде.

Интернациональ әдәплелек һәм дуслык мөнәсәбәтләрен безнең китапларыбыз һәр кешедә даими тәрбияләргә тиеш. Беркемнең дә, беркайчан да башка милләт кешесенең горурлыгына ямьсез кагылып, аңа кимсетеп карарга хакы юк. Ул да синең кебек үк кеше бит: бәхетен һәм хезмәтен, икмәген һәм коякы җылысын синең белән уртак бүлешә.

Интернациональ коллектив турында язасың икән, син, әле югарыда әйтелгәннәрдән тыш, теге яки бу милләт халкының холкын-фигылен, фикерләү рәвешен, гореф-гадәтләрен, тарихын, килеп чыгышын, хәзерге көндә ирешкән уңышларын бик җентекләп өйрәнергә, төгәл белергә тиеш буласың. Ә бу халыкларның бүгенге көне инде кичәгесенә охшамаган. һәр край, республика яки өлкә бу турыда ышандырырлык, бәхәсләшергә урын калдырмаслык итеп, саннар белән исбатлап сөйли ала.

Татарстан республикасы Ленин декреты белән 1920 нче елда оештырылды.

Билгеле булганча, язучыларның беренче Бөтенсоюз съездында шул вакыттагы татар әдәбияты турында да аерым доклад тыңлана һәм Горький татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләренә зур бәя бирә. Андагы персонажларның хезмәтне яратулары бик охшый аңа. Ләкин бу персонажларның күбесе авыл хезмәтчәннәре була, чөнки ул вакытта эшче сыйныфы республика халкының 22 процентын гына тәшкил иткән. Хәзер җәмгыятьнең әлеге алдынгы отрядында — гализҗәнап эшчеләр сыйныфы сафында халыкның яртысы диярлек. Зур промышленность коллективларындагы хезмәт темасын сәнгатьчә күрсәтү, алда инде телгә алынган профессиональ осталыктан һәм тормышны тирәнрәк өйрәнүдән тыш, иҗтимагый-политик һәм, турысын әйтергә кирәк, фәнни белемнәр белән кораллануны да таләп итә. Әгәр дә кайсы да булса әдәбият тарафыннан эре планлы һәм фундаменталь әсәрләрдә эшче темасы сәнгатьчә чишелмәгән икән, моны, иң беренче чиратта, шундый белемнең, осталыкның җитмәвеннән дип аңлатырга кирәк.

Илдәге бөтен милли әдәбиятлар шактый зур үсешкә ирештеләр, һәм алар, хәтта азчылык булганнары һәм яшьләре дә, даими рәвештә, дисциплина белән киеренке эшләгәндә иң җаваплы һәм катлаулы иҗади мәсьәләләрне чишәргә сәләтле. Чөнки, халык җырында әйтелгәнчә, үткән гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да. Хәтта иртәгәге иң яхшы көн дә үткән көнне кайтара алмый.

Сүзне йомгаклап, съезд делегатлары карамагына безнең оешма кушуы буенча ике практик тәкъдим кертәм.

Беренчесе. Язучының эш вакыты һәм таланты җәмгыять байлыгы булганга, аны сакларга һәм бу эшкә махсус иҗтимагый әһәмият бирергә кирәк. Эш вакытын рациональ файдалану, безнең уйлавыбызча, уставның мәҗбүри таләбе булырга тиеш. Кайбер яшьрәк язучылар бар. Алар озак еллар буе бернинди сәбәпсез берни дә язмыйлар, иҗат җимешләре бирмиләр. Әсәрләр язудан һәм бастырудан туктаган менә шундый «язучылар» алга таба да Союз члены булып торырга хаклымы? Бәлки, вакыт ягыннан билгеле бер чикләү куяргадыр?

Икенчесе. Китапларның тиражын һәр милли республикада, өлкәдә яки округта халык саны буенча билгеләргә кирәктер. Билгеле, бу Россия Федерациясенә генә кагыла. Чөнки союздаш республикаларда тираж күләме һәр очракта төрлечә расланa. Ә күп милләтле Россия Федерациясендә иң соңгы чик әз һәм күп санлы милләтләр һәм халыклар өчен дә бер үк төрле куелган: проза — 15 мең, поэзия — 10 мең данә. Әлеге шартларда, мәсәлән, халкы 100 мең булган милләт шагыйре халкы миллион һәм күп миллионлы шагыйрь белән тираж буенча ярыша аламы? Әз санлы милләт язучысының 15 мең тиражлы китабы чыгуы бөтен гомере буена төшенә дә кермәскә мөмкин. Минем, мәсәлән, шәхси китапханәмдә бик сәләтле һәм актив эшләүче язучы Давид Кугультиновның калмык телендә 1,5 мең данә тираж белән басылган китабы бар. Китапларга бирелгән бер басманың тиражы турындагы законда ачык күренеп торган логик бәйләнешсезлек бар. Моны тизрәк бетерәсе иде.

Иптәшләр! Без күп милләтле әдәбиятның алга таба үсеш бурычлары турындагы мәсьәләне бик матур вакытта, бөтен тирә-як чәчәк атканда, җәйге кояш аерым бер кызулык белән хезмәт итеп, башакларны һәм җимешләрне мул өлгерткәндә карыйбыз. Совет язучыларының да күңелләре шул кояштай күтәренке. Иҗади уңышларыбыз да шулай ук мул һәм сыйфатлы булсын иде!

---

# ЭШ БЕЛӘН, ЯЛКЫНЛЫ СҮЗ БЕЛӘН

*Дуслык биографиясеннән*

Мәскәү яны. Язучыларның Переделкино шәһәрчеге. 1955 нче ел. Көзнең моң белән тулы, бәллүрдәй чиста һәм якты көннәре. Табигать-рәссам мул итеп төрле төсләргә манган агач ябалдашлары арасыннан бераз ашыга төшеп җил уза, кипкән яфраклар аяк астында йомшак кына кыштырдыйлар. Шаян җил каракучкыл-зәңгәр төстәге елга өслегеп шадралата. Алтынсу төскә манчылган илаһи киңлек ерактагы серле офыкларга барып тоташкан.

Шундый матур көннәрнең берсендә, без сагыз исе аңкып торган нарат бүрәнәдән салынган өр-яңа йортларга килеп урнаштык. Без дигәнем — СССР Язучылар союзының Югары әдәби курсларына (ВЛК) кабул ителеп төрле яктан килгән каләмдәшләр: украин Степан Чернобривец һәм Микола Тарновский, белорус Нина Тарас, казакъ Бердыбәк, кыргыз Камчы, литвалы Павлюс Ширвис, латыш Мейнгард Рудзитис, молдаван Ион Друце, Свердловскидан Вадим Очертин, чуваш халык шагыйре Педер Хузангай, Дагыстаннан Йосыф Хаппалаев, тувалы Степан Сарыг-Оол, Аджариядән Фридон Халваши... һәм тагын бер төркем мәскәүлеләр: Михаил Алексеев, Николай Шундик, Герман Нагаев, Николай Доризо, Николай Тряпкин... Ә өч иптәш чит илләр вәкилләре иде. Барлыгы 22 кеше. Ике ел укыйсы. Атнаның дүрт көне — теоретик дәресләр, бер көне — семинар: танылган каләм осталары безнең иҗатны анализлыйлар. Мәскәүгә бару-кайту өчен махсус автобус бирелгән...

Кыскасы, интернациональ яктан никадәр бай, матур исемнәр букеты! Йөрәкләр якынайсын өчен, бер-береңнең шәхесен, катлаулы холык-фигылен, иҗат манераларын өйрәнү өчен, аралашу өчен нинди зур мөмкинлекләр!

Гомер буена иң якын дус булып калачак каләмдәш — ерактагы якут туганым белән таныштырган ул көзгә һәм язмышка рәхмәт. Семен Петрович Данилов баш хәрефтән языла торган хөрмәтле кеше иде.

«С Ә М Ә Н!..» Үзебезнең телгә якынайтыбрак, беренче көннән үк бераз акцент белән әнә шулай эндәштем мин аңа.

Үткән көннәрне искә төшергән саен, хәтер дигән канатлы хис үзеңне намуслылык, хезмәт сөючәнлек, максатчанлык кебек сыйфатларга ия булган кешеләр белән чагыштырып, кылган эшләреңнең чын бәһасен аңларга мөмкинлек бирә.

Переделкинода Семен белән булган беренче йөгерек әңгәмә бүгенгедәй хәтеремдә калган:

— Данилов. Якут. Ерак Ленадан. Укытучы идем. Шигырьләр язам.

— «Казан ятиме». «Озын Заки». Ленага мәшһүр Иделдән «категорически» шигъри сәлам. Көлке шигырьләр язгалыйм...

— Рәхмәт, яхшы малай. Көлке капчыгы түгел, шигырь капчыгыдыр әле үзең. Тик «категорически» дигән сүзнең ни катнашы бар монда?

— Әйе, шигырьләр язам, ләкин көлкене күбрәк яратам. Сатира һәм юмор, димәк. Ә «категорически»— сугыш истәлеге ул. Белоруссия партизаны идем мин. Безнең командир Заслонов үзенең барлык приказларын «категорически таләп итәм» дигән сүзләр белән түгәрәкли торган иде. Менә шуннан бирле бу катгый сүз минем дә телгә кереп калган...



*Зәки Нури (алгы рәттә, сулдан беренче) әдәбият-сәнгать эшлеклеләре белән (1959 ел).*

Семен аз, ашыкмыйча һәм өздереп сөйли, һәр сүзен сизгерлек белән әйтә. Анык «мин» дигән алмашлыкны бер дә кулланмавы ошый иде миңа. Күпвакыт күзләре белән елмая. Нишләсә дә хәрәкәтләрне аз, чама белән генә ясарга тырыша. Бу тыйнаклык, үзгәрми торган тыныч холык күңелгә бик хуш килә. Сизелеп тора, зур шәһәрнең шау-шулы ритмнары аңа ят әле. Кыскасы, бу кешегә гадилек һәм табигыйлекне табигать мул биргән. Дөньяны ул балаларча самимилек һәм хыялый күңел белән саф килеш кабул итә бела.

Семен белән ничектер тиз һәм, әйтергә кирәк, категорически нык дуслашып киттек. Моңа Переделкино урманының айлар буе без таптаган сукмаклары һәм юллары да ярдәм иткәндер, мөгаен. Ул — тайга баласы. Минем дә урманны төп йортым дип атарга хакым бар: урманга терәлеп торган авылда туып-үскәнмен. 1939—40 елларда Амурдагы Николаевск шәһәренә китеп, зур тәзелешнең урман бүлегендә эшләдем. Инде чыгарылыш имтиханнарын бирен ятканда сугышка да бөтен группабыз белән урман техникумыннан китеп бардык. Сугыш елларындагы барлык шигырьләрне диярлек белорус урманнарында, партизан учаклары яктысында язарга туры килде.

Семен Петровичның ул вакытта инде рус теленә тәрҗемә ителгән зурлар һәм балалар өчен китаплары да бар иде. Аларны игътибар белән кат-кат укып чыктым. Мәскәүдә ул үзенең тәрҗемәчеләре белән тагын да ныграк һәм нәтиҗәлерәк аралашты. Курсташлар буларак, без бер-беребезнең шигырьләрен туган телләргә тәрҗемә итә идек. Шунысы куанычлы, Семен табигатьне «кәнфитләмичә» генә, кычкырып торган бизәкләрдән качып, әмма җыйнак һәм үтә күренмәле штрихлар белән сурәтли иде. Зурлар өчен язган шигырьләрендә ул тирәнтен фикер йөртә, истә ка-

лырлык образлар, әсәрне эчтән балкытып торырлык сүзләр эзли һәм таба, үзе турында сөйләгәндә башкаларны уйлый, шәхси кичерешләренә иҗтимагый яңгыраш сала.

Яшем һәм иҗатым белән аңардан яшьрәк буларак, бервакыт дусларча сорап куйдым:

— Кадерлем, ничек соң әле синең шулай бик җиңел һәм яхшы килеп чыга? Моның сере нәрсәдә?

— Син, яхшы малай, тагын шаяртасың! Шагыйрь халкының нинди сере булырга мөмкин? Начар язма — үзеннән-үзе яхшы килеп чыгачак...

Күргәнегезчә, биредә ул үзе шаяртты. Сөйләшү дәвам итте. Иҗат һәм аның серләре турында һәркайсыбыз үз фикерләрен әйтә. Семен Петрович кулына каләм алган һәркем өчен зарур төп дүрт сыйфатны санап чыкты. Биографияң булу. Тормышны белү. Сәнгатьле фикер йөртү. Сүз осталыгына ирешү.

«Яхшы сүз йөгәнле дә, иярле дә була»,— дигән якут мәкален кайчак хәзер дә үзалдыма кабатлыйм. Әйе, дустым Семен сүзләрне, нәкъ менә халык әйткәнчә, йөгәнләгән һәм иярләгән икән.

Характерлар бер-берсенә охшамаганлыктан, арабызда, бәлки, каршылыклар да аз булмагандыр. Ләкин эчке рухи туганлык, дөньяга карашларыбызның уртаклыгы, сүзгә, димәк, язучылык хезмәтенә, партиялелек бурычына карата үтә җаваплы мөнәсәбәт безне һәрвакыт чиксез шатландыра, берләштерә иде. Биредә Владимир Ильичның «Сүз — шулай ук эш ул»,— дип кабатларга яратуын искә төшерү дә бик урынлы булыр.

Ә бит без кайчак бәхәсләшә дә идек. Егетләрчә, бер-беребезне рәнҗетми генә, тормышта һәм әдәбиятта алдашмыйча гына.

Мисал өчен, көлке бакчасындагы тарихны, дөресрәге, уен-көлкегә бәйләнгән вакыйгаларны алыйк. Ял сәгатьләрендә яки бергәләшеп кая да булса барганда без тормышта күргән-ишеткән, кайчандыр укылган нинди дә булса кызыклы нәрсәләр турында сөйләшергә күнегеп киттек. Моны һәркем кыска һәм күңелле итеп сөйләргә тырыша. Ягъни, җитди шаяртабыз. Кайбер иптәшләр, шул исәптән Семен да, иҗаттан бүленеп торган арада китап яки газета-журнал укып утыралар, шау-шулы әңгәмәләрдән читтә булырга тырышалар иде. Партизан чакларыннан ук калган гадәт буенча, менә исә күбрәк шаярыбрак, күңеллерәк сөйләшү үзенә тарта. Семен Петровичның «Яхшы малай тагын шаярта...» дигән репликасы күзгә күренеп ешайды.

...Киеренке уку хезмәте, иҗат, әдәбият һәм сәнгать дөньясы белән якыннан аралашу хисләре белән тулы булган Мәскәүдәге ике еллык әдәби курс көннәре сизелми диярлек тиз үтеп тә китте.

Инде 1957 нче елның июненә аяк бастык.

Сугышка кадәр үк нык таралган һәм безгә яхшы таныш булган юл җырының сүзләрен кабатлар чак җиткән икән:

> **Расставанья и встречи — две части,**
> **Из которых строится счастье...**

Ныклап әзерләнәбез һәм чыгарылыш имтиханнары бирәбез. «Штепсель» (озын Зәки) һәм «Тарапунька» (ярты метрга тәбәнәгрәк Семен) ярышырга сүз куештылар: кемнең «биш»ләләре күбрәк булыр? Аз йоклыйбыз. Семен Петровичның самолет белән Якутскига җибәреләчәк әйберләрен посылкага тутырабыз. Җитмәсә, 1941 нче елның июнендә үк үткәрелергә тиешле булып та, илебезгә фашистик Германия һөҗүм итү сәбәпле, озак еллар кичегеп торган Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы безнең «кайнар» көннәр белән бергә туры килде. Декада программасына кертелгән барлык нәрсәләрне дә карыйсы килә Семен Петровичның. Ә минем аның «хезмәтчесе» булуыма, һәркайда һәрнәрсәне тәфсилләп аңлатырга, кыскасы, безгә лекцияләрдә әйтелгәнчә, интерпретация ясарга тиешлегемә шатландым гына. Бу сүзне акцент белән, юри хата белән («Ин-тер-три-па-ция»?!) әйтүем — һич кәтмәгән,

идем — Семенны кычкырып көләргә мәҗбүр итте. Беренче тапкыр! Юмор һәм сатира темасына барган эчке бәхәстә бу минем беренче җиңүем иде.

Ә инде концертлар, әдәби кичәләр, татар театры спектакльләре, рәссамнар күргәзмәсе, безнең китаплар өчен мактау сүзләрен мулдан яудырды ул:

— Рәхмәт сиңа, яхшы малай, якташларың бик әйбәтләр икән! Декада да яхшы, гадел икән — әдәбияттагы тырыш хезмәтләрең өчен сине бик дөрес бүләкләде. Молодец, тәбрик итәм!

Язучылар йортында узган чыгарылыш кичәсе, имтиханнарда гел «биш»ләр генә алган өчен, безгә шулай ук рәхмәт белдерде.

Тиздән Ленинградка коллектив белән зур экскурсиягә барачакбыз. «Советский писатель» нәшрияты бүлегеннән куанычлы хәбәр дә килеп төште: Ленинград шагыйрьләре тәрҗемәсендә минем «Без яшибез Иделдә» дигән беренче русча җыентык чыккан. Бу бөек шәһәрдә яңалык һәм шатлыкның иге-чиге булмады! Шулар белән бергә, йөрәкне кысып ала торган сагышлы хисне дә кичерергә туры килде — фронттагыча әйтсәк, сугышчан дуслар белән саубуллашу иде бу.

Хәзер, чирек гасыр узганнан соң хәтер дәфтәрен актарганда, канунныр һәрвакыт нык, изге булган бу дуслык сәхифәләренә хөрмәт һәм дулкынлану белән тукталасың. Безнең чыгарылыш бөркетләренең — идеология фронтының алгы сафында атлаучыларның бүгенге уңышлары, алар яулаган иҗат биеклекләре күңелдә зур горурлык хисләре уята. Горурланырлык эшләре һәм кешеләре аз түгел аның! Биредә РСФСРның М. Горький исемендәге һәм СССРның Дәүләт премияләре лауреатлары, Социалистик Хезмәт Герое, язучылар оешмасы җитәкчеләре, язучылар матбугатының баш редакторлары булган дистәләгән хөрмәтле исемнәрне санап китәргә мөмкин...

Ә соң Семен Петрович?!

Җәмәгать эшлеклесе буларак, ул үз республикасының Верховный Совет депутаты, РСФСР Язучылар Союзы идарәсе секретаре һәм Якутия Язучылар союзы идарәсе председателе вазифаларын башкарды.

Ә шагыйрь буларак?

> Юк, язмыйдыр кебек... Гүя
> Җанлы шигырь үзе ул.
> Чөнки аның һәр сулышы
> Үзе шигырь сүзе ул...

Кеше буларак?

Миңа Семен белән дуслашмауны күз алдына китерүе дә куркыныч...

Әйе, без аның белән 1957 нче елның июлендә Мәскәүдә аерылыштык. Ләкин арабыздагы урталык һәм бергәлек һаман саен көчәя, тирәнәя генә барды. Таң калырлык хәл: бу тормыш дигәнең язмышларны кайчак шундый нык итеп бәйләп, төенләп куя — аны бернинди көч тә, тәкъдир дә кире сүтә, аера алмый икән!.. Якутиядән килгән беренче хатлар да чын күңелдән әнә шул хакыйкатьне раслый иде:

«...Мөгаен, безнең сыман ике телдә сөйләшүчеләр сирәк дуслашадыр. Сине бик еш искә алам, кыен чакларымда: «Зәки булса иде!» — дип куям, шатлыклы минутларымда: «Әй, аның белән дә бергә булсак!» — дип уйлыйм. Гомумән, бәхетле ике ел эчендә сиңа шулкадәр күнеккәнмен икән, хәзер инде янымда бик тә әһәмиятле нәрсәләрнең юклыгын сизәм. Синең шаянлыктан башка (гәрчә алар еш кына ачуымны китергән булсалар да), синең оптимистик көлүеңнән башка дөньяда яшәүләре бик тә авыр икән...» (январь, 1958).

Шулай итеп, ике арада хатлар — йөрәк илчеләре йөри башлады: бер-беребезгә кызыклы нәрсәләр, тормышта һәм иҗаттагы яңалыклар хакында язабыз, нәрсәдер сорыйбыз (таләп итәбез, дусларча фәрман бирәбез!..) һәм болар барысы да һәр ике як тарафыннан «категорически» төгәл үтәп барыла. Югарыда китерелгән өзектән Семен Петровичның тормыштагы күңелле өлкәдә — юмор һәм сатира үрнәкләренә тамырдан борылыш ясавын сизгәнсездер, мөгаен. Шулай булмый ни! Мин бит аңа бу хакта тулы бер агитацион трактат язып салдым: үземнең партизанлык биографиясенә конкрет таянып, сугышның иң авыр минутларында да төшенкелеккә бирелмәвебезне, Твардовский поэмасындагы Василий Теркин сыман бер-беребезне юату, уен-көлке һәм

мәзәк сүзләр, очкынлы яисә шаян фразалар белән рухны, кәефне күтәрүебез турында ныклап аңлаттым.

Әле шуларга Гогольнең: «Яхшы, якты итеп тирән һәм изге күңелле кеше генә көлә ала»,— дигән сүзләрен дә өстәдем бугай. Хат Голсуорсиның «Юмор хисен югалтма. Кеше өчен ул роза чәчәгенә хуш ис кирәк булган шикелле үк зарури»,— дигән чакырулы сүзләре белән тәмамланды. Һәм, ниһаять, шушы темага, Семенның үзенә багышлап «Елмаю-көлүне яклап» дигән шигырь яздым.

**Шаян-шук сүз — үзе зур көч!**
**Шуны яхшы белү кирәк.**
**Йөрәк еламасын дисәң,**
**Елмаю һәм көлү кирәк.**
**Кемгә яхшы, кемгә яман —**
**Шуны гадел бүлү кирәк:**
**Шуны җыр итә алырлык**
**Елмаю һәм көлү кирәк.**

Аңа багышланган шигырьләр күңелнең балкып киткән чакларында соңрак та язылды...

...Тора-бара Семенның барлык хатларына диярлек җылы һәм эшлекле елмаю үтеп керде.

— Күптән түгел үзебезнең Себер буйлап йөреп кайттым. Биредә инде кыш: 15 нче май көнне битемне өшеттем.

— Татăр әдәбиятының акшакалы[1] буларак сиңа язам: безнең нәшрият Муса Җәлилнең зур гына сайланма җыентыгын әзерли. Кичекмәстән татарча оригиналларны, булдыра алсаң, подстрочниклар җибәр. Шушы теләгемне үтәсәң — тагын да яхшырак малай икәнлегеңә ышаначакмын!

— Быел кечерәк кенә дача эшләттем әле... Менә шунда туңып яткан көннәребез (1958, июнь).

Семенның үзенә түбәндәгеләрне хәбәр иткәнмен, сораганмын, җибәргәнмен, алганмын:

— «Казан утлары», «Азат хатын» журналларында, татар Ленинианасы томнарында (алты китап) тәрҗемә итеп бастыру өчен якут шигырьләре.

— Тәрҗемә итү һәм татарча бастыру өчен якут мәкальләре һәм әйтемнәре. Сайлап алу өчен революциягә кадәр үк чыккан якутча-русча 3 томлы сүзлек килгән.

— Партизан язмаларын берләштергән татар телендәге китабымны җибәргәнмен (русчага тәрҗемәсе эшләнеп кенә ята иде).

...Шул вакыт эчендә Семен Петрович мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен минем «Таныш булыйк» дигән китапны якутчага тәрҗемә итеп бастырган. Бу китапны кечкенә улына укуы хакында болай дип язды: «Ул сине «Зәки Нуль» дип атый...» (Семен тагын шаярта!). Гаиләдә аны «Чиэстэ Бухатыыр» (камыр батыр) дип йөртәләр икән. Монысы да шаяртудыр дип уйларга кирәк... Семен, партизан китабын алганнан соң, күрәсең, аны Якутиядә яшәүче һәм эшләүче якташларыбызга биргән: «Алар китабыңны үтереп мактадылар. Берсе хәтта матбугатка язам дип тә янады...» Аннары «Дуслар китабы» җыентыгына кертү өчен яхшы гына фоторәсем һәм шигырьләр сорап яза. Азакта тагын елмаю: «...айлар буе тайгада югалып йөрим. Быел мин 10—13 потлар чамалы бер болан һәм 4 кыр кәҗәсе, исәпсез күп үрдәк һәм куяннар атканмын, дип шаярталар...» Аннары тагын: «17 майда искитмәле рекорд куйдым — таң сызылган арада кырыклап үрдәк атып төшердем» (1963, июнь). Хат эчендә Семенның чыннан да үрдәкләргә уралып төшкән күңелле фоторәсеме дә бар иде...

Сизелә, дустым мине үзенең тайгалы ягы белән кызыктырмакчы була: «Мартапрельне Заполярьеда, кая да булса Колымада... яки Төньяк Боз океаны утрауларында үткәрергә уйлыйм. Командировка алып, килеп чыгар идең, ичмасам... Шәп идея бит бу! (1958, январь)... Яңа елда төньяк балкышын күрергә карлы-бозлы якларга кил әле (1959, январь)... Син безгә ничек тә килеп чык. Яңа ел безнең очрашу елы — синең Якутиягә сәфәрең елы булсын. Уруй-Айхал! (1961, февраль)... Без һәрчак көта-

[1] Сүз уйнату: аксакал сүзеннән «ак шакал» ясау.

без, сине үзебезнең өйдә күрәсебез килә (1969, октябрь)... Хәбәрләреңне һәм үзеңне көтәм — елмаеп торган чагыңны күрәсем килә...» (1970).

Республикабызның Язучылар союзындагы зур хезмәтләр һәм җәмәгать эшләре миңа Казаннан озакка китәргә мөмкинлек бирмиләр иде.

Семенның үзенә бәхет тизрәк елмайды — 1962 нче елның көзендә ул Казанга килеп төште! Әдәби тәрҗемә мәсьәләләре буенча РСФСР Язучылар союзы оештырган киңәшмәгә (тема: «Танышлыктан — туганлыкка»). Шатлыгыбызның иге-чиге юк иде! Ике көн киеренке эшләдек, аннары — шәһәр буйлап йөрү, башкалабызның атаклы урыннары белән танышу. Семен Петрович минем фатирда яшәде: өч төн буе йокы эләкмәде диярлек: сорау-сорашулар, китап актарулар, милли ашлардан авыз итү... Семен туганнарча, ләкин үзенә аерым игътибар итү кирәкмәвен сиздерергә тырышып, йөрәгенең шаярткалавы хакында беренче тапкыр әйтеп куйды. Беләм, сизәм: ул беркайчан да артыгын әйтмәс. Аның бу классик гадилеге һәм ышандыру көче гомергә онытырлык түгел. Һәрвакыт төгәл йөри һәм тиешле шөребен борганнан соң 15 секунд дәвамында будильник сыман чылтыри торган кул сәгатемне бүләк иткәндә дустыма түбәндәге теләк-фәрманны да кушып бирдем: «Шушы сәгать буенча яшә, сиңа ул бәхетле, сырхаусыз, иҗади тормыш минутларын озын-озак еллар буе санасын!»

Безнең алдагы очрашулар — елына ике-өч тапкырдан ким түгел — автономияле республикалар Союзларының җитәкчесе буларак, Мәскәүдәге пленумнарда, СССР һәм РСФСР язучыларының съездларында, бөтенсоюз масштабындагы кайбер чаралар вакытында дәвам итте. Семен Петрович миңа да астма дип аталган яман, бәйләнчек чир ябышканын белә иде. Шуңа күрә саубуллашканда бер-беребезгә һәрчак бер үк теләкләрне юллыйбыз:

— Йөрәгеңне сакла!

— Әсмага[1] бирешмә!

Ниһаять, 1975 нче елда Якутиянең «күз иңләмәс чиксез киңлекләрен»[2] күрү теләге чынга ашты: 21—30 июньдә үткәрелгән рус әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашырга туры килде. Сергей Михалков, Сергей Смирнов, Антонина Коптяева, Муса Гали, Виктор Тельпугов, Давид Кугультинов, Олег Шестинский, Семен Шуртаков составындагы безнең группа күпмиллэтле Россия әдәбиятыннан вәкил булып барды. Ул көннәр истәлеген чагылдырган материаллар Якутия китап нәшриятында төсле альбом (1975) һәм «Сокландыргыч дуслык бәйрәме» (1976) дигән китап рәвешендә дөнья күрде.

Вакыт агышы безне һәр мизгел саен кичәге көннән ераклаштыра бара. Әмма без, һәр көнебезне авыр һәм иҗади хезмәт белән баета барып, тайпылышсыз рәвештә киләчәкне якынайтабыз, үзебезнең язмышыбызны бишьеллыклар тарихы сәхифәсенә, Ватаныбыз һәм республикаларыбызның кайнар сулышына кушабыз. Бу сафта, безнең арабызда дустыбыз Семен Петрович юк инде... Әмма аның туган җиренә, баһадир Ватаныбызга, дусларына булган сүнмәс мәхәббәтен дусларының йөрәге һәрвакыт сизә һәм бу хакта иң якты хатирәләр саклый.

*Март, 1981 ел.*

# ҺАМАН ЭЗЛӘП ИҢ МАТУР, ИҢ ЯҢАНЫ...

Тәрҗемә проблемаларының теоретик һәм практик әһәмияте турында конкрет һәм эшлекле сөйләшүләргә һәрвакыт зур игътибар бирелә, чөнки бу — каләм осталарының массаларны интернационализм һәм халыклар дуслыгы рухында тәрбияләү буенча төп һәм конкрет эше. Тәрҗемәче иҗаты тугандаш әдәбиятларның иң күренекле әсәрләренә илебезнең барлык почмакларына барып җитәргә,

---

[1] Семен Петрович биредә сүз уйната: астмага, диюе.
[2] «Якут җирендә сөйләшү» исемле шигырь юллары.

дөнья әдәбияты мәйданына чыгарга юл ача. Тәрҗемә бер халыкның культура казанышын икенче халыкка җиткерә, аларны туганлаштыра, үзара элемтәләрен ныгыта. Ниһаять, тәрҗемә — әдипләр иҗатына яңа этәргеч бирүче илһам чыганагы да, яңа рухи байлыклар чишмәсе дә ул. Тәрҗемәнең бик уңышлысын, ким дигәндә, яхшысын, шуңа күрә дә үзенә бер бәйрәм — иҗат бәйрәме дип бәяләргә кирәк. Русның зур шагыйре һәм тәрҗемәче Павел Антокольский шигъри тәрҗемә хакында болай дип язган иде:

**Бер-берсенә китап юллый шагыйрьләр,**
**Йөрәкләргә сала тирән эз алар.**
**Һәм гасырлар, еллар аша ерактан**
**Дуслык кулын алар кыю сузалар.**
**Ә анныры, серен аңлап ят телнең,**
**Бези щагыйрь һәм баета үз телен.**
**Һаман эзләп иң матур, иң яңаны**
**һәр иҗатчы үзен һаман үстерер.**

Үзебезнең шушындый гражданлык бурычыбызны үтәп, без уртак хәзинәбезне ишәйтәбез, бер-беребездән осталыкка өйрәнәбез. Билгеле булганча, бернинди миллилек тә аерым хәлдә, «саф килеш» тора алмый, милли күренешләрнең һәркайсында башка халыклардан алынган һәм иҗади үзләштерелгән элементлар була. Бу уңайдан, Азия һәм Африка илләре язучыларының Алма-Атада уздырылган V Конференциясендә (1973 ел) ишетелгән сүзләр искә төшә. Угандадан килгән әдәбият белгече менә нәрсә диде: «Бүтән әдәбиятларны ятсынган язучының ташбакага охшап калуы бик мөмкин. Ташбака бит иң уңдырышлы елларда да туйганчы ашый алмаган, ди — аңа өстендәге таш күлмәге комачаулаган».

Әйбәт тәрҗемә — дөресрәге, милләтләр арасындагы туганлыкны чагылдырган елъязма — бер-берсенә бик якын булган, бер-берен яхшы аңлаган ике йөрәкнең бердәм тибүе шикелле нәрсә, биографияләр уртаклыгы ул. Һәм тәрҗемәче, һәм тәрҗемә ителүче автор — дуслык һәм мәхәббәт кебек, бер-бере өчен яңгыраган кайтаваз сыман — һәркайсы «күпме алса, шуны кайтара» (Герцен). Өстәп шуны да әйтик: мондый хезмәттәшлек фикер бердәмлеге белән көчле. Һәм бу язучыларның икесе дә гомумкешелек хакыйкатен раслауда милли булып кала. Рус шигърияте һәм тәрҗемә эшенең зур остасы Леонид Мартынов нәкъ шул фикерне үзенең шигъри юллары белән дә раслый бит:

**Барыңны бүлеш бүтәннәр белән!**
**Һәркем тырыша шулай эшләргә:**
**Кеше кайгысын чит-ят итмәскә,**
**Пыскыган утка ялкын өстәргә.**

**Син дә су сибеш, син дә нур өстә —**
**Кайда үссә дә гөлләр сулмасын.**
**Җыр дигән байлык — уртак хәзинә,**
**Күңел сандыгың бикле булмасын.**

Ике иҗади шәхес — автор белән тәрҗемәченең мондый дуслыгы аларның фикер уртаклыгы, политик карашларының төгәллеге, гражданлык хисләренең бердәмлеге һәм художество зәвыкларының охшашлыгы белән көчле.

Үз заманында А. П. Чехов гаять кыю, кирәгенчә кырыс һәм бик кискен фикер әйтә: «Гомерендә бер агач та утыртмаган кеше үзе утын агачы ул...» Яңгырашы бик үк матур булмаса да бернинди дорфалык юк биредә. Әдәби практикага күчергәндә, аны болай аңларга кирәктер кебек: булдыра алган хәтле көч куеп, вакытын һәм илһам җегәрен кызганмыйча, һәр калăм остасы үз күңелен тарткан бүтән авторның яки авторларның бүтән әдәбиятлар офыгын да ниндидер яңа ачышлар яки табышлар белән киңәйтә алган әсәрләрен тәрҗемә итәргә тиеш. Шулай булмаганда ул үз иҗа-

ты үрнәкләренең бүтән телдә яңгырашын күтәргә — өмет итәргә яки дәгъваларга хаклымы икән?

Язучылар җәмәгатьчелеге, төрле киңәшмәләрдә һәм хәтта съездларда чыгышлар ясап, күптән инде бөтен тәрҗемә эшләрен ил күләмендә планлаштыра, оештыра, координацияли торган бер үзәк кирәклеге турында сүз алып бара — тәрҗемәләр нәшрияты турында хыяллана. Бу, безнеңчә, бик урынлы. Хәтта исеме дә уйланылган инде аның: «Халыклар дуслыгы» нәшрияты!

Безнең илебездә — интернационализм һәм кешенең тормыш законы булып әверелгән шартларда, халыкларның культура казанышларын уртаклашу мөмкинлекләре һаман арта барган саен тәрҗемә эше көннән-көн киңрәк колач ала, ул инде һәм культура-политик күренеш, һәм барлык республикалар тормышының сулышы буларак, күптән инде дәүләткүләм әһәмият казанды. Шуны гына искә төшерү дә җитә: тәрҗемә китаплар чыгару өчен махсус нәшрият оештыру совет властеның культура өлкәсендәге беренче эше булды. Хәзер безнең илебез — әдәбият иң күп тәрҗемә ителә торган держава.

Бу өлкәдәге үсеш-казанышларга китергән төп факторлар исә менә нидән гыйбарәт: беренчедән, партиябезнең культура революциясен тормышка ашыру юнәлешендәге төп карарлары. Икенчедән, барлык республикаларда экономика һәм культураның моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә үсеше. Өченчедән, барлык республикаларда әдәби көчләр сафы ныгыды, сәләтле язучылар күпләп үсә. Хәзер инде һәр милләт язучысы, заманында Максим Горький хыялланганча, үз халкы өчен генә түгел, Советлар иленең барлык халыклары өчен дә иҗат итә. Китапларыбыз җитмештән артык телдә чыга. Шулар арасында тәрҗемә әсәрләрнең өлеше зур һәм аларны тәрҗемә сәнгатенең иң тирән серләрен һәм нечкәлекләрен белүче осталар эшли.

СССР Язучыларының II съездында (1954 ел, декабрь) күп милләтле әдәбиятыбызның өч зур әһеле — Павел Антокольский, Мохтар Ауэзов һәм Максим Рыльский бергә язган махсус доклад тыңлаганнан соң тәрҗемәче юлындагы кайбер теоретик киртәләр, аның эшен кыенлаштыра, кәефен кыра, эчен пошыра торган буташтырулар бетерелде инде.

Әйтик, бүген Шекспир һәм Һейне, Пушкин һәм Лермонтов, Нерис һәм Межелайтис, Тукай һәм Җәлил төрле телләрдә укылалар икән — поэзияне тәрҗемә итеп булмый, бер телдән икенче телгә адекват тәрҗемә эшләү гомумән мөмкин түгел, дигән фикерләрнең нигезсезлеге, мәгънәсезлеге көн кебек ачык инде. Үзара тыгыз аралашулар эш мәйданыбызны һаман киңәйтә. Язучы белән язучы, шагыйрь белән шагыйрьнең шәхси очрашулары, иҗади элемтәләре өчен бөтен юллар ачык. Үзебезнең теләсә кайсы республикада яшәүче әдипләр һәм чит илнекеләр белән иҗади элемтәгә бик тиз керә алабыз. Язучылар союзы командировкаларын алып була: вакытыңны планлаштыр да бар, әдәбиятын тәрҗемә итәргә теләгән республикада кирәк хәтле йөр, халкының тарихын, культурасын, көнкүрешен һәм гореф-гадәтен өйрән. Ләкин тәрҗемә өчен әсәрләр сайлаганда, художник буларак, йөрәгең авазына колак сал: ул тугандаш әдәбиятларның иң яхшысы һәм әһәмиятлесе, синең укучың өчен иң кирәклесе булсын. Икенче төрле әйткәндә, тәрҗемә өчен сайланган әсәргә аны үзең язарга җыенып та син әле кәгазьгә төшерергә өлгермәгән кульязма итеп кара.

Әдәби тәрҗемәнең сыйфаты һәм эстетик таләпләре җәһәтеннән дә томан каплаган үзәннәр, ачыкланып җитмәгән мәсьәләләр юк шикелле. Тәрҗемәчеләр алдына куелган таләпләр зур һәм катлаулы, ләкин аларның берсе дә чын талант күтәрә алмаслык, ерып чыкмаслык түгел: оригинал язылган телне һәм үз телеңне бик яхшы белеп кенә эшләү зарур. Хәрефкә дә ябышып ятма, авторда юкны да аңа өстәмә. Оригиналның шигъриятенә, аның яңа формаларына, милли үзенчәлекләренә бернинди хилафлык кылмасын. Инде әйтеп үткәнебезчә, тәрҗемә өлкәсендә шулай эшләп кенә гомумкешелек хакыйкатенә тугрылыклы булып калу мөмкин. Моңа ирешүнең төп юлы — үз стилең, үз телеңдә шигырь язуның законнары нигезендә эш итү. Җыеп әйткәндә, синең күңелдә туган шигъри сандугач оригиналның шигърият бакчасында ят кош булмаска тиеш.

Әлбәттә, һәр гөлнең үз чәчәге дигәндәй, һәр очракның аерым бурычлары була һәм алар конкрет эш барышында гына хәл кылыналар. Гомуми киңәшләр, алдан әйтеп куелган тәкъдимнәр булышлык итә алмый.

ЮНЫС ӘМИНЕВКА 60 ЯШЬ

# КЕШЕЛЕКЛЕ ИҖАТ



Сүз осталарының үзләре турында язуы җиңел түгел. Драматурглар турында язу тагын да читенрәк. Ни өчен шулай? Драматургия әдәбиятның иң үзенчәлекле төрләреннән берсе булганга микән әллә? Драма әсәренең гасырлар буе чарланган үз формасы, үз калыбы бар. Монда яңалыкка ирешү гаять кыен, шуңа күрә драматургның әдәбиятка һәм сәнгатькә алып килгән яңалыгын аерып күрсәтү дә җиңел түгел. Аннары драматург меңәрләгән кеше белән берьюлы сөйләшә, сәхнәдән торып тормыш турында, актуаль мәсьәләләр хакында фикерләшә. Ләкин турыдан-туры үз исеменнән сүз алмый, аның өчен аерым артистлар сөйли, режиссер аңлата, сәхнәне бизәгән рәссам күрсәтеп бирә. Автор үзе каядыр икенче, өченче планда кала.

Менә ни өчен драматург турында язуы кыен.

Юныс Әминев башы-аягы, җаны-тәне белән драматург кеше. Кайчандыр балалар хикәяләре дә язган ул, аның пьесаларында еш кына җыр һәм шигырьләр дә очрый. Әмма ул, иҗатчы буларак, бары тик драматург кына. Тормышта, иң әүвәл, сәхнәгә ярарлык драматик һәм комик конфликт күрә белә ул.

Юныс Әминев... Тамашачыга үзе еш күренеп йөрергә, премьералардан соң чыгып залга баш иярга бик үк яратмый торган, артык тыйнак, хәтта артык оялчан, сабыр кеше. Әмма күп меңләгән укучыга һәм тамашачыга яхшы таныш язучы. Егермеләп пьеса авторы. Татар театрларының барысында да, шул исәптән Г. Камал исемендәге академия театры сәхнәсендә, пьесалары уйнала торган, үзешчән артистларга да иң якын торган драматургларның берсе.

Ю. Әминев әдәбиятка пьесалары белән килеп керә, хәзер дә шушы жанрга тугрылык саклап иҗат итә. Аның 50 нче — 60 нчы елларда язган әсәрләре язылган урын дип Барҗы авылы күрсәтелә. Бу — авторның үз авылы, ул анда укытучы була. Димәк, Ю. Әминев иҗатка әдәбият укыту аша, ягъни әдәбияттан килгән, дип әйтергә тулы хокукыбыз бар шикелле. Авторның беренче әсәрләре дә моны раслый кебек: аларда сюжет йомшаклыгы да, конфликт схемачылыгы да, образлар сайлыгы да юк түгел... Ләкин һәммәсендә, хәтта кече күләмле пьесаларда, иң беренче скетчларда ук бер сыйфат мондый кимчелекләрне каплап тора: аларда тормыш дөреслегенә омтылыш бар, тормышчан җирлек көчле. Тормышны һәм кешеләрне яхшы белү иҗат тәҗрибәсезлегеннән күп өстен. Әйе, драматург Юныс Әминев әдәбиятка тормышның тап үзәгеннән килгән язучы. Аның барлык әсәрләренең дә көчен барыннан да элек әнә шул үзенчәлек билгели.

Юныс Әминев язганнарның барысы да дип әйтерлек сәхнәдә уйнала. Дөрес,

егермеләп пьеса арасында үзешчәннәр репертуарына гына кергәннәре дә бар. Бигрәк тә кече күләмле әсәрләр. Ләкин бу әле һич тә андый пьесаларның әһәмияте аз дигән сүз түгел. Алар жанр таләпләренә җавап бирерлек итеп, сәнгатьлелек җәһәтеннән җитешле эшләнгән. Кеше характерын ямьсезли торган, гайре табигый булган саранлык, ялкаулык, физик эшне сөймәү кебек кимчелекләрне ышандырырлык һәм көлкеле ситуацияләр ярдәмендә күрсәтеп биргән «Тикшерү», «Латыйфа», «Саран малы — саранның үзен ашый» һ. б. комедияләр шундыйлардан. Болар, нигездә, илленче елларда иҗат ителгәннәр.

Драматургның беренче зур күләмле әсәре 1947 елда ук языла башлап та, камилләшкәннән камилләшә барып, ун елдан соң гына дөнья күрә. Бу — сәхнәләрдә еш уйналган «Тамырлар» сатирик комедиясе. Автор сәхнә сәнгатенең үзенчәлекләрен төшенүгә шушы әсәре аша килде. «Тамырлар» — аның өйрәнү, тәҗрибә туплау мәктәбе булды. Аңа Минзәлә театры коллективы, аның шушы еллардагы баш режиссеры Сабир Өметбаев зур ярдәм күрсәтте.

Шулай да авторга беренче зур уңышны алып килгән әсәр монысы түгел, ә «Язылмаган законнар» драмасы булды. Минзәлә театрының бу драма буенча куелган спектакле 1957 елда Мәскәүдә уздырылган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашып югары бәя алды. «Язылмаган законнар»да Ю. Әминевның көчле яклары, аның драматургия кануннарын аңлавы, иҗат принциплары тәүге тапкыр ачык бер төс алды һәм формалашты. «Тамырлар»га әле конфликт ачыклыгы һәм кискенлек җитми, персонажларның эчке бөтенлеге ачык ук түгел, тәнкыйть объекты ваграк. «Язылмаган законнар»да исә бу яктан авторның профессиональ осталыгы арткан. Гаилә ныклыгын, үзара мөнәсәбәтләр сафлыгын һәм гаделлеген тәэмин итә торган, язылып куелмаган булса да, халыкның күңел түрендә саклана һәм аның яшәешендә төп рольне уйный торган закон-кагыйдәләр бар. Тракторчы егет Шәйхенур аларны үтәмәү юлына баса, шуның нәтиҗәсендә калган гомеренә җитәрлек ачы тормыш сабагы ала. Аның ялгышы, шул ялгышны төзәтүе вакытындагы эчке кичерешләре — иң гүзәл әхлак нормаларының тормышта җиңүе һәм тантана итүе дигән сүз ул. Драматург яратып мөрәҗәгать итә торган конфликт төзү алымы ачыклана һәм өешып җитә. Бирердә ул Шәйхенурның хатынына һәм әнисенә, шулай ук авылдашларына каршы чыгуы рәвешендә формалаша. Гомумән, алга таба да Юныс Әминев пьесаларында конфликтның шушы үзенчәлеге алга сөрелә. Үзара каршылык ир белән хатын, атаана белән балалар, әби-бабай белән оныклар, ягъни якын туганнар арасында килеп чыга. Пьесаларының берсен драматург «Кан кардәшләре» дип атый да. Мондый конфликт иң катлаулы әдәп-әхлак проблемаларына үтеп керергә, гаиләнең тотрыклылыгына, яшәү көченә нигез булган тойгыларның ныклыгын ачыкларга мөмкинлек бирә. Драматургның сәхнә әдәбиятына алып килгән яңалыгы да, бу юлда куйган хезмәте дә, иң элек менә шуның белән билгеләнә.

Илленче елларда ук ачыкланган бу иҗат юнәлешенә Ю. Әминев һаман тугрылыклы булып килә. Мораль-этик мәсьәләләрне художестволы хәл итүдә ул аерата принципиаль эзлеклелек күрсәтә.

Кешенең гаиләдә үз урынын дөрес билгеләве аның җәмгыятьтәге үз урынын табуына да турыдан-туры тәэсир ясый, дигән фикер үткәрә драматург. Ягъни, әхлак кагыйдәләренә тугрылык саклаганда гына кеше җәмгыять өчен дә файдалы булып җитлегә. Әхлак нормалары социалистик яшәү принциплары белән берлектә генә камил була ала, алар бер-берсе белән табигый кушылып китәләр. Ләкин әлеге нормалар үзлегеннән урнашмый һәм яшәми, алар өчен көрәшергә, аларны якларга да кирәк. Ю. Әминев иҗаты, тулаем алганда, әнә шул көрәшкә өндәүче иҗат.

Ю. Әминев җәмгыятьтә үз урынын эзләүче, аны табарга тиеш һәм мәҗбүр булган, шунда гына үз шәхси бәхетен дә тулы татыган, кимчелекләреннән арына барган шәхескә җитди игътибар бирә. «Өти балак» (1968) комедиясендә үзәк персонаж — Гөлүзә акрынлап «йоклап» һәм «үчләшеп» яшәү авыруыннан котыла. Аңар иң шифалы дару ролен физик хезмәт үти. Кыз фермада эшләүнең мәгънәсен күрә, башка кешеләрнең ышанычын яулап алуның нинди күңелле булуына төшенә башлый. Шәхеснең үз-үзен табуы, аякка басуы, формалашуы процессы тамашачы күз алдында уза.

Кешенең хезмәттә җитлегүе темасы Ю. Әминев пьесаларында эзлекле чагылыш таба. Бу үзенчәлекне «Кошның үз канаты була» (1967) музыкаль комедиясендә дә,

«Уҗым бозавы» (1968) комедиясендә дә, «Минем җинаятем» (1971) һәм «Кан кардәшләре» (1974) драмаларында да очратырга мөмкин. Ул тема бигрәк тә «Гөлҗәннәтнең җәннәте» (1972) психологик драмасында тулы яктыртыла һәм яңача хәл ителә. Тормышны мещаннарча аңлау фәлсәфәсе ышандырырлык төстә кире кагыла.

Юныс Әминев иҗатының бу юнәлеше фаш итү ягыннан шактый көчле, сәнгатьчәлек җәһәтеннән дә камил. Шунысын гына әйтү дә җитсә кирәк, Ю. Әминев драматургиясенең өчтән ике өлеше комедиядән тора, ягъни көлүдән һәм фаш итүдән гыйбарәт. Хәтта «Минем җинаятем», «Гөлҗәннәтнең җәннәте» кебек драмалар үзәгендә дә тискәре персонажлар тора.

Шулай да, Ю. Әминев иҗатының әһәмиятен арттыра торган икенче юнәлеш — раслаучы юнәлеш, һәм ул нәкъ менә аның драматик әсәрләрендә төп урынны били. Кайбер комедияләрдә дә уңай тенденцияләрнең җиңүе конкрет образлар ярдәмендә чагылдырыла.

...Ревизия ике сатучының дүрт мең акчасы җитмәүчелеген ача. Бу ни хәл? Дуслар аптырап калган, туганнар куркудан нишләргә белми, кемнәрдер сөенә. Кискен ситуациядә «гаепләләр» ныклы характер күрсәтәләр һәм дөреслек җиңәчәгенә ышанычларын югалтмыйлар. Шуның белән бергә бу хәл дусларның дуслыгын сынарга, дошманнарны фаш итәргә бик шәп булып чыга. Җитмәүчелек ялгышлыктан гына икән: һәр метры 40 ар сум торган материал 20 шәр сумнан сатылган. Радиодан хәбәр иткәч, сатып алучыларның зур күпчелеге аерманы китереп түли, җитмәүчелек каплана.

Комик ситуация, кызыклы диалоглар, ягымлы кешеләр. Хикмәт бигрәк тә шунда, матур һәм эчкерсез мөнәсәбәтләр өстенлек ала, кешеләргә ышану, яхшылыкка һәм изгелеккә инану җиңеп чыга. Шуларны үзләре өчен бердәнбер дөрес кагыйдә саналган Хәрия һәм Җәүдәтләр чын мәгънәсендәге кешелекле һәм эшлекле булып хәтердә калалар.

Кешелекле һәм кечелекле, эш сөючән, оптимист, кимчелекләргә һәм җитешсезлекләргә килешмәүчән геройлар, гомумән, Ю. Әминев пьесаларын бизәп торалар. Бер очракта алар — гаять актив һәм агрессив тискәре персонажларга, тормыш кыенлыкларына һәм кимчелекләргә каршы торучылар гына. Икенче очракта исә бу геройлар — әйдәп баручылар, активлар, үзләре һөҗүмгә ашкыналар. Мондыйларның хезмәттәге уңышлары тагын да ныграк ышандыра, аларның төрле гариплекләргә һәм җитешсезлекләргә каршы чыгулары да табигый. Тискәрене кире кагу һәм кыекны турайту вакытында, кайбер гарип рухлы адәмнәр белән көрәшкәндә бу геройлар беркайчан да икенче чиккә барып төшмиләр. Егылганны тәпәләү юк аларда. Гарип рухның да җәрәхәтләнергә сәләтле булуын белеп һәм тирән кичереп эш йөртәләр.

Кыскасы, тискәре геройны да мәгълүм бер дәрәҗәдә хөрмәт итү, аның да кеше икәнен хәтердән чыгармау Ю. Әминев драматургиясендә буйдан-буйга сузыла. Менә шул ягы белән ул, иң әүвәл, Мирхәйдәр Фәйзине искә төшерә. Кешене олылый торган табигый мөнәсәбәтләрне, рухи матурлыкны алга чыгаручы, кешегә ышанычны ныгытучы бу әсәрләр бүгенге әдәбиятта үзенчәлекле стиле белән аерылып тора. Әлеге сыйфатлар драматургның завод тормышын гаять оста чагылдырган, хезмәтчеләренең олы җанлы образларын сәхнәгә чыгарган, характерлар байлыгы ягыннан аеруча отышлы «Кан кардәшләре» (1974) исемле комедиясенә дә хас. Нефтьчеләргә багышланган «Сөймим дисәң дә» (1976) исемле җитди комедия үзенең тормышчан булуы белән татар драматургиясендә бу темага караган иң яхшы әсәрләр рәтендә урын алды. Тормыш чынлыгына тугрылык һәм кешегә, аның изге хисләренә хөрмәт революция елларын, дәһшәтле вакыйгаларны чагылдырган «Умырзая чәчәкләре» (1967) дип аталган героик-тарихи драмада күренде.

Драматургның художество арсеналы шактый бай. Инде әйтелгәнчә, ул тормышчан конфликт таба белә, оста итеп сюжет төзи, диалоглар һәм репликалар җанлы, образлы, табигый, характерларның эчке мәгънәсенә ятышып тора. Җиңел, уйнак сүзләр һәм гыйбарәләр ярдәмендә җитди фикер уздырыла. Автор отышлы аерым детальләр сайлый һәм уңышлы файдалана.

Мәсәлән, «Умырзая чәчәкләре»ндә «изге ялган» детале бар. Фәния исемле яшь кыз башка революционерлар белән бергә атылырга тиеш. Ләкин ул исән кала ала, әгәр дә... әгәр дә үзенекеләргә хыянәт итсә, җыйнап озатылган икмәкнең баржага кай урында төяләчәген акларга әйтсә. Фәния аны белә, һәм ул әнисеннән үтенә:

«акларга серне чиш, мине үлемнән йолып кал...» Ана мондый хыянәткә бармаячак, ләкин үлем шаулысеннән югалып калган кызына моны аңлатып торырга вакыт та, мөмкинлек тә юк. Фәниясенең соңгы минутларында халык алдында, иптәшләре каршында җебеп торуын, горурлыгын җуюын да теләми ул. Һәм изге ялганга мөрәҗәгать итә: сөйләшәм, сине атмаслык булсалар, ак шәлемне бөркәнеп чыгармын, син мылтык көпшәләренә кыю карап тор — сине атмаслар, ди ул. Кыз яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең тирән мәгънәсен, хыянәт исәбенә яшәүнең газаплы хурлыгын тулы аңлый — анасын гафу итә, үлемнең күзенә туры карарлык көрыч ихтыяр күрсәтеп һәлак була. Милли драматургиябездә беренче тапкыр һәм уңышлы кулланылган бу образлы деталь бөтен пьесага поэтик мәгънә бирә, автор фикерен һәм характерларны эреләндерә.

Ю. Әминевның әдәби осталыгына тагын бер мисал китерәсе килә. «Кан кардәшләре» әсәре комедиячел ситуациягә корылса да, анда, бер Әсрарны искә алмаганда, комик характерлар юк. Ләкин бер карлыгач яз ясамый, җитмәсә тагын Әсрар бит икенче планда гына торган образ. Ю. Әминев каләменең үзенчәлеге бу: ул драматик характерларны көлкеле хәлләрдә ача белә, «яшь аралаш көлә» һәм көлдерә. Аның иҗатының тормышчанлыгы, тамашачыны җәлеп итү көче дә, мөгаен, шундадыр.

Пенсиягә чыгучы цех начальнигы Хисами үз урынына кеше калдырырга тиеш. Булачак җитәкче — Хисаминың якыннарыннан берсе. Һәм менә шунда кызык хәл туа да инде. Берсе начальник булырга үзенең лаеклы түгеллеген белеп, баш-аягы белән каршы чыга. Икенчесе бу урынга үзе атлыгып тора... Бу вакыйга тирәсендә характерлар ачыла, кимчелекләр фаш ителә, уңай принциплар раслана.

«Мәснәви (*Сәрдиягә*). Син утыр. Дуңгыз гына басып торсын.

Хәтирә. Бу нишләвең инде, үз киявеңә үзең...

Сәрдия. Киявең дуңгыз булгач, мин кем булам инде, абый?

Мәснәви. Син дуңгыз хатыны буласың, сеңелем.

Хәтирә. Үз туганыңа шулай дип әйтеп буламыни инде?!

Мәснәви. Ник булмасын, әйттем ич. (*Күкрәгән үып.*) Үз туганнарым булмаса, җенем дә бу кадәр котырмас иде. Үз туганнарым шул, үз туганнарым!.. (*Әсрарга ырындык бирел.*) Утыр, мисез ишәк. Аякларың талгандыр...

Әсрар (*борынын мышкылдатып*). ...Ярый инде, судка бирегез.

Мәснәви. «Судка бирегез...» Сиңа әйтүе җиңел. (*Эчке ачыну белән.*) Ә кемне хөкем итәләр? Эшчене! Кайсы цехныкын? Безнекен. Цехка, заводка хөрмәт юк синдә. Үзең белән бергә эшләгән иптәшләрең өчен аз гына да борчыла белмисеңмени?

Әсрар (*уңайсызланган булып*). Борчылмаган кая? Күзләренә күренергә оялам.

Мәснәви. Ояласың?.. (*Иркен сулап куя.*) Оятың бетеп җитмәгән икән әле... Хатирә, чәеңне чыгар.

Хәтирә. Нинди чәй? Куярга кушмадың ич.

Мәснәви. Ир кушмады дип, юньле хатын чәй куймый торамы? Йөгер».

Менә шулай яза драматург Юныс Әминев. Көтелмәгәнчә итеп, комедия алымнары белән җитди әйберләр турында сөйли, җанлы характерлар сурәтен ясый.

Кайвакыт драма әсәрендә чатлы-ботлы сөйләшүләр, үзара кискен-киеренке мөнәсәбәт, катлы-катлы аңлаулар өстенлек алса, аны «кырыс реализм» дип бәялибез. «Кырыс» сүзе артында, һичшиксез, тормышны тулы чагылдыру, «туры» дигән мәгънә, ягъни реализмның тулылыгы күз алдында тотыла. Юк, дияр идем мин. Реализмның менә бусы — Әминевтагычасы — кешеләрне һәм тормышның үсеш тенденцияләрен матур хәлендә сурәтләү нигезендә ятканы үз билгеләмәсенә тулырак җавап бирә. Чөнки ул кешенең кешелеген гади итеп, нәкъ тормышның үзендәгечә итеп, әмма тулырак ача, сәнгатьлерәк формада күз алдына бастыра, эстетик ләззәтне дә мулрак бирә.

Җитди һәм моңсу комедия, җыйнак һәм кырыс драма остасы, сәхнәне бик яхшы өйрәнгән язучы, яулап алганнары белән генә һич канәгатьләнмәстән, сәнгатьтә яңа юллар эзләүче тынгысыз кеше — үзенең 60 еллыгына менә шундый булып килә драматург Юныс Әминев.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН.**

# БАЛАЧАККА ЕШРАК КАЙТЫГЫЗ!

Табигать безнең һәркайсыбызга тәпи йөри башлаганчы ук искиткеч күркәм сыйфатлар бүләк итә: самимилек һәм зирәклек, чын күңелдән соклана һәм сөенә белү, теләсә нинди җисемгә «җан өрү» һәм үз-үзеңә читтән карый алу сәләте... Бу сыйфатлар, терекөмеш сыман, тормышның теләсә нинди буасын ерып ташларга да, күз ачып-йомганчы исраф ителергә дә мөмкин. Шагыйрь җаннар гына шушы хәзинәнең чын бәһасен белә, шуңа да аны берьюлы суга салмыйлар. Алар, үз өлешләрен дә бәрәкәтле тотып, аны дөньяның бүтән балаларына һәм, әйтергә кирәк, өлкән яшьтәгеләренә дә бөртекләп өләшәләр: саф-таза асылыңны саклау — өзлексез көрәш-хәрәкәттә булу нәтиҗәсе ул, дип искәртәләр.

Үзебезгә дә бик кадерле булган әлеге «терекөмеш бөртеге»н без балаларыбыз учына салабыз. Бу мирас аларга, бәлки, татлы күз яше яисә язгы кояш тамчысы булып күренер. Алар аңа соклану бәхетен һәм аны югалту нәүмизлеген кичерерләр. Шушы тойгы күңелләрендә гомер буена сакланып калыр һәм, «терекөмеш тамчысы кебек, тормыш учыннан тәгәрәп төшә күрмәгез!» дип, һәрвакыт кисәтеп торыр.

Балалар өчен язылган һәр шигырьгә әнә шул терекөмеш бөртеге түгел микән дип карыйсы килә...

1

Сабый чак бәхетен ятимлек белән кыерсыткан язмыш Роберт Миңнуллинга аҗәтен соңлап булса да түләргә уйлагандыр, күрәсең... Университетны тәмамлагач, ул очраклы рәвештә генә диярлек балалар матбугатында эшли башлады. Нәниләр өчен язылган беренче шигырьләре дә баштарак әле шундый бер очраклылык булып кына тоелды бугай. Табигать этюдлары... Пират исемле мәзмәй белән шигъри телдә сөйләшүләр... Яшь автор, әйтерсең, өлкәннәр өчен дигән дәфтәреннән кайбер парчаларны нәниләргә дә укып күрсәтергә карар кылган иде.

Тора-бара бу «шаярулар»ның яхшы мәгънәсендәге «кәсеп» булып калуы, язмышка әверелүе күренде.

Балалар өчен язган шигырьләре Робертның тулаем иҗатын көтелмәгән яктан ачып җибәрде. Андагы моңсулык, сабыр-салмак агыш та — заман тизлекләренә битарафлык һәм шәхси кичерешләр утында гына пыску түгел икән, киресенчә, бу — мода җилләренә баш бирмичә, шигъриятнең асылына тугры калу, хисләрнең табигый сафлыгына омтылу, дөньяны яңабаштан ачу шатлыгын кичерү икән. Менә ни өчен аның шигъри сүзе «махсус» атап язмаганда да балаларныкы булып китә алган! Менә ни өчен аның балаларга дигән шигыре олылар өчен дә мәгънәсен югалтмый. Безгә бу иҗат тылсымы үткән заманда да (үз балачагыбызда), хәзерге һәм киләчәк заманнарда да (балаларыбыз белән бергә) яшәү мөмкинлегенә бирә. Балачак һәм табигатьнең үлемсезлеге тормышның чиксез дәвамын тоярга, аның мәңгелек сорауларын аңларга ярдәм итә.

Табигать балалар шагыйре генә булырсың дип аерым сәләт бирми торгандыр. Балалар поэзиясе — кайберәүләр өчен генә бүлеп куелган кишәрлек түгел. Ул, асылда, шигъри тоемлау, фикерләү рәвеше, дөньяга мөнәсәбәт стиле белән бәйләнгән. Димәк, Роберт Миңнуллинның да иҗади кыйбласы беренче карашка гына очраклы тоелган. Шигырьдән шигырьгә, китаптан китапка үсеп, ул балалар әдәбиятының зурлыгына, изге вазифасына ышануын һәм аңа мавыгып хезмәт итүен раслый. Бу өлкәдәге барча уңышлары шагыйрьнең гражданлык активлыгы, иҗатта зур җаваплылык тоюы нигезендә күтәрелә.

Активлык һәм җаваплылыкның бер мисалы итеп, телевидениедә Р. Миңнуллин алып бара торган «Шигъри тәлгешләр» тапшыруын гына да искә алырга мөмкин. Бу инде — шагыйрьнең фидакарьлегә, тәрбия

Роберт Миңнуллин. Җиде абый тай җигә. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

һәм мәгърифәтчелек белән турыдан-туры шөгыльләнүе, шигырьләрендә башлаган сүзен бүтән формада дәвам итүе, иҗатының бер тармагы. Әйтерсең, ул җаны-тәне белән уенга бирелгән сабыйлар арасында: менә ул аларны бүлдерми генә яңа уен башлап җибәрә, балалар үзләре дә сизмәстән шул уенга кушылалар. Аларга ул үзләре уйлап тапкан булып тоела. Уен үзелми, аңа яңа буыннар өстәлеп китә.

Гомумән, Р. Миңнуллинның балаларга багышланган иҗаты — кайдадыр өзелеп торган мөһим җепне ялгау, бер мизгелгә генә туктап торган мәңгелек двигательне хәрәкәткә китерү кебек тәэсир калдыра.

...Өлкәннәрнең тай җигә алмауларын күреп торган кыю малайны ул:

Җәфа чиксәм,
Чигәр идем,
Мин ул тайны
Җигәр идем...

— дип ашкындыра.

«Әни эштән кайтканчы...» дигән шигырьнең булдыклы герое да ничек тә игелек эшләү уе белән янган үз эшләрен матур үрнәгенә ияртеп китәрлек. «Елмаючы бүреләр» белән «Куян йөрәкле Бүре» турында укыгач, бик теләгәндә явызлыкны да йөгәнләргә була икән дип ышанасың.

Хәрәкәткә чакыру, аңа дөрес юнәлеш бирү — игелекле һәм бәрәкәтле эш. «Урман аша үткәндә», «Акбай шулай ди...» кебек аз гына хәйләкәр шигырьләре шагыйрьнең тиешле нәсихәтне җайлы гына, киная белән генә бүтәннәргә җиткерә алу осталыгын күрсәтте. Ул «уйнап кына» җитди мәгънәгә алып килә, намус, туґрылык, хезмәт сөю кебек олы төшенчәләрнең асылын аңлата. Шул ук вакытта, беркатлы булып кыланмый, укучысын рәнҗетми һәм үчтеки иттереп юатмый да. Биредә аңа табигый кече күңеллелек һәм шаянлык, бала җанын аңларга тырышу сыйфатлары, шуның өстенә беркадәр артистлык та ярдәмгә килә.

Белгәнебезчә, һәр сабый үзе дә тумыштан «артист». Шагыйрь исә аны партнерлыкка чакыра, аның фантазиясен очкынландырып җибәрә, аңа «рольгә керергә» булыша. Бу — әлеге дә баягы «мәңгелек двигатель»не хәрәкәткә китерү, уенга җәлеп итү, эшкә-иҗатка рухландыру, дөньяның искитмәле күренешләрен үзең табарга һәм аңларга өйрәтү. Шушы хәрәкәтнең беренчел этәргече, әлифбасы сүз уйнатулардан башлана.

Нәни укучыга шигырь иң әүвәл гаҗәеп яңгырашлар, сүз фокуслары булып килә. Бер мәлгә үзеңне циркта утыргандай хис итәсең. Р. Миңнуллинның «Акбай цирк карый» дигән беренче җыентыгында «Урманнан фил китеп бара» кебек, турыдан-туры тамашага нигезләнгән шигырьләр дә байтак. Хәтерлисездер, бөтен «йөк»не цирк маҗаралары җилкәсенә салган очракларда авторның үз табышлары югалыбрак кала, аның үзенә генә хас тавышын аеруы шактый кыенлаша иде. Шулай да бу цикл артистлыкка беренче адым, дөньяга сабый күзләре белән карарга тырышу булып хәтердә калды.

«Җиде абый тай җигә» җыентыгында да тышкы эффект белән мавыга төшү, хәрәкәт механизмы бер үк пружинага корылган шигырьләр очрый әле (мәсәлән, «Әйтмим» һәм «Мактанмыйм» кебекләр). Әмма биредә табышлар өстенлек итә. Тамашаларда бала үзе катнаша. Серле сүзләр урманында ул «юлбарыслан, мәчеләп, төлкерпе» дигән җанварларны күреп гаҗәпкә кала. АвтоБусның автоДуска әверелүенә сөенә. Сүз, бишектәге сабый төсле, елмаеп кына яткан чакларында да сокландыра.

Без тоткан йолдызлар белән
Зу-ур чиләк тулган иде,
Чиләгебез йолдыз белән
Чүмәкәй булган иде.

Бу шигырьләр шактый тыныч-тигез агышлы. Аларны укыганда, капылт кына борылышлар булыр да, көтелмәгән хәлләргә юлыгырсың дигән уй гадәттә күңелгә килми. Шулай да уяу-аң булырга кирәк!

...Әнә, малайлар үзләре ясаган ракета эченә кереп утырганнар да: «Ни дисәң дә кораб бит. Очып китсә әгәр дә, безнең эшләр харап бит»,— дип шүрләп калганнар. Алга таба шигырьне, билгеле, колак торгызыбрак тыңларга мәҗбүрсең. Ярый әле ракета очып китә алмый кала! Менә хәзер сер бирми инде бәләкәй героебыз: «һәй, очып китсә дә, куркып тормаган булыр идек әле»,— дигән була. «Урман аша үткәндә» шүрәлегә очрый язган малай белән дә шундыйрак хәл булган иде бит.

Әлеге шигырьләрдә күз буу юк, алар — сере менә-менә ачылыр кебек тоелган һәм шунлыктан бигрәк тә кызыктырып торган фокусларга тартым. Бәләкәй геройның булыр кебек көттереп тә, булмый калучан маҗараларда сыналуын, шуннан ипле генә итеп гыйбрәт чыгаруны Р. Миңнуллин аеруча яратып куллана. һәм, яше-

рен-батырын түгел, бу аңа бик килешеп тора. Качкын кәҗәнең кыр кәҗәсенә әверелүен, елгада балык урынына йолдыз каптыруларны искә төшерик...

Әлбәттә, мондый җиңеллек озакка бармый. Чынбарлык тыштан караганда гына бер күзәнәкле булып күренгән икән. Сабыйның күңел дөньясын тулырак, тирәнрәк аңларга омтылганда, шигырьләр дә катлаулырак, нечкәрәк төсмерләргә байый бара. Чөнки барысын да уен-көлкегә бору яки шуңа гына кайтарып калдыру — шагыйрь өчен иң мөһиме түгел, төп максат — «уеннан уймак» чыгару, ягъни укучының игътибарын туплау һәм аны уйга калдырырлык сүз әйтү. «Акбай цирк карый» җыентыгында ук:

**Гөрләвекләр гөрләмәгәч,**
**Яз була алмас инде...**

дип кайгыручы, яки пешереп алгач юашланып киткән кычыткан турында уйланучы нәни геройлар белән танышканда, күңелдә шагыйрьнең зур киләчәгенә өмет хисе туган, шул юнәлештә ай үсәсен көн үсүен күрәсе килгән иде. «Сүз тыңлый», «Әни эштән кайтканчы», «Бүтәннәр күрмәсә дә» кебек шигырьләр әлеге юнәлешнең дәвамы булып кабул ителә. Роберт Миңнуллин иҗатының бик үзенчәлекле һәм мөһим принципка — күңелле мотивлардан җитди сөземтәгә ирешү принципына нигезләнүе яңа җыентыгында тагын да ачыграк беленә.

Гомумән, Р. Миңнуллинның ике китабын һич сагаюсыз янәшә куеп карарга һәм кистереп әйтергә мөмкин: соңгысы — үзеннән ике ел алданрак чыкканы белән игезәк түгел, ягъни ике арадагы үсеш-аерма күзгә ташланып торырлык. Бу үзгәрешнең уңай якка булуына ким дигәндә ике зур дәлил бар.

Беренчесе — шагыйрьнең иҗади мөстәкыйльлеккә ирешә баруы.

Робертның иҗаты хаклы рәвештә тулаем безнең бай традицияле балалар поэзиясе мәктәбеннән дип танылды. Шул ук вакытта аны әле дә өйрәнчеклек чорында кала дип санау гаделлек булмас иде. Билгеле, үзүзеңә ташлама ясыйсы килү тойгысы бар әле дөньяда, әнә шул тойгы төшен кәнфиткә алыштырган малайлар-кызлар турында кайтып-кайтып язарга мәҗбүр итә, «Хушпашабыз бакча белән» шикелләрәк сөенделек шигырьләрдән баш тартмаска кыстый... Әмма шагыйрьнең бераүне дә кабатламаган үз табышлары бар. Әйтик, Ш. Галиев безне, нигездә, җете, контраст буяулары белән җәлеп итсә («...Керпе һаман йөрәгемне чәнчеп тора...», «Йөзә белмәсәң, чәйгә сикермә!») Р. Миңнуллин йомшаграк, сизелмичә диярлек күчеш ясаучы тоннар сайлый һәм уңышка үзенчә ирешә. Моңа бик күп мисаллар китерергә мөмкин.

Шагыйрьнең үсешенә икенче дәлил — табигыйлекне саклаган хәлдә, шигъри сүзнең мәгънәви тыгызлыгына йөз тотуы.

Кызганычка каршы, күп сүз белән ниндидер гыйбрәт чыгарырга азаплану, чыпчык борыны кадәр фикерне сәгать буе укырлык әкият-мораль итеп сузу балалар поэзиясендә әле бүген дә очрап тора. Иҗатының башлангыч чорында Роберт та «Елның дүрт төсе» дигән циклы белән әлеге «тел тегермәне»нә бер чүмеч су салган иде. Инде әйтеп үтелгәнчә, «цирк» циклы да әллә ни истә калырлык булып чыкмады. Ләкин шигъри бәйләмнәр белән мавыгуы тикмәгә булмаган икән: ул киңрәк картиналарны, зуррак гомумиләштерүләрне күздә тоткан. Әмма әлегә колач кына тар булган, осталык кына җитенкерәмәгән.

Инде менә «Җиде абый тай җигә» җыентыгындагы күпчелек шигырьләр бер фикергә алып килә: Роберт Миңнуллин үз сүзен шигырьдән-шигырьгә саллырак итеп әйтә белә торган шагыйрь булып формалаша. Бүген ул дүрт шигырьдән торган цикл күләмен дүрт строфалы бер шигырьгә берләштерә, иртәгә исә шул дүрт строфаны дүрт юлга сыйдыра алыр дип өметләнергә кирәк. Юк, бу үзмаксат түгел, бу — укучы таләбе: балалар өчен язылган шигырьнең бер сүзе дә куыш эчле булмаска, һәр юлыннан егәр ташып торырга тиеш. Аның һәр юлын тормышның тирән катламнарына алып керүче, Балалыктан Кешелеклелеккә илтүче гаҗәеп спиральнең бер буыны итәсе иде! Шул чакта гына шигырь — салават күпере кебек катлаулы һәм табигый күренеш булып калачак. Иҗатта табигыйлеккә ирешү — балачакка кире кайту кебек үк мәңгелек сәфәр. Яңа әсәргә керешкән саен әр-яңадан түзелә һәм кичелә торган сират күпере. Әмма, никадәр генә авыр булмасын, шагыйрь аны урау юллар белән алыштыра алмый.

**САЛИХ МАННАПОВ**

# Шәүкәт Галиев

## Аю качкан цирктан...

Аю качкан циркттан,
Аю чыккан иреккә!
Читлегенә бер типкән,
Урман ягына киткән:
Теләсәм — урмәләрмен,
Теләсәм — тәгәрәрмен,
Теләсәм — укерермен,
Теләсәм — тик йөрермен!

Аю кайткан урманга,
Рәхәтләнгән ул анда,—
Эштән котылдым, диеп,
Төп башларында биеп,
Иркенлеккә шатланып,
Ботакларга атланып,
Анда-монда тукталып,
Шактый йөргән буталып,
Кыланып куйган инде,
Тузанын койган инде!

Тик яңа тормышында
Нидер җитми шул монда...
Җирси аю, пошына.
Бик куңелсез аюга
Кичен кояш баюга...
Җитми цирк утлары,
Җитми футбол туплары!
Кирәк аңа алкышлар —
Кулда кагынган кошлар...
Малайлар, кызлар җитми,
Яратып карау җитми,
Кыскасы... аңлау җитми!
Түзеп, чиккә җиткән ди,
Черек төпкә типкән ди,
Аю кире киткән ди:
Ирекгә дә цирксыз!—
Иреклеләрдән ирексез!

Аю качкан ирекгән!—
Аю кайткан циркка!

## Ат «йөртүче» малай

Мотоциклны бирдек,
Мотоциклда йөрде.
Аннары соң ул безнең
Атта йөргәнне күрде.

«Бик гади техника!»—
дип,
Шәһәр кунагы көлде.
«Ат йөртү соң эшме!»—
дип,
Урындык куеп менде...

Арты белән атланды,
«Булды бит!» — дип
мактанды,
Боргаланды, кыланды,
һәм төшеп тә капланды.

Аксап-туксап килде дә,
Сорау биреп тора шул:
Моны ничек йөртәсе,
Кай төшеннән борасы?

Кайда моның тизлеге,
Газны ничек өстәргә?
Тормоз ничек салырга,
Туктамаса нишләргә?

Әйттек кунак егеткә:
— Озак булыр аңлату,
Белү генә җитмәстер,
Кирәк булыр ярату.

Машинаң кебек итеп
Ярату җитми хәтта —
Ат та сине танысын,
Яратсын сине ат та!

Әйтү бушка китмәде,
Төшендерү ярады —
Беренче кат ул атның
«Фара»сына карады...

## Бер шөреп

Әрле-бирле урындык,
Алай-болай утырдык...
Карасаң күз төшереп —
Төшкән икән бер шөреп...

«Бер шөреп?!»— дип
кул селтәп,
Көлеп кенә карама,
Бер шөребен — бер
шөреп,
Ә урындык тарала...

Бер шөрепкә иренгәч,
Биш шөрепне кем бора —
Аягыннан тота да
Чүплеккә үк тондыра.

Велосипед та шундый,—
Бер шөребе бушаган,
Бусының да язмышы
Тегесенә охшаган...

Машинага утырсаң,
Ракетага-фәләнгә,
Мәңгелеккә китәрсең
Бик тә ерак галәмгә...

Хәер, андый төшләргә
Алалар бик тикшереп.
Төшәсең дә каласың,
җитешмәсә... бер шөреп!

## Көзгеләр көлеп тора

Бүлмәгә керәм генә,
Мин ниләр күрәм менә:
Стена келәм генә,
Идән дә келәм генә.
Көзгеләр көлеп тора,
Сервантлар көлеп тора,
Бәясен белеп тора —
Бәллүр тезелеп тора!
Нурлар бөркелеп тора!

Кисәтәдер әнисе,
Өстәп тора әбисе:
— Чү, чү, залга кермәгез!
— Юк, юк, аннан
йөрмәгез!
— ...кагыласы булмагыз!

— ...ягыласы булмагыз!
— ...сузыласы булмагыз!
— ...тузынасы булмагыз!

Булсаң монда кунакта —
Бусагага кунакла...
Сөмсерләре коелып,
Гарьлектән чак тыелып,
Дустым тора боегып...
Монда шкафлар хуҗа,
Тик алар түрдән уза!
Аптырап басып тордым,
Борылдым да
сыптырдым...
Көзгеләр көлеп калды,
Иптәшем елап калды...

## «Аякъязма»

Беренче кар, беренче
кар —
Язылмаган дәфтәр
сыман!

Ап-ак битен башлап
кышның
Атлап барам
уртасыннан.

Иһи, миңа хәтле мәче
Эзен сырлап узган икән.
Терт-терт, терт-терт
сикергәләп
Чыпчык исмен язган икән.

Яфрак-яфрак тамга салып
Титаклаган үрдәк-каз да.
...Укый барам мин
мәктәпкә
Шундый кызык

аякъязма!

## Тәрәзәдә термометр

Терекөмеш тере имеш,
Көпшәдән күреп торам:

Җылыда сузаеп тора,
Салкын — чүгеп утыра...

## Җылы эз

Чатлама суыкта бер кош
Оча тиз-тиз кагынып,
Оча җылы кояш эзләп,
Оча җәйне сагынып.

Оеган кыш уянсын, дип
Бозлы гөмбәзгә кага,
Өметтәнме, канаттанмы
Күктә җылы эз кала...

## Бик рәхәт!

Тими миңа салкын, салкын
Килми миңа якын, якын!
Тияр иде — тик тормыйм,
Тешләр иде —
тоттырмыйм!
Җитез минем аяклар,
Очлы минем таяклар!

Сәнәк алып селтәнәм!
Көрәк алып кизәнәм!
Курка шул, якын килми,
Салкын ул миңа тими!
Хәрәкәттә бәрәкәт.
Бик рәхәт!

# ХАЛЫККА КАРШЫ

Кешелек тарихында яңа эра башлануын игълан иткән Бөек Октябрьны, Россиянең буржуаз-феодаль элементлары кебек үк, татар һәм башкортларның өстен сыйныфлары да теш кайрап каршы алды. Алар аклар ягында сугышучы берничә частьтән торган милли гаскәр тупладылар.

Ләкин тарих тарафыннан бетүгә дучар ителгән сыйныфларны берни дә коткара алмый иде инде. Солдатлар, ялгышларын аңлап, халык ягына чыга башладылар. Бары фанатизм белән агуланган контрреволюцион элементлар гына мәгънәсез каршылык күрсәтеп маташты. Гражданнар сугышы тәмамлангач, Россиянең тар-мар ителгән көчләре белән бергә татар-башкорт контрреволюциясе дә эмиграциягә агылды. Соңрак, татар контрреволюциясенең башлыкларыннан берсе Гаяз Исхакый үзенең васыятендә: «Без, үз гаскәрләрен югалткан генераллар шикелле, чит илләргә качарга мәҗбүр булдык»[1],— дип язды.

Польша, Төркия, Кытай, Япония, Германия, Финляндия, Франция кебек капиталистик илләрдә утырып калган татар-башкорт эмиграциясе социаль составы белән бер төрле генә түгел иде. Алар арасында капиталистлар, коммерсантлар, җирбиләүчеләр, дин әһелләре, патша офицерлары, буржуаз интеллигенция вәкилләре һәм башкалар бар. Күбесенең элеккеге байлыклары, өстенлеге юкка чыккан, шуңа күрә Совет властен көчле нәфрәт белән күралмыйлар.

Буржуаз эмигрантлар баштан ук Россиянең бәреп төшерелгән сыйныфлары җәелдереп җибәргән көчле антисоветик пропагандага кушылып киттеләр. Алар Совет җәмгыятенә ярсынып яла якты, аны антидемократизмда һәм шовинизмда гаепләде, буржуаз парламентаризмны күкләргә чөеп мактады. Халыкка каршы пропаганданың социаль тамырларын, ысулларын ачып, Галимҗан Ибраһимов 1924 елда болай дип язды: «Җиреннән, шахтасыннан, прииискасыннан, банкасыннан аерылган рус буржуазиясе үзенең заграницада чыгарылган ак газеталарында менә җиде ел инде Совет, Октябрь, коммунизм, пролетариат турында иге-чиге, төп нигезе булмаган ялганнар, гайбәтләр, провокацияләр белән дөнья пычраталар... безнең татар, ислам, төрек контрлары да үзләренең рус агаларыннан калырга тырышмыйлар икән»[2].

Россиянең башка контрреволюцион көчләре белән бергә, Совет властен бәреп төшерүнең зарурлыгын пропагандалап, төрки халыкларның контрреволюцион эмиграциясе тагын үзенең генә яшерен максатларын да күз алдында тотты: башлыча, алар Идел буе, Урал, Казагыстан һәм Урта Азия территориясендә буржуаз-җирбиләүче Туран дәүләтен төзү турындагы пантөркиләр идеясен алга сөрделәр. Тулаем алганда, бу идея яңа түгел иде. Октябрь революциясенә кадәр үк туган бу фикер революция барышында үз милли республикаларын төзегән халык массаларының кан дошманы шул эмиграция булуын бик тиз күрсәтте. Әмма контрреволюция үз идеяләреннән ваз кичмәде. 1923 елда Берлинда татар контрреволюциясе инициативасы белән пантөркиләрнең «Туран» оешмасы төзелде.

Егерменче — утызынчы елларда татар-башкорт эмиграциясе лидерлары көчле әдәби эшчәнлек башлап җибәрде. Муса Бигиев, Абдулла Баттал-Таймас, Әхмәтзәки Вәлиди, Гаяз Исхакый һәм башка кайберәүләрнең китаплары дөнья күрә. Аерып алганда

[1] «Коммунист Татарии», 1970, № 10, 9 бит.
[2] Г. Ибраһимов. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар. Мәскәү, 1924 ел, 20 бит.

Баттал-Таймас 1925 елда Стамбулда басылып чыккан «Төрки Казани» китабының соңгы бүлекләрен татар милли хәрәкәтенең тарихына багышлый. Ул большевикларны халык массаларын үз ягына аударып милләтче буржуазиягә буржуаз «Идел-Урал штатлары» төзүгә комачаулауда гаепли. 1933 елда Парижда рус һәм француз телләрендә дөнья күргән «Идел-Урал» китабында татар буржуаз милләтчесе Гаяз Исхакый ВКП(б)-ның милли политикасына тагын да кискенрәк яла яга. Партия һәм Совет властен төрки халыкларын «руслаштыру» политикасы алып баруда гаепләп, Исхакый болай язды: «Элек рус миссионерлары булдыра алмаган эшне хәзер большевиклар тормышка ашыра»[1]. «Россия мөселманнарының хәзерге хәле» (Будапешт, 1930) дигән китабында башкорт милләтчесе Әхмәтзәки Вәлиди дә СССРдагы төрки халыкларының совет илендәге чынбарлыгы турында шундый ук караңгы тоннарда яза. Контрреволюцион эмиграция башлыкларының көнбатыш илләрдәге китап базарларын тутырган бу «хезмәтләре» совет иленә каршы язылган әдәбиятның болганчык агымына килеп кушылды.

Егерменче елларның икенче яртысы, бигрәк тә утызынчы еллар башы — капитализмның гомуми кризисы тагын да кискенләшкән чор. Эшчеләр сыйныфы җитәкчелегендә хезмәт ияләренең буржуаз хөкүмәтләр алып барган политикага каршы көрәше тагын да көчәя һәм ныгый. Шул ук вакытта империализм кайбер капиталистик илләрдә фашистик тенденцияләр китереп чыгара. Германиядә властька фашизм килә. Бу исә татар-башкорт контрреволюцион эмиграциясенең эшчәнлеген тагын да көчәйтеп җибәрә.

1926 елда Польшадагы фашистик переворottан соң барлык контрреволюцион көчләрне Советларга каршы оешмага берләштерү өчен уңай мөмкинлекләр туды. 1927 елда фашистик Польша хөкүмәте канаты астында Әзербайҗан, Украина, Төркстан, татар-башкорт һәм башка буржуаз милләтчеләрне берләштергән «Прометей» Лигасы барлыкка килә. Бу оешмада бары Белоруссия һәм Әрмән милләтчеләре генә юк иде. Анда Идел-Урал халыкларының «вәкиле» булып, Гаяз Исхакый да керә. Бу оешма формаль яктан Советка каршы пропаганда белән шөгыльләнсә, чынлыкта исә аның бурычы киңрәк була: эмиграциядәге офицерларны Советлар Союзына каршы сугышка әзерләү, СССРга шпионнар һәм диверсантлар җибәрү, шпионлык мәгълүматлары туплау һәм башкалар. Соңрак Төркиядәге немец-фашист илчесенең үз хөкүмәтенә җибәргән хәбәрендә «Прометей»ны Польша генштабының бер тармагы дип атавы очраклы хәл генә түгел[2].

Чит илләрнең акчалата булышлыгы контрреволюцион эмиграциягә үзенең вакытлы матбугатын булдыру мөмкинлеген дә бирә. «Идел-Урал» дигән татар-башкорт эмиграцион комитеты Берлинда, әнә шулай 1928 елны үзенең «Милли юл» журналын чыгара башлый. (1930 елдан «Яңа милли юл»). Шул журнал битләрендә татар-башкорт эмиграциясе унбер елга якын котырынып антикоммунистик пропаганда алып барды. Журнал нәширләре Идел буе һәм Уралда социалистик төзелешнең мөһим мәсьәләләре — социалистик индустрияләштерүгә, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү, культура революциясенә саннан-санга ялган бәя һәм эчтәлек биреп, Россиядә Совет власте таркала, аны бәреп төшерү өчен бер этәргеч кенә кирәк, дигән фикер таратмакчы булдылар. Журналның 1929 елның январь санында, мәсәлән, болай диелә: «Беренче карашка Советлар Россиясендә большевиклар режимы яшәсә дә, ул үзенең көчен күптән югалтты инде, ул бары инерция буенча, аңсыз рәвештә генә власть башында кала бирә. Халык (контрреволюция — М. А.) өчен бу мәгънәсезлекне юк итү хәзер бары вакыт эше»[3].

Бу журнал «җырын җырлаган» солтангалиевчеләр — Совет властеның эчке дошманнары да СССРда пролетариат диктатурасының тиздән бетүенә өмет баглыйлар иде. Шуңа күрә дә солтангалиевчеләрнең контрреволюцион оешмаларын тар-мар итү татар-башкорт эмиграциясен чыгырыннан чыгарып котырындырды. Контрреволюция советка каршы пропаганданы көчәйтү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга омтылды. 1931 елда, мәсәлән, Иерусалимда III Бөтендөнья мөселман конгрессы җыел-

---

[1] Г. Исхакый. Идел-Урал. Париж, 1933, 45 бит.
[2] Германиянең тышкы эшләр министрлыгы документлары. Германиянең Төркиядәге политикасы (1941—43 еллар) М., 1946, 38 бит.
[3] Г. Касыймов. Пантөрки контрреволюциясе һәм аның агентурасы солтангалиевчеләр. Казан, 1931, 52 бит.

гач, «Идел-Урал» комитеты анда СССР вәкилләре килүгә каршы көчле кампания оештырды. Комитет белдерүендә СССРда мөселман дине эзәрлекләнә, шуңа күрә аннан конгресска вәкилләр күз буяу өчен генә җибәрелә диелгән. Гаяз Исхакиның конгресстагы чыгышы да Совет дәүләтенә дошманлык, тирән нәфрәт хисләре белән сугарылган була.

Утызынчы еллар башында яңа бөтендөнья сугышы ачылу куркынычы тагын да арта. Япон сугыш чукмарларының Ерак Көнчыгышта Манчжурияне басып алулары Япониянең Советка каршы политикасының кискен булуын бәхәссез төстә раслады. Шуны гына көтеп торган татар-башкорт контрреволюциясенең җитәкчеләре тиз арада Кытай, Корея һәм Япониядә яшәүче антисоветик элементларны берләштерү чарасын күрә башлыйлар. 1934 елда Гаяз Исхаки, Ерак Көнчыгышка килеп, «Паназиат клубы»нда (Токио) чыгыш ясый. Андагы милитаристларның Тын океаннан Уралга кадәр «Бөек Япония» төзү турындагы хыяллары белән Исхакиның «азиатларның бердәмлеге» турындагы идеяләре аваздаш яңгырый. Шуңа күрә алар реакцион Япония матбугатының киң яклавын тапты. Шул ук елны Кобеда (Япония) Исхаки үз тарафдарлары белән киңәшмә уздыра, ә 1935 елда аның инициативасы белән Мукденда (Манчжурия) милләтчеләр съезды җыела. Анда дини, финанс, мәгариф идарәләреннән торган «Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини-милли мәркәзе» төзелә. Тиздән «Милли Байрак» газетасы да чыга башлый (1935 ел). «Әгәр Япония хөкүмәте интересларына туры килмәсә, Идел-Урал төркиләренең бу эшчәнлеге мөмкин дә булмас иде, билгеле»,— дип яза шул чакта немец фашистлары матбугаты. Нәтиҗәдә татар-башкорт эмигрантларының хокуклары да киңәя: элегрәк Япония һәм Манчжоу-Го курчак хөкүмәте аларны Россия гражданнары дип йөртсә, хәзер исә алар үз милләт кешеләре дип карадылар.

Икенче бөтендөнья сугышы алдыннан Төркиядәге контрреволюцион эмиграция дә активлаша. Ул төрки халыкларын берләштергән Төрек иле дәүләте төзергә котырынып омтыла. Бу пантөрки идеяне Әхмәтзәки Вәлидов һәм аның тарафдарлары яклый. Шуларның берсе «Бозкурт» («Соры бүре») журналында болай дип язды: «Кемнәр без? Без — Соры Бүреләр. («Соры Бүре» — пантөркизм символы.— М. А.). Безнең идеология Соры бүренең төркилеге. Нәрсәгә ышана Соры Бүреләр? Төрки расасының һәм төрки милләтенең башка раса һәм милләтләрдән өстен торуына ышаналар алар. Бу өстенлекнең чыганагы нидә? Төрки кан...» Пантөрки тарафдарлары үзләренең Гитлерга булган симпатияләрен яшереп тә тормады. Кайберләре хәтта чачләрен һәм киемнәрен дә фюрерча йөртәләр иде. Аларның эшчәнлеге Төркия хөкүмәте игътибарыннан читтә кала алмады, билгеле. Аларны фашистик переворот әзерләүдә гаепләделәр. Үзара дошманлык, политик каршылыклар, йогынты өчен көрәш, файдалы керем чыганаклары өчен бәхәсләр — буржуаз эмигрантлар арасында даими күренеш. Моны объектив карашлы буржуаз тарихчылар да таныды.

Икенче бөтендөнья сугышы һәм, бигрәк тә, фашистлар Германиясенең СССРга явызларча һөҗүме Идел буе һәм Урал территорияләрен «большевизмнан» азат итеп үзләренең халыкка каршы булган планнарын тормышка ашырырга омтылучы контрреволюцион эмиграциянең өметен беркадәр яңартып җибәргән иде. Ләкин, фашистлар Германиясе җитәкчеләренең нинди дә булса «милли дәүләт»ләрне танып, алар белән алыш-биреш итү уйларында да юк иде. Алар Исхаки, Вәлиди кебек эшлеклеләргә шик белән карады. Татар-башкорт милләтләрен җитәкләүне өмет итеп, 1942 елда Германиягә килгән Вәлидинең Тышкы эшләр Министрлыгы тарафыннан бернинди дә аңлатусыз илдән сөрелүе моның ачык дәлиле.

Фашист җитәкчеләре, Германия интересларында кулланулы күздә тотып, бернинди дә принциплары булмаган, эмигрантлар арасында да артык дан казана алмаган вак коммерсант Шәфи Алмас (чын исеме — Габдрахман Шәфиев) кебегрәк тыңлаучан кешеләрне сайлый. Шәфи Алмас, мәсәлән, Көнбатыш Германия тарихчысы П. Мюлен фикеренчә, политикага карагандa күбрәк алкоголь белән шөгыльләнүче «загыйфь шәхес» һәм аның татарлардан «Татарише миттельштелле»гә («Арадашчылык») сайлануы милләтчеләрнең теләкләрен үтәү генә иде. «Арадашчылык»ка тагын хыянәтче Тимербәк Дәүләтшин (кушаматлары — «Өязбәк», «Тимербәк», «Ак») һәм яшь чагында артык мактанчыклыгы өчен «Шыр Шиһап» кушаматы алган Шиһап Нигъматул-

линнар да кертелә. Милләтчеләрнең «Татар-немец корреспонденциясе» журналына редактор итеп хыянәтче Гариф Солтанов билгеләнә (кушаматлары — «Солтан Гариф», «Солтан Гариф Уфалы», «Азат Салават»). Гестапо агентлары Дәүләтшин һәм Солтановны «Татарише миттельштелле»ның вице-президенты дәрәҗәсенә куеп, һәр икесенә дә фашистлар махсус ышаныч күрсәтәләр.

Көнчыгыш фронтта фашистлар үзләре һич көтмәгән зур югалтуларга дучар була. Немец командованиесе, русларны корал көче белән генә җиңеп булмасына ышанып, СССР халыклары арасында дошманлык уяту теләге белән 1941 елның ахырында «милли» легионнар төзү уена килә. Әсирлеккә төшкән Совет Армиясе офицерлары һәм солдатларыннан 1942 елның көзендә татар-башкорт легионы төзелә башлый. «Милли» легионнар төзүдә катнашкан СС группенфюреры, хәзерге «галим» — ориенталист Г. Менде, имештер, әсирлеккә төшкән татар офицерлары һәм солдатлары үз дошманнарының дошманнарына (немец фашистларына — М. А.) симпатия белән карадылар һәм аларның кайберләре үзләренең милли азатлыкларын кысучыларга (коммунистларга — М. А.) каршы көрәшү өчен немецларга хезмәткә язылдылар, дип язды. Чынлыкта исә... әсирләр легионерлар сафына политик карашлардан чыгып түгел, ә фашистларның көчле басымы астында һәм исән калу, беренче уңай очракта ук партизаннар ягына чыгу теләге белән басты, дип язды үз китабында немец буржуаз тарихчысы П. Мюлен. Фашистларның татар-башкорт легионы батальоннарын Кызыл Армия гаскәрләренә каршы куллану уе барып чыкмый. Бары Дәүләтшин, Нигъмәтуллин, Солтанов, Әйдәголов һәм Исхаков кебек хыянәтчеләр генә, фашистларга хезмәткә яллаңып, әсирләр арасында «идеологик эшкәртү» һәм күзәтү алып бардылар. Фашистик матбугат битләрендә киләчәктә татарларга аерым өстенлекләр биреп һәм аларга рейх протектораты астында Идел-Урал дәүләте төзүдә булышачак гитлерчыларга һәрьяклап ярдәм күрсәтергә кирәк, дип кычкыручы мәкаләләр басыла. Аеруча Дәүләтшин зур тырышлык күрсәтә. Мәкаләләрдән тыш, фашистлар ярдәме белән ул рус һәм башка халыкларга карата нәфрәт, милләтчелек хисләре белән сугарылган тагын ике брошюра да язып чыгара. һәм «Бөек Германия рейхы һәм аның җитәкчесе Адольф Гитлер үз интереслары өчен генә көрәшеп калмыйча, Европаны еврей властеннан коткарып калу өчен дә тырыша. Төрки-татарлар өчен бердәнбер котылу юлы шушы көрәштә»,— дип белдерә ул «Татар тарихы» китабында[1].

Билгеле булганча, кешелек җәмгыятен күрә алмау пропагандасы татар-башкорт легионерларына әллә ни сизелерлек йогынты ясый алмады. Аларның күбесе Туган илләренә тугрылыклы булып калды. Биредә татар шагыйре Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен патриотик группаның да роле зур булды, билгеле.

Хыянәтчеләр һәм сатлык җаннар совет яшерен оешмасының эзенә төшә. Билгеле булганча, бу кара эштә Шәфи Алмас, Солтан Гариф, Кунафин һәм Җамалетдинов бигрәк тә тырышлык күрсәтәләр. Гариф Солтановка үзе саткан Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен җәзалап үтерүдә катнашу мөмкинлеге бирелә.

Немец фашистлары белән хезмәттәшлек итүнең соңгы чорында татар-башкорт контрреволюциясе 1944 елда Грейфсвальдта (Германия) «корылтай»га җыела. Съездда «Идел-Урал республикасы» төзелү игълан ителә, составына Шәфи Алмас, Солтан Гариф, Кунафин, Дәүләтшин һәм башкалар кергән комитет сайлана. «Корылтай»ның эше, асылда, шуның белән чикләнә дә. Фашистларның басып алынган Көнчыгыш территорияләре эше буенча министры Розенберг съезд тарафыннан сайланган «Идел-Урал» комитетын раслаудан баш тарта һәм «Татар арадашчылыгы» «Большевизмга каршы көрәш союзы» дип үзгәртелә[2].

Совет Армиясе гаскәрләре Берлинга якынлаша башлагач, сатлык җаннар һәм җәмгыять тарафыннан кире кагылган элементлар тиешле җәзадан качып Көнбатышка, Англия, Америка гаскәрләренә таба качтылар.

---

[1] «Советская Башкирия», 1978, 14 июль.
[2] Ю. Карчевский, Н. Лешкин. Лица и маски. Уфа, 1975, 116—119 битләр.

Әле Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланып та өлгермәде, ә инде Америка Кушма Штатларының идарәче даирәләре дөньяда хакимлек итүгә юнәлдерелгән политик курсларын игълан иттеләр. Халыкара империализм әледән-әле киеренкелек учаклары булдыра торды, атом бомбасы куллану белән янап, азатлык яулаган халыкларның эчке эшләренә тыкшынырга маташты, шпионнар һәм диверсантлар җибәрде, социализмга каршы яла ягу кампанияләре киң масштабларда уздырылды. «Салкын сугыш» шартларында АКШ һәм башка империалистик илләрнең шпионлык һәм пропаганда аппаратларына күп санда фальсификация һәм дезинформация буенча тәҗрибәле «белгеч»ләр, шпионнар кирәк була башлый. Һәм алар Украина, Литва, Кырым, татар-башкорт һәм башка милләтчеләр, сатлык җаннар арасыннан табыла да. Кичәге җинаятьчеләр — немец фашистларының ялчылары Англия һәм Америка разведкаларының агентларына әйләнә.

1953 елда Мюнхенда (ГФР) ЦРУның филиалы булган «Азатлык» («Свобода») радиостанциясе үзенең корткычлык эшләрен башлап җибәрде. «Азат Европа» радиостанциясе кебек үк, «Азатлык»ның эшчәнлеге халыклар арасында үзара мөнәсәбәтне яхшыртуга, халыкара хокук нормаларына каршы килә иде. Көнбатыш матбугаты билгеләп үткәнчә, бу радиостанцияләр социалистик илләрдәге тыңлаучыларны провокация максатында таратылган гайбәтләргә ышандырырга, аларның киләчәккә ышанычларын какшатырга, хөкүмәтләренә каршы котыртырга тырышалар. Бу уңай белән Швейцариянең «Нойе цюрхер цайтунг» газетасы: «Азатлык» радиостанциясе алдында Совет җәмгыятенә каршы ачыктан-ачык көрәштән баш тартып, СССРга каршы идеология диверсиясе алып бару бурычы йөкләтелгән»,— дип язды[1].

«Азатлык» радиостанциясендә татар-башкорт редакциясе дә эшли. Хәзерге вакытта аны куллары Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең канына буялган сатлык җан Солтан Гариф җитәкли. Солтан Гарифның кара пропагандадагы коллегалары Шиһаб Нигъмәти (кушаматлары — Йосыф оглы, Йосыф Аксан оглы), Галим Әйдәголов (А. Галим, Б. Мусабай), Фатих Исхаков, ак эмигрант Гали Акыш һәм башкалар. Татар-башкорт редакциясе Идел буе һәм Урал республикаларына каршы көчле пропаганда алып бара. Совет матбугаты хәбәр иткәнчә, «Азатлык» радиостанциясе татарча тапшыруларында фактларны бозу, чынбарлыгыбызның кайбер якларын тенденциоз яктырту юлы белән КПСС һәм Совет хөкүмәтенең милли политикасына явызларча яла яга. Татарстан АССРны кысуга һәм аның тигезсез хәлдә булуына, татар теле һәм милли культурасына карата «руслаштыру политикасы» үткәрелүенә тыңлаучыларны ышандырырга маташа.

Матбугат хәбәрләренә караганда, «Азатлык»ның татар-башкорт редакциясе «эшчәнлеге» моның белән генә чикләнми. Татарстанга кунакка килгән чит ил гражданнары аша Совет гражданнары арасыннан үзенә «корреспондентлар» тупларга һәм шул ук вакытта Советка каршы һәм милләтчелек рухы белән сугарылган документлар таратырга маташа. Безнең дошманнарыбызның ниятләре ачык: артта калган аерым кешеләрнең күңелендә милләтчелек карашлары уяту һәм Совет хөкүмәте, коммунистлар партиясенең политикасына шик уяту.

Сатлык җаннар һәм ак эмигрантлар күп вакыт бергәләп эш итәләр. Алар СССРга каршы әдәбият һәм провокацион хатлар җибәрү, безнең илгә килер алдыннан чит ил агентларына инструктаж бирүдә катнашу, чит илләрдәге Совет гражданнары белән бәйләнешкә керү юлларын эзләү, төрле провокацияләр әзерләү белән шөгыльләнәләр. Мәсәлән, Солтан Гарифның ГФР территориясендәге Совет туристларына социалистик җәмгыятькә каршы фикерләр тагарга маташу очраклары билгеле[2]. Шул ук Солтан Гариф, хаҗга баручылар белән очрашып, Совет җәмгыятенә каршы котырту һәм АКШның үзәк разведка идарәсе өчен информация туплау максаты белән берничә тапкыр Мәккәгә барды[3]. Ә күптән түгел Совет матбугаты татар-башкорт һәм Үзәк разведка идарәсенең башка агентлары тарафыннан Мюнхенда әзерләнеп, тормышка ашырылган провокациясе турында хәбәр итте. Һәрвакыттагыча, аларның Совет

---

[1] «Комсомолец», ВЛКСМның Ростов өлкә комитеты органы, 1977, 1 март.
[2] Ю. Карчевский, Н. Лешкин. Лица и маски. Уфа, 1975, 7—14 битләр.
[3] «Неделя», 1977, № 15, 9 бит.

спортчыларын Көнбатышта калырга «үгетләргә» тырышулары бөтенләе белән уңышсызлыкка дучар булды [1].

1950 елда Мюнхенда оештырылу көненнән алып «Азатлык» радиосы белән тыгыз мөнәсәбәттә торган «СССРны өйрәнү институты» чын мәгънәсендә фальсификаторлар һәм ялган галимнәр оясына әверелә. Биредә СССР тарихын өйрәнү чынбарлыкны советка каршы пропаганда максатларында бозып аңлату белән алыштырылган. «Институт» үз хезмәтләрен бастырып чыгара, әледән-әле «фәнни» конференцияләр оештыра. Аларда күп вакыт «профессор» Дәүләтшин, ике университет дипломын кулга төшерү җаен тапкан «доктор» Солтан Гариф һәм башка ялган галимнәр катнашалар.

Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр турында фикер алышуларның «фәнни» дәрәҗәсе турында конференциядәге чыгышлар бик ачык сөйли. «Институт»ның X конференциясендә, мәсәлән, хәзерге совет авылы турындагы мәсьәлә хакында фикер алышуларда Йосыф оглы (Шиһап Нигъмәти) дә катнаша. Ул хәтта СССРның кан дошманнарын да шаккатырган «ачыш» ясый: СССРда чирәм җирләрне үзләштерү, имеш, КПССның халыкларны күчереп утырту ихтыяҗыннан килеп чыккан зарурилык икән! «Халыкларның бу күченүе белән,— дип яза Йосыф оглы дигән «галим»,— КПСС яшьләрнең берниндн принципсыз, милләтсез, денсез булып үсүләрен тели» [2]. Дәүләтшин да үз язмаларына фәнни төс бирергә омтыла. Ләкин барча «хезмәтләренең» төп идеясе — имештер, Лениннан башлап, Совет җитәкчеләре татар халкына карата кысу политикасы алып баралар... Кешелек сыйфатларын инде тәмам югалткан бу мескен хыянәтченең әлеге белдерүләреннән аның коммунистлар партиясенә, безнең илнең барча азат халыкларына, шул исәптән татар халкына да нәфрәтенең көчен аңларга мөмкин.

Җитмешенче елларда Дәүләтшинның Совет Татарстанына багышланган тагын бер хезмәте дөнья күрде. Аның да эчтәлеге шул ук: элеккеге татар буржуазиясе эшлекләрен чиктән тыш мактау, татар халкын көчләп ассимиляцияләү һәм руслаштыру турындагы ялган уйдырмалар. Бу мисаллардан соң Совет авторларының «Дәүләтшин бер сынык икмәк өчен теләсә кемгә хезмәт итәргә дә әзер» дип әйтүләренә ышанмый мөмкин түгел.

Ак эмигрант Гали Акыш та үзен череп беткән антикоммунист итеп танытты. Аның китабы татар һәм башкорт халыкларының үткәне һәм бүгенгесе турында надан фикерләр белән тулы. Аерым алганда, ул Совет тарихчыларын башкорт халкының Салават Юлаев җитәкчелегендә 1773—75 еллардагы крестьяннар сугышында катнашуларын ялган яктыртуда фаш итмәкче. «...Совет тарихчылары,— дип яза Акыш,— азатлык өчен бу хәрәкәтне сыйныфлар арасында барган көрәш итеп күрсәтәләр, аның бары рус пролетариаты җитәкчелегендә генә мөмкин булганлыгын расламакчылар...» Моның белән Акыш Совет тарих фәненнән аз гына да мәгълүматы булмавын күрсәтте, чөнки XVIII гасырда Россиядә әле капитализмның да, пролетариатның да булмавы бездә хәтта һәр балага мәгълүм.

Татар-башкорт контрреволюциясе, төрле «үзәкләр» һәм «институтлар» белән хезмәттәшлек итеп, Америка разведкасы күрсәтмәсе буенча аерым оешма буларак та берләшергә омтыла. Әнә шулай, 1952 елны ГФРда Үзәк Разведка Идарәсе средстволарына Дәүләтшин, Солтанов, Әйдәголов, Шәфиев һәм башкаларны берләштергән «татар-башкорт милли комитеты» төзелә. Бу комитет ике ел буе һәр сәхифәсе яла ягу һәм антисоветизм белән тулы «Азат Ватан» журналы чыгарды. Әмма бу органнар озак яши алмады: хыянәтчеләр арасындагы үзара ызгыш-талаш тиздән комитетның һәм журнал редакциясенең таралуына китерде. 1972 елда Исхаков (Аяз Хәким оглы) җитәкчелегендә эмигрантларның «Татар-башкорт либераль-демократик хәрәкәте» дип аталган Советка каршы яңа группасы төзелде. Җәмгыять тарафыннан кире кагылган кешеләрне берләштергән бу төркемнең программасын һәм максатларын Исхаков Казанга язган хатларының берсендә белдерде. Аның сүзләренә караганда, бу максатлар СССРдагы «тоталитар диктатура режимын бетерү өчен, язучылар, шагыйрьләр, сәнгать хезмәткәрләренә тулы иҗат ирege бирү өчен» көрәшүдән гыйбарәт, ул шушы «хәрәкәт» программасы нигезендә эш итәргә чакыра [3]. Бүтәнчә әйткәндә, Советка

[1] «Неделя», 1978, № 24, 6 бит.
[2] СССРны өйрәнү институтының X конференциясе. Мюнхен, 1958, 188 бит.
[3] «Социалистик Татарстан», 1977, 10 декабрь.

каршы бу оешма уставыннан Советлар Союзында яшәп килгән дәүләт строен үзгәртү максаты ачык күренә.


Совет чынбарлыгына каршы көчләр эшчәнлеге өчен безнең илебездә социаль нигез юк, билгеле. Совет социалистик җәмгыяте коммунистлар партиясе җитәкчелегендә коммунистик җәмгыять төзү өчен фидакарь хезмәт итүче эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар һәм халык интеллигенциясенең ныклы союзына нигезләнгән.

Контрреволюцион эмиграциянең эшчәнлеге халыкара киеренкелекне йомшартуга комачаулый, халыкара мөнәсәбәтләрдә төрле социаль системалы дәүләтләрнең янәшә тыныч яшәү принципларына киртә булып тора, халыкара хәлнең начараюына китерә. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежнев 1978 елның май аенда Германия Социал Демократик партиясенең атналык органы «Форвертс» корреспонденты сорауларына җавап биргәндә, «салкын сугыш чорларын сагынып», социализмга каршы агрессив планнар коручы элементларның эшчәнлеге турында искә төшергәндә, барыннан да элек, эмиграциядәге төрле контрреволюцион оешма һәм группаларны, аерым алганда, аларның ГФРда җирлек тапканнарын да күз алдында тотты. Шуңа күрә безнең партиябез Совет халкын уяу булырга, безнең дошманнарыбызның төрле мәкерле тыкшынуларын кире кагарга һәрвакыт әзер булырга чакыра.

**МИДХӘТ АБДУЛЛИН,**
тарих фәннәре кандидаты.

# «ТУКАЙ» — ШАГЫЙРЬНЕҢ ФАМИЛИЯСЕМЕ, ПСЕВДОНИМЫМЫ?

Габдулла Тукайның тәрҗемәи хәленә кагылышлы «ак таплар» һаман да очрап тора. Аларны бетерәсе, һич югында, киметәсе килә. Тикшеренүчеләргә тиешле документлар белән ныгытылмаган, төрле гөманлы фикерләр аркасында барлыкка килгән буталчыклардан да сакланырга кирәк. Югыйсә, «Казан утлары» журналының 1973 елгы 12 нче санында «XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар» дигән мәкаләдә (авторы М. Мәһдиев) болай диелгән: «Әдәбиятка аяк баскан, сәнгать дөньясына зур дәрт белән омтылган яшь язучыны, шагыйрьне үзенең иң гади исем-фамилиясе канәгатьләндерми башлый. Ниндидер күркәм, кешедә булмаган, поэтик яңгырашлы исем аласы килә. Мәсәлән, Тукай «Габдулла Мөхәммәтгариф улы» яки һич югында, «Габдулла Гарипов» булырга тиеш иде. Ләкин ул үзенең иң беренче публикациясенә үк «Габдулла Тукай» дип имза куя. Тукайның нәсел-нәсәбеннән дә, замандашларыннан да бу псевдонимның каян килгәнен әйтеп калдыручы булмаган. Тукайның ерак нәселендә дә андый кешенең бар-


Копия

ЗАПИСЬ АКТА О ЗАКЛЮЧЕНИИ БРАКА № 3
НЕКЕ ҚИЮ ТУРАЛЫ АКТІНІ ЖАЗУ

декабря 1895 г.

СВЕДЕНИЯ О ВСТУПАЮЩИХ В БРАК — НЕКЕЛЕСУШІЛЕР ТУРАЛЫ МӘЛІМЕТТЕР

| | | Он | Она |
|---|---|---|---|
| | Фамилия — до заключения брака | Забиров | Тукаева |
| | после заключения брака | | Забирова |
| | Имя | Абурахман | Бибигазиза |
| | Отчество | Фахрутдинович | Мухаметгарифовна |
| 4 | Время рождения | 19 г. | 19 г. |
| | Возраст | исполнилось лет | исполнилось лет |
| 5 | Место рождения | город (селение), район, область (край, республика) | город (селение), район, область (край, республика) |
| 6 | Национальность | татарин | татарка |
| | Где и кем работает (если не работает, то указать источник к существованию) | | |

Бибигазизә белән Габдрахманның никах язуы

лыгы иска алынмый. Каян килгән бу? Габдулла Гарипов аны очраклы рәвештә алмагандыр бит? «Тукай» сүзенең мәгънәсен бәлки гарәп-фарсы сүзләреннән чыгып эзләргә кирәктер? Гарәп-фарсы телләренең белгечләре моны ачыкларга бәлки ярдәм итәрләр?

Чыннан да, «Тукай» шагыйрьнең фамилиясеме, әллә псевдонимымы? Бу сорауга биредә китерелгән никах акты тулы рәвештә җавап бирә. Акттан күренгәнчә, Тукайның апасы Газизә Зәбирова кыз чагында Тукаева фамилиясен йөрткән. Шулай булгач, аның энесе Габдулла да шундый ук фамилияле була түгелме соң? Югарыда телгә алынган мәкаләдә бу мәсьәлә турында фараз ителгән сүзләр чынбарлыкка туры килми. Мәкаләдәге «Тукайның ерак нәселендә дә андый кешенең (Тукай дигән кешенең) барлыгы иска алынмый» дигән сүзләргә дә ризалык биреп булмый. Тукайның нәселләре үзләренең җиде бабаларын белгәннәр. Безгә, үзенең балаларына, әни шулай ди торган иде: «Һәрбер кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш. Сезнең бабагыз Мөхәммәтгариф (Тукайның атасы), Мөхәммәтгарифның атасы — Мөхәммәтгалим, Мөхәммәтгалимнең атасы — Шәмсетдин, Шәмсетдинның атасы — Мортаза, Мортазаның атасы — Туктулы. Шуннан килеп чыккан «Тукай»... Уральск шәһәрендәге татарлар өчен ачылган рус мәктәбендә учитель Әхмәтшада укыганда ук шагыйрьнең рәсми документларда теркәлгән фамилиясе Тукаев була (1896—1897 еллар). Шуны да истә тотарга кирәк иде: Габдулла Тукай тышкы ялтырау, «матурлыкларга» кызыккан кешеләрдән булмаган. Аның эчке рухи байлыгы, матурлыгы, җәүһәрләре тышка да балкып чыккан. Аңа төрле «күркәм», «поэтик яңгырашлы» исемнәр кирәк булмаган. Кайбер белгечләргә Габдулла Тукайның бу сыйфатын да онытып җибәрмәскә кирәк иде. Димәк, фактлар күрсәткәнчә, «Тукай» сүзе шагыйрьнең псевдонимы түгел, ата-бабалардан калган фамилиясе.

**Х. ЗӘБИРОВ.**

*Казан шәһәре*

Зәки Нури

# ЧӘНЕЧКЕЛӘР, КЕЧКЕНӘ МӘСӘЛЛӘР, НӘНИ ШАЯРУЛАР

## Артык әби

— Димәк, күрше, инде кире кайттың...
Туйдырдымы әллә Казан-кала?
— Оныкларым үсеп буйга җитте,
Үз-үзләрен инде карый ала...

## Бәлагә тару

— Тормышкаең, дустым, ничек тәгәри?
— Тардым әле, тардым заман бәласенә:
Биш йөз сумлык ссудага тун алдым —
Миңа иргә чыкмый калган... кәләшемә.

## Җәлләү кирәкми

Әгәр әнкәң миңа бирмим дигән икән,
Өзгәләнмә, мине җәлләп елама:
Күңелемдә күптән йөргән бер чибәр бар —
Иртәгә үк өйләнәләм мин аңа.

## Кәләш эзли...

«Булсын,— диеп,— әти-әниле!»
Кәләш эзли гомер итәргә.
— Ә ник кирәк әти-әнисе?
— Кирәк чакта... хатын китәргә.

## Сәер имгәнү

Берәү, марля белән бәйләп,
Кулын муенга аскан.
— Ни булды?

— Буфетта кемдер
Аягы белән баскан?!.

## Зур культура

— Урамга чыгып өрмим дә,
Кухняда гомер итмим:
Мин балконда гына торам —
Зур культуралы эт мин!

## Уйлый абзый

Доктор әйтә: «Эчсәң — башың бетә...
Һәм ташларга кирәк тартуны...»
Уйлый абзый: «Димәк, биредә дә
Булган икән минем хатыным».

## Бар да, юк та

Кемдер гайбәт тараткан:
Имештер, эштә йоклыйм?!.
Ничек дип йоклыйм булсын,
Чөнки бит эштә... юк мин?

## Көзгегә карап уйлану

Тизрәк иргә чыгар идем,
Табылмый бит кияү һаман...
Бу бизәнү-ясанудан
Туеп беттем инде тәмам.

## Уйнап әйтсәң дә уйлап әйт икән

— Ялгышканмын моннан ун ел элек
Бер танышка әйтеп: «Кергәлә!..»
Шуннан бирле көн дә килми калмый,
Бер башыма алдым мең бәла...

## Борчак сипте бераү

— Тәнкыйтьнең күзе коралды.
Әмма минеөүтерми ул.
Зыяны тик укучыга,
Безгә... зарар китерми ул.

## Буш кармак

Тар бәкедән башын өскә сузып
Балыкчыга әйтә түрә-балык:
— Кем капсын ди синең борчагыңа —
Ник килмәдең кызыл икра алып?

## Егылганны кыйнамыйлар

Яңа чыккан китабына
Капланган да бер автор
Шулай ди икән... син, тәнкыйть,
Димәк, аннан ерак тор!

## Ауда

— Әнә куян! Тизрәк ат та тидер!
Сиңа дигән, сиңа язган ит ул...
— Ашыктырма, тукта! Күреп калыйм,—
Әгәр атсам, качып китә бит ул.

## Шагыйрь белән сөйләшү

— Бу шигырь бит күзгә йокы кертә...
Китергәнсең безгә юкка син.
— «Бишек җыры» дигән исем куйыйк,
Теләгәннәр, әйдә, йокласын!

## Утсыз яктылык

Лампадалар. Люстра һәм төнлекләр...
Бар да кирәк. Бар да асыллар.
Ә бирedә шуның барчасына
Шәм яндырып... ремонт ясыйлар.

## Һәркем үзенчә курка

— Поэмам бу. Тоташ ут дип беләм!
Мин башладым аны бик яшьләй...
Ә мөхәррир уйлый:— Монда су да
Аз түгелдер әле, иптәшкәй?!

## Чөй белән чөй сөйләшә

— Ник соң әле болай бер-беребезне
Чыгарабыз бәреп урыннан?
— Балта-чүкеч төшми чөнки, дустым,
Һич кайчан да оста кулыннан.

## Ялдан соң

— Йөз китап укыдым!.. Ләкин
Башта калганы сирәк.
— Димәк, рухи азыкны да
Чәйни белергә кирәк.

## «Эштән чыкты»

«Тарта. Эчә. Газит-журнал алмый...
Көпчәккә гел таяк тыга...»—
Шефны тәнкыйть иткән өчен
Бер бичара эштән... «чыга».

## Ишек төбендә этюд

Иренең кулында чәчәк,
Хатыны тукмак тоткан.
Абзый дәшми, ык-мык итә:
Эчкән дә... телен йоткан.

## Пегас белән хушлашу

— Хуш син, атым! Боза диеп антын
Уйлый күрмә... Күчәм «Волга»га!
Юнәлешен һәм тизлеген хәзер
Үзгәртмичә акмый елга да.

## Бер морж белән сөйләшү

— Каян килде сезгә шундый кыю түзем —
Бозлы суга чумганда да чыдарлык?
— Былтыр кышын мунча кайнар сусыз булды
Шунда туды һәм чыныкты чыдамлык.

## Чирем нинди?

— Бар да миңа «Телеңне тый!» диләр,
Әйтмәүчеләр шуны бик сирәк.
Аны, доктор, ничек тыеп була?
— Теш артында тотарга кирәк!

## Күп кешеле күргәзмәдә

— Өч-дүрт сәгать карап тордым синең «Яз»га...
Бер күңелем мең төрле уй уйлый иде.
— Ник бик озак?
— Чөнки бүтән сурәтләрнең
Берсенә дә якын килеп булмый иде...

## Зурдан кубу

— Тик үз сайланмамны укыйм!—
Бүтән китап кирәкми.
Безнең теләк — зур Кит тоту,
Ә вак балык... эләкми.

# 1981 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР


КОЯШЫБЫЗ — ЛЕНИН

Велюгин А. **Давыл алдыннан.** Шигырь. **№ 4.**
Вәлиев Д. **1887 ел.** Пьеса. **№ 4.**
Майтени Э. **Ленинны онытмыйбыз.** Шигырь. **№4.**

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Белялов У. **Бүгенге һәм киләчәк хакына. № 1.**
Фәтхуллин Р. **Гап-гади Халиков.** Очерк. **№ 2.**
Хамматов Ш. **Муса Җәлил — партия солдаты. № 1.**
Шәрипов В. **Сынаулар аша. № 2.**

СЪЕЗДГА — ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

Камалов Х. **Фикер уты.** Шигырьләр. **№ 2.**
Рәхим Г. **Иген өчен — илең өчен.** Шигырь. **№ 2.**
Сафин Ф. **Яңа таң.** Шигырь. **№ 2.**

КПССның XXVI СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Абдуллин Ф. **Чакырулар. № 5.**
Гәрәев М. **Горурлык.** Очерк. **№ 9.**
Зарипов М. **Шәһәрнең ачкычлары. № 7.**
**Проблемаларның үзәгендә — кеше.** Түгәрәк өстәл янында. **№ 10.**
Хөснимәрдәнов М. **Ерактан төшкән килен. № 7.**
Хәбибуллин Ш. Т., Әгъзәмов Ф. И. **Максатлар бердәмлеге. № 8.**

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: ЭШЛӘР ҺӘМ КЕШЕЛӘР

Шакир С. **Ил һәм халык рәхмәте. № 11.**
Әмирханов М., Кильматов Р. **Яңа күпер. № 11.**

ИЛГӘ — ИКЕ МИЛЛИАРД ТОННА ТАТАРСТАН НЕФТЕ

Гыйләҗев А. **Татарстан могҗизасы.** Хатирәләр, очрашулар, уйланулар. **№ 10.**
Зарипов И. **Нефткә табан.** Очерк. **№ 9.**
Сафин Ф. **Җир шарының...** Шигырь. **№ 10.**

ТАТАРСТАНДА КАРАКАЛПАКСТАН ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Абдирахманов У. **Туй.** Хикәя. **№ 5.**
Бекбаулов У. **Легенда.** Әсәрдән өзек. **№ 5.**
Каипбиргәнов Т. **Үз-мәз үзем хакында. № 5.**
Каипов М. **Үз каным.** Хикәя. **№ 5.**
**Каракалпак шагыйрьләре иҗатыннан үрнәкләр. № 5.**
Мәгъсүтов К. **Безгә көч биргән дуслык. № 5.**

**Татарстан сәламе.** Шигырь. № 5.
Торсынова Г. **Яшәү яме.** Хикәя. № 5.
Хәмидуллин Л. **Ерак араларны якын итеп.** № 5.

## 8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Бәширова Ф. **Эш.** Шигырь. № 3.
Галиева Ф. **Мактама син мине.** Шигырьләр. № 3.
Гыйматдинова Н. **Бердәнберем хакына.** Повесть. № 3.
Рәхимова Б. **Кыяк үләненең чыклары.** Шигырьләр. № 3.
Сәгыйтова Т. **Күк гөмбәзе йолдыз атып уйный.** Шигырьләр. № 3.
Хәбибрахманова В. **Күңелдәге якты нурлар.** Шигырьләр. № 3.
Хәлиуллина Ф. **Керәш уты ага канымда.** Шигырьләр. № 3.
Шәрифуллина Э. **Табигать җимеше.** Шигырьләр. № 3.

## 1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

Вәлиев Р. **Кайтаваз кайда яши!..** Шигырьләр. № 6.
Галиев Ш. **Безнең йорт малайлары...** Шигырьләр. № 6.
Ихсанова В. **И гүзәл җир, и газиз бала!** № 6.
Миңнуллин Р. **Энекәш кирәк миңа...** Шигырьләр. № 6.
Нури З. **Күпме беләсе килә...** «Нәниләр китабы»ннан. № 6.
Рәкыйпов Ш. **Саубуллашу җыры.** «Кайдан син, Жан?» повестеның икенче кисәгеннән. № 6.
Тимергалин А. **Көрәшү.** Фантастик хикәя. № 6.

## ПРОЗА

Бабель И. **Мопассан.** Хикәя. № 9.
Бикчурин Ш. **Тирән катлам.** № 4, 5, 6.
Бәширов Г. **Сарут.** Хикәя. № 1.
Вәлиев Р. **Гөлмәрҗан мәкләре.** Хикәя. № 2.
Гайнетдинов Х. **Әбиләр чуагы.** Хикәя. № 7.
Гыйләҗев А. **Әтәч менгән читәнгә...** Повесть. № 8.
Еники Ә. **Соңгы китап.** Истәлекләр. № 10, 11.
Кашапов Х. **Ак әби.** Нәсер. № 7.
Кутуй Р. **Сөенче.** Хикәя. № 8.
Кәрами Р. **Сагышлы кояш.** Повесть. № 9.
Кәримов К. **Бер арбада.** Хикәя. № 7.
Минский Г. **Канафер чәчәге.** Хикәя. № 9.
Миңнуллин Т. **Хәсән Вагыйзович.** Повесть. № 6.
Мәһдиев М. **Торналар төшкән җирдә.** Лирик-документаль повесть. № 10, 11.
Нуруллин В. **Һәлакәт.** Повесть. № 12.
Рәхимов Җ. **Тәвәккәл таш яра.** Повесть. № 1.
Сабиров С. **Утлы фарватердан.** Повесть. № 7.
Хәйдәрова Л. **Кырым хикәясе.** № 11.
Хәсәнов Г. **Карт сандугач.** № 7.
Шамов А. **Соры мәче.** Хикәя. № 3.
Шәмси С. **Соңгы юаныч.** Хикәя. № 2.
Шәфигуллин Ф. **Өй салуның нне бар.** Повесть. № 2.
Юныс М. **Бияктә калу.** Повесть. № 3.
Яруллин Ф. **Фаҗига.** Хикәя. № 4.
Әмир М. **Казан.** Автобиографик повесть. № 9.

## ПОЭЗИЯ

Акмалов Н. **Таң.** Шигырьләр. № 2.
Анак Ш. **Шат шигырьләр чоры.** № 3.

Арсланов Н. **Дулкыннарга карап.** Шигырьләр. **№ 4.**
Афзал Г. **Ага сулар.** Шигырьләр. **№ 5.**
Баянов Ә. **Ак канатлар.** Шигырьләр. **№ 1.**
Беляев И. **Тимер юлда уйлану.** Шигырь. **№ 2.**
Булатова К. **Печән исте...** Шигырьләр. **№ 7.**
Гадел Ә. **Хәтер.** Шигырь. **№ 5.**
Галиев М. **Яңгыр шавы.** Шигырьләр. **№ 6.**
Гатауллин Р. **Йөзүчеләр.** Шигырь. **№ 3.**
Гаташ Р. **Бабич.** Шигырь. **№ 11.**
Гәрәева С. **Урал дәфтәреннән. № 12.**
Гыйззәтуллина Ф. **Рәхмәт сүзе.** Шигырьләр. **№ 9.**
Зәйдуллин Р. **Сезнекеме!** Шигырьләр. **№ 11.**
Зөлкарнәев Л. **Бар дөньяның.** Шигырь. **№ 4.**
Зөлкарнәев Л. **Якты күләгәләр. № 12.**
Идиятуллин Р. **Бүген туган көнем.** Шигырьләр. **№ 4.**
Измайлова Н. **Ракеталар, нервлар һәм акыл.** Шигырьләр. **№ 6.**
Камалиев Т. **Кырык яшьтә.** Шигырьләр. **№ 5.**
Латыйп Г. **Таңнар, таулар...** Шигырьләр. **№ 7.**
Латыйп К. **Дүрт җыр.** Шигырьләр. **№ 9.**
Маликов Ә. **Күтәрелеп буразнадан. «Якташлар» циклыннан. № 8.**
Маннапов Ш. **Гипноз сеансында уйлану.** Шигырьләр. **№ 4.**
Мингалим Р. **Ике авыл арасы.** Поэма. **№ 6.**
Минһаҗева А. **Болгарда уйланулар.** Шигырьләр. **№ 9.**
Миңнуллин Р. **Киләчәккә таба.** Шигырьләр. **№ 2.**
Моратов Г. **Бер йотым су җитми кала.** Шигырьләр. **№ 11.**
Мәхмүдов Ә. **Бәхетем үзем белән.** Шигырьләр. **№ 7.**
Рәхим Г. **Немец дустыма.** Шигырь. **№ 5.**
Рәхим Г. **Олыгаю.** Шигырьләр. **№ 7.**
Рәшитов Ә. **Бәхетсезлек күбрәк булыр иде...** Шигырьләр. **№ 7.**
Сафин Ф. **Сандугач җыры.** Шигырьләр. **№ 11.**
Сөләйманов Б. **Себер урманы.** Шигырьләр. **№ 9.**
Төхфи Х. **Төрле еллардан.** Шигырьләр. **№ 7.**
Фәйзуллин Р. **Авыл дәфтәре.** Шигырьләр. **№ 8.**
Хәким С. **Егерме бишенче август.** Шигырьләр. **№ 1.**
Хәким С. **Яңа шигырьләр. № 12.**
Хәлиуллина Р. **Яшенле яшьлегем.** Шигырьләр. **№ 7.**
Хөсәен М. **Ике сонет.** № 9.
Шабаев М. **Карт солдат монологы.** Шигырьләр. **№ 9.**
Юнысов Р. **Исталеккә.** Шигырьләр. **№ 1.**
Яруллин Ф. **Өйрәт, тормыш.** Шигырьләр. **№ 8.**
Әюпов Х. **Тукай клубы.** Шигырь. **№ 4.**

## ҖЫРЛАР

**Юллар җыры.** Әнвәр Бакиров **музыкасы,** Зәки Нури **шигыре. № 2.**
**Ватаным.** Рәшит Абдуллин **музыкасы,** Разил Вәлиев **сүзләре. № 8.**
**Якты көн.** Фасил Әхмәтов **музыкасы,** Гариф Ахунов **сүзләре. № 10.**
**Туган якта һәр тал җырлый.** Әгъзам Фәттах **музыкасы,** Сибгат Хәким **шигыре. № 11.**

## ДРАМАТУРГИЯ

Хәмид Р. **Синең урыныңа кайттым.** Драма 2 бүлектә. **№ 9.**
Юзеев И. **Очты дөнья читлегеннән...** Шигъри трагедия. **№ 10.**

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Арсланов Н. **Юмарт дуслар.** Шигырь. **№ 8.**
Нури З. **Ватан сугышы елларының көлке капчыгыннан. № 5.**

Нури З. Чәнечкеләр, кечкенә мәсәлләр, нәни шаярулар. № 12.
Рәхим Г. Битараф бәндәгә. Шигырь. № 8.
Шәфигуллин Ф. Чират. Корт чаккыры. Хикәяләр. № 8.
Үзләре турында үзләре. № 3.

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Галиев Ш. Аю качкан циркта. Шигырьләр. № 12.

## ДУСЛАР ИҖАТЫ

Бездә кунакта: удмурт шагыйрьләре. № 7.
Бездә кунакта: «Звезда» журналы авторлары. Шигырьләр. № 4.

## ОЧЕРКЛАР ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Вәлиев Р. Якты төн. № 3.
Зәйнуллин З. Карбыз сугышыннан — чын сугышка. № 5.
Зарипов М. Ап-ак карабодай кырлары. № 10.
Кутуй Р. Яшәү орлыгы. № 3.
Котов А. Хәерле юл! № 3.
Мөэминова Э. Ул — остазым минем. № 10.
Нагнойных А. Братск каһарманы. № 8.
Низамиев М. Татарстан — Лейпциг ярминкәсендә! № 3.
Рафиков М. Язмышлар. № 12.
Сыркин Л. Идел бөркете. № 6.
Хамматов Ш. Муса Җәлил — журналист, тәнкыйтьче. № 5.
Хәкимуллин Н. Арктика киңлекләрендә. Юл язмалары. № 2.
Хуҗиәхмәтова Ф. Яннарына үзем барам. № 7.
Шакир С. Намус кушканча. № 1.
Шакиров К. Кырыс язмышлар. № 6.
Әйди Т. Мәрзия ханым исталеге. № 7.
Әйди Т. Аталар һәм уллар. № 12.
Әмирханов М. Татарстан могҗизасы. № 3.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ахунов Г. Ярыш. № 7.
Вәлиев М. Шагыйрь уты. № 11.
Галиуллин Т. Бизәкләр төрлелеге. № 6.
Галимуллин Ф. Хикәя укыганда. № 7.
Кукушкин Р. Шигъри бишек. № 4.
Маннапов С. Мин сезгә ышанам (Вакыйф Нуруллин иҗаты турында). № 7.
Миңнуллин Т. Яшьләр колагына бер сүз. № 2.
Миңнуллин Ф. Тәнкыйтьче бәхете. № 5.
Миңнуллин Ф. Хикәя һәм хикәячеләр. № 10.
Мусин Ф. Тормышка актив мөнәсәбәт. № 2.
Мөхәммәдиев Р. Шигъри хәрәкәт һәм аның кайбер тенденцияләре (1980 нче елгы поэзиябезгә бер караш). № 8.
Рәхимова Г. Без кемнәр! № 4.
Урманчеев Ф. Дастаннарга лаек замана. № 2.
Хантимерова Г. Төсләр балкышы (Мәдинә Маликованың иҗат портретына штрихлар). № 8.
Юныс М. Еллар, гасырлар, сулар агышына карап (Илдар Юзеевның иҗат портретына штрихлар). № 9.
Юзиев Н. Уйлы туйра. № 11.
Яркимбаева Ф. Йомшак җилләр булып исәрмен... № 9.
Әхмәтов Р. Сез кем, шагыйрь! № 4.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Вәлиев М. Сандугачлар, кыр казлары һәм кеше. № 3.
Галимуллин Ф. Яшьләр юлга чыга. № 8.
Зөлкарнәев Ф. Максатка ни илтә. № 5.
Кәримуллин Ә., Хәйретдинов Р. Фәндә зур адым. № 1.
Маннапов Ш. Себер киңлегеннән. № 3.
Маннапов С. Юлы җиңелләрдән көнләшмик. № 5.
Маннапов С. Дулкыннар ни сөйли... № 9.
Маннапов С. Бала чакка ешрак кайтыгыз. № 12.
Мостафин Р. Камиллек һәм тирәнлек. № 9.
Мәхмүтов Х. Җыр хәзинәбез. № 11.
Нигъмәтуллин Э. Йолдызлар сүнмәсен. № 7.
Хисамов Н. Әдәбиятка тарихи караш. № 1.
Хисамов Н. Шагыйрьнең күңел яктысы. № 10.
Әгъзәмов Ф. Вөҗдан баскычларын санаганда. № 7.
Әгъзәмов Ф. Рухи туганлык нигезендә. № 10.
Әхмәтҗанов Р., Ханзафаров Н. Тәнкыйть сүзе — кадерле сүз. № 8.

## КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Бәдигов Ш. Хәкимҗан Халиков. Уйныйсың киләме! № 11.
Бәйрәмова Ф. Клара Булатова. Гел кояшка карап. № 11.
Габиди Ә. Батулла. Ташламам, җанкисәгем. № 9.
Гыйльметдинов Х. Казан татарларының халык җырлары. № 9.
Зөлкарнәев Ф. Рашат Низамиев. Йолдыз яңгыры. № 2.
Кәримов К. Адлер Тимергалин. Таш алиһә. № 6.
Леронов Л. Мөдәррис Әгъләмов. Без, без, без идек. № 11.
Мөхәммәдиев Р. Альберт Хәсәнов. Тугрылык. № 2.
Мөхәммәдиев Р. Җәүдәт Дәрзаманов. Төнге маҗара. № 6.
Насыйров Т. К. М. Фасахов. С жизнью в ногу. № 9.
Хәйдәрова Л. Роза Хәлиуллина. Агыйдел — аккош иле. № 2.
Шәрәфетдинов Д. Илдус Илдарханов. Олимп тавына ничек менәргә! № 9.
Шәфигуллин Ф. Шәүкәт Галиев. Әз-мәз мәзәк. № 2.
Янов Х. Резеда Вәлиева. Зәңгәр иртә. № 6.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

Хөснетдинов З. Хыялларга хыянәт итмәгез. № 3.
Шаһиев И. Агым уртасындагы язмышлар. № 3.
Янов Х. Чишмәләр кайдан башлана! № 3.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Вәлиев Н. Юллар чатында. № 2.
Нәфиков Р. Габдулла Тукай һәм аның даирәсе. № 9.
Шамов А. Хатирәләрдән берсе. № 9.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Госманов М. Эзләр дастанга илтә. № 8.
Ильясов Р. Остаз. № 8.
Мәхмүтов Х. Мәңгелек ядкарь. (М. Кашгариның «Диване лөгат-ит-төрк» китабындагы халык иҗаты әсәрләре). № 7.
Мөхәммәдиев Ә. Таңкәләр телгә килсә... № 6.

## СӘНГАТЬ

Белялов Р. **Тамырлары — халыкта. № 3.**
Кумысников Х. **Гөлсем Камскаяның тууына 80 ел. № 3.**
Якупов Х. **«Зур Идел» кыңлекләре. № 1.**
Әһлиуллина Ф. **Алтынчәч. № 3.**

## ФОЛЬКЛОР

Арсланов Л. **Карагаш халык авыз иҗаты. № 2.**

## И. Н. УЛЬЯНОВНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Миндубаев Ж., Трофимов Ж. **Яктылыкка таба. № 7.**

## МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Гарифуллин Д. **Телдән телгә, кулдан кулга. № 11.**
Госманов М. **Шагыйрьнең иҗаты һәм мирасы. № 11.**

## ГАФУР КОЛӘХМЕТОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Вәлиев Д. **Ашкыну. № 5.**
**Гафур Коләхметов хатлары. № 5.**
Шәрипова Г. **Гафурлар гаиләсе.** Романнан өзек. **№ 5.**

## МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Мөлеков М. **Халык күңелендә калган моң. № 10.**
Фәйзуллин И. **Шодадагы көннәремнең таҗы.** Истәлек. **№ 10.**

## ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Иделле Г. **Сөекле шагыйребезне сагынганда. № 1.**
Мөхәммәдиев Р. **Синең Такташың бар. № 1.**
Туфан Х. **Җырланган җырлар турында. № 1.**

## КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Гыйззәтуллин Н. **Яңа тормыш, яңа әдәбият хакына. № 12.**

## ГОМӘР БӘШИРОВКА 80 ЯШЬ

Миңнуллин Р. **Әңгәмә дәвам итә. № 1.**
Поварисов С. **Энҗе бөртекләре. № 1.**

## АФЗАЛ ШАМОВКА 80 ЯШЬ

Мусин Ф. **Көрәшчеләр токымыннан. № 3.**

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Арсланов Н. **Безнең Муса. № 2.**
Бровман Г. **Муса Җәлил белән фронтта очрашу. № 2.**
Гаффар Ә. **Дастанчылар. № 2.**
Енакаев Р. **Бер шигырьнең тарихы. № 2.**
Мостафин Р. **Серле йомгак эзеннән. № 2.**

Фәйзуллин Р. **Еллар үткән саен бнегәя. № 2.**
Харис Р. **Ватандарлык тамырында. № 2.**

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Мөхәммәдова Г. **Фидакарьлек. № 12.**

СИБГАТ ХӘКИМГӘ 70 ЯШЬ

Мөхәммәдиев Р. **Башка бернн дә кирәкми... № 12.**
Поварисов С. **Зөбәрҗәт, алтыннарың!.. № 12.**

НӘҖИП ҖИҺАНОВКА 70 ЯШЬ

Гиршман Я. **Иҗади казанышлар юлыннан. № 1.**

ЗӘКИ НУРИГА 60 ЯШЬ

Ахунов Г. **Күрәштә чыныккан поэзия. № 12.**
Данилов С. **Шагыйрь дуска. № 12.**
**Котлау сүзе. № 12.**
Нури З. **СССР Язучыларының бишенче съездына әзерләнгән чыгыш. № 12.**
**Оршадан хат. № 12.**
Рамазанов Г. **Урманчы. № 12.**
**Эш белән, ялкынлы сүз белән. № 12.**
**Һаман эзләп иң матур, иң яңаны... № 12.**

ГАМИЛ АФЗАЛГА 60 ЯШЬ

Шәфигуллин Ф. **Көлеп моңая, уйлап елмая. № 5.**

ӘДИП МАЛИКОВКА 60 ЯШЬ

Бикчурин Ш. **Озын юллар, ерак еллар арасы. № 8.**

ЮНЫС ӘМИНЕВКА 60 ЯШЬ

Әхмәдуллин А. **Кешелекле иҗат. № 12.**

РӘШИТ ГӘРӘЙГӘ 50 ЯШЬ

Гәрәй Р. **Ветераннар җырлый.** Шигырьләр. **№ 5.**
Харис Р. **Арыш тамырыннан җыр да шыта. № 5.**

РАДИК ФӘИЗОВКА 50 ЯШЬ

Фәизов Р. **Җинаять.** Хикәя. **№ 5.**

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Арсланов Н. **Ибраһим Салаховка 70 яшь. № 8.**
Бәйрәмова Ф. **Асия Хәйруллинага 60 яшь. № 7.**
Бәширов Г. **Игелекле иҗат.** Гарәфи Хәсәновка 60 яшь. **№ 6.**
Вайда-Сәйдәшева Г. **Рөстәм Яхинга 60 яшь. № 8.**
Галиуллин Т. **Нил Юзиевка 50 яшь. № 1.**
Ганиева Ф. **Хәниф Хәйруллинга 50 яшь. № 9.**
Гобәйдуллин Х. **Гыйләҗ Казанскийның тууына 90 ел. № 7.**

Гобәйдуллин Х. Габдерәүф Ниязбаевның туунына 100 ел. № 11.
Гобәйдуллина Ә. Шириязданн Сарымсаковка 70 яшь. № 5.
Гәрәй Р. Габделхәй Сабитовка 50 яшь. № 6.
Гөлсем Болгарскаяның тууына 90 ел. № 10.
Ибраһимова С. Сәрвәр Әдһәмованың тууына 80 ел. № 4.
Константин Лебедевка 60 яшь. № 8.
Маннапов С. Адлер Тимергалинга 50 яшь. № 1.
Миңнуллин Т. Альберт Яхинга 50 яшь. № 11.
Петров К. Василий Юдинга 70 яшь. № 1.
Сабиров С. Садри Җәләлнең тууына 90 ел. № 6.
Сидоров С. Г. Паушкинга 60 яшь. № 2.
Сәйдәшева З. Солтан Габәшинең тууына 90 ел. № 5.
Флера Гыйззәтуллинага 50 яшь. № 9.
Фәхри Әсгатьнең тууына 80 ел. № 10.
Хәйруллина З. Мәрьям Рахманкуловага 80 яшь. № 11.
Хәкимҗанов Ф. Бай эрудицияле галим (Әдһәм Тенишевка 60 яшь). № 5.
Шагыйрә — аккошлар иленнән (Роза Хәлиуллинага 50 яшь). № 7.
Ярлы Кәримнең тууына 80 ел. № 11.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Абдуллин М. Халыкка каршы. № 12.
Баттал С. Шигъри мөрәҗәгать. № 7.
Бадамшин Х. Биш хатирә. № 4.
Гыйльманов Җ. Соңгы «таянычч». № 7.
Иксанов Н. Давыл кардәше. № 8.
Мостафин Р. ЭВМ ни әйтер!.. № 6.
Мөхәммәтҗанов Р. Кояш белән ай микән... № 8.
Рәсулова З. Еллар истәлеге. № 4.
Фәсәхов К. Татарстан АССР төзелү һәм вакытлы матбугат. № 1.
Шакир С. Кызыл чәчәкләр үсәр... № 8.
Шиһапов М. Җанлы курчаклар (Татар дәүләт курчак театры тарихы сәхифәләреннән). № 8.
Шәйхиев Р. Төбәкчелек. № 4.
Әмирханов Р. Социалистик идеаллар чишмәсе. № 2.

Укучының күңел дәфтәренә № 1, 2, 3, 4, 7, 8.
Галиев Ш. Хикмәтле сүзләр. № 2.

## УКУЧЫ СҮЗЕ

Х. Зәбиров. «Тукай» — шагыйрьнең фамилиясеме, псевдонимымы! № 12.

## БЕЗНЕҢ САФКА

Гыйззәтуллина Флера. № 10.
Хәмид Ризван. № 10.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышы булды. Анда «СССР язучыларының VII съезды йомгаклары һәм Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының бурычлары турында» доклад белән СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов чыкты. КПССның XXVI съезды, СССР язучыларының VII съезды куйган бурычлар яктылыгында, илдәге гомуми әдәби процесс фонында республикабыз әдипләре алдында торган яңа иҗат үрләре турында фикер алышуларда Сибгат Хәким, Ринат Мөхәммәдиев, Мәдинә Маликова, Асия Хәсәнова һ. б. иптәшләр катнашты.

Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча җыелыш эшлекле карар кабул итте.

## КҮЧМӘ УТЫРЫШТА КАТНАШУ ӨЧЕН

РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары Гариф Ахунов һәм Сергей Залыгин җитәкчелегендә Петрозаводскида һәм Мурманскида РСФСР Язучылар союзының проза буенча Советының киңәйтелгән күчмә утырышы булды.

Язучылар В. Астафьев, В. Белов, В. Личутин, В. Распутин, «Современник» нәшриятының директоры В. Гусев, «Роман-газета»ның баш редакторы В. Ганичек һ. б. лар составындагы зур группа биредә Россия әдәбияты көннәрендә, «Север» журналын һәм Мурманск прозаиклары иҗатын тикшерүдә катнаштылар. Язучылар белән промышленность предприятиеләрендә, фәнни учреждениеләрдә, балык тоту судноларында әдәби очрашулар үткәрелде.

## МЕҢЕНЧЕ СӘХИФӘ

«Социалистик Татарстан» газетасында даими чыгып килә торган «Әдәбият-сәнгать» сәхифәләренең 1000 нчесе дөнья күрде. Бу — республика культура тормышында әһәмиятле һәм истәлекле бер вакыйга. Меңенче сәхифәдә «Партиянең XXVI съезды карарлары яктылыгында газета битләрендә әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен яктыртуны тагын да яхшырту турында» дигән темага уздырылган сөйләшү материаллары тәкъдим ителде.

«Түгәрәк өстәл» янындагы әлеге сөйләшүне газета редакторы Ш. Х. Хамматов ачып җибәрде. Бу зур сөйләшүдә әдәбият һәм сәнгать эшлекләре, редакция журналистлары катнашты.

## НИЗАМИ ГАНҖӘВИНЕҢ 840 ЕЛЛЫГЫ

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Ринат Мөхәммәдиев Әзербайҗан ССРда Шәрыкның даһи шагыйре Низами Ганҗәви юбилеена багышлап үткәрелгән Әдәбият атналыгында катнашты. Ул Баку һәм Кировобад (борынгы Ганҗәү) шәһәрләрендә уздырылган тантаналы кичәләрдә, Әзербайҗан телевидениесе оештырган тапшыруда һәм республика әдәби газетасында чыгыш ясады.

Әлеге атналыкта Әзербайҗан ССР Язучылар союзы чакыруы буенча Мәскәү, Ленинград һәм союздаш республикалардан килгән галимнәр һәм язучылар катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Прозаиклар секциясендә тарих фәннәре докторы, профессор Р. И. Нәфыйков белән очрашу үткәрелде. Анда катнашучылар галимнең иҗтимагый-политик хәрәкәт һәм культура тарихы мәсьәләләре турында сөйләвен зур кызыксыну белән тыңладылар, күп санлы сорауларга җавап алдылар.

*
* *

Драматургия секциясенең чираттагы утырышында яшь язучы Фәүзия Бәйрәмованың яңа трагикомедиясе тикшерелде. Әсәр турында фикер алышуларда Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Рөстәм Мингалим, Гөлшат Зәйнашева, Әхмәт Булатов һ. б. лар катнашты. Чыгыш ясаучылар яшь авторның иҗатын, нигездә, уңай бәяләделәр.

*
* *

Балалар әдәбияты секциясендә яшь язучы Камил Кәримов иҗаты турында сөйләшү булды. Утырышта Мансур Вәлиев, Аяз Гыйләҗев, Роберт Миңнуллин, Сафа Сабиров, Рәзил Вәлиев, Ләбибә Ихсанова, Габдулла Шәрәфи, Зөлфәт, Хәкимҗан Халиков, Саимә Ибраһимова чыгыш ясады. Яшь язучыга файдалы киңәшләр бирелде, аның иҗаты тулаем уңай бәяләнде. Секция утырышы К. Кәримовны СССР Язучылар союзына член итеп алырга тәкъдим итте.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ — ЛЕНИНГРАДТА

Шушы елның октябрь башында бер төркем язучылар Ленинград шәһәрендә булып кайттылар. Язучылар Мөсәгыйт Хәби-

буллин, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Кутуй, Роберт Миңнуллин, нәшрият хезмәткәрләре Кыям Миңлебаев, Миңлебикә Фәйзуллина һәм китап сөючеләр җәмгыяте хезмәткәре Ф. Закирова составындагы делегация шәһәрнең В. И. Ленин белән бәйләнешле урыннары белән танышты, Разлива, Пушкин һәм Петергоф шәһәрләрендә булды. «Молодой Ленинград» клубында, Петродворец сәгать заводында һәм «Нева» журналы редакциясендә укучылар белән очрашулар уздырылды. Очрашуларда Ленинград шагыйрьләре дә катнашты.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Укытучылар күне уңае белән язучылар Аяз Гыйләҗев һәм Шамил Рәкыйпов Татарстан Мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре белән очраштылар. А. Гыйләҗев СССР язучыларының VII съездында алган тәэсирләре белән уртаклашты, татар әдәбиятының бүгенге торышы турында сөйләде. Ш. Рәкыйпов үзенең иҗат планнары белән таныштырды, яңа әсәреннән өзекләр укыды.

## РЕДАКЦИЯ КУНАКЛАРЫ

«Казан утлары» журналы редакциясендә илебез буенча сәяхәттә йөрүче япон язучылары Нобуюки Кондо, Хироси Сакагами һәм Масаёси Сиракава белән очрашу булды. Баш редактор урынбасары Ринат Мөхәммәдиев кунакларга татар совет әдәбиятының традицияләре һәм казанышлары турында сөйләде, аларны журнал редакциясенең эше белән таныштырды. Татар һәм Япония язучылары арасында әдәбият темасына мавыктыргыч әңгәмә булды.

## ҮЗБӘК СТУДЕНТЛАРЫ ӨЧЕН

Үзбәкстан югары уку йортлары студентлары быел «СССР халыклары әдәбияты» дигән яңа дәреслек-хрестоматия буенча укый башладылар. «Укитувчи» нәшриятында басылган бу хезмәттә (төзүчеләре Р. Мукимов һәм М. Шәрипов) күренекле татар әдипләренең дә биографик мәгълүматлары һәм әсәрләре тәкъдим ителә. Тукай шигырьләрен Миртимер, Шукрулло, Ә. Мохтар, М. Бобоев, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романыннан өзекләрне А. Уразаев, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ннән аерым шигырьләрне М. Бобоев тәрҗемә иткән.

Бу хакта безгә Ош педагогия институты доценты Н. Морадымов хәбәр итте.

## ЯҢА СЕЗОН АЧЫЛДЫ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры үзенең 76 нчы сезонын драматург Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» исемле публицистик драмасы буенча куелган спектакль белән ачты. Театр өлеге спектакльне яңадан Мәскәү тамашачыларына да күрсәтергә әзерләнә.

* * *

Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры яңа сезонны премьера — СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое композитор Нәҗип Җиһановның уникенче симфониясе белән башлап җибәрде. Бу симфониясен композитор КамАЗ хезмәт ияләренә багышлаган.

* * *

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының 1981/82 елгы сезоны Н. Җиһановның «Җәлил» героик операсы белән ачылды.

## КИНО ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘРЕ КИҢӘШӘ

Казан кинохроника студиясендә СССР Кинематографистлар союзының нәфис фильмнарны тәрҗемә итү буенча Бөтенсоюз комиссиясе пленумы булды. Анда илебезнең төрле шәһәрләреннән килгән сәнгать осталары катнашты. Пленум программасында Казан кинохроника студиясе фильмнарын карау, нәфис фильмнарны татарчага тәрҗемә итүчеләр белән иҗади очрашу һ. б. булды.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен композитор Рөстәм Яхинга, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән, «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## ӘДИП МАЛИКОВКА 60 ЯШЬ

Нефтьчеләр төбәгендәге авыл, шәһәр мәктәпләрендә, китапханәләрдә язучы Әдип Маликовка 60 яшь тулуга багышланган күргәзмәләр, әдәби кичәләр үткәрелде.

Әлмәт шәһәренең Техника йортында булган юбилей кичәсен Халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты председателе В. Гыйрфанов ачып җибәрде. СССР Верховный Советы депутаты, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Татарстан Язучылары союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов юбилярның иҗат юлы турында сөйләде һәм СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән шагыйрь һәм прозаик Әдип Маликовка «Почет билгесе» ордены тапшырды.

КПССның Әлмәт шәһәр комитеты, Халык депутатларының шәһәр һәм район Советлары башкарма комитетлары исеменнән партиянең шәһәр комитеты секретаре Р. Гайнетдинов, Татарстан Язучылары союзы идарәсе председателе урынбасары Илдар Юзеев, шагыйрь Гамил Афзал, «Татнефть» берләшмәсе бүлек начальнигы М. Шәмсетдинов, «Әлмәтнефть» идарәсе начальнигы урынбасары Ш. Таипов, Чаллы

машина тәзүчеләре исеменнән шагыйрь Разил Вәлиев, Габдрахман урта мәктәбе укучылары һәм башкалар Әдип Маликовны кайнар котладылар, аңа бүләкләр тапшырдылар.

Кичәдә КПССның Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре Ә. Баһаветдинов, Татарстан Язучылары союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин, «Татнефть» берләшмәсе генераль директоры урынбасары Ү. Саттаров катнашты.

•

## ТЫН ОКЕАН ЯРЛАРЫНДА

Күренекле рус язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе А. Фадеевның 80 еллык юбилее уңае белән аның балалык һәм үсмер гомере, көрәштә чыныгу еллары үткән Приморье краенда «Көрәш һәм хезмәт героикасы. Совет әдәбиятының революцион-патриотик традицияләре һәм А. Фадеев иҗаты мирасы» дигән темага Бөтенсоюз конференциясе һәм совет әдәбияты көннәре уздырылды. Бу чараларда СССР Язучылар союзы делегациясе составында шагыйрь Равил Фәйзуллин да катнашты. Ул Владивосток, Уссурийск, Находка шәһәрләрендә, тайга эчләрендә урнашкан Чугуевка, Яковлевка районнарында булып, корабльләрдә һәм заставаларда, вуз аудиторияләрендә һәм завод цехларында, урман хуҗалыгы клубларында һәм балыкчы тораклырында оештырылган күп санлы очрашуларда катнашты һәм чыгыш ясады.

## ИҖАДИ БӘЙЛӘНЕШЛӘРНЕ ЯКТЫРТУЧЫ ХЕЗМӘТ

1981 елда Ижевск нәшриятында филология фәннәре кандидаты Федор Ермаковның «Удмурт әдәбиятының рус һәм башка әдәбиятлар белән иҗади бәйләнеше» дигән зур күләмле монографиясе дөнья күрде. Аның фәнни редакторы филология фәннәре докторы профессор В. В. Горбунов. Бу хезмәттә удмурт әдәбиятының рус, украин, белорус, татар һ. б. әдәбиятлар белән иҗади бәйләнеше киң яктыртыла.

Татар һәм удмурт әдәбиятләры арасындагы бәйләнешләрнең бай тарихы бар. Автор удмурт һәм татар әдәбиятлары арасындагы бәйләнешне ныгытуда, бу әдәбиятларны пропагандалауда М. Гафури, М. Җәлил, Х. Туфан, З. Нури, Н. Арсланов, М. Петров, М. Воронцов, С. Широбоков, И. Гаврилов, Г. Ходырев кебек әдипләр керткән өлешне киң яктырта. Бу хакта педагогия фәннәре кандидаты Ф. Исламов хәбәр итте.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Менә сез 1981 нче елда журналда басылырга тиеш булган әсәрләрнең соңгылары белән танышып чыктыгыз. Редакция исә, күптән инде, киләсе ел саннарында, 1982 нче елда дөнья күрәчәк әсәрләрне әзерләү белән мәшгуль.

Укучылар журналның 1982 нче елгы 1 нче санында нинди язмалар белән танышачаклар соң?

Журнал шагыйрь И. Юзеевның СССР төзелүгә 60 ел тулуны каршылау йөзеннән язган яңа шигыре белән ачыла.

Роман, повесть яратучыларны алдан ук шатландырырга мөмкин: киләсе елда журнал андый әсәрләргә аеруча бай булачак. 1 нче санда шуларның берсе — А. Расихның «Ямашев» романы бирелә башлый. Әсәр Хөсәен Ямашевка багышланган трилогиянең соңгы өлешен тәшкил итә. Романның Х. Ямашев туугa 100 ел тулган көннәрдә язылып бетүе аерым игътибарга лаек.

Проза әсәрләреннән тагын А. Хәсәновның «Авыр миссия» исемле хикәясен, Ә. Гаффарның «Сиксән беренче ел икмәге» исемле очеркын күрсәтергә була.

Шагыйрьләр Н. Арсланов, Г. Латыйп, Р. Сафин бу санга яңа шигырьләрен тәкъдим иткәннәр.

Әдәби тәнкыйть бүлеге материаллары КПСС Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйть турындагы мәгълүм карары чыгуга 10 ел тулу уңаеннан язылганнар. Монда әдәбият галимнәре М. Хәсәнов, Х. Хәйри мәкаләләре һәм язучыларның редакция анкетасына биргән җаваплары урын алган.

Журналның бу санында да «Безнең календарь», «Сәнгать», «Төрлесеннән», «Елмаеп та, көлеп тә...», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» кебек рубрикалар бар. Аларга тупланган язмалар да укучы күңеленә хуш килер.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210